ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2009



# ТЕЛНЕ, МИЛЛӘТНЕ САКЛЫЙК ДИСӘК

Мөхтәрәм каләмдәшләр!
Хөрмәтле укучыларыбыз!

Сер түгел, матбугатыбызны халыкка тарату елдан-ел кыенлаша бара. Моның заман үзгәрешләренә бәйле, бездән генә тормаган җитди сәбәпләре барын сез үзегез дә яхшы беләсез. Әмма без, сәбәпләрне ачыклаудан, акланудан бигрәк, иң әүвәл авыр хәлдән бергәләп чыгу юлларын эзләргә тиешбез. Мәсьәлә үтә мөһим: сүз туган телебезне ничек тә саклап калу һәм үстерү турында бара. Ә тел, мәгълүм булганча, милләтне милләт иткән төп билге, төп күрсәткеч. Телнең сакчысы—халык, бигрәк тә аның үз тарихын белгән, киләчәге турында уйланган зыялы катламы. Телнең яшәү даирәсе—гаилә, мәктәп, хезмәт-эш урыннары, сәхнә-театрлар, тамаша-концерт заллары, базар рәтләре... Әмма затлы классик телнең нигезе-бишеге—ул әдәбият һәм матбугат. Халыкның гасырлар буе җыйналып, чарланып килгән асыл җәүһәрләре—аларда. Газета-журналларыбызны, шул җөмләдән, бер гасырга якын тарихка ия иң өлкән әдәби журнал, халкыбызның рух мирасын барлаучы төп басма булган «Казан утлары»н саклыйсы, үстерәсе, күтәрәсе иде. Моны, әлбәттә, редакция хезмәткәрләре көче белән генә башкарып чыгып булмый. Сезнең дә, хөрмәтле авторларыбыз һәм укучыларыбыз, хәлне аңлап, бу үтә кирәкле һәм саваплы эштә актив катнашуыгыз сорала. Теләгәндә һәм чынлап торып тотынганда сез дә яхшы ук булыша алыр идегез. Үзегез яшәгән төбәктәге халыкка—туганнарыгызга, дусларыгыз-танышларыгызга, хезмәттәшләрегезгә аңлатып мөрәҗәгать итсәгез икән. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары да бу эштә һичшиксез катнашырга тиешләр. Алар үзләре генә дә берничә данә яздырта алсалар да, журналның тиражы шактый ишәер иде! Киләчәккә өметебез булган яшьләр дә бу хәрәкәттән читтә калырга тиеш түгел дип уйлыйбыз. Безгә хәзер бердәм һәм бербөтен булып, милли матбугатны саклап калу кыйммәт!

Шунысын да исегезгә төшерәбез: вакыт аз калып бара, язылу 28 декабрьгә кадәр генә дәвам итәчәк.

Сезнең теләктәшлеккә һәм ярдәмегезгә ышанып,

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре,*
*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире.*

*Язылу бәясе Татарстанда аерым әбунәчеләр өчен—254 сум 10 тиен* ***(индексы 73210)****, юридик затлар (оешмалар, предприятиеләр) өчен—283 сум 80 тиен* ***(индексы 16262)****.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2009

**11**
**(1045)**

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

*НАШИРЕ:*
***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

*: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*: Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
*:* **Факс**—*(843) 562-11-28.*
*:* **E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Шигырь тажы. *Шигырьләр.* ..... 5
Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман-эпопея. Дәвамы* ..... 9
Фәрит ЯХИН. Күке фалы. *Хикәя.* ..... 33
Гәрәй РӘХИМ. Алма бакчасында уйлану. *Шигырьләр.* ..... 39
Зөлфәт ХӘКИМ. Легионер. *Роман. Ахыры* ..... 43
Хәмит ЛАТЫЙФ. Дүртьюллыклар. ..... 79
Мөнир ВАФИН. Кеше атлы туганнарга... *Шигырьләр.* ..... 82
Рахман ШӘФИГУЛЛИН. Гайсә йозагы. *Кыйсса.* ..... 85
Фәнзаман БАТТАЛ. Ка-аш-мар!.. *Хикәят.* ..... 91

**ДӘРДЕМӘНДНЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ**

ДӘРДЕМӘНД. Шигырьләр. ..... 100
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. «Милләт уянсын дисәң...» ..... 103
Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ. Дәрдемәнд иҗатының мифологик тамырлары. ..... 115
Дәрдемәндкә тәкълид-нәзыйрәләр, багышлаулар. ..... 119

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Режиссер хыялы һәм кырыс чынбарлык. ..... 123
Тәлгат НӘҖМИЕВ. Әбрар Кәримуллинның туган ягына язган хатлары. ..... 139
Гомәр БӘШИРОВ. Күңел дәфтәре. ..... 168

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рашат НИЗАМИ. Сугышларны кичкән догалык... ..... 149
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Уйландыра да, кисәтә дә. ..... 153

**ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ**

Вильям ШЕКСПИР. Сонетлар. Ш. Мөдәррис тәрҗемәсендә. ..... 156

**ФӘН**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Төрки сүз сәнгатенең тажы. ..... 160

**ФӘТХЕРАХМАН ӘХМӘДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

«Татар сәнгате күгендә атылган йолдыз». ..... 166

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. Татар җанлы Вараксин. ..... 175

**ТАРИХ**

Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. ..... 180

Илдар Зариповка 70 яшь. ..... 165

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман-эпопея А. ХАЛИМА «Хунвейбин» (прод.),
роман З. ХАКИМА «Легионер» (окон.); рассказы Ф. БАТТАЛА,
Р. ШАФИГУЛЛИНА, Ф. ЯХИНА;
стихи Л. ШАГИРЬЗЯН, Г. РАХИМА, Х. ЛАТИФА, М. ВАФИНА.
«К 150-летию Дардеменда»: стихи поэта; статьи Л. ХАМИДУЛЛИНА,
И. ФАЗЛУТДИНОВА; стихи, посвященные поэту.
«Память»: М. УСМАНОВ. «Мечта режиссера и суровая действительность»;
Т. НАЗМИЕВ. «Письма А. Каримуллина»; Г. БАШИРОВ. «Дневниковые записи» (окон.).
«Книжное обозрение»: рецензии Р. НИЗАМИ на книгу М. Амирханова «Моя молитва»,
Р. ШАРАФИЕВА на книгу М. Ахметзянова «Выбирай друзей в дорогу».
«К 90-летию Шарафа Мударриса»: сонеты В. Шекспира в переводе Ш. МУДАРРИСА.
«Наука». Х. МИННЕГУЛОВ о книге Баласагунлы «Котадгу белик».
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод).
«История»: А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского
происхождения» (прод.).
«Искусство»: в номере отмечаются 70-летие художника И. Зарипова, 80-летие
композитора Ф. Ахмадеева.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Цветок жизни». Работа И. ЗАРИПОВА; поэтесса Н. АХУНОВА.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: epic novel by A. HALIM «Hunveybin» (continuation),
novel by Z. HAKIM «Legionnaire» (ending); stories by F. BATTAL, R. SHAFIGUL-
LIN, F. YAHIN; poems by L. SHAGIRZYAN, G. RAHIM, H. LATIF, M. VAFIN.
«To the 150th anniversary of Dardemend»: poems of poet; articles by L. HAMIDULLIN,
I. FAZLUTDINOV; poems dedicated to poet.
«Memory»: M. USMANOV. «Director's dream and harsh reality»;
T. NAZMIEV. «A. Karimullin's letters»; G. BASHIROV. «Diary entries» (ending).
«Book review: reviews by R. NIZAMI on book by M. Amirkhanov «My Prayer», by
R. SHARAFIEVA on book by M. Akhmetzyanov «Choose friends for long way.»
«To the 90th anniversary of Sharaf Mudarris»: sonnets by Shakespeare in translation by
SH. MUDARRIS.
«Science». H. MINNEGULOV about book by Balasagunly «Kotadgu Belik».
F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
«History»: A. HALIKOV. «500 Russian surnames of Bulgar-Tatar
origin»(continuation).
«Art»: in issue is celebrated 70th anniversary of I. Zaripov.
Pages from Tatar Encyclopaedia.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Flower of life». Work by I. ZARIPOV;
poetess N. AHUNOVA.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.10.2009, график буенча 27.10.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–1590. Тираж 3457.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.



Лена
Шагыйрьҗан

# ШИГЫРЬ ТАҖЫ

## Ачыл, Чәчәк, кояш нурында!..

**Сүз бирелгән безгә—әйтер өчен**
**ни-хәл барын Уйлар кырында...**
**Табигать ул телсез дөнья түгел—**
**сөйләп тора үзе турында,**
**яңграп җилнең җитмеш кылында...**

**Аваз сала кошлар—меңтавыштан,**
**көйли чишмә—үзе хакында.**
**Ачылырга көнгә!—Көнбагыштай!—**
**Тик шул хыял иҗат халкында—**
**ачылмаса, тына акын да...**

**Төннәр буе ут яндыру нигә,**
**күрми калсаң таңнар атканын?..**
**Милләт, милләт, диеп, оныта күрмик**
**Иләт суы иңрәп акканын...**
**Чәчәкашар кортлар артканын...**

**...Мин үземне күптән сөйләттерәм,**
**ачыла йөрәк шактый көттереп.**
**Әй, җәелгән Шигырь таҗы җирдә—**
**мәңге булмас, җыеп, бетереп—**
**чәчәк җанын булмый үтереп...**

**Сөйли җиһан—үзен ишетер өчен,**
**күзге ясый—үзен күрергә.**

---

Лена ШАГЫЙРЬҖАН—*шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; «Мөлдерәмә күңел», «Божра һәм Хөҗрә», «Сагынмаклык» һ. б. китаплар авторы. Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Кара такта сөя—акбур төсен,
ак таш битен ача—күмергә:
Тел хакына алар гел бергә...

Кара коелма син, йолдыз түгел,
чыра гына сүнсә кулыңда...
Үз телемне сөюдән дә артык,
үз телемдә сөйләүдән дә артык
Бәхет очратмадым юлымда,—
ачыл, Чәчәк, кояш нурында!..

*2009*

## И, Телем син—Иделем син!..

Иделемдә йөзгән ак балыктай,
и, Телемдә йөзеп карадым!..
Иңләп-буйлап, чумлап төбенәчә—
шигъырем булды көймә-карабым...

И, Телем син, иңле Иделем син,
синдә—назым, синдә—ярсуым.
Идел суы кебек эчтем сине,
сусынымны бастың, Җансуым!..

Сине яклап күпме җырлар яздым,
авыз суларымны корытып...
Җиде-ят бит белми синең тәмне,
карамаган килеш бер йотып...

Җир йөзендә күп лә су-дәрьялар,
тирәндерме алар, бик киңме...
И, Телем син! Аһәң-аваз суым!—
Синнән башка яшәү мөмкинме?!

*2008*

## Абау, гөлләрем, күбәләкләрем!..

Якты язларның тансык хуш исен
Яңартасыз күк күңел бакчамда.
Сезгә ашыгам, язгы ташудай,
Ялгызлыгымнан чыгып качканда—
Абау, гөлләрем, күбәләкләрем!..
Яз җитү белән, сез яшәрәсез,
Шул серне миннән ник яшерәсез?
Нилектән болай һаман сез бергә,
Ник болай рәхәт сез булган җирдә?—
Абау, гөлләрем, күбәләкләрем!..
Әйдәгез әле, бергәләп тагы
Җырлыйк җырларны—сезнең хактагы:
Уятыр, бәлки, сөю утларын
Шул дәртле көйләр—без яшь чактагы...
Абау, гөлләрем, күбәләкләрем!..
Очып күңлемә керче, күбәләк,
Моңлы җаныма үрелче, гөлем!
Беләсездер сез сөюдән башка
Җирдә яшәүнең кызык түгелен...
Абау, гөлләрем, күбәләкләрем!..
Көйләгез миңа мәхәббәт җырын,
Ачыгыз миңа бергәлек серен—
Дөнья салкыны туңып үләрлек,
Сыенышмасаң береңә берең—
Абау, гөлләрем, күбәләкләрем!..

*2006*

## Сусыз акчарлак

*Тагын кайтып төштем үземә,*
*мин үземне үзем сагынып...*
Л. Ш.

...Заманында шундый җырлар белән
мин коткара идем үземне,
Кабат-кабат кайтып төшеп үземә,
ялгый идем шигъри сүземне...

«Үзем» дигәнем ул асылым булган,
хәятымның төше-үзәге!
Хыялыма җегәр биреп торган
хисләремнең асыл бизәге.

Елларга ияреп, хыяллар да
ераклаша барды, читләште.
Күңелем исә явыз рухка очрап,
кырысланды, шактый этләште.

Үкендерә... Коеналмыйм инде
хыял дәрьясына чумып мин.
Әйләндерә алмыйм юкны барга,
йомыкый булмасам да, йомык мин...

Калды дәрья, әле дә ята җәйрап...
Тик теләк юк иңләп йөзәргә.
Чал бер дулкын үзе киңәш бирде
хыялдан дип вакыт бизәргә...

Ярый, дидем, чыктым коры җиргә,
үз-үземнән, имеш, качарга.
Басып торам, охшап—яр читендә
сусыз калган акчарлакларга...

*2007*

## Ачы сагыну

Сагыну уты өтә йөрәгемне:
күрешү өмете чөнки өзелгән...
Бердәнберләр, алыштыргысызлар
хәтер дисбесенә тезелгән.

Ишетәм күк кайчак дәшүләрен,
тутыргандай бушлык сагышын.
Шул авазлар гына көйлидер күк
гомерем елгасының агышын.

Үз көенә йөзми инде көймәм,
хәтер ярларына тукталып.
Очып китәлмыйсың хыялда да
«күреп кайтыйм» диеп укталып.

Һәр югалткан җанга «көтәм!» диеп
хәбәр салалмыйсың талпынып.
Йөрәгеңне ут ялкыны сыман
куырып ала юклык салкыны.

Ямансулап, гаҗизлеккә батам,
бер чара юк—шунысы йөдәтә.
Бергә чаклардагы бәхетемә
сагыну белән түлим йөзләтә...

Ах, юксыну!..
Өмет белән генә
татлы икән бит син кешегә...
Җан күшегә... догалардан гайре
бер дәва юк Сагыну хисенә...

*2006*

## Бер ялтырап китәр...

Кызык түгел дөнья,
белдек бөтен серен—
әләм итеп элгәч
бар да күңел керен...
Тоташ яңгырлар да
юып бетералмас...
Безне бу җиһанга
кабат китералмас
иске яңалык та,
яңа искелек тә...
Хәтта күктән төшкән
яңа Изгелек тә...
Без кичергәннәрне,
безнең күргәннәрне
беркем беркайчан да
аңлап җитмәс мәңге...

Өр-яңадан безне
берни тудыралмас,
күмелеп кала барса
җир-балчыкка алмаз.
Яңа буын туар,
искелекне куар,
Кеше исә һаман
үзенекен «куар»...
Болыт чыккан арты
Кояш чыкмый калмас.
Бер ялтырап китәр
яңгыр юган алмаз...
Күмелер әмма кабат
сазлык-былчыракка...
Күнегеп беттек инде
шундый һәр очракка...

*2009*

## Гомеркәйләр кире кайтканда...

Чыгып китим ерак сәфәрләргә,
өйдә ятып, җаннар мүкләнде.
Йөрәк-йортның иске чардагына
кошлар түгел, җеннәр төпләнде.

Ишек-тәрәзләрне шар ачыйм да,
бикләп-нитеп тормый капкасын,
Чыгып китим әле... Көтмәсеннәр,
белеп булмый кайчан кайтасын...

Кем белә бит, бәлки бик еракта—
кайтмас җирдә торып калырмын.
Ара-тирә—мине җуйганнарга
җилләр аша хәбәр салырмын...

Чыгып китим юлга үз җаема,
җәяүләпме шунда, очыпмы...
Югалтмыйча—Күңел кыйбласына
юл күрсәтеп торган өч укны:

Берсе—атам-анам туфрагына,
икенчесе—сөйгән ярыма...
Өченчесе—гомерем елгасының
мине көткән ташлы ярына...

Һәм утырып шунда хәл алырмын,
үткән гомерләрне сагынып.
Баш очымнан очар язлы-көзле
кыр казлары канат кагынып...

Үткән гомеркәйләр кире кайткач,
кузгалырмын кызык сәфәргә...
Җанга җыелып калган саф хисләрне
ләйсән яңгыр итеп чәчәргә...

*2006*

Айдар
Хәлим

# ХУНВЕЙБИН

РОМАН-ЭПОПЕЯ

## III

Сораулар бихисап иде, әмма Дамир Хажиевич кунакны арытмаска, сорауларны туктатырга чакырды.

—Мин генә бирәм, мин генә бер сорау бирәм дә!—Кап-кара күзле, сызылып киткән кап-кара кашлы, кара чәчләренә ап-ак тасма бәйләгән кара күбәләк кебек кызкай тотлыга-тотлыга урыныннан талпынды.—Ба-а-бай, се-ез-не-ең ү-зегез-нең ж-жирегез б-бармы?

—Рәхмәт. Бар, сылуым. Бар. Егерме акр жирем бардыр кү.

—Акыр? Сезнең жирегез егерме тапкыр акырамени?

Балалар бердәм көлештеләр.

—Юк, бу мәйдан үлчәме. Гектарга күчергәндә... бер акр нуль бөтен уннан дүрт гектар... димәк, сигез гектар. Алты гектарында өч өлешкә бүленгән умарталык, ике гектарында йорт-жир, парк, балык буасы...

Сораулар күп булса да, очрашуның артык озакка сузылуыннан ни сәбәпледер шөбһәгә төшкән директор: «Иркен-ага мәктәпкә тагын да киләчәк әле»,—дигән сылтау белән аларны чикләде. Сүзенең азагында очрашуны оештырганнары өчен рәхмәтләр әйтте һәм форсаттан файдаланып, үзенең юлдашы—татар милләтенең асыл улларыннан берсе булган китап сәхибе, китапсыз калган авылларга үз акчасы исәбенә китап өләшеп йөргән (бу батырлыгы белән кардәшемез атаклы Гиннес китабына да керә алыр иде дип өстәде) Рәгыйбь-кардәш Хөснетдингә бирде.

Рәгыйбь гадәтенчә сүзен кыска тотарга тырышты. Ул көтмәгәндә генә Мамадыш юлы өстендә Иркен-ага белән танышa алуына куаныч белдерде, чиксез рәхмәтләр житкерде, аннан «куян күчтәнәчләре» капчыгыннан «Иман шарты», «Кыйсса-аль-әнбия», Гаяз Исхакыйның «Зиндан», Фәүзия Бәйрәмованың «Карурман», Илдар Хафизның «Гомеремнең ун көне» дигән китапларын чыгарып, мәктәп китапханәсенә, алдынгы укучыларга һәм укытучыларга бүләк итте. Ул кешедә шәхесне, шәхестә ирек хисен тәрбияли торган иң көчле корал—шигърият белән дуслашырга, бу дуслашуны мөнәжәтләрдән, Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха»сыннан, халык дастаны «Идегәй»дән башларга чакырды. Әгәр без шигърият белән тәрбияләнмибез икән, без сәнгатьне бөтенләй дә аңламаячакбыз, керләнеп бетәчәкбез, диде. Тәнне мунчада гына мунча кертеп булса, жанны бары тик шигырьдә генә

*Дәвамы. Башы 9, 10нчы саннарда.*

мунча кертеп була икән. Кеше күңеле шундый җан мунчасыннан соң гына икенче кеше өчен сызлана ала. Безнең күңелләр сезнең күңелләр, сезнең күңелләр безнең күңелләр өчен сызланырга тиеш! Менә бу шигырьне кем язган, тынлап карагыз әле?

Сызла, сызла, сызла, күңлем,
Сызла бер туктамыйча,—
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!

—Кем әйтә кем язганын?

Әйтүче юк иде.

—Татарның шушы юлларны язган өченче бөек шагыйрен белмәгән кешене татар дип атап буламы, балалар? Без моңа лаекмы? Без, укытучылар, лаекмы?

—Юк, юк!—дип шаулашты балалар. Укытучылар тынсыз иде.

—Әйтегез инде, кем язган?—дип кайнады зал.

—Сәгыйть Рәмиев! Без бер-беребез өчен шулай сызлансак кына татар булып яши алачакбыз... Мин туганнарының чыбык очларын булса да табышуда мөхтәрәм Иркен-агага ярдәм итүегезне үтенәм!.. Алоэ гөле кебек сабыр, ярангөл кебек ялкынлы булыгыз!..

Зал кул чапты.

—Тагын укыгыз, тагын!..

Шигъриятнең тәмен сизгән сабыйларны туктату мөмкин түгел иде. Очрашуның көтмәгәндә генә шундый нәтиҗә белән тәмамлануыннан күңеле нечкәргән мөгаллимнәр оялган карашларын идәнгә юнәлтеп, яшьләрен сөрттеләр. Мондый сызлау ләззәтен аларга китап таратып йөрүче балта остасы Рәгыйбь Хөснетдин бүләк итте.

—Кайсыларыгызның бабалары Ватан сугышында һәлак булган?—дип сорады балалардан Рәгыйбь.—Кулларыгызны күтәрсәгез, исемнәрен әйтсәгез иде...

Нибары ике бала кулын күтәрде һәм фронтта һәлак булган картаталарының исемнәрен әйтә алды.

Китапчы очрашуга җыелган балаларның исемнәрен сораштырып чыкты.

Фикция Саматовна аларны санап та куйган икән. Җәмәгатьчелек алып барган аңлату эшләре нәтиҗәсендә авылда иске, дини исемнәр бирүдән котылганнар. Фикция Саматовна төзегән исемлектә йөзгә якын укучы арасында малайлардан ун Марат, сигез Рөстәм, алты Эдуард, сигез Тимур, җиде Артур, җиде Алик, алты Вадим, кызлардан ике Эллипс, бер Гербицид, биш Алинә, алты Алия, биш Эльвира, дүрт Регина, дүрт Ләйсән, өч Айгөл, өч Назгөл, өч Язгөл, өч Сазгөл бар, бер генә дә Галиябану, бер генә дә Сәхипҗамал, бергенә дә Сөмбел юк иде...

Укытучылар кунакларны күрше бүлмәгә чәйгә алып керделәр. Фикция Саматовна нишләптер күренми иде. Директор «Мондый очракларда кунакларга тәкъдим итмичә дә булмый инде, үзегез аңлыйсыз инде...» дигән булып, кәнтәй хатыннар кебек боргалана-сыргалана, ярты гәүдәсе белән кара мичкә кереп, ак костюмын шактый гына корымга буяп, ике кулына берьюлы ике гранат тоткандай, ике шешә китереп чыгарды.

—Америкадан әллә нигә бер килеп!.. Серләшеп утырыйк әле!..

Кунаклар аракыга кискен каршылык күрсәтсә дә, форсаттан файдаланып, бераз хәмер дә капкалаштырып кызарынган директор һәм аның ират хезмәттәшләре, чәй эчкән арада әңгәмәне «миллият юлына» кертеп җибәрүне хуп күрделәр:

—Америкада татарлар күпме соң? Очрашкалап торасызмы?

—Бу хакта рәсми мәгълүматлар юк. Күп түгелдер. Белүемчә, биш меннән дә артмастыр. Билхаккый, хәзер күбәяләр. Һәр акыллы, талантлы татар Рәсәйдә белем ала да, Әмрикәгә килә ята... Детройтта унбиш, Сан-Францискода утызлап, Нью-Йоркта ике йөзләп татар гаиләсе бардыр күг. Әмрикәдә татарларнын ин күп урыны Нью-Йорктыр. Бер мең чамасы. Берничә гаилә татарлар һәр шәһәрдә дә очрай диярлек. Нью-Йоркта татар балаларның якшәмбе мәктәбе эшли. Доктор Гариф Солтан үз акчасына тота. Анда мин дә лекцияләр укыштырам. Без, татарлар, елына ике-өч тапкыр очрашып-күрешеп алабыздыр. Сан-Францискода ел да сабантуебызны үткәрәбез. Һәр татар әмрикән фатыйрында намаз бүлмәсе бар. Бәлеш, аш-су әзерләү буенча ярышлар үткәрәбез. Сирәк кенә булса да Татарстаннан артистлар килә. Күптән түгел Айдар Галимов булып китте..

—Айдары да, бәлеше дә һәйбәт, кәнишне-е-е....—дип сузды корым буялган костюмы белән урындыгында шыгыр-шыгыр килгән Дамир Хажиевич.—Мин менә нәрсә хакында сездән сорамакчы идем... татар телен ничек бу кадәр яхшы беләсез? Каян алдыгыз сез аны? Нинди импорт-экспорттан?—Ул күләргә маташты.—Авыл общественносте хәзер хәтта монда, авылда да рәхәтләнеп урысча сөйләшә, так ведь, җәмәгать?! Сезнең туган Ватаныгыз да юк, шулай бит?!..

—Дөрес, дөрес!..—диеште директорларын куәтләп башкалар.—Искиткеч! Таң калырлык! Шаклар катарлык! Колоссально!..Капитально!..

—Сез әйткән телсезлек...туган телдән китү...—Иркен-ага педагог кешедән бу кадәр беркатлы ихласлык көтмәгән иде.—Мондый күренеш сезнең туган вә тарихи Ватаныгызда яшәп тә, кальбегездә шул Ватанны югалтканнан килми микән?

—Ничек югалта, ди?—Директор жанланып китте.—Юк, минуточку, без югалтмаган... Без нормаль Ватанда яшибез, әле ана формаль суверенитет та алып бирдек. Без ватанлы—һәм нор-рмально, ә сез ватансыз—һәм формально, шулай бит? Сез читтә яшәгәч, Ватаныгыз бөтенләй дә булмаган булып чыга бит инде!..

—Ватан... Ватан...—дип кабатлады Иркен-ага.—Нәрсә соң ул Ватан?.. Сөт калыр, Ватан китәр, дигән бит әле теге бөек шагыйрь... Туган телне белү, аны онытмау өчен берниндн Ватанның да бөтенләй кирәге юк. Балага ил-тел дигән тарихи тойгыны мирас итеп бирү өчен ата-ананың бары тик иманлы булуы, иманлы йөрәк, димәк ки саф кальб кенә кирәк. Ә менә сезнең Ватаныгыз бармы соң?

—Бар,—диде директор бәллүрен күтәреп.—Россия! Шунын хакына!..

—Татарстан, диген!—дип төзәтте аны кемдер.

—Юк, Россия!—дип кабатлады директор.—Татарстан «Ватан» булалмый, «туган як»кына була ала!

Бередә, анын каршында, татар хунвейбинчылыгынын бераз төшереп тә алып кызган, гадиләрдән дә гади бер Шүрәле энекәше, биологлар әйтмешли, мутант вәкиле утыра иде.

—Тупас көч белән үз Ватанынны—жиренне, теленне, иманынны тартып алган дәүләт Ватан була алмай...—диде Иркен ага.—Сез нигә мине Ватансыз дип уйлыйсыз? Глобаль мизаннан караганда, язмыш адәм баласын өч рәвештә Ватанлы итә: беренчесе—туып-үскән Ватан. Икенчесе—гомер иткән, яшәгән Ватан. Өченчесе—тарихи Ватан, ягъни минем өчен—минем Татарстаным. Минем шушы өч төр Ватанымның өчесе дә бар. Туып-үскән Ватаным—Кытай, Шәркый Төркестан, мин анда татар мәктәбендә татарча, институтта кытайча белем алдым. Телемә хыянәт итмәдем, тарихи Ватаным исә гел генә күнелемдә сакланды. Әмрикәдә инглизине үзләштердем. Телемә хыянәт итмәдем, тарихи

Ватаным үземдә калды. Ә сезнең... ә сезнең...—Ул сүзен әйтәлмичә газапланды, йөзе буйлап ниндидер тулгак сызлануны үтте.—Сез... тарихи Ватаныгызда туып, яшәп тә тарихи Ватансыз, димәк, телсез калгансыз... Бу иманлы ата-аналык мирасын, ананың күкрәк сөте белән кергән газиз телен, иманлы калебен, гражданлык ихтыярын югалту дигән сүз...

—Миңа китәргә вакыт,—диде Иркен аганың колагына Рәгыйбь.—Көн кичкә авыша... Минем Ишкидә булганым да, тукталыр танышым да юк... Бүген барып кунып, иртәгә мәктәпләрендә булырга һәм аннан Көмешкүл, Арташ якларына кузгалырга иде...

—Амин, солтаным, хәерле сәгатьтә!..—диде моңсуланып Иркен ага.—Берәрне кунар идеңез лә!..—Ул мәҗлестәшләренә күз салды.—Йәнез, булмаса, чәйгә дога кылаек. Биредә китәсе инсан бардыр кү. Без калабыз, сез китәсезләр... Жылы кабул итүенез өчен тәшәккүрмен!..—Ул дога кылды.

Мөгаллимнәр һәм директор «Амин тотаргамы-юкмы?» дигән хәлиткеч кыяфәттә үзара карашып торганнан соң шулай да уч төпләре белән битләрен сыйпап куйдылар.

Кунаклар кузгалды. Сихәт-сылу тәмам агарынган, балтасы суга төшкән кеше кебек югалып калган иде. Аларны янадан балалар сырып алды. Мондагы сораулар ике түгел, егерме көн яшәсәң дә бетмәс иде кебек.

—Без әле очрашырбыз...—диде сабыйларга Иркен ага.—Мин биредә берничә көн булачакмын!

Ул арада арбасын җиңел тәгәрәтеп, Рәгыйбь тә чыкты.

Анардан китап сораучы булмады. Укучылар һәм мөгаллимнәр аларны мәктәп капкасына кадәр озаттылар.

—Әрмән малаен әйтәм... Башлы, чукынган!..—диде Рәгыйбь Иркен—агасына елмаеп.—Татарстанда сатылмаган бер нәрсә—халыклар дуслыгы дигән лозунг кына калды инде. Әрмәннәр турында бер мәктәп мәзәге дә йөри. Укучылардан инша яздыралар. Бер бала болай дип язган: «Яз килә. Карлар эри башлады. Кара каргалар да килде. Озакламый әрмәннәр дә килер инде...»

Елмаештылар.Рәгыйбьне берәр көнгә булса да калырга Сихәт-сылу да кыстап карады. Юк, кардәшләренен үз туксаны туксан иде. Иркен-аганың бу җырдагы шикелле ике ялгыз кыр казын инде ничәнче кат бергә итәсе килеп китте. Сихәт-сылу аларны авыл очыннан күтәрелгән сыртка таба алып китте. Сыртка күтәрелгәч, комлы тигез юл башланды. Гүя Рәгыйбьнең арбасы юл, юл исә Рәгыйбьнең арбасы өчен яратылган да, шуна күрә кечкенә эрзин көпчәкләр сырт юлыннан келтер-келтер җырлый да башладылар...

Басу чигендәге тирәклеккә житкәч, алар адресларын алыштылар. Рәгыйбь Казанның Бертуган Касыймовлар урамындагы гомумторакта яши икән. Иркен-ага моннан соң Баулы тарафларына барачагын житкерде. Рәгыйбь-кардәшен, юлы төшсә, Чаллыга чакырды.. Хушлашу бик тәэсирле булды. Кем уйлаган бер-ике тәүлек эчендә шулай якынаерлар дип!..

—Хушыгыз, Иркен абзый!.. Тагын да очрашырга язар микән?

—Амин!. Шулай була күрсен!..

Китте. Китте, бик моңсу итте. Авыл тарафына бераз баргач, артка борылдылар. Рәгыйбь тә, Ходай бәндәсе, борылып карап тора икән. Кулларын болгаштылар.

Иркен-ага берничә минут Рәгыйбь турында уйланып барды. Ул инде аны сагына да башлады. Күрешерләрме тагын? Татар дөньясы буйлап китап таратып йөргән татар Рәгыйбь аның өчен барлык Галәм татары иде. Ул үзен шушы имән төбе кебек тәбәнәк, үзе чәнечкеле, үзе йомшак күңелле тукайҗан

алдында бер бөҗәк итеп тойды. Әйе, ихластан бөҗәк, хәтта барлык Әмрикәсе үзе бу гаҗәеп адәмзат каршында бөҗәк иде. Бар микән шәхси эгоизм белән турыга каткан, акча, байлык диеп котырган, анасы кызын, атасы улын белмәгән бу супергигант мәмләкәттә Рәгыйбь кебек милләт вә кешелек турында кайгыртып, эрзин итекләрдә, изрәп беткән күлмәк-чалбарда, артына биштәр асып, кулларын арба тоткасыннан алмыйча китап таратып йөргән бер кеше? Юктыр. Аның Әмрикәдә булуы мөмкин дә түгел. Анда кеше күршесен, туган туганын белми. Анда кунакка, чәйгә чакырып сыйлау дигән нәрсә юк. Анда син кешедән хәл-әхвәлен сорашып вакыт үткәрә алмыйсын—бу кешенен «эчке эшләренә тыкшыну» була. Бер караганда, үзен бетүгә бара дип санаган татар җәмгыяте үзенен әле булса саклап килә алган гореф-гадәте, йолалары белән Әмрикәгә караганда күпкә бәхетлерәк, киләчәге Әмрикәгә караганда күпкә өметлерәк иде. Әгәр кулында булса, ул Иделнен Казанга алып керә башлаган яры өстендә Әмрикәнен «Азатлык сыны»ннан да биегрәк итеп, Китап тоткан Рәгыйбь, йә тагын да шул Китап тотып, Акбузатка атланган Рәгыйбь сынын куяр иде...

Сырттан авылга таба, бар тирә-якка чиксез манзара ачыла икән. Иркен-ага Ватан һавасын күкрәген тутырганчы сулап, күзләрен тутырганчы карады. Авыл Чак-суның хәтфәдәй яшел үзәнендә урнашкан, үзән буйлап сузылган үзәк урамнан һәм аннан сул тарафка яткан урамнардан тора икән. Тирә-ягын өйкем-өйкем урманнар, агарып яткан басулар биләгән. Күптән инде төшлектән үткән кояш, кинлекләрне алтынга манып, офыкка таба тәгәрәп ятадыр.

—Кизләү чишмәсе алыстыр кү?

—Юк, монда гына...—диде Сихәт-сылу ун тарафтагы калкулыкка күрсәтеп.—Күрәсегез киләме?

—Бик тә. Ә тегендә нинәрсә?

—Чучка комплексы. Әткәй әйтмешли, кешегә күрсәтерлек нәрсә—зират һәм чучка комплексы калды. Күрәсегез киләме?

—Килә... Барысын да күрәсем киләде...

Юл комлы, күнел шомлы иде.

Икәүдән-икәү генә калсалар да, Иркен аганың тота-каба улларының кая чыгып югалуы, абыйсының ни сәбәпле зинданда тотылуы турында сорарга батырлыгы житмәде. Бәлки аның моңсулыгы, кайгы-сагышлары, тирә-якка ниндидер гозер белән караган карашларының әллә нинди көтелмәгән сәбәпләре бардыр? Төпченергә яратмаган Иркен ага көтәргә булды—бәлки үзе чишелер? Шулай да бу сөальне бирү өчен аны әзерләү йөзеннән тормышы, хәл-әхвәле турында сораштырырга булды. Сихәт-сылу Минзәлә педагогия колледжының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап, төзелә генә башлаган Чаллыга килгән. Килүен килгән, әмма шәһәрдә бердәнбер, анысы да исем өчен генә татар дип йөртелгән Вахитов мәктәбендә эш тапмаганнар. Тизләтелгән курслар тәмамлап, озак еллар сәркәтиб булып эшләгән, күптән түгел, фирмалары банкротка чыгып, эшсез торып калган икән...

—Димәк, сезне Чаллы колач җәеп каршыламаган?

—Әйе, колачлары көтелмәгәнчәрәк булды...

Сихәт-сылуның керфекләре дымланды. Аның тирән кичерешләр өермәсендә торып калуын күрү читен түгел иде. Ханымда ике хис—йөрәген ачарга теләү һәм бу адымга барудан курку хисе тартышты. Берүк вакытта аның кем белəндер кинәшәсе, бигрәк тә Иркен ага кебек көтелмәгән, олпат, күпне күргән, сер саклый белгән һәм тәҗрибәсе, көче, ихтыяры әллә каян ургылып торган ир кеше белән кинәшәсе, аның ярдәмендә киләчәккә бердәнбер дөрес булган юл сызасы килә иде. Әйе, ир-атта гомере буе күрергә хыялланган сыйфатларга ия иде аның тормышына шулай көтмәгәндә

килеп кергән Иркен-ага. Кичәле-бүгенле ул үзендә шушы тойгыны сизеп сискәнә. Бу тойгы уянган саен аның назга сусаган тәнен ниндидер күптән кичерелмәгән, инде онытылып та барган кайчы телгәләгәндәй итә. Мондый чакта карашларын түбәнгә юнәлеп, җиргә карый, кадерле тойгыларын йөрәгенең иң эчке, беркем дә керә һәм күрә алмаган урыннарына яшереп куярга тырыша...»Мөмкинме? Мөмкин эшме?» дип өзгәләнә дә, бу хакта бөтенләй уйламаска тырышып, татлы шик-шөбһәләрен улларының, абыйсының билгесез язмышлары белән капларга, онытырга теләп, үзен мавыктыру ниятендә ниндидер эшкә тотына...

Нибары ике көн чамасы гына бергә булсалар да, тиз өйрәнеп китте ул Иркен агасына. Әгәр ул янында булмаса, нәрсәдер җитми кебек. «Мөмкинме? Нигә мөмкин булмасын, бу мөмкин эш»,—ди беренче тавыш. «Мөмкин түгел»,—ди икенче тавыш. Аның сөекле хатыны, бәхетле гаиләсе бар. Аннан, ул синнән байтакка, сине бар иткән атаңнан да өлкән бит!» Юк, аның Иркен агага берниндн дәгъвәте юк һәм була да алмый: ул Америкада бергә яшәгән хатынының никахлы ире. Сихәт исә Рәсәйнен Чаллы дигән төпкелендә гомер сөргән ирсез хатын. Әгәр алар арасында уртак хис хасыйл булган хәлдә дә аның бары фаҗига—йөрәк ярасы белән чикләнәчәге көн кебек ачык...

Ничек кенә булмасын, анарда Иркен-агага карата иң җитди тойгылар уянган иде. Ул моны сиздермәскә тырыша һәм әгәр сизенгән хәлдә, вакыйгаларны ашыктырып, мөнәсәбәтләрне бәйләнмәгән килеш өзеп куюдан курка иде. Укучыбызга яшермичә, турысын әйтсәк тә урынлыдыр (хәер, моны ул үзе дә аңлагандыр!): кырык өч яшьлек Сихәт-сылу алтмыш җиде яшьлек Иркен-агага Ләйлә Мәҗнүненә гашыйк дәрәҗәдә гашыйк иде. Үз гомерендә икенче тапкыр кичерә иде мондый җитди хисләрне Сихәт. Ташу ташканда гөрләвек белән шаярма, дигәндәй, соңгы мәхәббәт дигәннәре шушы була микән әллә, дип яшрен утта яна иде ул. Мондый очракларда, күреп капланды, диләр бугай. Гомумән алганда, бик тә чибәр, сабыр холыклы, сирәк акылга ия бу хатынкай кыз чагында да, хатынлык чорында да җенси теләкләрен артык узындырмаган, хисләрен таушалтмаган һәм аларны исраф итми саклый алган гашыйка иде. Нишлисең, шушы гашыйкалык, хатын-кызның һәркайсына, гафу итегез, хас булган шушы «җиңелчәлек» дип әйтикме, аның бердәнбер абыйсына, улларына бәйле булган кайгысын җиңеләйтә, йомшарта төшә, улының бүген-иртәгә табылачагына, абыйсының төрмәдән азат ителәчәгенә өмет өсти иде...

Ниһаять, анарда Иркен-ага белән сөйләшү, эч серләрен мөмкин кадәр генә ача биреп, хиссияти якынаерга теләү тойгысы җинде...

—Бик газаплы башланды минем Чаллыдагы тормышым...—дип керешге ул үзенең бәянына.—Радио-телевидениедән, газеталардан көне-төне игълан: Чаллы комсомол-яшьләр төзелеше!.. Халык агылды гына: Чаллы, анардан йөз чакрым радиустагы авыллар, алар янында өстәмә палатка авыллары үсеп чыкты. Килгән халыкны еш кына көчләп диярлек хосусый хуҗалыкларга фатирга кертә башладылар. Шәһәрдә коткы китте: шәхси йортларны көчләп күчертәчәкләр! Иске Чаллыны су астына җибәрәчәкләр! Имеш, кем күчми, шуларның йортларын тартып алып, вакытлыча яшәп тору өчен комсомолларга бирәчәкләр...Ә кем кертә, имеш, йортларына кагылмый торалар...

И-и, ул чактагы хулиганлык, тәртипсезлекләр!.. Союзның төрле тарафларыннан килгән, еш кына татар дигән халыкны җене сөймәгән, безнең гореф-гадәтләребездән көлгән деклассированный элемент, шпана, флаг күтәреп, эш өстендә һәм эштән соң ылкынганчы эчә, акыра-бакыра, сугыша, оятсыз музыка акырта, һәр өйнең ишек алдында әдәпсез танцы-манцылар оештыра... Урамга чыгарлык, транспортка утырырлык түгел—«Халя-баля! Не балякай на своем!» дип күзне ачырмыйлар безгә мат аша

матур тормыш төзергә килүчеләр... Татарча эндәшер алдыннан унга-сулга карарга кирәк булды...Палаткаларга татар хатын-кызларын өстерәп алып керәп көчләү күренешләре дә булмады түгел, булды...Булган хәлме? Сез беләсезме... Сез беләсезме...Нәкъ шул чорда бит инде Чаллы татар кызлары командированный һәм палаточный кавемгә әйләнде...

—Ничек?—диде Иркен-ага анламыйча.—Командированный... палаточный?

—Бик нечкә нәрсә ул...Психология!.. Их, Иркен ага, бетүгә барабыз без... Мондагы татар җәмгыятен беләсегез килсә, татар хатын-кызларын өйрәнегез...Татар дөньясын без, хатын-кызлар, җимердек!.. «Татар ирләре—тар мангай, артта калган, урыс ирләре—киң күнелле, прогрессив, имеш!.. Татар ирләре кер юмый, ашарга әзерләми, баланы детсадка илтми, урыс ирләре кер дә юа, ашарга да әзерли, баланы да детсадка илтә!», татар фәлән, татар төгән, имеш! Әле буыннары ныгымаган уналты-унсигез яшьлек татар кызлары менә шушындый расовый күрә алмаучылыкка корылган кызыл сүзләргә алданып, әнә шул сазлыкларда, буразналарда... командированный комсомолларның, гафу итегез, астына яттылар һәм нәселсез-кияүсез дә калдылар...Чәчен сарыга буяткан мондый туташларның күбесе, бүген, утыз елдан соң... шул Чаллысында, Сидоровкасында ир һәм пенсия көтеп картая... КамАЗ татар хатын-кызын ирсез, гаиләсез, баласыз итте... Димәк, ирне илсез итте!.. Алкаш итте!..Чаллы ирсез хатыннар шәһәре... Әгәр сез бүген Чаллыда һәм аның бистәләрендә кырык-кырык биш яшь өстендә булган күпсөйләр, итәк астыннан эш йөретеп, гаиләнең, тормышның кадерен, мәгънәсен анламаган, ир-атка өстән, бер җанвар итеп карап, юньле гаилә кора алмаган ирдәүкәләр, коммунистик пропаганданы үз файдасына борган эшлексез болтушкалар, «бөек төзелеш»тән бөеклек чире белән тилереп каешланган, үзләрен генә яратып, амбициядә ярым-йорты шизикка әйләнгән кызыл авыз ханымнар, яшерен эчкән, яшерен тәмәке тарткан, яшерен зина кылган татар хатын-кызларын очратасыз икән, аларның күбесе нәкъ әнә шул чакта, унҗиде-егерме яшьтә «боз өстендә бозылган» Чаллы кызлары булыр!..

Иркен ага Сихәт-сылуның тел байлыгыннан мөкиббән иде.

—Аларны КамАЗ бөеклек чире, амбиция белән чирләтте. Телләре булмаса, күзләрен карга чокып китә, аңлыйсызмы? Өйләрендә урысча гына мәтәштергән булып, милләтнең телен череткән, күлмәк-карыннан башка берни белмичә, милләтне үлемгә алып барган плебей хатын-кызларыбыз безнең шушы булыр!..Юньле татар мондый бозылган товаркаларга өйләнми, урыс белән исә үзләре яши алмый... Мин үзем дә аккош түгел... кайгыларым да бар, гөнаһларым да юк түгелдер, Иркен ага...Мин бит бабайларыбызның хәраменә хыянәт иттем, Иркен ага!.. Шул КамАЗ аркасында... Ул булмаса, ясар идемме мин бу адымны?!

Ул туктап Иркен-аганың күкрәгенә капланды да, һушына килеп, кинәт читкә тартылды.

—Ниндәен адым?!

Сихәт-сылуның бит очлары ялкынланып яна, колагындагы алтын алкалары янында бөтерелгән чәч учмалары гүя бу кайнарлыктан үзләреннән-үзләре бөдрәләнә иде...

—Әйтсәң—сүз, төртсәң—күз, дигәндәй...—Ул сүзен өзелгән җиреннән ялгап китте.—Чаллы урамнарында татарча сөйләшергә ярамады!.. Сәлимәләр Соняга, Мөхәммәтләр Мишага, Зарифлар Зорикка, Искәндәрләр Игорьга әйләнде!.. Шулай итеп, татарның мең еллык исем кушу йоласы бетте, исемнәр бакчасы—ономастика фәне чүплеккә әверелде. Аһ!.. Ничә мең татар кызы урыс белән язмышын бәйләп, бәхетсез-нәселсез калды?! Безгә

читтән килгән бозык, оятсыз, җиде ят хатын-кызлар ничә меңләгән татар егетенең башына җитте икән?! Күпме татар егетләре төрмәләргә эләкте... күпме алма кебек кызларыбыз алданып, үзенә кул салды?.. Кыз баланың абруе бит аның, үзегез беләсез, кыл өстендә, кылдан төшсә—юл өстендә... Язарлармы бу хакта берәр заман? Мина ул заманда күпмедер вакыт шәһәр шифаханәсенең хирургия бүлегендә җыештыручы булып эшләп алырга туры килде. Менә кайда күрдем мин тегеннән башы ярылган, моннан ыргытылган яшь татар егетләрен!.. Көн саен ун-унбиш яралы татар егете килә иде. Исрек тә түгелләр, һәммәсе айнык!..Бу хакта әйтергә, язарга ярамый!..

—Рәттән бар татарны кырмаганнардыр кү?

—Сез тагын...бигрәк!.. Чагыштырып әйтелә. Чечняда ни өчен тугыз яшьлек балага кадәр ир женесен кыралар? Хатын-кызны ирсез-яклаучысыз, илне баласыз—кешесез калдыру өчен!..

—Татарга каршы җирле геноцид?

—Юк, геноцид ук түгел. Дәүләт үзе үткәргән милли кысым дип әйтү хактыр. Рәсәй хөкүмәте илдә сан ягыннан икенче урында торган татарга каршы ачыктан-ачык геноцид үткәрә алмый бит инде. Милиция дә кеше кыйнап кына яши алмый. Чаллыда БКД дигән бер оешма... «Боевая комсомольская дружина» дигән нәрсә оештырдылар... Бу кансыз дружина белән Штейнберг дигән бик тә шыксыз, одиоз фигура җитәкчелек итте. БКД-га бары урыслар, беренче чиратта җирле урыслар, урыслашкан татарлар гына кабул ителде. Алар җирле татар психологиясен яхшы белеп эш итте. Шул чакта КамАЗ җитәкчелегенә Бех, Комм, Сигал, Якобсоннар килде...

Иркен ага яңадан куанып куйды: сылуының теле, сөйләү куәсе, белемле, сәяси хәбәрдар булуы ифрат та ошый иде.

—Сөйлән!.. Сөйлән!..

—Ничәмә-ничә татар кызының язмышын ватты, ничәмә-ничә татар кызын пычактан үткәрде икән бу комсомолецлар ул көннәрдә? Әгәр берәр татар гаделлек эзләп барса, әле һаман Сталин галифесен салмаган татар түрәсе үрә катып, «Бөек төзелешкә килгән комсомолец-доброволецларны шулай хурлыйсызмы?!» дип кенә авызын йомдырды. Шул көчләнгән кызларны яклап, бер бықыдышникны пычакка алган Җәлил абзый биш ел төрмәдә дә утырып кайтты... Мондый «комсомолец-доброволец»ларның күбесе зур акча артыннан төзелештән-төзелешкә качып йөри, беркайда да эшләми, урлаша, эчә-эчә дә китеп бара, аларның урынына икенчеләре килә тора... Әлбәттә, барысы да андый түгел, менә дигән, бөек шәхесләр бар иде алар арасында!.. Намуслы, чиста җаннар да күп иде... Мин килгән халыкның Чаллыны ничек үзгәртүен гомумиләштерәм генә... Урлашуның нәрсә икәнен белмәгән Чаллы угрылар башкаласына әйләнде... Ышанасызмы, көпә-көндез бу комсомолецлар мал урлап суялар иде!.. Житмәсә—көз, чиләкләп яңгыр коя, техника белән ергаланган урамнардан үтеп булмый, күк йөзендә өзгәләнгән болытлар... Алар күктән җиргә ишелердәй булып асылынып торалар... Резин итек кимичә урамга чыгып булмый, чыксаң, исерек урыслар сагалап тора, без, кызлар, кич белән урамга чыгарга да куркабыз...

1972 елның көзендә Чаллыда чак-чак кына сәнәкчеләр сугышы кабынып китмәде. Мин Кызылгвардеецлар урамындагы Таһир бабайларда фатирда яши идем. Күршеләребез—бер яктан тетя Маруся, икенче яктан—итекче Гыйльман абзыйлар, Нәфисә әбиләр... Чаллының төп халкы, гомер буе бер кашыктан ашап яшәгән урысы-татары, кыз-кияү алышу кебек хәрамга бармыйча, бергә аралашып яшәгән. Бер көнне шулай безгә горкомнан комиссия килеп керә. Өйдән өйгә йөреп, хуҗаларны, теләсәләр, төзеләчәк күпкатлы йортлардан

фатир алырга, телəмилəр икəн, йортларын Сидоровка, йə «Дикий» бистəгə күченеп утыру өчен кодалап йөрилəр икəн. Яна төзелешкə һəм ГЭС буасы астында калачак жир мəйданнары əзерлилəр, имеш.

Гомер буе җыйган дөньясын шулай бер тында суга салырга телəмəгəн халык мондый күченешкə теше-тырнагы белəн каршы булды. Күп кешелəр комиссияны кертмəс өчен капкаларын йозак белəн биклəп куя, бəйдəн этлəрен ычкындыра торганнар иде... Комиссия тəмам тынгы бирми башлады. Көн саен йөри!..Беркемнен күченəсе килми—ə күченү өчен ике генə ай вакыт бирелə. Күченмəсəгез, йортларыгызны конфисковать итəбез, бульдозер белəн җимерттерəбез! Үзегезне урамда калдырабыз!

—Тегe ТИҮнен соңгы җыенында чыгыш ясаган «ни гурыт-ни сала» Зөфəретдин абзый кебек була инде...—диде Иркен-ага.—Базар мəйданында ачлыкта ятадыр кү...

—Әйе, əйе! Ул абзый халык җыенында дөресен əйтте... Комиссиядə бер кысык күзле татар бар иде. Ул алдашканлыгын белеп, сөйлəшкəндə читкə карап сөйлəшə, кап-кара кысык күзлəре автоматик режимда туктаусыз йөреп кенə тора. Ана «япун» дигəн кушамат та тактылар. Бер көнне бу Таһир бабайга йорт-җире өчен ике мен сум акча алып килгəн. Үзеннəн аракы исе килə. Тегe чыкмый тек чыкмый.Түземе беткəн бабай сəнəгенə тотынды: «Аh, йөзең кара! Мəлгунь! Күземə күренмə!»—дип чак-чак котылды. Күп тə үтми тагын килə безгə тегe «япун». Күченергə атна вакыт бирə. «Йə биек йорттан фатыйр аласыз, йə Сидоровкада биш сутк ы җир билəп алып, йортыгызны күчертəсез, башкача—җимерттерəм!»—дип җикерə бу. «Юк, мин бернинди ташкапчыкка да күчмим, моннан да китмим!»—ди Таһир бабай. Аның бит монда ун суткы җир, ап-ак чəчкəдə утырган җилəк-җимеш бакчасы...

Бер атнадан «япун» бульдозерларын иярт еп, Кызылгвардеецлар урамындагы йортларны эттерə башлады. Аларга каршы кулларына сəнəклəр тотып каршы чыккан җиде-сигез бабайны милициялəр кулларыннан каерып, участокка алып киттелəр... Сез Чаллыга кайткач, Муса Җəлил бакчасында утырган тирəклəргə игътибар итегез. Аларның очлары шулай киселгəн гүя, гүя безнең татар бабайлары ике япьле сəнəклəр күтəреп, офыктагы бульдозерларга каршы баралар...

Таһир бабай бу законсызлыкны күтəрə алмыйча аягыннан егылды. Бүтəн аягына басмады. Бөек Ватан сугышы ветераны, Берлинны алып та тере калган фронтовик Таһир Каһарманов менə шулай туган җирендə КамАЗ котлованына салынган беренче корбаннарыбызнын берсе булды, мəрхүмкəй...

Иркен ага Сихəт-сылуны култыклап алды.

—Күз алдыгызга китерегез—ноябрь, салкын яңгырлар... аякларны өстерəп булмый... үзле балчык...Чаллынын тəрбияле урамнары чучка сөрентесенə əйлəнде. Һавада мат-перемат. Без, чилəклəп яуган яңгыр астында, Таһир бабайның ашык-пошык кораштырылган сарайга куелган җəсəде белəн хушлашабыз... Аны соңгы юлга озату өчен үзе кебек йөзлəгəн хокуксызлар, куылганнар, үз җиреннəн, туган Чаллысыннан инде исеменнəн үк чит һəм ят булган Сидоровкага яна сөргенгə сөрелгəннəр килгəн... Бу кайгылардан соңгы чиккə җиткəн Хөснелхаят əби, Таһир бабайның карчыгы, балалары белəн кинəшкəннəн соң, йортны Сидоровкага өстерəтеп күчерергə мəҗбүр булды...

Икенче язда без иптəш кызлар белəн Иске Чаллының кырылган-җимертелгəн, сөрелгəн урамнарын, йорт урыннарын, бакчаларын барып карадык... Җирлəр казылып, актарылып ташланган, һəркайда чүп-чар, гүя Колчак үткəн диярсең... Имеш, яна төзелеш килə... Әйтегез əле, яна төзелеш искене шулай имансыз итеп җимереп килергə тиешме?! Аларны бер тапкыр Ленин белəн Сталин җимергəн иде бит инде. Йөз ел төзəтə

алмый интегәбез. Иске белән яңа бездә янәшәдә яши алмыймени соң? Ул сездә, Америкада да, шулаймы?

Сихәт-сылу кинәттән Иркен-агага борылып, күзләренә укталды. Алар яшен ташы кебек зә-ә-әп-зәңгәр икән, ләбаса... Сихәт-сылуның саф, чиста тын алышы, аның текә күкрәкләреннән ургылган шаукымы Иркен-агага килеп кагылгандай булды.

—Таһир бабайны югалту кайгысыннан диярсен—агачларыбызның күбесе канатлары сынган кошларны хәтерләтеп, егылган. Исәннәре һаман да бирешмичә ап-ак чәчкәдә утыра... Шунда ук кыйралган тальян. Күреген буш шешә тишеп чыккан... Утырып елыйсылар килде. Мин шартлап сынган алмагач кәүсәсенә утырып сыктадым... Берүк вакытта мин тормышның илаһи көченә сокландым. Сез беләсезме, Иркен-ага: кайгы-хәсрәтләре зур булса да, исән агачлар бәйрәмчә матур итеп киенгәннәр иде, иляһым!... «Күрәселәребез булган икән, диләр иде алар гүя.—Әйдәгез, исән чакта бер-беребезгә җырлар җырлыйк...» Һәм алар гүя берсен-берсе ботаклары белән сыпыра, сыйпый, иркәли иде...

Мин мондый авыр вакытта Таһир бабай гаиләсен ташламадым. Йортны күтәрешергә ярдәм иттем. Без Сидоровка бистәсендә абзар, мунча кебек нәрсә кораштырып, башта шуларда яшәдек. Ноябрь ае бит! Суык. Әби ашны иртән керосинкага куя, кичкә генә пешеп чыга... Барлык алып килгән йорт җиһазлары янгыр астында кайсы бозылып, кайсы череп үк бетте.. Менә шулай башланды минем өчен КамАЗ эпопеясы. Әле булса Хөснелхәят әбиләрдә яшим. Хәзер инде социаль яклау идарәсе белән аны үлгәнчегә кадәр тәрбияләргә дигән килешү нигезендә карыйм.

—Канча яшьтә?

—Туксан өчтә инде...—Аның бит алмаларында тагын да теге уймак чокырлар хасыйл булды.

—Китче!..

—Хактыр. Беләгендәге беләзегенә житмеш биш ел.Таһир бабайның мәһәр бүләге...Таһир бабай белән Хөснелхәят әби, татарның шушы иң гади ике җан иясе, гомерләрендә бер грамм аракы капмыйча, бер грамм хөсетлек кертмичә хәләл никахта яшәделәр. Таң калырлык бит!.. Без килеп тә җиткәнбез, Иркен-ага!.. Менә безнең Чөкәймә-тау!—Сихәт-сылу кеше куллары өйгән-корган тауны хәтерләтеп, берьялгызы чөкәймәләнеп күтәрелгән җыйнак, әмма текә тауга күрсәтте.—Карагыз әле, чәчкә атканнар! Бу ниткән могҗиза?

Иркен ага аһ итте: алар каршына елга үзәнлегеннән йөгереп чыгып, сиреньнәр чәчкә аткан иде. Ул аларны өзәргә итте, әмма кулы күтәрелмәде. «Әгәр Сихәт-сылу өзәргә үрелсә, бер-ике тәлгәш өзеп бирермен» дип уйлады.

Сылу үрелмәде.

—Сиреньнәр!...—Ул сабыйларча куанып һәм нәрсәдер эзләгәндәй, сиреньнәр тирәли йөри башлады.—Сентябрьдә...бер җәйдә ике тапкыр чәчкә аткан!.. Мөмкинме?! Дөрес, бу хакта ишеткәнем бар иде!.. Сәбәбе нәрсәдә? Жылыдан гынамы? Әллә икенче сәбәп despite бармы? Бу юкка түгел, Иркен-ага, юкка түгел!... Улларым табылачак!..

—Сезнең улларыгыз... кайда соң?—Иркен-ага соравын бирергә булды.—Сез моны миннән яшерәсез. Нигә?

—Әле түгел!.. Әле түгел!..—Сихәт-сылу кара чәчләре өстеннән кош канатлары сыман кыеклап бәйләнгән яулыгының чите белән яшь тамчыларын сыпырды да, чаттагы сиреньнең бер кечкенә тәлгәшен өзеп алды һәм иснәде.—Нинди матурлар!.. Нинди хуш исләләр!..

Шуны гына көткән Иркен-ага аңа икенче бик күркәм тәлгәшне өзеп бирде.

—Рәхмәт. Әй, рәхмәт!..

—Кизләү үзе... чишмә үзе кайда?

—Әнә бит!

Үзәннең алар басып торган төшендә, бераз гына астарак, зур тимер чаннан башка бер нәрсә дә күренми иде. Иркен-ага чишмәнең үзәнен, аккан үзәнен, Кизләүнең кизләвен эзләде. Әмма үзән бар, тик аның аккан суы, кечек кенә булса да инеше, иделе юк иде...

—Кизләүнең...чыганагы.. чыккан жире кая?

—Шунда ук... Әйдәгез...

Ул Сихәт-сылуны кулыннан тотты.Кайчандыр нык тапталган, инде хәзер кеше-кара аягы басмагач, ишелгән, ике ягы да үлән белән сарылып, тар гына арасы калган сукмактан артыш таягы ярдәмендә сак кына омтылышлар ясап, Иркен-ага үзе һәм Сихәт-сылуны кизләүгә алып төшә башлады. Чокыр төбенә төшеп житәрәк алар биек, чәкән башлы камыш, эре сарут үләннәренә күмелде, сиздереп кенә биткә су салкыны бәрелде.

Иркен-ага көткән агымсу һаман да күренмәде. Менә алар чокырның төбенә үк төшеп життеләр. Агымсу юк, гомер буе кинәнеп аккан чишмәнең үзәне коры иде.

Алар алдында, тирәндә, чишмәнең кара күз кебек тирән коесы йәшкәзеп ята, әмма бу коедан ниндидер торба чыгарылып, ул астагы тимер чанга барып тоташа иде.

Сихәт-сылу тәмам аптыраган Иркен-ага хәленә кереп, йөрәген бигүк яраламаска тырышып, анлатырга тотынды:

—Чишмәне торбага куып кертеп, суынын яртысын чучка комплексына, яртысын авылга төшерделәр...Чишмәне бушка агызып яткырганчы, болай файдалырак, диделәр... Үз басымы, үз ирке белән төшә, имеш. Бюджеттан акча, «федераль үзәк»дигән обжор-командалан рөхсәт сорап тормыйча. Бушка, имеш. Татар бәхете!..

Иркен-ага һаман да төшенеп житми иде. Миллион еллар аккан чишмәне шулай тиз генә, кинәт кенә торбага куып керту аның башына сыймады.

—Су... Агымсу иркен чикләү... Сихәт-сылу, бу кемгә нинди бәхет китерәде?

—Безнен ирек—торбага куып кертелгән агымсу ирке инде.

—Үзәнлектәге агачлар... жиләк-жимеш куаклары... үсемлек-үләннәр... кош корт... жанвар-киек нишләйде? Үләде?

—Алары вак мәсьәлә. Шулай дип анлаттылар.

—Чишмә суын авыз итеп болады?

—Булырга тиеш...—Хәзер Сихәт-сылу Иркен аганы житәкләде.

Алар тимер чанга таба мәтәвекләнделәр. Чанның теге, авылга караган аскы ягында нәзек кенә торбадан эркелгән «артык су», басымы кимесә, үзәнлеккә «тамчылап кына тамып», басымы күтәрелсә, ягъни кәефе тагын да яхшыра төшсә, үзәнлеккә чәптергәләп тә алып, кипкән агымсу юлынын тенкәсендә уйнап тора иде...Әмма океан артыннан егерме мен чакрым юл үтеп кайткан мөһәжир туган чишмәсенең газизләрдән газиз алкымын учына алып, тәмләп тә карый алмый иде.

Ул чишмәсез калган иде. Аның аяклары сызлагандай итте.

Жирдән чеметем генә кара туфрак чемтеп алды. Ул аны тел өстенә салып, йотып жибәрде.

Алтмыш жиде яше өстендә, тарихи Ватанымда туган чишмәмне күрү бәхетенә ирешсәм, шулай итәр идем, шундый сүзләр-теләкләр әйтер, шундый догалар укыр идем, ата-бабаларның барча васыятьләрен житкерер идем дип ничек кенә хыялланмаган, нинди генә нәзерләр әйтмәгән Иркен ага бу колхоз системасы хәстәрләп куйган манзарадан телсез калган иде.

Ул чынлап та телсез иде.

Иркен-ага иелеп су алырга итте. Аяклары бирмәде. Баш бармагы белән чишмә үзәненә күрсәтеп, бала кебек, ыггы-ыггы килде.

—Хәзер!.. Хәзер, Иркен ага!..

Сихәт-сылу кыенлык белән чан торбасына иелде, аннан тамчылаган суда кулларын чайкады һәм кушучына су тутырып, Иркен-агага тәкъдим итте. Күтәлмәгән, башына да китерә алмаган тәкъдимнән югалып калган Иркен-ага, «Шулай да мөмкин икән?» дигәндәй кыяфәт белән бер мизгел иләс-миләс торды да, ниһаять, таягына таяну ноктасы табып, иелә бирде һәм, бисмилласын әйтеп, Сихәт-сылуның кушучындагы суны тамчысына кадәр эчеп бетерде...

—Зәмзәм... Әбелхаят суы... Тагын!..

Сихәт-сылу аңа тагын да кушучында су сузды.

—Тагын...

Ул аңа тагын да эчерде.

—Житәрдер... Туймасмын кеби...

Инде бу юлы сукмактан югарыга алдан күтәрелеп, аны тирән чокырдан Сихәт-сылу тартып чыгарды.

Кинәт җилнең юнәлеше үзгәрде, бар тирә-якны моннан бер-ике чакрым тирәсендә яткан чучка комплексыннан таралган яман ис басты. Алардан уң кулда, шулай ук бер чакрым тирәсендә уйсулыкта яткан сәер күренешне абайлап, Иркен ага аптырап калды. Бу урман дисәң урман, иген дисәң, чәчкән иген булмаган нәрсәнең, бик игътибар белән дикъкать итсәң, кайчандыр биек булып, бүген башыннан кыркылып алынган агачлык булганлыгын чамалап була иде.

—Нинәрсә?

—Урман иде. Чучкалар тамырларын чокып корыттылар. Алла каһәрләдеме безне, элеккеге карурманнар билләреннән алата корып, сыналар да төшәләр...

Алар хәзер сырт буйлап чиста комташка әйләнгән юлдан авылга таба киттеләр. Тирә-якта сасы ис көчәйгән саен меңләгән дуңгызларның тишкеч кебек үткер тоякларыннан мең тапкыр тишелеп, тапталып, сидек һәм нәҗес белән берлектә изелгән, әвәләнгән, аракы апарасыдай әчегән, күпергән, басылган, ниһаять беркайчан бернинди тереклек үсмәслек-үрчемәслек итеп кипкән, майлы кара түскә кереп шомарып, көя көйдергән сыман караеп көйгән җирдән бара иде алар. Комплекска якынлашкан саен җир җепши, сусыл баткакка әйләнә, җил исә әчкелтем-төчкелтем исләр белән апраланып әчи һәм күңелне болгата иде.

—Авылга көчләп чучка комплексы утырту—партком секретаре Икзим Фәрдүнәтовичның эше. Кыланышы кырга сыймады. Моны төзетү өчен Казаннарга гына түгел, Мәскәүләргә—Үзәк Комитетларга кадәр барып җитте. Һәр татар авылында сарык фермаларын бетереп, ашыктыра-ашыктыра чучка комплекслары салдырган татар житәкчеләренең урыннары—җәһәннәмдә. Аларны анда Мәскәү коткарып калалмас инде...Татар авылына чучка фермасы китертү аны атом белән бомбага тотуга тиң булды, Иркен ага. Чучка тоягы тигән туфракта бернәрсә дә үсми... Авылда:

Эчеп жибәр салганын,
Закускага—колбаса,
Закуска да булмас иде,
Дунгыз балаламаса,—

дигән такмак Икзим Фәрдүнәтович заманында чыкты бит инде...

Тегендә-монда аунап яткан целлофан капчыклар, иске автомобиль көпчәкләре, жимерек трактор, тимер-томыр, арматур баганалар артындагы акшарлы-пычрак бинаның капкасы өстенә зур хәрефләр белән «Свинокомплекс имени «Дружбы народов» дип язылган иде.

Юл аша чыелдый-чыелдый бер-берсен талап, күсе-комаклар өере үтте.

Иркен ага артыш таягы белән селтәнде.

—Авылны басты, хәерсезләр... Чучка белән бергә татар авылына гомердә булмаган крыса керде. Авылны коткару буенча махсус программа булдырмасак, бетә, бетәчәк бу авыл...

Иркен-аганың хәтеренә юлга чыгар алдыннан Чаллыда Татар Иҗтимагый Үзәге җыенындагы бер бөтерчек инсанның Татарстанда аракы сатуны һәм чучка үрчетүне тыярга чакыруы төште. Ул гаделлектән ерак тормаган икән ләбаса!..

Әйләнеп үтәргә мөмкинлек юк, артка киткән хәлдә, юллары бик уралып басачак иде. Алар кирпеч нигез тышына тимер чөйләр белән ныгытылган тимер-бетон такта каршында туктап калдылар. Аларга бер билгесез инсанның мозаика белән ясалган сурәте карап тора иде.

—Менә шушында була инде безнен авылның чын музее. Ә бу авылның иң атаклы кешесе...—Сихәт-сылу көлемсерәде һәм укып китте.—«Михаил Федорович Иванов ( 1871—1935), совет дуңгызчылык зоотехниясенең атасы, СССР Фәннәр Академиясы академигы, ак украин нәселле дуңгызларның авторы... «Нәсел ул һич кенә дә мәңгелек нәрсә түгел. Тормыш шартларын үзгәртә барып, без нәселне дә үзгәртә алабыз...» Менә ничек дип язган булган совет зоотехниясенең Мичурины!.. Кеше нәселләрен, халыкларны да үзгәртә алабыз, димәк!..

Каяндыр салкын җил өргәндәй булды. Менә шулай көтмәгәндә туган Кизләвенең чучка комплексында академик Иванов ядкаре белән очраклы гына очрашу аның нәселнең затлылыгы вә затсызлыгы турындагы кадими уйларын кузгатып җибәрде.

Алар киртәләр белән ихаталанган кара баткак дингезендә йөзеп тешләшкән, мыркылдашкан ана чучкалар, тирес корты кебек агарып, үзара уйнашып, аркан булып ишелгән, берсен берсе алсу-кызыл борыннары белән сөзеп чинашкан чучка балаларының дәүләтләре яныннан үтеп киттек дигәндә генә Сихәт сылу юлдашын туктатты, беләкләреннән тотты һәм ихластан :

—Минем сезгә... бары сезгә генә сөйләр сүзем бар иде, Иркен-ага... Чаллыда статистик хисапта биш йөз меннән артык кеше торса да, сер сөйләрлек, мине аңларлык берәү дә юк...

Иркен-ага карашы белән утырыр урын эзләде, ләкин тирәдә кипкән, көйгән кара балчыктан башка бернәрсә дә юк иде.

—Мин дә шушы елларда таралган комсомол коткысының корбаны булдым бит... Имеш, татарлар гаиләдә канэчкеч-тиран, урыслар—аккош икән. Мәхәббәтнең милләте юк дигән шушы бер бөек ялганның корбаны булуым аркасында ирсез, гаиләсез калдым бит мин бүген... Мәхәббәтнең милләте бар икән, ничек кенә бар икән әле! Мәхәббәтнең йөрәге, теле генә түгел, куллары, аяклары, күзләре, колаклары, аш-су тоткан калаклары, кигән күлмәкләренә, үзара әрләшү-талашуларына кадәр милли икән!... Мәхәббәтнең карурманнары, җидегән йолдызлары, җидегән чишмәләре, җиде кызлары, җиде егетләренә кадәр милли... Иркен-ага, дөрес аңласагыз иде... Мин, ашыгыч курсларда сәркәтиб һөнәре алган унсигез яшьлек татар кызы, төзелеш идарәсенә эшкә киләм һәм аны-моны уйламыйча, Кама буендагы Прости авылыннан Павел Селиверстов дигән урыс егетен күрәм

дә капланам...—Ул әйтим микән, юк микән, дигәндәй, уйланып калды да Иркен аганы култыклап, аны йөнә юлдан авылга таба алып китте.—Озак та үтми, аһ, ул көннәр!... Пашадан авырга калам...Паша, ата-анасы белән киңәшеп тормыйча, мина тәкъдим ясый. Алар ана татар кызына өйләнүне тыя. Мин авырлы булуым һәм Павелның ата-анасының безнең никахны тыюы турында Хөснелхәят әбигә сөйлим, ул минем нәселемне карайөрәкләр белән кушмас өчен көмәнемне төшертергә акушер да таба...

Сихәт-сылу, үксеп җибәрә күрмим дигәндәй, беравык тын торды.

—Тик мин беренче көмәнемне төшерүдән баш тартам. Ул мине җитәкләп диярлек, Кизләүгә алып килә һәм урыс егетенә бирмәс өчен әткәй-әнкәй белән киңәш кора. Инде хәзер урыска чыгудан мине үземнекеләр тыя. Мин алар белән килешмичә, Чаллыга качып кайтам һәм Павелга кияүгә чыгам. Балабыз туа. Игезәкләр!.. Мин Ихлас һәм Сабыр кушыйк, дим. Павел—Александр һәм Станислав, ди. Ахырда аның туганнары, балаларымны урлап алып китеп, авылларында һаман да шул Александр белән Станислав исемнәре кушып кайталар. Бу вакыйгадан соң безнең тормыш тәмугъка әйләнде. Көнебез һәм төнебез әрләш-талашта үтә торган булды. И-и, андагы кимсетелүләрем!.. «Поганая татарка» дип йөземә төкерә, балалардан үч ала, аларны да кимсетә, туктаусыз эчә, кыйный, чәчләремнән өстерәп йөртә башлый. Мәхәббәтнең барлыгы-юклыгы, милли эчтәлеге бала тугач кына ачыла башлый икән ул...Мин шул көннәрдә генә Ленинның «Мәхәббәттә икәү генә катнаша, әмма аның өченче әгъзасы—бала туганнан соң гына ул мәхәббәт гаиләгә әйләнә» дигән сүзләренең мәгънәсен аңладым... Минем түземем бетә башлады. Нервларым какшавыннан ике тапкыр хастаханәдә яттым... Икенче тапкыр яткач, Павел тагын да минем юклыктан файдаланып, туган авылына балаларны чукындырырга алып кайтырга җыена башлый. Бу хакта минем дус кызларым белеп калып, Хөснелхәят әбигә хәбәр итә һәм ул мине хастаханәдән килеп ала...Мин эчке киемнәремдә чыгып чабам, алкамны биреп, такси тотам, Простига кайтып төшәм... Анда исерек Павел, аның исерек ата-анасы һәм карайөрәкле дистәләгән крестныйлар, минем газиз балаларымны... түтенле кара мунчада... салкын сулы лаканга чумдырып, кальбенә тәре индерергә маташалар!..

Бу тарихтан һава шартларга җитеп кысылды. Иркен агага тын житмәде. Сихәт-сылуны туктату мөмкин түгел иде. Кирәкми дә иде. Ул әрни-әрни сүзен дәвам итте:

—Беләсезме, минем белән нәрсә булды? Мондый чакта бер Аллаһым көч бирә икән. Бисмиллаһ иррахман иррахим! Аллаһу Тәгалә, көч-кодрәт бир!.. Зарлы булсам да—буем гарьле. Мин тәреле-сулы лакан өстендә ялкынлы факелга әйләндем! Мин башкалар каршында ялкынланып яндым, гүя башкаларны ялкыным белән сукырайтып, ике улымны кара поп кулыннан суырып алдым да, ике кулыма ике биләү салып, яланаяк һәм яланөс Простидан чыгып тайдым!..

—Сез кандай каһарман хатын!..

—Әй, Иркен-ага!.. Алтын башлы хатын булганчы, бака башлы ир булсаң икән ул!..

—Сез кандай сирәк... кандай акыллы хатын!..

—Әй, мактамагыз әле, Иркен-ага!... Хатын-кызны мактарга ярамый.

—Нигә?

—Бозыла,—диде тынычлана төшкән Сихәт-сылу. Ул авыл кызларына хас шаянлык белән тагын да зеңгелдәп көлде.—Куанычыннан күбенә, ди. «Алты хатын тартканчы, алтмыш ир тартыр идем», дип әйткән ди бит ат та... Менә шулай итеп, мин улымны Кизләүгә—әткәйләргә алып

кайтам һәм сөннәткә утыртам... Күрше авылдан мулла алып килеп исемен дә янартам. Александрын ташлап, ике тапкыр батыр, ике тапкыр көчле булсын дип Биарыслан дигән исем кушам... Би—гарәпчәдән «ике» дигән сүз. Биарыслан!..Ике тапкыр арыслан, димәк. Станиславларын ташлап, икенчесенә Хәбибнажар кушам. Анысы «Котылган сөеклем» була инде... Матурлармы, Иркен ага?

—Бик матур! Бик батыр!..

—Алар чынлап та матур да, батыр да!.. Алар, беләсезме, ике күкрәгемне парлап имделәр!..

Иркен ага бу камыш кебек зифа, әмма тимер кебек курку белмәс хатынга Дәрдемәнднең кульязмалары арасыннан табылган шигырен укымый булдыра алмады:

Бертуганың читкә тибә
Дәүләт тигез булмаса;
Ана сөтен аеры имә
Бала игез булмаса...

—Ходай Тәгалә насыйп итсә, сез аларны күрерсез дә әле, иншалла... Икесе дә таза гәүдәле, иңнәре ат иңнәре кебек почмаклы, беләкләре бәләк кебек каты һәм төерем!..

Алар корыган, чак кына дымланып яткан инеш аша чыктылар. Алда авыл очының беренче өйләре күренде.

Аны бу кадәр дә сирәк җан иясе белән очратканы өчен Иркен ага язмышка инде ничәнче тапкыр рәхмәтле иде.

—Балаларымны сөннәткә утыртканнан соң, Пашаны һәм бер бүлмәле фатирымны ташлап, Хөснелхаят әбигә килеп урнаштым. Бала хакына мин милләтемне сөймәгән урыс белән дә түзеп яши алган булыр идем... Ләкин ул... Паша... Искиткеч надан кеше иде... Сез ничектер, минем үземнең татар шагыйрьләреннән иң яраткан шагыйрем Габделҗаббар Кандалый. Дәрдемәнд артык сәер серле, аристократ, диим микән инде. Мәхәббәтне сурәтләүдә Кандалый янында Петрарка, Пушкиннар да сабый бала гына!.. Сез тыңлагыз әле, тыңлагыз!.. Мин аны Чаллыда сәхнәдән укый идем...

Сихәт-сылу кызларча житезлек белән янында торган таш кисәгенә сәхнә итеп менеп басты һәм ихластан җилкенә-җилкенә сөйли дә башлады:

Надан ир куйнында яту,
Ара да булмаса тату,
Эченә чыгадыр кату,
Ки бер йомгак төен кебек.
Кече яшьдин матур булдым,
Гыйлем булдым да зур булдым,
Надан ир берлә хур булдым,
Булып гомергә мәхсүрә...
Кягъэзе иде пуштавый,
Сүзенең килгән уставый,
«Мәңа кил!»—ди-ди кыстадый,
Өзеп эчемне бик бора... .

—Без әткәй белән улларыбызны чын татар егетләре итеп үстерергә тырыштык...—дип дәвам итте Сихәт-сылу.—Иңнәре ат иңнәре кебек... Күрерсез дә әле, иншалла!..

—Югалуларына ничә көн?

—Өч.

—Өч!..—Иркен-ага кычкырып җибәрде.—Сез... ана кеше... ничек түзәсез?! Ник сез аларны һаман да эзләмәйсез?

Сихәт-сылуның ирен читләрендә нерв җепселләре тартышты. Менә-менә үксеп җибәрер кебек иде. Әмма ул тешләрен кысып түзде.

—Эзлибез. Ничек кенә эзлибез әле... Дәү әтисе, дус егетләре дә эзлиләр...—диде серле итеп Сихәт-сылу.—Монда кайбер нечкәлекләр бар... Бездә бер өметле хәбәр бар барын, бүген төнгә каршы мин үзем дә аны эзләргә чыгачакмын...

—Бу хакта милисигә хәбәр салынгандыр кү?

—Юк. Милициягә хәбәр итә алмыйбыз шул.

—Нинди сәбәп илә?

—Эш шунда ки, 1996 елдан бирле алар Чечнягә бармас өчен урыс армиясеннән качып яталар... Мөселман чечен туганнарыбызга каршы мылтык күтәрү татарга олы гөнаһ бит!.. Алар...—Сихәт-сылу кеше ишетми микән, дигәндәй, тирә-ягына каранды.—Алар М. районында «Басып алынган татар халкының уллары, урыс армиясенә хезмәткә бармагыз!» дигән шигарь астында бер оешма сыман нәрсә дә оештырып маташтылар...

—Мәрхәбә!.. Кандай батырлар!..

—Шуның өчен нык кына эзәрлекләнделәр. Урындагы хакимият аларны эзәрлекләүдән... Чечня белән Рәсәй арасында Хасавьюрт килешүләре[1] төзелгәч кенә беразга тынып калды... Анлыйсыздыр, аларга хакимият күзенә бик ташланырга ярамый.

Иркен ага телен тешләгәндәй булды. Сылуның гайрәтле ирләргә хас тынычлыгы, сабырлыгы һәм акылы таң калдырды.

Алар авыл башына килеп керделәр. Иркен-ага кечкенә, түбәсе белән диярлек җиргә сеңгән өй ишарәтенең түбә тактасына язылган язуны иҗекләп укыды:

—У-ли-ца капи-та-на Сал-ган-ско-го... Бу нимә болады?

—Урам исеме. Капитан Салганский.1939 елдагы совет-фин сугышында берүзе финнәрнең бер полкын кырып салган диме шунда...

—Татар? Тумышы белән Кизләүдәнме?

—Юк. Белоруссия яһүде.

—Ә нигә аның исемен... Кизләүдә мәңгеләштергәннәр?

—Кизләүнекеләргә мондый исемне бирмәгәнгә. Менә бу өйдә бик кызык бер апа яши. Кереп чыгыйкмы?

—Керик. Бәлки ул безнең шәҗәрәне дә белә булыр?...

—Юктыр. Ул килмешәк кеше. Әгерженең Олы Барҗы авылыннан күченергә мәҗбүр булган ул. Берүзенә ике кушамат: «Безнең Барҗыбызда» һәм «Ирдәүкә Мөнәвәрә».

—Бер кучтәнәчсез...

—Әнә, кибет!..

Алар урамнан эчкәрәк кереп салынган, тышы ак пластика белән тышланган кибеткә юнәлделәр.

—Үзебезнекеләр салды. Яңа татар сәүдәгәрләре!

Тышы кебек, эче дә чиста кибетнең киштәләре төрле илләрдән китерелгән колониаль тауарлар, җиләк-җимеш, азык-төлек, сагыз-магыз тулган иде. Йөзәрләгән сорт аракы-шәрабны аргы һәм бирге башка бүлеп ике урынга куйганнар. Уртада сәнәгый тауарлар бүлкәсе. Шушы бүлек-

[1] «Хасавьюрт килешүләре» — 1997 елның маенда Рәсәй Федерациясе президенты Борис Ельцин һәм Ичкерия Республикасы президенты Аслан Масхадов кул куйган тарихи документ.

бүлкәләр арасында аларны кайнаган сөт кебек якты кабарган татар хатыны елмаеп каршылады. Тауарлар шул кадәр күп, шулкадәр кычкырып тора, алар теләмәсәң дә кулыңа сикерергә әзерләр иде.

Сәнәгый тауарлар бүлкәсе каршына бер карт күзләре белән чекрәеп, кулындагы ниндидер металл кулланманы әйләндерде-әйләндерде дә:

—Сарманнан микән әллә, дигән идем, германнан икән,—дип кулланманы кире сатучыга бирде дә чыгып китте.

—Рәхмәт, һәр тауарга ике телдә язып куйгансыз!—диде сатучыга Сихәт-сылу тутырмага күрсәтеп.—«Моя любимая свиная»... «Минем яраткан дуңгызым»!..

—Ә кәк же!..—диде сатучы елмаеп.—Үзебезнең кулдан килми. Районнан килеп тәрҗемә итеп китәләр. Түлибез...

Иркен-ага Чаллыдан да, Мамадыштан да алып маташмаган күчтәнәчләрен—җиләк-җимешен вә чәй-шикәрен, хатын-кызларга шәльяулык, ирләргә күлмәк кебек әйбер-сәйберен менә хәзер, Кизләүнең үзендә сатып алды да куйды. Кичә төнлә буш кул белән килеп кергән Шәйхенурларга да житәчәк. Менә бит дөньяның барлыгы, киңлеге вә рәхәтлеге!..

Кибеттән чыгып, теге кечкенә алачыкка кире килделәр.

Яшел капкасы каршында аларны уртачадан калкурак буйлы, эре сөякле, җиңелчә шадра йөзле, битенә көзге яфрак сарысы саркылган моңсу карашлы апа-җан каршылады:

—И-һи-һи, Сихәт! Бик һәйбәт туры килдең әле, апаем. Иртәдән бирле үрле-кырлы дәвлинҗәм сикерә. Әйдә, тиз генә үлчә дә, берәр нәрсә эчер! Дару миндә бер кочак...—Ул кече капкасын янтайтып ачты һәм кунакларны эчкә үткәрде.—Керегез, кер. Безнең, ирсез карчыкларның, йорт-җире шундый ташландык була инде ул... Бәй-бәй, монысы кем була тагын, бер дә безнең якларга охшамаган?—диде ул Иркен агага текәлеп карап.—Кияүгә чыктың мәллә?..

—Чыктым шул!.. Нигә чыкмаска?—Сихәт-сылу һәрвакыттагыча зеңгелдәп көлде.—Америкадан. Кунагыбыз.

—Юкны сөйләмә. Америкадан алып үз акылындагы кеше монавында хәтле килә буламы...

Өйалдының иске сайгакларында сыгыла-сыгыла эчкә үттеләр. Апа-җан дивардагы төймәгә чек итеп басты, әле генә караңгы базны хәтерләткән кечкенә алачык үзенең бар ятимлеген күрсәтеп гөлт яктырды. Бүрәнә дивардагы күкеле сәгать, чатнаган көзге һәм борынгы чүпләм тастымал, чәчкәле чигешләрдән, чынаяклы өстәл, агачтан кырып ясалган иске караваt, ике-өч урындык, аксакаллардай картаеп, төрле якка уасын чыгарып, чыш-пыш килеп янып яткан мичтән, мич каршында тырым-тырагай ташланган пүләннәрдән башка бернәрсә юк иде.

—Газ кертмәдем. Кыйбат та. Җә жанып та үләрмен!..—диде хәлсез булса да, үзен тере тоткан апа-җан.—Утын белән тудым, утын белән картайдым, утын белән теге дөньяга китсәм иде, илаһым... Әйдәгез, утырыгыз, апайларым. Байлык та байлык дип тилерәләр хәзер. Байлык! Һм! Нәрсә ул байлык? Байлык ул—бер айлык. Ярлылыктан да яхшы нәрсә юк. Ярлылык—гомерлек...

Сихәт-сылу аның кан басымын үлчәде. Ул чынлап та югары—йөзгә йөз сиксән дәрәҗәдә иде. Хатын целлофан капчыктагы даруларны өстәлгә бушатып, караштыра башлады.

—Һи-и, Мөнәвәрә апа, менә бит иң кирәк дару! Моны Чаллы әптикләрендә дә таба алмыйлар. Эчкәнең бармы? Әллә тозлап яткырасыңмы?

—Нинди ул, апаем?

—Престариум. Бер сәйләнен эчеп җибәр. Хәзер үк.—Сихәт-сылу мич арасына кереп касәдә су алып чыкты.—Мә.

—Старый, дисенме? Үлмәмме, апаем?

—Юк, үлмәссен. Терелерсен.

—Амин, илаһым.

Инде бу яшендә тиресе үтә күренмәле булып җилсенгән, кан юллары кипшенгән куллы, әмма яшь чагында бу кулларның ирләргә хас көрәктәй кул булганлыклары әллә каян сизелеп торган апа-җан даруны йотты.

—Менә рәхәт булып китте...—диде ул шундук.—Рәхмәт инде, апаем...

Татар авылында шушындый кешелек табигыятен беренче мәртәбә диярлек күргән, мондый тере сөйләшне беренче тапкыр диярлек ишеткән Иркен ага шуның белән генә дә бәхетле иде.

—Садыйк карттан өч тиенгә сатып алынган шушы тавык кетәгендә егерме җиде ел гомер итәм инде...—диде ул.—Кизләүгә барыбер илегә, өйрәнә алмыйм... Кая инде, безнең Олы Барҗыга житә диме!.. Шул Барҗымны мактый башласам, тоталар да «Бик яратсаң, Барҗына кайт та кит!»—дип тотыналар, Сихәт ыланкаем...—Янында яше ягыннан күрер күзгә күп булса ун яшькә кече булган ят ир кеше барлыгын да онытып, сүзен дәвам итте:—Туган-үскән илләрдән көчләп күчендергәндә кузгалды бит инде минем шушы югары басымым, ләгънәт!.. Менә диган яшәп ятканда безнең Олы Барҗыны Иҗау суларыннан электр алабыз дип су астында калдырдылар бит... Илсез-җирсез, хәтта ирсез калдырдылар... Шул Түбән Кама дингезе диган нәмәстәкәй аркасында, кадалып киткереләре, бу кадәр өстемнән көлгәч... туган җирләремнең канелашын күрмим, ераккарак ычкыныйм дип... тәүбә-тәүбә... әллә кайларга чыгып олактым бит... Йә, Ходай, нинди гөнаһларыбыз өчен? Калхузга кереп, мәчет манараларын кискән өчен алган бәддогаларыбыз өстебезгә төштеме?! Төшләремдә салкын тирләрдә уянам, ыланкайларым!... Шомыртлар, өянкеләремне, сыерчык оясы кебек уймак өемне сагынам... Безнең Барҗыбызда кояш та нурлырак, җилләре дә сагынычлырак, мин сезгә әйтим!.. Әй, Сихәт, нишләп чәйсез утырабыз? Анавы чәйнүкне электрга тоташтыр әле!

Сихәт-сылу урыныннан күтәрелеп, чәйне куйды һәм кисәү агачын алып, мичтәге утыннарда актарынды. Аның йөзен ялкын яктыртты.

—Язмыш дигәнең шушында язган булгандыр. Барҗылар Кичкетаңга күченде, югыйсә. Безнең, хәерченең, очсызга алдандым. Барҗыны сагынуым йөрәгемә чир булып күчте, апайларым. Ябыктым, сулыктым... Барҗым исән булган булсамы?! Артыма борылып та карамыйча кире йөгерер идем!.. Их, сез чит-ят җирләргә китәргә мәҗбүр булган кешеләрне анламыйсыз шул...Мин кичергәнне сез кичерсәгез...—Ул түземен җуеп, кечкенә тәрәзәсе янына килде һәм үз янына Иркен аганы чакырды һәм, кулын каш өстенә куеп, зәңгәр тәрәзә пыяласы аша ерак офыкларга күрсәтте.—Әнә, теге яланнар өстендә өелешкән ак болытларны күрәсеңме? Шунда гына бит минем Олы Барҗым... Чикләвекле Балтач Чаганлыкларым... Бер якка янтайган килеш су астында калган йортҗирем... Бәбкә үләнле ихатам, туган кара туфрагым!... Чит-ят җирләрдә сагышлардан саргаеп үләм бит, бәгырькәйләрем!..

Ул хәле бетеп урынына утырды.

—Ул хәтле бетеренмә әле, Мөнәвәрә апа!—диде Сихәт-сылу чәй ясап.— Чәйдән авыз итегез.

—Әле дә кердегез әле... Күнелнен тулышкан чагы иде...—Карчык чәен җәйпегә салып, авызын чылатты.—Әнә, күлчәләреннән, бавырсагыннан авыз итегез...

—Бетеренмә, дим шул. Монда да татар җирендә яшисен, Мөнәвәрә апа,—дип юатырга тырышты Сихәт-сылу.—Америкаларда яшәсән, барып та күрә алмас иден әле...

—Нәрсә ул Амырикада Баржыны күрмичә яшәү?!—диде карчык үзендә көлемсерәр көч табып.—Күпкә җинел бит ул. Китткән—беткән!.. Америка аны, Баржыны исән дип уйлый. Ә ул исән түгел!.. Син аны менә монда, Мамадыш Кизләвеннән су астында калган Баржыны күрмичә яшәп кара!..

Күзләреннән серле, гадәти булмаган ялгызлык моны бөркелгән Мөнәвәрә апа-җан, үзе бер төрле акыл иясе, дөрес фикер йөртә иде. Иркен-ага анарда нинди дер бер ачылмаган эчтәлек күргәндәй булды һәм теленә килгән беренче соравын биргәнен сизми дә калды:

—Балаларыгыз юкмыни?

Сихәт-сылу Иркен-агага «Нигә бу теманы кузгаттыгыз?» дигәндәй караш ташлады.

Мөнәвәрәнен йөзе гүя көзгә кебек чатнады, төрле кисәкләргә бүленеп таркалды, нерв җепселләре йөгереште, йомылган күз кабаклары тартышты, гүя алар бу дөньяга карамаска, ачылмаска карар иткән иде. Ниһаять апа-җан эчке тетрәнү белән сыкранды, тау күтәргәндәй көч куеп, күз кабакларын күтәрде...

—Сазаган кыз мин, апаем. Кияүгә чыга алмый калган идем шул...

Өйдә уңайсыз тынлык урнашты.

—Кактус...—диде сөйләшүне икенчегә юнәлтергә тырышкан Сихәт-сылу.—Карагыз әле, кактус чәчкә аткан! Ул бит сирәк чәчкә ата...

—Бик сабыр гөл ул...—диде Мөнәвәрә-апаҗан кәефе килеп.—Сабырлык гөле ул. Минем кебек...

Ишек аша песи мыяулады.

Сихәт-сылу ишекне ачты. Аннан, зәңгәр күзләре белән һаваны көйдереп, йөнтәс бенгаль песие керде.

—Менә шушы песием белән икәү исән чыктык без Түбән Кама диңгезләре астыннан...

—Мөнәвәрә апа, ачуланма инде, туры килгәндә сорыйм әле: яшьлегендә берәр яраткан егетең булгандыр бит?—диде кинәт кенә Сихәт-сылу.

Көтелмәгән бу сораудан Мөнәвәрә апа-җаннын күзләре юмарт яшәрде, бу юмартлык аның барлык йөзенә җәелде.

—Һи-и, апаем, булмый диме!.. Булды. Сугыш челпәрәмә китерде планнарны. Сөйгәнемне үкси-үкси фронтка озаттым. Колхоз мина гәрүчи ташучы дилбегәсен тапшырганые. Мытыестан крәчин, сәләрке ташыдым. Ике йөз литрлы мичкәләрне кулда гына уйнаттым. Урман кистем. Агач ташыдым. Колач җитмәс имәннәрне сала алмасам, чанама капланып елый идем. Ирләр күтәргәнне күтәрдем, ирләр бушатканны бушаттым... Башымда кырпу бүрек, өстемдә сырган чалбар, сырма. Кырык өчтә Галимҗанымның һәлак булу хәбәре килде. Минем күз яшьләремнән карлар да чаж-чож килеп эри иде. Күнелемдәге нечкә хисләр гәрүчи мичкәләре астында изелде. Әнә шулай мин Ирдәүкә Мөнәвәрәгә әйләндем. Сугыштан кайткан бравай егетләр безне сайламады, яшьләрне сайлады... Менә шулай гомер үтте, апайларым. Бәлки, үлмәгәндер дип Галимҗанымны кырык ел көткәннән соң... инде авылыбызның

да башына житәсе елны мине хатынсыз калган күршем Габдерахман соратты. Кушылырга да өлгерми калдык, су басымы кайгысыннан кан басымы күтәрелеп, йөрәге шартлады, мәрхүмкәйнен. Бәлки мин дә, картлык көнемдә булса да, бер килеп, ир кадере күрермен дигәндә... Менә шулай, авыл өстендә, ил өстендә—югары су басымы, миндә югары кан басымы...

Иркен-ага Мөнәвәрә апаның үзе турында сөйләп, анардан Сәлахиләр нәселе турында сорашып торуның мәгънәсен күрмәде. Аның үз кайгысы үзенә житкән иде.

Күзләренә саркылган яшьләрен яшерергә тырышкан Иркен ага белән Сихәт-сылу аңа күчтәнәч бирделәр, шәлъяулык бүләк иттеләр. Шәлъяулыкны ул озак кына алмый матašты. Ниһаять, белгәнен укып дога кылды һәм шәлне иңенә салып, чатнаган көзгесе янына килеп үзенә караш ташлады:

—Әллә көзгем матур күрсәтә, әллә мин үзем шулай матур инде...—дигән булды, шаяртырга тырышып.—Рәхмәт төшсен... Туктагыз, бүләккә каршы—бүләк!..—Ул караваты астыннан ак калай тасмалары белән шакмакка-шакмак көпләнгән сандыгын чыгарды һәм, анда байтак ботарланганнан соң, чүпләмле тастымал китереп чыгарды:

—Кыз чагымда чүпләгән идем. Беренче баламны тәрермен дип. Насыйп булмаган. Мин аны су астыннан исән алып чыктым. Стенагызда матур күренер ул. Төсем итеп эләрсез...

Ул тастымалын ай-вайга куймыйча Иркен-агага тапшырды. Иркен аганың зиһенендә бөек Гомерның «Илиада», «Одиссея»ларындагы диңгезләр чоңгылыннан кулларында чүпләм тастымал, тастымалда кояшлы бәби күтәреп килеп чыккан легендар Ифигения, Пенелопалар, диңгез Сусылулары пәйда булды. Одиссейны егерме биш ел көтеп челтәрен сүткән дә бәйләгән, сүткән дә бәйләгән Пенелопа гынамы безнең татарның риваяти Мөнәвәрәләре?! Аның бер Мөнәвәрәсе үзе ун Пенелопага тора!..

Алар көтмәгәндә танышудан туган монсулык белән аерылыштылар. Урамга чыккач, шактый ара сүзсез бардылар. Иркен аганың бу очрашудан соң нәрсәдер сорашасы-ачыклыйсы килде.

—Урыслар шул кадәр яман халык түгелдер кү?—диде ул.—Әллә ихластан яман?

—Юк, әйбәт халык. Алар белән яшәп кенә булмый. Шунысы сәер, татарларны, нәкъ менә алар бәхете өчен илсез-ирсез калган Мөнәвәрә түткиләрне яратмый... Чынында аларны без яратмаска тиеш идек. Алар безне басып алган, биш гасыр буе кол итеп изгән бит. Биредә киресе килеп чыга: без, кабул итмәскә тиешлеләр, аларны кабул иткәнбез... Ашатканбыз, ашатабыз-эчерәбез, киендерәбез, аларга бушка кызлар бирәбез, милләт кадәр милләтебезне донор итеп, балаларны урыс ясыйбыз, урысны ишәйтәбез-яшәтәбез, нефть-газыбыз, жиребез-малыбыз белән баетабыз, ә алар, безне басып алучылар, без аларны кабул иткән, «яраткан», ишәйткән саен, ныграк баеткан саен ныграк яратмый. Һәм беркайчан да яратмаячак. Ни өчен, дисез?

—Ни өчен, сылуым?

—Мин сездән сорыйм.

—Минемчә, монда расачыл күрә алмау ярылып ята...

—Хак,Иркен-ага. Урыс белән татар, Иркен-агам, жаныкаем, Аллаһудан икесе ике материк, ике Галәм, ике Галактика, ике фәлсәфи система булып яратылганнар. Аларга бергә кушылырга ярамый. Алар

бергә кушылган жирдә—фажига. Менә ни өчен алар белән катнаш гаиләләр беркайчан да иректе һәм бәхетле булалмый. Аларда бәхет һәм гармония мотлак икенчесенен бәхетсезлеге исәбенә яулана. Бу темага татар диссертация язалмый. Аны расачылыкта гаеплиләр. Урыс дөньяда күрелмәгән «интернационалист» икән ул. Югыйсә, проблема даһиларча гади хәл ителгән: кичә дә, бүген дә кол, колониаль татар белән кичә дә бүген дә колбиләүче, колонист, империалист арасында тигез мәхәббәт, ярату була аламы? Татар белән урыс арасындагы мәхәббәт ул тарихның чалыш елмаюы. Әгәр урыс татарны «Яратам» ди икән, сез мона чалыш елмаеп кына куегыз. Менә ни өчен никахның икенче көнендә үк аларның «поганый татарин-татаркалары» янгырый башлый. Яратуданмы? Юк, кимсетүдән. Мин менә шундый кимсетү белән килешә алмадым һәм кара төндә сигез айлык балаларымны урлап, исерек иремнән алып качтым һәм чын татар итеп үстердем!.. Менә ни өчен урыс белән катнашырга жөрьәт иткән татар урысның бу кадәр агрессив холкын моңа кадәр белмәгән-аңламаган булып чыга. Мондый гаиләләрнең туксан проценты таркала, әлбәттә. Әйе, татар баласы моны төптән уйлап житкермичә урыска кияүгә чыгуын чыга, маржага өйләнүен өйләнә, тик менә шундук баласын урыс итәргә, малын урысныкы итәргә, динен урысныкы итәргә әзер түгел булып чыга—ул, ни дисәң дә, ике мең еллык бөек цивилизациясе булган бөек татар баласы бит әле!.. Менә ни өчен урыс-татар катнаш никахлары арасында бәхетле бер генә никах та күрмәдем. Әгәр мондый никахлардан берәр татар «Мин бәхетле»! дип әйтә икән, ышанмагыз, аның балалары урыс һәм аның бәхете дә карын туклыгы, кием-салым, елтыр беләзек һәм постель бәхете генә булып чыга!..

—Урыс белән татар—күк һәм жир. Алар—ут һәм су, алар—мич башында яту һәм авыр хезмәт, алар—эчкелек һәм эчкелектән тыелып яшәү, иман һәм имансызлык, эшлексезлек һәм гамәл кебек капма-каршы сыйфат чыганаклары...—дип дәвам итте ул сүзен.—Аларның бергә сыешып тыныч яшәвендә шушы сыйфатларның диалектик капма-каршылык бердәмлек түгел, ә бәлки татарларның бу гаделсезлекләргә эндәшмичә түзеп яшәве ятадыр? Сез бу ике халыкның эчкелек рәвешенә генә игътибар итегез. Мин аларны үз тәнемдәге йодрык эзләреннән беләм. Бергә яшәгәч—беләм!..Бергә яшәп, бергә яшәргә ярамый икәнлеген белдем! Бабайлар мондый бергәлекне биш гасыр буе бары тик дәгъвәт аша, женси якынлык кылуга харәм карап, милләтне ничек чиста саклый алганнар!... Ә без партком житәкчелегендә комсомол төзелешләре төзеп, нибары егерме елда чыгалмаслык нәжескә баттык!..

Алар авылга керделәр. Сихәт-сылу аны тау ягыннан алып китте. Еракта шәйләнгән урман өстенә оялаган сирәк, әмма кабарынкы болытларның чит-читләрен ялкында эретеп агыза-агыза, Кояш офыкка якынлаша иде. Офыкның уң як яртысы ялкында, сул ягы исә әле бу ялкыннарга кереп кенә килә. Иркен-аганың туган авылының һәр сызатын беркайчан да онытылмаслык итеп энә күзеннән үткәрергә тырышты.

—Әнә безнең йорт,—диде Сихәт-сылу алга таба күрсәтеп.—Монысы безнең бәрәнге бакчабызның очы...

Сихәт-сылуның йөзе кайнар илһам белән яна-ялкынлана иде.

Алар тыкрыктан янгырдан сон кипшенгән урамга чыктылар һәм чокырларга төшеп китүдән куркып, коймаларга ешына-ешына килделәр дә ихатага үттеләр...

Шәйхенур-кардәш ихатада да, өйдә дә күренмәде. Иркен ага арыган

иде. Ул Сихәт-сылу салып биргән урын өстенә ауды. Сызлый башлаган аягын урындык артына куйды. Шулай йоклап та киткән. Күзен ачса—тышта карангыланырга чамалый икән. Бер сәгать чамасы изелеп йоклап алган ләбаса. Монысы яхшы. Ул алгы якка чыкты. Беркем дә юктыр. Сихәт сылу да. Болдырга чыгып басты. Арба тора, ләкин аты күренми. Иркен ага нәрсәнедер исенә төшерергә азапланды. Ул йокы аралаш кемнендер ат тоякларын дөпелдәтеп чыгып чапканын төшендә кебек кенә хәтерләде. Сихәт-сылу үзе булмадымы? Бая Рәгыйбь-кардәшне озатып кайтканда «Төнгә каршы Биарысланнарны үзем дә эзләргә чыгам»,—дигән иде бит. Бик чая, бик булган хатын күренә. Абзар кырыендагы җәйге алачыктан кемнендер шабырдатып сыер сауганы ишетелә. Иркен-ага песи кебек тавышсыз-тынсыз гына сөт ташкыны чыгарган музыкага таба китте. Юк, анда чәчәкле яулыгын күзенә кадәр төшереп бәйләп, кечкенә урындыкка утырып, Тәрбия ханым сава икән ала сыерны.

Чиләккә дезелдәп бәрелгән сөтнең сабый чактан жанга якын моңын үзе белән өстерәп, Иркен ага урамга чыкты. Кеше-кара күренми. Офыктан кояшның канлы кызарып баеган түбәтәе менә-менә төшеп китәрдәй булып күренә. Түбәтәй тирәсенә шундый ук канлы-кызыл болытларның ертык утраулары килеп тыгылган. Урам яшеллеккә дә, җиләк-җимеш бакчаларына да бай түгел икән. Йортлар сирәк куаклар, биек булып үскән эре кыяклы чүп үләннәре арасында утыралар. Бер тавыш-тын юк. Урамнан үтүче-сүтүче техника да, адәм заты да күренми. Әгәр кайдадыр сирәк-саяк өреп куйган эт, эндәшкән аһән, ябылган ишек авазлары ишетелгәләмәсә, авылны бөтенләй үлгән дип тә уйларга мөмкин булыр иде.

Иркен аганың кичектергесез рәвештә Сәлахиләрнең нәсел тамырын эзли башлыйсы килде. Ә нишләп тора ул, нигә һаман тотынмый? Алтмыш ел хыялланган хыялы тормышка ашты—ул, ниһаять, ата-бабаларының туган җиренә кайта алды... Әмма багана кебек баскан да, «Бохар ялкавы» кебек, кулларын кушырып, нишләргә белми тора. Синме бу, Иркен? Аларныкыннан биш-алты йорт аша урамның сул ягындагы йортта ут алдылар. Үзләре ягындагы йортның капкасы төбендә ниндидер шәүлә күзгә чалынды. Каршыдан төшкән ут яктысында бу шәүлә ниндидер елтыр кабырчыклар белән ялт-йолт килә. «Бәлки Сәлахиләрнең тамыр очын ул башлап ачар?»

Мөһәҗир, куерып килгән карангыда таягы белән юл саба-саба, шул шәүләгә таба китте. Башына елтыр калай әтәчле фуражка, өстенә мундир, мундиры ниндидер якты калайлар, орден-медальләр белән чуарланган карт үзенә якынаеп килүчегә әлләни игътибар бирмәде.

—Әссәламәгаләйкем, кардәшем!..—Иркен ага аңа мөселманча ике кулын сузды.

—Никакуй салам. Пинсә көтәм,—диде чос карт аның кул сәламен бөтенләй ишетмәгәндәй итеп.—Көндез китермәделәр, бәлки төнлә китерерләр, әднә сбалата!..Менә алар өчен канынны кой!..

—Минем атым Иркен...—диде мөһәҗир мондый илтифатсызлыктан соң сүзен ничек башларга белмичә.—Ә сез кем буласыз? Атыңыз кем?

—Атсыз мин. Виттыран. Нирвынный виттыран. Чирем дә шул нивыапаталуктан.

—Ә мин Әмрикәдән... Туганнарымны эзләп кайттым.

—Төн килденисә, без монда барыбыз да Әмрикәдән кайтабыз,—диде бу сәер зат.—Йә, әйт, ни йомыш?

Бөтенләй дә таныш булмаган бу кешегә килеп бәйләнгәненә үкенә башлаган Иркен-ага:

—Сезнең... Сәлахиләр шәҗәрәсе турында ишеткәнегез булмадымы?—дип сорады.

—Андый нәрсәне гүпчим дә ишеткәнем булмады. Нәрсә ул?

—Нәсел агачы. Нәсел тарихы...

—Нинди нәсел?—диде теге ыржаеп.—Нинди агач? Мин берәр сурьезный нәрсәдер дип торам тагын. Вак мәсьәлә бит бу. Нәсел, имеш. .. Нәсел—влачта!.. Нәсел—әрмиянең ныклыгында!.. Чичнәдә кан коела, ә монда... Әнә, Орлык Шәйхенурның ике оныгы, ике ел инде Чичнә сугышыннан качып ята... Эрәзве это не сбалата? Эрәзве әрмияне шулар таркатмый? Аһ, көчле бит безнең урыс әрмиясе... Әле генә теллебизырдан әйттеләр: Ижау забутында өрәкитә белән ата торган мәтәстикләр чыгарганнар. Менә шул мәтәстикл менә шушыннан бара...—Карт кулы белән чокыр-чакырлы урамга күрсәтте.—Һәм гөлт тә гөлт рәкитә ыргыта... Күрелгән хәлме бу!..Без Чахаславакайга кергәндә мәтәстикл гаскәрләрен бетергәннәр иде. Ялгышасыз дидем. Тынламадылар. Дөнья булгач, кирәк була ул!.. Сәмәлүтләр, танкылардан гына түгел, мәтәстиклдән кырачакбыз без тыррорисларны...Мәтәстиклдән генә уничтәжәйт итәчәкбез дошман сәмәлүтләрен, танкыларын!..

Сөйләшеп торуның мәгънәсе дә калмады кебек.

—Булсын иде миндә бер генә шундый өрәкитәле мәтәксикл, җаннарын кыяр идем мондагы тыррористларның!..

«Көнбатышта булса, Чехословакиягә басып керүдә катнашканы өчен гарьлегеннән моны теленә дә алмас иде. Ә биредә, үзе басып алынган милләт вәкиле, башкалар өчен башкларны басып алуы белән горурланып утыра. Ишәктән егылу аттан егылудан яманрак шул».

—Хәерле төн сезгә,—диде мөһаҗир.—Исән-аман булыгыз.

—Син дә Әмрикәгә киттенме?—диде теге.—Кара, сәгать тугызда первай каналдан главкомандыюший Ельцинның соңгы сайлануы алдыннан Чичнәдә үткәргән ваянпарадны кабат күрсәтәчәкләр. Ай-һай, шәп парад!..

Шундук артыннан кычкырып туктатты.

—Син... өйләнгән кешеме сон?

—Өйләнгән. Балаларым, оныкларым бар.

—Мин хәләстүк. Татарда юньле хатын бетте. Биш тапкыр өйләндем. Бишесенең дә исемнәре матур, үзләре юньсез булып чыкты...—Туктарга мәҗбүр булган Иркен ага караңгыда аның мырык-мырык килеп сөйләнүен генә тыңлады.—Беренчесе тукмач баса белмәде.Аердым. Зәлинә исемле иде. Икенчесе бала таба белде, карый белмәде, паллы. Исеме шәп иде—Мәлинә. Аердым. Өченчесе кер юа белми, атналар буе сасытып яткыра. Исеме матур иде. Әлинә. Аердым сволочьны. Дүртенчесе түлке тегене ярата, йокы бирми, тәмуг кисәве. Исеме матур Замира. Аердым мур кыргырыны. Бишенчесе, Рәлия, көн дә туган көнен үткәрде!.. Барысы да Сигезенче Март празднигы тәрбияләгән сбалата!..

Иркен-ага килгән сукмагыннан капшана-капшана көч-хәл белән кайтып керде.

Тәрбия-ханым савыт-сабалары белән бар ихатаны шалтыр-шолтыр китереп йөри иде.

—Анау... биш-алты йорт аша... нindirәк инсан ул?

—Чахаславак героемы? Безнең оныкларга бәйләнәме? Хромосом Сәйфетдинеч. Тире җыючы булып эшләде. Хәрби корал, әрәкитәләрне мактый-мактый, хатын-кызны хурлый-хурлый ычкынган шунда.

Бер капчык кәбәккә бер бөртек бодай сала да, болгата да болгата... Ваянпинсәсе гомер буе балта сайраткан Шәйхенурныкыннан биш тапкырга артык...

—Ничә яшьтә ул?

—Ничәдә икәнен белеп булмый. Сөян агачы кебек саргаеп каткан, яше билгесез. Әйдәгез, керик, чәй эчик!..

Алгы яктагы кәккүкле сәгать тугызны сукты.

—Кайтмадылармы?

—Юк.Бәлки иртәгә таң белән...

Алар яңа кайнаткан карлыган кайнатмасы белән чәй эчтеләр. Иртәнге вак бәлешне Иркен ага җылытмаска кушты. Ул бала чактан суынган бәлешмазарны кайнар чәй белән ашарга ярата. Ире өйдә булмаган мөселман хатыны белән озын-озак сөйләшеп утыруны әдәпсезлек санап, ул чәй өстәле артыннан торды һәм эчке якка үтте.

—Утны кабызыйк...—Тәрбия-ханым эчкә үтмичә генә кулын сузып электрны тоташтырды.—Ятарга булсагыз, урын-җир әзер...—Йокы бездә ифрат та тәмле ул... Телевизорны кабызыйммы?

—Кирәк имәс.

—Ярый алайса. Тыныч йокы сезгә.

*Ахыры киләсе санда*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



Фәрит
Яхин

# КҮКЕ ФАЛЫ

ХИКӘЯ

Ул елны авылга җәйнең иң матур вакытында, июньнең икенче яртысында ук кайтырга насыйп булды. Көннәр шундый да рәхәт һәм матур тора иде. Әле печәнгә төшәргә иртәрәк. Авыл кырларында, яшелчә бакчаларында эшләрнең беразга бетебрәк торган чоры. Халык тыныч ялда. Кичләрен урамның әле бер башында, әле икенче очында йә гармун-тальян моңы кузгала, яки берәр яшь йөрәк кычкыртып магнитофон-радио ишене ялгап куя. Җыр агыла, көй. Алар белән бергә сагыш яисә дәрт күңелгә йогып кала.

Дүсем авылы гаҗәеп матур таулары, тугай һәм чишмә-инешләре, әрәмәлек һәм яшел тирәкләре бишегендә көннең татлы имчәгеннән ләззәт имеп яши. Минзәлә инешенең аръягындагы, тауларга менеп киткән Ләшәүтамак авылының һәр селкенгән чиләге, киртә башына менгән әтәче, вакытсыз адашып аваз салган кәҗәсе-сарыгы, урамнарына болыннан муенчагын өзеп килеп менгән бозауларының мөгердәшүе, кешеләренең үзара вакытлы-вакытсыз аваз салып сөйләшүләре белән генә бу илаһи дөньяда да адәм балаларының, алар белән бергә терлек һәм кошларының, табак һәм савытларының яшәүләрен искә төшерә. Ә Дүсем, табигате аларныкы кебек шыр ялангач булмаганлыктан, күз рәхәтендә генә түгел, җан сәгадәтен дә табып, сабый бала сыман гамьсез хәлендә хәтта көндезләрен дә йоклыйдыр сыман. Монда аваз салып эндәшү түгел, кешеләр колактан узып исәнләшергә дә кыенсыналар. Гүяки шулай илаһи тынлыкны, сандугачларның тирәкләрдә шашынып сайравын, күкеләрнең шау агачларны тибрәтеп кычкыруларын бозасылары, шушы җәннәт кошларын куркытасылары килми.

—Нинди рәхәт вакытлар!—диде әнкәй.—Күкләрдән нигъмәт тама.

Ул шунда кечкенә, матур, йомшак учларын алга сузды. Менә аларга шул нигъмәттән бер орлык иңәр дә, әнкәй аны миңа бирер сыман иде. Ә аннары авызыма кабармын аны. Шундый да тәмле булыр!

Фәрит ЯХИН (1961)—*шагыйрь һәм прозаик; «Пәйгамбәребез Мөхәммәт», «Ак эбиләр догасы», һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Мин тугайга төшеп вак-төяк чыбык-чабыклар җыеп, учак тергезгән, шунда шашлык кыздырам дигән ниятемдә идем. Соңгы елларда бу рәвешле тәгамьләнү һәммә кешенең диярлек гадәтенә әверелеп китте. Шәһәрдән кунакка кайталар да, су буенда яки болында, учак ягып, табигать кочагында ит кыздырып, шуны капкалап, гаиләләре, туганнары, дуслары белән ял итә бездә халык. Башкалар шулай эшләгәч, минем әнкәй генә үз баласының ниятенә каршы килә димени инде! Өйдә мул ризыклы өстәл тулып, тәмам сыгылып торса да яшьләрнең табигать кочагын үз итүләрен хуплый иделәрме аналар? Әллә моны да ял итүнең бер шарты дип уйладылармы— белмим. Әмма татарда борынгыдан сәйранга чыгу дигән гадәт булган. Минем дә учагым шул сәйранга чыгудан безнең көннәргәчә килеп җиткән яки соңгы елларда гына яңара башлаган җирсү идеме—әйтә алмыйм. Тәгаен генә шуны беләм: тугайда учак ягып, ит кыздырып ял итү шундый да рәхәт һәм күңелле.

Уңымда-сулымда өзелеп-өзелеп сандугачлар сайрый, арырак кәккүк кычкыра. Аны икенчесенең авазлары алыштыра. Артта әлеге дә баягы тауга менеп баручы иләмсез Ләшәүтамак авылы, онытылып китеп, үз тормышы белән шаулаша, түрдә, Минзәлә инешенең бу ягындагы минем Дүсем авылында, кемдер тагын тальян моңы белән җыр суза, балаларым, хатыным, тугайдан болынга күтәрелеп, чәчәкләр җыеп йөри. Дөньям—түгәрәк, оям—җылы, бәхетле. Күкеләр тына белми күкелдиләр, гүяки нәрсәне булса да миннән санаттырасылары килә. Мәсәлән, кесәдәге акчамны, киләсе-китәсе байлыкларны, гомерне, әйеме?

Берүк «әйе» дип килешә күрмәгез, кесәсендәге акчаны беркем дә күкедән санатмый. Ә менә алда булачак гомерне? Анысын беләсең килсә, күкедән сорау фалы бар халыкта. Әллә соң тәвәккәлләргәме? Юкка кычкырганчы, санасын әйдә! Әнә бит, туктаганнары юк, берсен икенчесе алыштырып кына торалар: «Кәк-кү, кәк-күк, кәк-кү!» Сорыймммы әллә?

Юк! Сорамыйм! Ходай күпме биргән, шул инде безгә. Анысын да күкедән санатып торырга димени? Аннары, каян белсен ди ул? Күке—фәрештә түгел. Аллаһының Тәкъдирләр китабын укый алмый һәм бөтенләй укый да белми!

Шунда исемә төште: убыр, шайтан ялчысы, урманда «кәк-кү» дип кычкыра-кычкыра, кешеләрне үз артыннан ияртеп китеп адаштыра икән, имеш.

Бервакыт, шулай урман буенда кызлар, күз йомышлы уйнаганда, күзе бәйләнелгәннән кача биреп: «мин монда, кәк-кү», «мин монда, кәк-кү» дип, шарт куешканча аваз салалар икән. Аларны шайтан тыңлап торган да, убырны күкегә әверелдереп очырган. Кызлар, кечкенә энгердә, иптәшебез чакыра дип, аның артыннан китеп адашканнар.

Шушы риваять күңелемдә хатирә рәвешенә кереп яңарды да үз хәлемнән үзем көлеп куйдым. Хорафәт бит бу! Күкенең кемгә күпме гомер калганлыгын шайтаннан белешеп торуы турында сөйләүләре дә әкият кенә! Андый имеш-мимешләргә ышанырга монда—юләр түгелдермен лә!

Ә күке туктый белми һаман күкелди. Аның тавышы җанны иркәли, ымсындыра, күңелгә рәхәтлек бирә:

—Кәк-кү, кәк-кү, кәк-күк!..

Күкләр-җирләр, чишмәләр, таулар гүяки күке тавышы белән үзара сөйләшә. Сандугачлар, башка төрле кошлар тал-тирәкләрдән, җимешләнә барган бакчалардан үз моңнары белән аларга оркестр ясап кушыла. Тальянга гармуннар, баяннар ияргәләп ала, радио һәм магнитафоннар да кимен куймый. Дөнья эче бәйрәм белән тулы. Бер күкегә икенчесе кушыла. Әмма болар нинди дер тәртипсез шаулашу түгел, табигый бер симфония сыман

тоела. Мин учак янында тәэссоратта утырам, тынлыйм, тынлыйм, тынлыйм. Тагын кайчан ишетермен дим. Мондый матур вакытлар кабатланачакмы?

Кабатланыр әле, кабатланыр... Бу минем туган җирем, туган авылым. Әнә балаларым болында чәчәк җыеп уйнап йөри. Хатыным да аларга ияргән, ул аларга нидер аңлата, сорауларына җавап бирә, табигатьне танырга, яратырга өйрәтә. Әнкәй, кулына яшел кузгалаклар тотып, учагыма таба килә. Аның бу яшендә дә сакланып калган затлы сыны, зирәклек чалымнары күнелемдә мәңге картаймас төс-кыяфәтләре белән берлектә гүзәл сурәтен яңарталар.

Әнкәй, тукталып, үләннәр арасыннан тагын да кузгалак кыякларын өзеп ала, кайсыберләрен татып та карый. Җылы, рәхәт. Дөньялык, шундый ямьле вакытың бу синең!

Минем әнкәй кап-кара озын чәчле чибәр кеше. Бервакытта да тормыштан зарланганы булмады. Ятим бала булып, үги ана кулында үскән, Бөек Ватан сугышы елларында, уналты яшеннән «Бакыртау колхозы»нда бригадир булган. Гомере буе җәйләрен кырда, кышларын фермада эшләде. Пенсиягә чыккач та аны эшсез тотмадылар, сөт җыючы да, идарәдә җыештыручы да ул булды. «Атказанган колхозчы» исеме бар иде, алты бала анасы. Җитмеш яшенә җиткәч кенә, кешедән оялам дип, үзен колхоз эшеннән биздерде, әмма йорт эчендә барча йөкне, кош-корт, мал-туар карауларга кадәр үзе алып бара иде. Сыеры, бозаулары, сарыклары, тавыклары, казлары, үрдәкләре абзар-кураларда тулып торды. Бер эшен дә кешедән эшләтмәде. Бакчасын да карый, ашларны да оста пешерә иде. Кайберәүләр сәнәк, көрәк ишедән курка торган булалар. Алар бит бары тик эш кораллары гына югыйсә. Шулай да, боларны кулына алсаң, эшләргә туры килә. Әнкәй исә бер генә төрле эш коралын да тыныч кына яткыра белмәде, һаман да ике кулы эшкә ятып торды. Озын төннәрне йон эрләп, балаларына, ишле оныкларына оекбашлар, бияләйләр бәйләп өлгертә, тунмасыннар дип илтеп тә бирә яки кеше аша да, күчтәнәчләре янына куеп, барчабызга бердәй җибәрә иде. Әле һаман да кышкы салкыннарда мин аларны киеп йөрим. Аякларым-кулларым җылыда рәхәтләнә.

Әнкәйгә быел җитмеш биш яшь тулды. Инде күптән чәче дә ак. Намаз белән гамәлдә даими. Һаман да эштә үзе. Әйтәм бит, күнелемдә сакланган яшь вакыттагы төсләре белән кушылып, аның сурәте миндә һаман да кырыктадыр дигән тойгы уята. Әмма үзем дә (әнкәй мине утыз бишендә тапкан) иллегә таба көннәремне санап баруга күчтем түгелме соң? Эшемдә дә авыр күтәрәсе түгел югыйсә, шулай да ял итәргә ятам. Ә әнкәй? Ул инде, без кайтасын алдан белешеп, бәрәңге бакчасының чүпләрен утап, гөл итеп куйган, терлек абзарлары да тәртиптә, тиресләре түгелгән, мал-туары да, үзе әйтмешли, «күвәшнә кебек». (Мөгаен бу сүз русның «квашня»сыннан татарчага авыштырып ясалгандыр? Үз кемлегенне кеше сүзе белән үлчәү— безнең халыкка хас сыйфат инде ул анысы.)

Замандашлары кебек үк әнкәй дә, тормышның ачысын-төчесен күп татыганлыктан, юк-барга бирелеп тормый иде. Ә ил тагын буталып китте. Шушы туксанынчы еллар аны—колхоз төзегән, шул колхозны үз җилкәсендә күтәреп барып баеткан кешене кызганмады, тагын бер тиен акчасыз һәм алган исемнәресез, ирешкән уңышларысыз калдырды. Терәге, барлыгы—үз ихатасы, асраган маллары, бакчасы, бүгенге тырыш хезмәте генә калды. Ярый әле аларына кул озайтучылар табылмады. Ояддылар. Безнең—балаларының да кулыннан әллә зурлык килмәде, ана ярдәм итә алмыйбыз. Гаиләләребез бар, имеш. Оныкларын аякка бастырырга кирәк. Их, шул кирәк дигән нәрсә—безне үзенә кол итә дә куя! Нишлисең, ул туксанынчы еллар барчабызны да тормыш диңгезенең салкын мохтаҗлык

утрауларына—ялангач кыялары арасына чыгарып ташлады. Әнкәйнен «илем» дип, «бәхетле җәмгыять төзүдә алдынгы булырлар» дип үстергән балалары, башка меңнәр һәм миллионнар кебек үк, яна заманга, «нуворишлар» иленә кирәксез һәм яраксыз иделәр. Дөрес, без дә ул хәлебез белән килешергә теләмәдек. Әмма үлгән социализмны да кабат кайтарып тергезү уебызда юк. Киләчәктә булачак нәрсәгәдер ышанабыз һәм өметләнәбез.

Безнекеләрне коммунистлар таламаганнар да бугай. Әткәм ягыннан бабам илгә дүрт тегермәнен, атларын, сыерларын, болыннарын, урманнарын һәм кыр-басуларын, башка төрле байлыклары белән биргә, «үз теләге» белән «бүләк иткән». Әнә «раскулаченный»ларга монын өчен компенсация түләде хәзерге хөкүмәт. Безнекеләргә ул да юк икән. Таланмаганнар. Бакыр бабам дәүләт судьясы, түрә хезмәтендә торган, ә Зат бабам исә Кызыл армиядә Фрунзе дивизиясендә сугышып, яраланып кайтып, гаиләсен барча байлыкларыннан котылдырып һәм азат итеп, савыга алмыйча вафат киткән. Әбкәм ай-яй гаярь кеше иде. Азнакай ягыннан мирза кызы, бай нәселдән диләр иде аны. Кулындагы балдак, йөзек, беләзекләрен сугыш елларында да, чабата киеп Чаллы элеваторына икмәк ташыганында да, урак урганында да, сабан сөргәнендә дә салмаган диләр иде.

Хәер, әнкәй ягыннан бабамнар кулаклардан исәпләнгәннәр. Борынгы бабам Арыслангәрәй патшада хезмәт иткән, күкрәк тулы медальләр белән кайткан. Ә әнкәйнең әтисен, колхозга кермәгәне өчен хөкем итеп, төрмәгә ябып куйганнар, шунда шактый череткәннән соң, туры сугыш авызына җибәргәннәр. Эченә каты яраланып кайткан да, озак тормый үлеп тә киткән.

Әнкәй боларны сөйли торган иде. Гыйбрәт булсын дигәндер инде. Әмма илне дә, аның җитәкчеләрен дә каһәрләмәде. Колхоз байлыгын, элеккеге коммунист рәисебезнең улы килеп, тәмам талап бетереп китте. Әйе, ул да рәис иде. Әмма булдыручы түгел, юк итәр һәм үзенә бар байлыкны убыр кебек йотар өчен килгән иде ул. Халык аның кылануларын күреп торды. Тимәде, сүз әйтмәде. Ә ул колхозның машина-трактор паркындагы һәммә ни бар, шуны өч кешесе белән актлап «списать» итте дә, ике ел буе көн дә тонналап-тонналап ташытып металлолломга тапшырды. Шунын керемена «КамАЗ»лар алды, башкача та кыландырды. Колхозчылар үзләренә һични дәгъва итмәделәр. Ул аларны хезмәт хакы түләми генә ун еллап үзенә эшләтте, фермадагы мал-туарны төрле хәйләле юллар белән шәһәрдәге ит кибетләренә озатып бетерде. Хәер, бер бездә генә түгел, ил эчендә бар җирдә шул хәл иде. Алар, өстәгеләр, халыкны, «базарга ашыгып кермәскә өндәп» тыя килделәр, ә үзләре, чарасызларга хас беркатлылыктан файдаланып, хәсрәтсез генә талый бирделәр. Менә шулай эшләнә икән ул гаделсезлек, менә шундый була икән ул кабәхәтлек.

Хәер, мин дә бит байларча ит кыздырып утырам. Әнкәй безнең кайтуыбызга атап сарык суйдырган. Ул кунак итәргә ярата, беләм. Мондый сыйлар үзенә тансыграк югыйсә.

Кулындагы болын кузгалакларын кечкенә аш өстәленә китереп куеп, аннары кире уйлап, табын итәргә дип җәелгән ашъяулыктагы ризыклар янына күчерде:

—Тансыкка... Авыз тәменә булыр, улым!—диде әнкәй, үлән өстенә ян беләнрәк, татар хатыннарынча җайлап утырып.

Ул күп сөйләшүне, аңлатып торуны яратмый иде. Гайбәтне сөймәде. Гади һәм гадәти төзек җөмләләр арасына «менә ничек», «шулай инде», «алай да була икән» кебек бәяләмәләрен кушып җибәрә дә, бәхәскә урын калдырмый.

Менә әткәм, мәрхүм, бөтенләй дә дөньяны ак белән кара итеп кенә

күрәдер сыман тоела иде. Әнкәй, аның белән киңәшкәндә, «дөрес эшләгәнсең» дигән сүзен ишетеп куана һәм, шушы сөйләшү дәртендә калып, бөтен эч серләрен чишеп ташлый. Башкача була да алмый, чөнки әткәй тыңлый белгән. Сүз үлчәмен һаман да тигез тоткан. «Кирәкмәс иде» дисә, әнкәй үзенең хаклыгына дәлилләр табарга тотына.

Аларның андый «киңәш мәҗлесләрен» корулары кызыклы була иде. Бала чагымда шул сөйләшүләренә еш колак тоттым. Әнкәй сөйли. Әткәй сүз үлчәвен җайлый бирә. Һәм менә, әле генә «дөрес эшләгәнсең» дип кат-кат өстәп килгән җиреннән, «кирәкмәс иде», ди. Әнкәй аптырашлы уйларда кала. Аннары, аңлатып бирүен таләп итмичә, «алай икән» дип әйтеп куя.

Гадәттә аларның «киңәш мәҗлесләре» кичен уздырыла. Кайбер көннәрдә әнкәй бик озаклап уйлана. Әмма ике кулы да эштә: әле табак-савытларны юа, әле икмәккә камыр изә, әле аш пешерә. Ә һаман әткәйнең «кирәкмәс иде» дигән «сүз казыгыннан» уза алмый интегә. Моның башкача түгеллеген мин дә беләм, чөнки әнкәй әле һаман уйлана, вакыйгаларны үз күңеле аша кабат җилгәреп, әткәй «корган үлчәүгә салып», вакыт-вакыт тагын да «алай икән» дип әйтеп куя. Бу аның «ике-икең дүрт була» кебек килеп чыга. Әткәй газеталар укый, мин журналлар караштырам.

Нәрсәләр турында сөйләшүләре инде онытылып беткән, әмма «күп сүз—баш казыгы» дигәннәре хәтердә калган. Ә без мәктәптә телләребез арып беткәнче дәрес сөйлибез... Бары тик математикада гына рәхәт, мәсьәлә һәм мисалларны чишәсең дә чишәсең. Аның әле әллә ниткән «язма сөйләм» дигән нәрсәсен дә уйлап чыгарганнар. Сөйләнә-сөйләнә язумы икән инде ул? Әнкәйгә ата-аналар җыелышыннан әйтеп кайтарганнар: имеш, миндә телдән сөйләү юк дәрәҗәсендә, ә менә язма сөйләмем шәп икән! Моның нәрсә аңлатканын миннән сораганнар иде, аптырап калмадым:

—Белмим, әлегә алай да, болай да эшләп караганым булмады, укытучыбыз бутагандыр,—дидем.—Бездә теге Сарайлы кызы гына теленә салына-салына яза!

Ул вакытта бу мәсьәлә ачык калды, хәзер инде ул «язма сөйләм» дигәннәренең ни-нәрсә икәнлеген беләм: сүз эчтәлекле итеп яза белү хакында барган икән!..

Ә менә күке кычкыра да кычкыра. Бер дә туктый белми. Табигатьнең хозурлыгы артканнан-арта тора. Кошлар сайравы, күкеләр кычкыруы бу дөньялыкны нindидер могҗиза урыныдыр сыман итеп тоярга мәҗбүрили. Рәхәт! Бик рәхәт! Ул һавасы, ул табигате, ул көне! Ипекәйгә бу хозурлыкның үзен май итеп ягып ашарлык инде, билләһи! Ә черкиләр?

Ә черкиләр әлегә чыкмаган. Алар кечкенә дым белән бергә үлән-кыяк арасыннан күтәрелә. Кояшның икендедән узып барыр вакыты гына әле. Гүяки күңелләрне дә назларга теләгәндәй йомшарып, ефәк иркә җил йөгереп уза. Учакның күзләренә җан керә. Мин аның янында кулыма кисәү агачы итеп таяк тоткан хәлемдә утырам. Шашлык исе болынга тарала. Нигъмәт тәме хәтта күкеләргә дә тынгылык бирмидер сыман. Әнкәй хәйран хәлендә аны тыңлый икән.

—Йә әле, кәккүк, санап күрсәт, минем күпме яшисем калды?—дип сорады ул шунда.

Моны ишеткәч, йөрәгем жу итеп куйды. Әнкәйгә борчулы күзләремне күтәреп карадым. Ә йөрәк һаман сикерә.

—Әнкәй, нигә алай әйттең инде?

Әмма күкенең ничәне санавын мин дә көттем. Әле яна гына берсен-берсе уздырырга теләгән кошлар да курыктылар бугай, тынып калган төсле иделәр. Авыр җиләс җил дә, каяндыр килеп җитеп, учагымның төтенен бөтереп алып очты. Хатыным, балаларым болында чәчәкләр арасында

иде әлегә. Алар да нигәдер шомландымы, бирегә таба килә башладылар. Шунда күке:

—Кәк-күк, кәк-күк, кәк-күк!—дип аваз салды. Әле тагын, тагын, тагын кычкырыр сыман иде югыйсә. Әмма тынып калды. Моңа мин риза түгел идем.

—Бик аз булды бит,—диде шунда әнкәй, елмаеп,—тагын кычкырырга иден: «кү-кү, кү-кү!»

Кабат авыр җил исеп куйды. Монысы миңа җан өшеткеч булып тоелды. Күкеләр инде тәмам тынып калды. Тик бераздан соң гына, иренеп, берән-сәрәнләп тавыш биргәләп алдылар. Әмма болары өтек аваз гына иде инде. Минем өчен аларның яме бетте.

—Яшәгән кешегә өч көне дә бик озын әле аның!—диде әнкәй. Ул бу вакытта еракка, офык читенә карап басып тора иде. Өстендәге яшел җирлекле вак сары чәчәкле күлмәген җил сыпыра, ак яулыгына ягыла, гүяки юатырга тели.

—Аллаһы Тәгаләнең серләрен ул мәхлук кошлар каян белсеннәр, әнкәй?—дидем. Ә күңелдә күкегә үпкә иде.—Әгәр кәккүкнеке хак икән, бөтен хәбәрләрне аңардан гына алыр идек. Алар хәтта фәрештәләр дә түгел! Хорафи шул, хорафи гадәт кенә!

—Мин дә шулай дип әйтәм!..

Әмма әнкәйнең йөзендә авыр борчылу билгеләре инде пәйда булырга өлгергән иде. Әле генә җәннәт бакчасы кебек тоелган дөньялык кабат караңгыланып киткәндәй сизелде. Җитмәсә кискен-кискен җилләр тагын-тагын да искәләп, болын чәчәкләрен ачу белән өзгәләп йөри башлады.

Офык читенә күтәрелеп карадым. Анда яңгыр болыты куерганнан-куера икән шул. Юлларда да тузан күтәрелде, аяз күкне жемелдәтеп яшен камчысы уйнап алды. Болытлар ашкынып агып килергә тотынды.

Иркенләп хәстәрләгән бәйрәм табыныбызны җыеп алырга туры килде. Хәер, шашлыкның тәме киткән иде инде. Чак өлгереп калдык, илне суга тутырып яңгыр яварга тотынды. Ярты сәгать эчендә булган табигатьтәге бу үзгәреш һәммәбезне хәйран итте. Кичке якта, яңгыр белән килеп, салкын һава инде. Без инде җылы өйдән чыкмаска булдык. Ә икенче көнне Казанга ашыгып китеп бардык. Салкын һава, салкын утлы яңгыр хәвефе күке вакыйгасын онытырган сыман иде.

Өч ел бик тиз үтеп китте.

Аяк өсте гамәлдә йөгереп йөргән әнкәбез көтмәгәндә түшәккә егылды. Вакыйга ураза гаетеннән соң булды. Ул хәбәрне ишетү белән авылга ашыктык. Әнкәйдә «кара чир» авыруы пәйда булыр дип башыбызга китергән идекмени без? Мөмкин түгел!

Әмма... Әмма тәкъдирдән узмыш юктыр ла ул!

Күкенең санавы хакыйкать түгел, очраклы хәл генә булгандырмы, белмим? Аның тавышын ишетүгә хәзер дә, май көннәрендә үк, кинәт шомланып калу гадәтемә керде, ахрысы.



Гәрәй
Рәхим

# АЛМА БАКЧАСЫНДА УЙЛАНУ

## Бер җылы өн

**Юк, тормыштан бөек булып булмый,**
**Без—тормышның бары коллары.**
**Бер җылы өн—туган халкыбыз бар!**
**Без бит аның тугъры уллары.**

## Догалы еллар

*Марсель Галиевкә, шул исемдәге китабы уңаеннан*

**Үткәннәргә кире кайтып булмый...**
**Шлагбаумнарда ул юллар.**
**Шулар аша безгә үрелеп карый**
**Догалы еллар.**

**Узганнарны уйлап җаннар сыкрый,**
**Вакыт—патша җирдә, без—коллар.**
**Кайтарыгыз мине яшьлегемә,**
**Догалы еллар!..**

**Әмма безгә гомер биргән өчен,**
**Биргән өчен, онык, кыз, уллар—**
**Һәрбер нәсел саен рәхмәт сезгә,**
**Догалы еллар!**

Гәрәй РӘХИМ (1941)—*шагыйрь, прозаик, публицист; татар, башкорт, рус телләрендә дөнья күргән егермедән артык китап («Вәгъдә», «Зирекләрнең кара бөдрәләре», «Сайланма әсәрләр» (ике томда) һ. б.) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Алда тагын ниләр күрербез без,
Язмыш безне ничек боргалар?..
Күрәчәкләребез сезнең кулда,
Догалы еллар...

Кеше гомере бигрәк нәзберек шул:
«Кыймылдыймы йөрәк... кан... куллар?..»
Тып-тын гына агып ята гомер,
Кеше гомере—догалы еллар...

## Галәми зат

«Әйдә, яула бу дөньяны!»[1]
Дөнья синнән калмасын.
Син аласы офыкларны
Башка берәү алмасын.

Күк Тәңребез кемнәрнең кем
Икәнен анык белгән.
Көч-куәтне, акыл-аңны
Лаеклы, гадел бүлгән.

Синең бездән аерманң шул—
(Моны әйтү бик зарур)—
Безнең өчен—дөнья бик зур,
Дөнья өчен—син бик зур!

Дөньяви зат кына түгел,
Галәми зат булдың син.
Яшәешнең иң-иң пешкән,
Алма кебек мәмрәп төшкән
Мизгелендә тудың син.

Әйдә, яула бу дөньяны
Чат саен када әләм.
Йолдызлар, мең еллар аша
Күз кыса сиңа Галәм,

Чакыра сине Галәм.

## Чарльз Дарвинга ачык хат

Дарвин әфәнде!
Кешене
Маймыл дәвамы диеп,
Бик зур ялгыш ясавыңны
Искәртәм, башым иеп...

Үзгәрде, бик нык үзгәрде
Бүген бездә дөньялар.
Җир шарын кулга алды бит
Маймыллар –
Бары алар...

Кеше дигән приматлар
Инде тарихта калды.
Синең фәнни хезмәтләрне
Заман үзенчә язды:

«Тора-бара Кеше заты
Маймыл сурәтен алган.
Кеше маймылдан чыкмаган –
Маймыл бездән яралган...»

Кичерә күр, и, Аллам!..

[1] Атаклы гаскәр башы Мүкәлинең Чыңгыз ханга киңәше.(Әренҗан Карадауанның «Чыңгыз хан»дигән китабыннан.

* * *

*(Ялган шигырь)*

**Чуртыма кирәкме яшьлек?!.**
**Картлык матур бит, дуслар.**
**Яшьлегем—черек бәрәңге...**
**Хәзер ашыйм цитруслар!..**

**Яшьли кызлар бүлешкәндә**
**Киң дөньялар тар иде –**
**Көнләшүдән бүртенешеп**
**Йөргән чаклар бар иде.**

**Хәзер күңел шундый тыныч,**
**Янмый да, талкынмый да.**
**Кызлар хәзер кояш булып,**
**Ай булып балкымый да.**

**Тормыш шундый рәхәт,тыныч,**
**Йокла да, аша гына...**
**Зур җиһанга карыйсың син**
**Тик бармак аша гына.**

**Чуртыма кирәкме яшьлек**
**Янып-көеп йөрергә?!!**
**Бер-береңә юл бирмичә**
**Этләр булып өрергә?!.**

**Дөньяның бар мәшәкатен**
**Салып иңгә,җилкәгә,**
**Вакыт тапма бер җылы сүз**
**Әйтү өчен иркәңә.**

**Хәзер бер дә мәшәкать юк,**
**Пенсия үзе килә.**
**Карчыкка татлы сүзләрем**
**Конвейрдай түгелә.**

**Буш вакыт муеннан ашкан...**
**Озак алам тәһарәт.**
**Юк, кирәкми миңа яшьлек,**
**Картлыгым ай-һай рәхәт!..**

**...Ялганым—сиңа рәхмәт...**

* * *

*Алма бакчасында уйлану*

**Мәхәббәтне инде онытырга**
**Вакыт җитә бугай миңа да.**
**Җитди уйлар белән яныйм,димен,**
**Җитмеш яшькә киткән мин—бала...**

**Бу дөньядан тегесенә кадәр**
**Ара инде ерак калмаган.**
**Ашап туймаганны ялап туймас –**
**Комсыз күңел, тыел, ялманма,**
**Гомер алда диеп алданма!..**

**Оныкларың туенда да һаман**
**Үз туеңдай тоеп утырма.**
**Малай булма, бабай була белче,**
**Котырмачы, күңел, котырма!..**

**Исән чакта мираснамәңне яз,**
**Оныкларга тәти сатып ал,**
**Кәфен-мазар хәстәрләүне уйла,**
**Җәсәдеңә урын алып кал.**

**Ә мәхәббәт калыр синнән соң да,**
**Аңа гына варис табылыр.**
**Синнән калган сөю очкынынннан**
**Яшь йөрәкләр дөрләп кабыныр...**

**... Бу дөньядан тегесенә кадәр**
**Ара инде ерак калмаган...**
**...Мин бакчага чыгам...**
**Каһәр Хәүва**
**Авыз итә әнә алмадан.**

* * *

*Бер мутланып алу*

Күзем каты минем –
Бер карасам,
Шундук гашыйк була хатыннар.
Күзем каты,
Кайнар карашымнан
Ургып тора утлар-ялкыннар...

Күзем йомшак минем –
Бер карасам,
Гашыйк булам һәрбер хатынга,
Күзем йомшак,
Язгы ак кар кебек
Җебеп төшәм алар каршында.

Күзем каты... Күзем йомшак минем...

## Шәрә кендекле кызга

Авылда бик тыйнак иде,
Оялчан, сабыр, кызмый...
Шәһәргә килгәч нишләдең,
Шәрә кендекле кызый?!.

Сыерлар күз аларткандай
Абзарга элгән тозга,
Егетләр карап китәләр
Шәрә кендекле кызга.

Яшә генә идең дә бит
Халкың әхлагын бозмый...
Урам тулы татар кызы –
Шәрә кендекле кызый...

Авылга кайтканда, зинһар,
Күлмәгең булсын озын.
Юкса әткәң тотып ярыр
Шәрә кендекле кызын.

Зөлфәт
Хәким

# ЛЕГИОНЕР

РОМАН

## 24

1954 нче елның көзе дөньяны алтын төсләргә манып маташкан көннәрнең берсендә Розаның атасы Куйбышев каласында ярым яшертен рәвештә дин хезмәтен алып баручы бер мулла картны тапты һәм шундук көнен билгеләделәр дә, күп тә үтми, никах укыттылар. Нәгыйм белән Әминәне шул кадәре ерак арага МТСтан машина сорап Сәет алып килде. Шулай итеп, Яббар һәм Роза ир белән хатын булдылар.

Розаның ата-анасы, туганнары Яббарның үз-үзенә бикләнү сәерлеген беренче көннәрдән үк абайладылар. Розаның күңелендә бер хыял бар иде—ир белән хатын булып яши башлагач, Яббарның легионнарда булганын, изменник дип мөһер сугылуын ата-анасы һәм туган-тумачасы кешеләрчә аңлап кабул итәрләр, аның язмышының ул ягына күз йомарлар дип өметләнгән иде. Ул уйлаганча булып чыкмады шул.

Розаның туганнан туган абыйсы—кызу холыклы ир-егет, сугыш ветераны Кызылъярга килеп Яббар турында белешеп кайтты. Шуннан соң Розаның ата-анасы, туганнары Кызылъярга беркайчан да аяк басмаска карар кылдылар һәм тормыш иптәшен дөрес сайламаганы өчен Розаны мөмкин саен чукырга тотындылар.

Шулай итеп, Роза белән Яббар бергәләп Куйбышевка да, Кызылъярга да кайтмас булдылар. Роза туып-үскән каласына ял вакытларында ялгызы гына кайткалады. Яббар исә, әнкәсен бик сагынгач, берүзе генә туган авылыннан әйләнеп килү җаен эзләде.

Алар бит бер-берсен яратып өйләнештеләр. Яббар үзе кичергәннәрне, башына төшкәннәрне тәфсилләп сөйләде аңа. Әнкәсенә сөйләмәгән кайбер нәрсәләрне дә сөйләде ул хатынына. Роза өчен исә Яббар легионер да түгел, җинаятьче дә түгел, ә нечкә күңелле, фаҗигагә дучар булган бер кеше иде. Гаилә тормышы аның күңел җәрәхәтләрен савыктырыр, тулы канлы тормыш белән яшәп киләчәккә атларга яна куәт өстәр дип уйлады. Алар чынлап та әйбәт кенә тормыш корып җибәрделәр кебек. Ләкин Розаның ата-анасы, туган-тумачасы Яббарга карата шикле һәм кырыс мөгамаләдә булгач, яшь гаиләдә тотрыклык какшады шикелле. Роза да отыры капма-каршылыклы уйлар белән бимазалана башлады.

*Ахыры. Башы 9, 10нчы саннарда.*

Ләкин алда икесен дә зур вакыйга көтә иде. Икеле-микеле уйлар кинәт юкка чыктылар, бернигә һәм беркемгә карамыйча, тормышны корырга, гаиләдә бәхетле иминлек урнаштырырга кирәк дигән эчке карар белән алар житәкләшеп алга, киләчәккә атладылар.

... Бала туудан да әһәмиятлерәк вакыйга булырга мөмкинме икән ир белән хатын өчен?! Тупырдап торган, Яббарга коеп куйган кебек охшаган малайга алар Вәсим дип исем кушалар һәм бала туу шатлыгы белән дәртләнеп яши башлыйлар.

Беркөнне Яббар үзенең нәчәлнигеннән жан өшеткеч хәбәр ишетә. Яббар туып-үскән төбәкләрне һичшиксез су басачак дигән имеш-мимешләр озакламый гамәлгә ашачак икән. Нәчәлник махсус карталарны да күргән—су астында калачак территорияләр күптән билгеләнгән, Кызылъяр авылы урнашкан тирәләрне су йотачагы инде мәгълүм ди.

Беренче агрегат худка жибәрелгән вакытта ук инде сусаклагыч якын тирәдәге авылларны, кырларны үзе астында калдырды. Әле сунын биеклеге тагы да ныграк күтәреләчәк, сусаклагычнын мәйданы Идел буйлап өскә үрмәләячәк бит.

Яббар үзенә урын тапмады. Дөрес, Роза аңа бу хакта бик артык уйламаска кушты. Гаиләбез турында, үзебезнең турында уйла, диде ул ана, сина бит туган ягында якты чырай күрсәтүче дә юк. Нигә син әллә нинди хәлең житмәс мәсьәлә буенча жаныңны ашыйсын? Хатынынын бу сүзләренә Яббарның ачуы килде. Ничек инде туып-үскән жир өчен кайгырмаска. Ничек инде газиз әнкәсе яши торган жир турында уйламаска. Ничек инде үзе туып-үскән авыл язмышы өчен борчылмаска. Су астында калу ул бит инде юкка чыгу, бетү дигән сүз.

Бик озак уйланганнан сон ул Әнсар янына барып кайтырга булды. Әнсар үз районнарынын райком секретаре лəбаса, туган якны, ичмаса туган авылны, күрше авылларны, авылларнын зиратларын саклап калыр өчен көч куймый калмас. Бәлки, Әнсар әле туган якка яна төрле афәт киләсен белмидер, әйтмәгәннәрдер, ишетмәгәндер.

## 25

Көн яктысыннан сон коридор карангы булып тоелды. Күз иялəшкәч стенада агымдагы 1956 елнын планнары, анын кайбер уңышлары хакындагы плакатлар, гәжитләр, графиклар, ниндидер фоторәсемнәр абайланды. Яббар аларны якынрак килә-килә карап барганда анын яныннан төз гәүдәле, оста ясалган прическалы бер хатын кулына кәгазьләр тотып, шык-шык басып үтеп китте. Биш-алты адым узгач, ханым туктап борылды:

—Яббар! Синме?

Яббар үз исемен ишетеп сискәнеп китте. Борылып караса, аңа таба якты елмаеп Фатыйма килә:

—Яббар! Танымыйсыңмыни?

Яббар чынлап та башта икеләнеп торды—улмы бу, юкмы.

Фатыйманы дөрестән дә танырлык түгел, ул бик үзгәргән, киеме, үзен тотышы, прическасы затлыланган.

—Фатыйма түгелме соң син?!—диде ул, шаккатып.

—Мин, мин,—диде Фатыйма, тагы да мөлаемрак елмаеп.—Исәнме!—Ул исәнләшергә дип жылы, йомшак кулын сузды. Яббар кыюсызланып, саклык белән генә анын ап-ак кулын кысып күреште.

—Исәнме!—диде Яббар, каушавын көчкә жиңеп.—Ә-ә-ә, әйе, әйе, син монда эшлисен бит. Мин сине танымадым. Киноларда гына күренә торган мадамга әйләнгәнсең. Нинди эштә сон син монда?

—Райкомнын бухгалтериясендә эшлим. Ә син райкомда нишләп йөрисең?

—Әнсарны райком секретаре итеп сайлаганнарын ишеткән идем, менә килергә булдым әле.

Яббар Фатыймадан күзен алмады. Кайчандыр аны яраткан Фатыймамы соң бу? Шул яшьлектәге беренче мәхәббәтеме соң бу? Фатыйма аңлады аның уй-хисләрен. Ул үзе дә шундый ук тойгылар кичерә түгелме! Өлкәннәрдән кача-поса, авылдашлардан читенсенеп кенә инеш буйларында очрашып, аулакта үзләрен дөньядагы иң бәхетле кешеләр итеп тоялар иде бит алар. Фатыймага бәйләнгәне өчен Әнсар Яббарның иң явыз дошманына әверелгән иде. Аның бәйләнүеннән ничек котылырга белми йөдәгәннән соң сугышуларга кадәр барып җиткәләр иде бит. Әнсар силсәвит рәисе малае булса да Яббар аңа бирешмәде. Чөнки Фатыйма Яббарны нык яратты. Мәхәббәт дәрт һәм дәрман бирә иде Яббарга. Ләкин язмышның йодрыгы Әнсарныкыннан катырак булып чыкты. Нык сукты, аямыйча, рәхимсез рәвештә китереп орды язмыш Яббарга. Аларга бергә булырга язмаган икән. Фатыйманы ачуланырга, гаепләргә аз гына булса да мөмкин түгел. Яббар үзегендә әле һаман да Фатыймага карата мәхәббәт утының сүнмәгәнен тойды.

Фатыйма кулындагы сәгатенә карап алды:

—Әнсар менә-менә кайтып җитәргә тиеш. Район буенча чыгып киткән иде. Нинди йомыш белән килдең?

—Бик җитди үтенеч белән,—диде Яббар.—Аннары үзе сиңа әйтер әле. Мине кабул итсә инде...

—Кабул итәр дип уйлыйм.—Фатыйма Яббарның күз карашыннан уңайсызланыбрак китте.—Болай тормышлар ничек соң?

—Бер көе.

—Улыгыз бар бугай?—дип кызыксынды Фатыйма.

—Әйе, улыбыз бар.

—Исеме ничек?

—Вәсим дип куштык.

—Вәсим... Матур исем.

—Сез дә кыз алып кайттыгыз дип ишеттем,—диде Яббар.

—Дөрес ишеткәнсең,—дип елмайды Фатыйма.—Кызыбыз туды, Сөнбел исемле.—Безнең хәзер бер малай, бер кыз.—Ул беравык икеләнеп торганнан соң сорарга җөрьәт итте:—Карале, Яббар, нишләп гаиләңне авылга алып кайтмыйсың?

—Аңлыйсың бит инде ник алып кайтмаганымны,—диде Яббар, караңгыланып.—Аны ник сорап торасың.

Фатыйма бу сорауны биргәненә читенсенеп:

—Гафу ит,—диде.—Аннары шатлык белән әйтеп куйды.—Безнең тагын бер шатлыгыбыз бар бит—ниһаять, Әнсарның күкрәгендәге кыйпылчыкны алдылар.

—Әйбәт булган. Райком секретаре булгач, хирургларның яхшылары тотынгандыр инде.

—Әйе, дөресен әйтергә кирәк, кешенең должностена, абруена карыйлар шул.

—Әнсар кыйпылчыгыннан арынган...—дип уйга калды Яббар.—Ә менә минем күнелемдәге кыйпылчыгымны берничек тә беркайчан да берниндә хирург алып ташлый алмаячак.

Фатыйма ягымлы итеп карады:

—Алай димә, Яббар. Тормышың яктылыкка таба юл алды бит инде. Өйләнгәнсең, улыгыз туган, эшлисең. Яшәү шартлары ничегрәк соң?

—Аерым фатир турында уйларга иртәрәктер әле. Баракта бер бүлмәбез бар, аңа да сөенеп туя алмыйбыз.

—Хатының нинди эштә?

—Безнең оешмада табельщица булып эшли.

—Алай икән,—диде Фатыйма һәм алар шактый вакыт сөйләшергә сүз табалмый бер-берсенә карап тордылар.

—Кем уйлаган язмышларның менә шушылай боргаланасын,—диде Яббар.—Иделнең Самарская Лукасыннан да катырак бормалана икән ул язмышлар!

—Әйе шул,—диде Фатыйма сагышлы тавыш белән. «Алдан күрү мөмкин түгел башның ни күрәчәген»,—дип җырлый иден бит син яшь чакта.

—Бергә чакларыбызны исенә төшергәлисеңме соң?

Фатыйманың күнеле тулды:

—Гел хәтеремдә, Яббар. Син миңа ачу-үпкә тотмыйсыңмы?

—Юк. Ни өчен мин сиңа үпкәләргә тиеш?!

—Сугыштан сине көтәм дип калдым, ә үзем Әнсарга чыктым.

—Син мине сугыштан көтәргә вәгъдә бирден, изменник дип лагерьда утырып чыгуымны көтәргә вәгъдә бирмәден бит.

Фатыйма күз яшьләрен көчкә тыеп тора иде.

—Син яшь чактагы шикелле үк якты күңелле, олы җанлы кеше булып калгансың, Яббар,—диде Фатыйма, атылып чыгарга торган күз яшьләрен көчкә тыеп.—Йөзең, кыяфәтең бөтенләй башка, күзләрең дә сәер, ә кешелегеңне югалтмагансың, күңелең катмаган. Гәүдәңне бераз турайт, башыңны күтәребрәк йөр, Яббар. Инде аңлаган кеше аңлагандыр. Аңламаганнарына исбатлап җаныңны ашама. Күп түбәнсенден инде—җитәр! Минемчә, алар барысы да сине әле һаман тиешле җәзаңны алмагансың, әле җәфаланырга тиешсең дип саныйлар. Мин сатлыкҗан түгел дип әйткән саен, алар һаман сине сатлыкҗан дип инандырырга маташырлар.

Фатыйма үзе дә олы җанлы кеше. Ләкин ул бит аны яратып йөрде, ә кияүгә Әнсарга чыкты. Юк, юк, аның башка чарасы юк иде. Дөрес, Яббарның күңелендә бераз үпкә бар, ләкин ул әйтә торган, белдерә торган үпкә түгел. Фатыйма аның сугыштан соң төрмәләрдә утырып чыгуын көтәргә тиеш булганмыни? Моңа туганнары, авылдашлары юл куймаслар иде барыбер. Фатыйманың атасы Нургали сугыштан кайтмады, кайдадыр яу кырында ятып калды. Абыйсы Кыям сугыш вакытында трудармиядә хезмәт иткән, мәетләр күмеп йөри-йөри сәерләнеп, психикасы нык үзгәреп кайтты. Шуңа да карамастан Яббарга карата җылы хисләр саклый Фатыйма—күзләреннән, тавышыннан күренеп тора. Инде алар икесе дә нык үзгәргәннәр, алар инде яшь чактагы Фатыйма һәм яшь чактагы Яббар түгелләр. Ә шулай да җанга якын кеше булып калган икән Фатыйма. Яшь чакта бер төрле чибәр иде, хәзер исә бөтенләй башка төрле гүзәлләнгән ул—карап туйгысыз, тора-тора гашыйк булырлык хатын-кызга әйләнгән.

—Рәхмәт сиңа җылы сүзең өчен,—диде Яббар.—Рәхмәт сиңа барысы өчен дә. Рәхмәт сиңа. Минем моңарчы яшәгән гомеремнең иң якты, рәхәт чагы—синең белән инеш буйларында йөргән көннәрем. Рәхмәт сиңа, Фатыйма, шул гүзәл хатирәләр өчен. Бәлки мин хәзер шул синең белән бергә чактагы бәхетле мизгелләрем ярдәмендә генә яши аламдыр.

Коридор башында аяк тавышлары ишетелде. Кыяфәтеннән түрәләргә хас олысымаклык һәм вәкарьлек бөркелеп торган берәү зур-зур адымнар белән атлап коридор башыннан өченче ишекне киереп ачты.

—Әнә Әнсар да кайтып житте.—Фатыйманың тавышында каушау ишетелде.—Бар.

Фатыйма коридорның икенче башына юл алды, Яббар исә Әнсар кереп киткән ишеккә таба юнәлде.

## 26

Каты яраланып госпитальдә дәваланганнан соң, Әнсар үзен кире фронтка җибәрүләрен үтенде. Әмма аны фронтка җибәрү мөмкин түгел диделәр. Ана Гомельдәге фильтрация лагерының саклау гарнизонында взвод командиры вазифасын тәкъдим иттеләр. Әнсар ризалык бирде, чөнки күкрәгендә алынмый калган кыйпылчык торымнан-торымга үзен белгертеп тора, фронтта дәваланырга мөмкинлек булмаячак, ә монда лагерьда ичмаса хәл алырлык һәм, ниһаять, мондагы эш тә гаять җаваплы, үзеннең кирәклегенне, читкә тибелмәгәненне тоячаксың.

Лагерьның киң, ләкин шыксыз, һәрвакыт әле тегеннән, әле моннан ишетелгән шомлы, куркыныч авазлары яңгырап торган ишегалдында Әнсар сыек кына томанлы көннең күкрәкне кысып бимазалавыннан котылыр өчен нишләргә белми әкрен генә ары-бире йөренеп торды. Бүген ул иртәнге разводны да көч-хәл белән уздырды, көн агымында эшләнәсе эшләренең барысын да үзенең урынбасарына тапшырып, лагерь начальнигеннән бераз ял итәргә рөхсәт алды.

Хәзер шушылай гомер буе интегер микәнни? Ул кыйпылчыкны каезлап алсалар йөрәккә зыян килер иде микәнни? Берәр әһәмиятле тамырлар киселер иде микәнни? Операцияләрдән соң хирургтан төпченеп карады ул, әмма теге бер сүз дә әйтмәде—караңгы чырайлы, бер сүз дәшми торган хирург иде ул. Әллә телсез булды микән? Ярар, аякка бастырганы өчен рәхмәт инде. Монда җыйналган дезертирлар, сатлыкҗаннар, легионерлар, оккупациядә дошманга хезмәт иткән кешеләр белән аралашу, аларны көн саен күрү дә Әнсарның ярасына унай тәэсир итми. Кем генә юк бит монда. Менә бер тәбәнәк кенә буйлы, ябык, ләкин, күренеп тора, кайчандыр таза, тыгыз гәүдәле булган урта яшьләрдәге берәүне ике конвоир тикшерүчеләр утыра торган бинага таба алып баралар. Чыраеннан ук изменник икәне күренеп тора. Кем икән ул? Моның күкрәгендә кыйпылчык юктыр. Үлем җәзасына хөкем итмәсәләр ул, мөгаен, үз срогын утырып чыгар, исән калыр. Әнсарныкына караганда яхшырак түгелме соң бу сатлыкҗанның хәле? Ничек яхшырак булсын инде! Моның хәлендә калырга язмасын.

Әнә следовательдән берәүне алып чыгып килэләр. Шыр сөякле, битен сакал-мыек баскан, бераз аксый. Конвоирларның берсе ана нәрсәдер әйтте, шуннан соң тоткын, авырлык белән булса да, кызурак атлый башлады. Әнсарга сак астындагы бу өрәк таныш кебек тоелды. Яннан үткәндә ул күкрәгенең кысуын да онытып кычкырып эндәште:

—Яббар!

Тоткын гына түгел, конвоирлар да сискәнеп куйдылар.

—Яббар, синме бу?—диде Әнсар, якынрак килеп.

—Мин бу,—диде тоткын.

Конвоирлар—икесе дә яшь солдатлар—начальникләре каршында үрә катып бастылар. Тоткынны баракка үзем озатып куярмын дип, Әнсар конвоирларга казармага барырга боерды. Тегеләр, честь биреп, китеп бардылар.

Ике авылдаш, ике күрше, ике көндәш туган яктан еракта, караңгы, салкын, шыксыз лагерь уртасында, һәр икесе үз күзләренә ышанмыйча, бер-берсенә карап тордылар.

—Нинди җинаять кылдың соң син?—дип сорады Әнсар.

—Әсир төшкәч, легионга кердем.

Әнсар Фатыймага фронттан әллә ничә тапкыр хат язып карады, әмма бер генә җавап та килмәде. Фатыйманың Яббарны яратуын сугышка кадәр үк белсә, аларның хат алышулары турында исә анасы язган хаттан мәгълүм иде аңа. Менә бит ничек ул дөнья—хәзер көндәше аның каршысында аяныч

хәлдә, чарасыз халәттә, куркыныч кыяфәттә кукраеп басып тора. Әнсарның күңелендә шатлык елтырап алгандай булды, көндәшенең мескенлеген күреп сөенеч хисе тойды шикелле. Тик шулай да күршесен монда, шушы мондый хәлдә очрату Әнсарны нык тетрәндерде.

Яббарның өзек-өзек сөйләгәнен тыңлаганнан соң, ул үзе дә сизмәстән:

—Фатыйма беләме?—дип сорады.

Бу сораудан Яббарның башы әйләнеп күз аллары караңгыланып китте:

—Әйтә алмыйм.

—Ничәнче баракта син?

—Дүртенчедә. Тәмәкең бармы?

—Син тартмый идең бит.

—Хәзер тартам.

Әнсар бер кап папирос чыгарып Яббарга бирде:

—Кабы белән ал.

—Рәхмәт.

Әнсар Яббарны җылырак баракка—өченчегә күчерүләрен кайгыртты. Аның үтенечен шул көнне үк үтәделәр.

Ул үзе лагерь территориясендәге офицерлар өчен махсус корылган аерым-аерым бүлмәле бинада яши иде. Яббарны очратканнан соң ул бүлмәсенә кайтып ятты. Күз алдыннан Яббар китмәде. Авылда берәрсе беләмикән?

Ул тумбочкасыннан бер буханка ипи, ике пачка махорка алып гәҗиткә төрде дә өченче баракка китте. Бер яктан Яббарның фаҗигасе аңлатып булмаслык канәгатьләнү тудырса, икенче яктан ничек булса да авылдашына ярдәм итәсе килде аның. Яббарны чакыртып ипи белән махорканы биргәч, ул аңа допросларда үзен ничек тотарга, сорауларга ни дип җавап бирергә кирәк икәнне аңлатмакчы иде. Тикшерү бүлегенең нәчәлник урынбасары майор Слепцовның бу тарафка килүен күргәч, Әнсар Яббарга тизрәк баракка кереп китәргә кушты һәм үзе майорга таба атлады.

—Кем белән сөйләштең син?—дип кызыксынды майор.

—Иптәш майор, ышанырлык түгел—авылдашымны, күршемне очраттым. Әле аның белән бер кызны бүлешә алмыйча сугышып йөргән идек. Һич башыма сыймый.

—Дезертирмы?

—Легионер.

—Нәрсә бирдең син аңа?

—Ипи белән махорка. Иптәш майор, бик кызгандым, ни дисәң дә бергә үстек бит, сугыша-сугыша булса да.

—Син күпне күргән, орденлы офицер, ә үзеңне куркыныч астына куясың. Мин сиңа моннан ары аның белән очрашмаска, сөйләшмәскә киңәш итәм. Сугыш бара, иптәш өлкән лейтенант... Ә ул—изменник...

Майор китеп барды. Әнсарга һава җитми башлады, ул шинеленең өске сәдәпләрен ычкындырды, көзге дымлы һава белән күкрәген тутырырга тырышып авыр һәм тирән иттереп сулады.

Шуннан соң Әнсар Яббарны читтән генә берничә тапкыр конвоирлар сагы астында допроска барганда, аннары себерке белән барак алдын себергәндә күргәне бар. Инде авылдашы белән якыннан аралашырга ул бүтән җөрьәт итмәде.

## 27

Фильтрация лагерындагы очрашу хәтердә аермачык булып уелып калды. Мөгаен, мәңгегәдер. Инде күпме вакыт узды, ә шулай да әле кичә генә булган кебек ул вакыйгалар.

Менә хәзер сугыш та юк, кан да коелмый, кешеләр төзелешләрдә эшлиләр, иген игәләр, нефть чыгаралар. Ник кирәк булган ул коточкыч сугыш? Кешеләрне, халыкларны канга батырыр өченме, әллә аерым кешеләрне сынар өченме?..

Нишләп тиз генә арада тыкрык аша күршеләр булган Әнсарның һәм Яббарның язмышлары шул кадәре төрле-төрле килеп чыкты соң?

Әнсар сугыш ветераны, каһарман, райком секретаре.

Ә Яббар? Аның да яраткан эше, гаиләсе бар, ата-анасы исәннәр, ләкин җан тынычлыгы инде мәңгегә җуелган.

Яббар авылдашы кереп киткән ишекне ачты. Әнсар әле үзенең кабинетына кермәгән, кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз машинкада баскан кәгазьләрне укып тора иде.

Яббар килеп керү белән үк:

—Исәнмесез!—дип эндәште.

Әнсар әкрен генә борылып мәгърурлык белән җавап бирде:

—Исәнмесез!

Ул Яббарны әллә танымыйча, әллә танымаган булып кыланып беравык карап торды.

Яббар якынрак килде:

—Әнсар Хәлиуллович! Исәнмесез!

—Исәнме, Яббар! Мин сине танымый торам. Фатыйма белән сөйләшеп торучы син идеңмени ул?

Яббар югалыбрак калды, ләкин дөресен әйтергә кирәк иде.

—Әйе, коридорда очраштык.

—Нишләп йөрисең?

—Мин сезнең янга дип килгәнием... Кабул итсәгез иде... Хәзер кабул италмасагыз, бәлки башка көнне мөмкин булыр.

—Минем хәзер вакытым бар, мин сине кабул итәм,—диде Әнсар. Аннары кулындагы кәгазьне өстәлгә куеп секретарьга мөрәҗәгать итте:—Моны тагын бер нөсхә бас.

Әнсарның эш кабинетына кергәч, Яббар сүзне нидән башларга белми югалып утырды, Әнсар да үзенең түрдәге урынында түземлек белән авылдашын тыңларга әзер торды.

—Менә килдем әле,—диде Яббар каушабрак.

Әнсар беравык Яббарны җентекләп күзәтеп утырды.

—Күптә-ә-ә-ән күргән юк сине,—диде ул һәм графиннан стаканга салып су йотып куйды.—Кызылъярга да кайтмыйсың бугай хәзер?

—Кайткалыйм,—диде Яббар.

—Без атна саен кайтып йөрибез, сине бер дә күргән юк, шуна әйтәм. Ничек соң хәл-әхвәлләрең?

—Бер көе.

—Алай икән, алай икән. Монда ни йомышлар белән килеп чыктың?

Яббар монда килүенең сәбәбен аңлатырга тотынды:

—Идел суының болай күтәреләчәген ГЭСны проектлаучылар үзләре дә алдан белмәгәннәрдер, мөгаен... Бәлки белгәннәрдер...

Әнсар авылдашының ГЭС хакында сүз башлавыннан аптырабрак китте:

—Шуннан?

—Куйбышев сусаклагычы әле бик нык киңәячәк. Су тагын да күтәрелгәч, әле хәтта Каманың түбән өлешен дә киңәеп күмәчәк. Күпме җир, күпме болыннар су астында калачак. Күпме авылга су астында калу яный.

—Ярар, арттырма инде,—диде Әнсар көлемсерәп.

—Инде шактый авылларны су басып китте. Кайберләре күчеп өлгерде.

Житешә алмыйча су астында калганнары да байтак.

—Шуннан?

—Су һаман күтәреләчәк.

—Водохранилище булгач, күтәрелер инде ул,—диде Әнсар бер дә исе китмичә.

—Безнең авылга да куркыныч яный,—диде Яббар, шөбһәле тавыш белән.—Кичекмәстән нәрсәдер эшләргә кирәк.

—Нәрсә эшләргә кирәк?

—Күченү ягын уйлау мәслихәт.

Әнсар тагын су эчеп куйды.

—Өстән кушмыйча без бит бернәрсә дә эшли алмыйбыз,—диде Әнсар.—Куйбышев водохранилищесы хакында обкомда сүз кузгаттылар. Кайбер авылларны калкулыккарак күчерү күздә тотыла. Су баса башласа, өстән кушарлар, күчерәсе авылларны күчербез, бер дә кайгырма.

—Ә зиратны?—диде Яббар, шомлы тавыш белән.

—Безнең авыл зиратын әйтәсеңме?

—Әйе. Зиратны күчерү турында хәзер үк уйларга кирәк, аны күчерү авылны күчерүдән дә авыррак булмагае. Каберләрне казып, ташып янадан күмү йортларны сүтеп яңа җирдә төзүгә караганда катлаулырак булачак. Мисаллар күп.

Әнсар кул селтәп урындыгында киерелебрәк утырды:

—Син монда коткы чәчеп утырма әле. Бәлки су безгә кадәр менеп җитмәс.

Яббар гасабилана башлады:

—Мин үзем күреп йөргән бик күп авыллар, зиратлар, кырлар, болыннар су астында калды. Күтәрелә су, күтәрелә! Әйтәм бит, хәтта Каманың да суы күтәреләчәк, Камага да тулачак су—югары агымына таба берничә йөз километрга кадәр. Шулай булгач, Иделнең ничек киңәячәген күз алдына китер.

Әнсарның да эче поша башлады, ләкин аңлашылмады—әллә Яббарның көтмәгәндә вакытсыз килеп шундый проблема күтәргәненнәнме, әллә чыннан да сусаклагычның күтәреләчәгеннәнме.

—Су басуы ихтимал дип хәзер зиратны актара башлыйкмы?!—диде ул, күзләрен челәйтеп.

—Ә каберләр су астында калса?! Мин тикмәгә килмәдем. Мине ничек куралмагыныңны белә торып, юк-бар мәсьәлә белән монда килер идеммени мин! Авылны, зиратны коткарырга кирәк—әлегә соң түгел!

—Нигә әле авылларны, зиратларны коткаруны син кайгыртып йөрергә тиеш,—диде Әнсар хакимнәргә хас эрелек белән.—Влач бар, махсус службалар бар. Партия беркемне беркайчан бәла-казада ташламас. Шуны да онытма—мин партиянең райком секретаре, мин райисполком рәисе түгел.

—Барыбер сез хакимлек итәсез, барыбер сез җитәкчеләр,—диде Яббар.—Син бик абруйлы кеше, Әнсар. Зиратны күчерергә бүген үк тотынырга кирәк!

Әнсар әңгәмәдән туюын күрсәтеп өстәлендәге кәгазьләрне актара башлады.

—Син җүләрләнден мәллә!—диде ул кирәкле кәгазен эзләгән булып кыланып.

—Бәлки җүләрләнгәнмендер,—диде Яббар, кыза башлап.—Чөнки туып-үскән җиренне су баса башласа чынлап та акылдан язарга мөмкин. Безнең туган җиребез, безнең балачагыбыз узган, ерак бабаларыбыз иген үстергән тарафлар су астында калачак—аңлыйсыңмы?! Зират та су астында калса

безне бабаларыбызның рухлары кичермәс!

Әнсарның йөзенә ачу чыкты:

—Ерак бабаларыбызның рухлары турында син уйларга тиешме?!

Яббарның бите агарып китте:

—Нишләп мин уйламаска тиеш?!.

Әнсарның гәүдәсе киеренкелектән калкыбрак киткәндәй булды:

—Хакың бар дип уйлыйсыңмы?

—Бар!—диде Яббар, тавышын күтәреп.

Әнсар авызын кыйшайтып көлемсерәде:

—Син онытылып киттең түгелме?

Яббар сикереп торды:

—Юк, онытылмадым! Нәрсәгә төрттергәнеңне аңлыйм. Онытылмадым! Һәм үз акылымда мин. Легионер киемен киеп фронтның бу ягына үрмәләп чыгуым да туган җиремне сагынганнан, туган ягымны күрәсе килүдән булды. Туган якның һәрбер сукмагын, һәрбер агачын, әрәмәсен, су буйларын бүтән беркайчан да күрмәм дип курыкканга дошман киемен кидем мин. Туган җиремә кайтып егылыр өчен беренче мөмкинлектә үк үзебезнекеләр ягына качкан кеше мин. Изменник дип ата, сатлыкҗан диген, легионер дип әйт, предатель диген, халык дошманы дип ата, ләкин кичекмәстән авылны, зиратыбызны коткар! Син райком секретаре. Син зур кеше, сүземә колак сал! Мин бит үзем өчен генә сорамыйм. Зинһар, зиратны су астында калдырмагыз!

—Әле бернинди куркыныч янамаган килеш нишләп бу кадәре ачыргаланасың син?!

—Чөнки мин беләм, үзем күрдем,—диде Яббар, өзгәләнеп.—Инде Иделнең аскырак өлешендә күпме җирне су басканны үз күзем белән күрдем. Су һаман күтәрелә, әле тагын бер ел яки ел ярым чамасы суның артуы дәвам итәчәк.

Әнсар шактый вакыт дәшми утырды. Өстәлендәге телефон шылтыравына да игътибар итмәде. Яббарның урыныннан кузгалырга ниятләвен сизенеп ул әкрен генә тавыш белән әйтеп куйды:

—Шушылай җан атып йөргәч, син үзеңне реабилитацияләрләр дип өметләнәсеңме әллә? Авылны су баса дигән сылтау белән килеп...

Яббар мондый сүзне ишетермен дип уйламаган иде, ул беравык тораташ булып катып, телсез калды.

—Аңламадым?..—диде ул, әкрен генә торып.

—Алай усал карама миңа,—диде Әнсар, авызын кыйшайтып.

Яббар кире урынына утырды:

—Мине дошман ит, ләкин сүземә колак сал.

—Әле болай өзгәләнеп йөргәнеңә үкенерсең.

—Ник алай уйлыйсың?

—Чөнки сиңа ярлыкау беркайчан да булмаячак!

—Юк, Әнсар, үкенмәм,—диде Яббар башын чайкап.—Мин бер генә нәрсәгә үкенәм.

—Нәрсәгә үкенәсең?

Яббар торып кискен хәрәкәтләр белән урындыкны читкә алып куйды:

—Теге фильтрация лагерында синнән бер буханка ипи белән махорка алганыма үкенәм.

Әнсар урыныннан торып, дошманнарча явыз караш белән авылдашына текәлде:

—Син үзеңнең пычрак биографияң белән ничек партия райкомына керергә җөрьәт иттең?!

Яббардан да нәфрәт бөркелде:

—Синең туган җиреннө шушы арада су басачак, синең туган ягың су астында калачак, ә син—партия, райком...

—Но-но! Кайда икәнеңне онытма!—дип җикерде Әнсар.—Үзеңнең кем икәнеңне һәрвакыт исеңдә тот!

Яббар түземлеген җуеп кычкырып җибәрде:

—Монда кергәнемә дә үкенермен, ахрысы!

Әнсарның чырае кинәт кып-кызыл булды, ярсудан аның хәтта куллары калтырана башлады.

—Күземнән югал, изменник Родины!—дип ысылдады ул.

Яббарның гәүдәсе кечерәеп калгандай булды.

—Мин изменник түгел!—диде ул буйсынулы тавыш белән.

—Алайса, ник бөрештен?—диде Әнсар, тешләрен кысып.—Нинди оешмага килеп кергәнең акылыңа яңа гына барып житте бугай. Инде хәзер үк үкенәсеңдер монда кергәнеңә, шулаймы?!

Яббар калтыранган кулы белән Әнсарның өстәлендәге графинны алды, кырыйга түгә-түгә стаканга су салды.

—Үкенәм,—диде ул кулындагы сулы стаканга карап.—Үкенәм. Мин сатлыкҗан түгел! Мин беркайчан предатель булмадым!—Шуннан соң ул муеныдагы кан тамырларын бүртгереп үкерде:—Мин беркемне, бернәрсәне сатмадым! Мин изменник түгел!

Яббар суны эчмәде, кулындагы стаканны өстәлгә куймакчы булды, әмма... Ник кирәк булды, нинди көч аны этәрде, нишләп үзен тыя алмады соң ул?!. Стакандагы суны ул көтмәгәндә, хәтта үзе дә сизмәстән, Әнсарның битенә сипте.

Әнсар гаҗәеп тынычлык белән чалбар кесәсеннән кульяулыгын алып битен сөртте.

Стакан Яббарның кулыннан идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде.

## 28

Судка туганнардан Сәет кенә барды.

Кайткач, ул суд утырышы турында башыннан ахырына кадәр бәйнә-бәйнә сөйләде.

—Нәрсә өчен дүрт елга хөкем иттеләр соң аны?—диде Әминә, еламсырап.

—Партия райкомына кергәне өчен!—диде Нәгыйм, карчыгына усал караш ташлап.

—Ник, ул бит анда начар ният белән кермәгән.

Нәгыйм башын салындырып чайкап куйды:

—Райкомга кереп каза кубарга ярыймы соң инде аңа!

—Судта да ул үзен дөрес тотмады,—диде Сәет.—Партияне сүкте, җитәкчеләрне сүкте, үзе эшләгән ГЭСтагы гаделсезлекләрне сүкте. «За измену Родине» утырып чыккан кеше судта шундый нәрсәләр сөйләгәч, ничек инде дүрт ел бирмәсеннәр! Әле ничек күбрәк бирмәделәр.

—Әнсарның битенә су сипкән өчен шулай күп биргәннәрдер дип уйлыйм мин,—диде Нәгыйм.

—Юк, Әнсар бөтенләй әйтмәде ул турыда. Киресенчә, ул Яббарны каты җәзага тартмауларын сорады. Яббарның Волжский ГЭСы, Куйбышев водохранилищесы безнең җирләргә зыян китерә дип әйтүен төп җинаяте дип таныдылар.

—Аның алай дип әйтүләрен шул Әнсар сөйләгәндер бит инде судта?

—Әнсар судта аны гаепләрлек итеп сүз әйтмәде. Әнсар сөйләмәсә дә, әллә син райкомда аларның сөйләшкәннәрен тыңлаучы булмаган дисеңме?! Анда яшертен генә тыңлый торган нәмәрсәләре юк дисеңме әллә?!

Әминә елап җибәрде:

—Әй, балакаем, тагын харап иттеләр бит үзенне.

—Үзе гаепле!—диде Нәгыйм.—Судимостьн була торып рәзе райкомга барып керәләр!

Кинәт Әминәдән монарчы ана хас булмаган ачулы көр тавыш чыкты:

—Ул синең балаң! Гел битәрләргә, ачуланырга торасың! Илленче елдан бирле, лагерьдан кайтканнан бирле синең ана бер генә дә җылы сүз әйткәнең булмады. Нишләсә дә, ялгышса да, абынса да, бәлага дучар булса да—ул синең балаң. Алайга калса, аның язмышында синең дә гаебең бар!

—Нинди гаебем бар минем?—дип гаҗәпләнде Нәгыйм, карчыгының җикеренүенә шаккатып.—Нәрсә, начар тәрбия бирдемме мин ана, әшәкелеккә өйрәттемме?!

—Авылларны, зиратларны су басудан коткарырга кирәк дип килгән кешене төрмәгә утыртырга кирәк микәнни?!—дип елап җибәрде Әминә.

Нәгыйм һаман үзенекен тукыды:

—Аның игелекле уй-ниятләр белән йөрүенә кем ышансын! Райкомга кермәскә иде ана!

Кайнар бәхәс шаукымы белән Хәлиулланың килеп керүен сизми дә калдылар.

—Керергә мөмкинме?—дигән булды ул, инде кереп ишекне япкач.

—Әйдә, әйдә, күрше,—дигән булды гел вакытсыз һәм кирәкмәгән чакта килеп керә торган күршесен өнәмәгән Нәгыйм.

Хәлиулла ясалма ягымлылык белән исәнләште дә ишек катындагы урындыкка утырды.

—Шулай диген, ә,—дип башлады ул сүзен.—Әнсар аны төрмәгә утыртуга каршы булды, шуны әйтергә кердем мин.

—Беләбез, күрше, беләбез,—диде Нәгыйм.—Рәхмәт. Язмыштан узмыш юк дип хак әйтәләр.

Башка сөйләшер сүз булмаганлыктан тынлык урнашты. Хәлиулла тәрәзә янында бер хәрәкәтсез утыручы Әминәгә эндәште:

—Ни... Әминә, син безнең белән сөйләшмисең соңгы вакытта.

Әминә күз яшьләрен яулык чите белән сөртеп Хәлиуллага таба борылды:

—Нәрсә турында сөйләшергә тиеш мин?—диде ул, күршесенә беравык карап торганнан соң.

—Элек Зәкия белән гел аралаша идегез бит.

Әминә тәрәзәдән тышка карап:

—Сезнең улыгыз райком секретаре, минеке кәтерҗән!—диде.—Ни турында сөйләшим мин сезнең белән?!

—Әнкәй, син инде бөтен кеше белән алай дорфа сөйләшмә,—диде Сәет.

—Мине дә төрмәгә утыртырлармы әллә?!—диде Әминә, улына усал карап.

—Карчык!—дип җикерде ана Нәгыйм.

—Тик кенә утыр!—дип каршы әйтте Әминә иренә.—Йөрәгең авырта икән, тынынны да чыгармыйча утыр! Синдә генә йөрәк!

Хәлиулла урыныннан кузгалды:

—Ярый, чыгыйм әле мин.

—Күрше, утыр әле, утыр,—диде Нәгыйм, күршесе алай-болай үпкаләмәгәе дип.—Тагын берәр йомышың яки әйтер сүзең бар идеме әллә?

—Бар иде шул,—диде Хәлиулла, кире урынына утырып.

Шул вакытны алҗып, әлсерәп Нәсимә кайтып керде.

—Уф, кайтып җиттем микәнни!—диде ул, ишек янагына сөялеп. Шуннан

соң гына:—Исәнме, Хәлиулла абый,—диде.

—Аллага шөкер, Нәсимә, исәнме. Каян кайттың болай?

—РОНОдан.

—Ник барган идең?

—Әй, безне яңа уку елы алдыннан шулай җыялар бит инде.—Ул Сәеткә карап ничегрәк итеп әйтим икән дип уйланып торды.—Район үзәгендәге мәктәпкә эшкә чакыралар.

Сәет хатынының бу яңалыгына ничек тәэсирләнергә дә белмәде:

—Син нәрсә дидең?

—Синең белән киңәшләшмичә нәрсә дим мин! Уйлашырбыз, дидем.

Хәлиулла күрше килененең бу хәбәрен хуп күрде:

—Ник, район үзәге район үзәге инде ул. Ризалык бирергә кирәктер, минемчә.

—Тагынниләр бар районда?—дип кызыксынды Нәгыйм.

—РОНОда ишеттем: тиздән бу тирәне су басачак ди. Безнең авылның да су астында калуы ихтимал икән. Иренә кайтып әйт, тиздән монда юньле эш табып булмаячак, су баскач бик күп авыл халкы район үзәгенә китәчәк, диделәр. Шуңа күрә район үзәгендәге мәктәпкә сөенә-сөенә күч, диделәр.

—Алар әле безнең энекәшебез барлыкны белмиләрдер,—дип мыгырдады Сәет.

Нәгыйм күршесе янында Яббар турында сөйләшергә теләмичә тизрәк сорап куйды:

—Су басачагы дөрес микән әллә?

—Мин дә шул хакта сөйләшергә кергәнием ләбаса,—диде Хәлиулла.— Мин дә ишеттем. Күрше авылның персидәтеле әйтте. Утсыз төтен булмый. Димәк, монда да су киләчәк. Имеш, безгә калкурак урында, Аулаш тавы итәгендә яңа йортлар төзеп бирәчәкләр. Кыскасы, яңа авыл салып безне шунда күчерәчәкләр... Алай-болай су баса калса инде...

—И Ходаем, тагын ниләр күрергә язган икән,—дипыңгырашты Әминә.

—Теге вакытта кайтканында Әнсар бу турыда бер сүз дә әйтмәгәние, менә шимбә көнне тагын кайта, төпченермен әле,—диде Хәлиулла.

Нәгыймнең ышанасы килмәде:

—Безнең авыл—борынгы Кызылъяр—үз урыныннан күчәр микәнни?

Хәлиулланың тавышында өмет яңгырады:

—Аулаш тавы итәгенә на всякий ыслучай гына йортлар салачаклар ди. Әле без әбизәтелне күчәчәкбез дигән хәбәр ишетелмәде.

—Ә алай-болай су басмаса, Аулаш тавына салынган авылны нишләтерләр?—дип уйга калды Сәет.

—Һи-и-и, анысы өчен бер дә борчылма,—дип кул селтәде Хәлиулла.— Кулланыш табарлар. Булган нәрсә тик ятмас.

Төрле фаразлар белән киләчәкне күзаллап, тормышның катлаулыгыннан зарланып, кеше гомерендәге авырлыклар турында гәпләшеп шактый вакыт сөйләшеп утырганнан соң, Нәгыйм чыгып китте.

## 29

1956 елның көзендә Яббарның хатыны Роза, бер яшьлек улын күтәреп, Кызылъяр авылына килде. Яббарның туганнары белән никахтан соң аның очрашканы булмады, Кызылъярга исә аның бу беренче мәртәбә килүе иде.

Авыл башында Нәгыймнәр йортын сорау белән үк аңа бер агай: «Теге, малае предатель Нәгыймнәрме?»—дигәч, Розаның, баласын кочаклаган килеш, ачык кырга йөгерәсе килде.

Авылның урамнары кисешкән үзәккә житкәч, ун-унике яшьлек бер кыз ана теләр-теләмәс кенә Нәгыймнәр йортын ничек табарга икәнне аңлатты.

Яббарның улын Нәгыймнәр йортында ничек кабул итеп, ничек яратканнарын күргәч, Роза хәтта монда килгәненә үкенеп тә куйды—шул кадәре җан җылысы, шул кадәре мәхәббәт белән кулдан кулга йөрттеләр Вәсимне. Йөрәгенең ярсуын көчкә тыеп утырды Роза. Шулай да түзмәде, бернечә тапкыр тып-тын гына елап алды. Сәет белән Нәсимә дә үз балаларыдай яратып карадылар Вәсимгә. Балалары булмау сәбәпле, алар өчен бигрәк тетрәндергеч вакыйга булды бу. Вәсим тач Яббар иде, баланың атасына охшаганлыгы барысын да таң калдырды.

Малайны сөеп, аны бәһасез хәзинә урынына кулдан кулга йөрткәннән соң, Роза үзенең килүенең сәбәбен, ниһаять, әйтергә җөрьәт итте.

Ул барысыннан да гафу үтенде, Яббарның әйбәт кеше икәнлеген сөйләде. Аннары кыяр-кыймас кына: «Яббарны көтә алмам инде»,—диде. Баланы алып Куйбышевка, ата-анасы янына кайтып китәчәген әйтте. Төрмәдән кайткач, Яббарга улын килеп күреп йөрергә рөхсәт булачак, диде. Соңрак, түзмәде, Яббарның Вәсимне ничек нык яратуын да сөйләп бирде.

Розаның бу хәбәреннән соң бик озак тып-тын гына утырдылар.

Берсе дә ашыкма, туктале, башта тынычлан, уйла, бәлки көтәрсең, димәде.

... Розаны баласы белән, МТСтан машина сорап алып, Сәет илтә китте.

Ул икенче көнне генә кайтты—кире кайтканда юлда машина ватылган. Төне буе Нәгыймнәр йортында ут сүнмәде, Сәетне борчылып көтеп утырдылар.

Сәет кайту белән үк Нәсимә:

—Вәсимне монда Кызылъярда калдырырга иде, үзебез үстерер идек,—диде.

Әминә сискәнеп китте:

—Мин үзем дә шуны уйлап утырдым. И Нәсимә, ник моны Роза монда чакта әйтмәдең?

Нәгыйм үзенең икеле-микеле фикерен әйтте:

—Онытыбызны монда калдыру әйбәт булыр иде дә... Ләкин авылда аны, изменник малае дип, кагарлар иде.

—Әти дөрес әйтә,—диде Сәет.—Үсә төшкәч, Вәсим үзе монда килеп йөрер. Жаен табарбыз. Тора-бара Яббарга да халыкның мөгамәләсе үзгәрер, бәлки.

## 30

Яббарның кайгысы Әминәне кинәт аяктан екты. Сәет аны врачларга йөртеп карады, ләкин диагнозны әле тегеләй, әле болай куеп, төгәл һәм дөрес дәвалый алмадылар.

1956 нчы елның кышына кергәндә Әминә инде урын өстендә ята, хәтта намаз да укый алмаслык иде.

Декабрь азагының ачы җилле, үтеп чыккысыз буранлы кичендә ул үзенең янына өйдәгеләрне чакырды.

—Төрмәдән чыккач, Яббар барыбер монда кайтачак,—диде ул иреннәрен чак кына кыймылдатып. Туган ягына кайтачак ул барыбер. Минем сезгә бер генә сүзем бар. Яббарны какмагыз. Әгәр сез алга таба да аны рәнҗетсәгез, минем җаным тынгылык тапмас. Әгәр сез минем улымны һаман да бимазаласагыз, туфрагым күтәргесез авыр булачак.

Аның бу сүзләреннән Нәсимә кычкырып елап җибәрде һәм авызын томалап тизрәк кече якка чыгып качты.

Сәет башын салындырып:

—Ярар, әнкәй, борчылма,—диде.—Тынычлан. Теләгеңне үтәрбез.

Шул мәлдә Нәгыйм гомер буена күпме авыр сүз әйтеп, күпме кырысланып карчыгын рәнҗеткәненә үкенеп шашар дәрәҗәгә җитте. Бу дөньядан китеп баручы изге җанны кочагына алып бернинди үлемгә бирмәскә иде! Юк, Нәгыймнең хәленнән килми бу. Гомер буена аның берәр тапкыр җылы сүз әйткәне булды микән карчыгына? Күкрәк гадәттәгедән катырак кысылды, ләкин бу юлы Нәгыйм барып дару эчәргә тотынмады. Газиз карчыгы урынына үзенең үләсе килде аның.

... Әминәне җирләп кайткан кичне Нәгыйм аңлады—Әминәнең җаны күкләргә ашкач, йорт та җансыз калды.

—Берүк зиратны су баса күрмәсен инде,—дип аваз салды ул бөтенләй бушап калган өйдә.—Чынлап та су күтәрелә калса, иң алдан зират күмеләчәк. Аллам сакласын!

—Аны авылыбызның зиратында җирләмәскә иде,—диде Нәсимә.—Су бик артачак дип тирә-якта инде бөтенесе шаулаша.

—Ничек инде әнкәйне авылның зиратында җирләмичә башка җирдә җирләргә мөмкин!—диде Сәет, ачуланып.

—Ник, аны башка авыл зиратына күмеп була иде бит,—диде Нәсимә.—Ник тыңламадыгыз мине?!

Сәет үзе дә шулайрак уйлаган иде дә, ләкин әнкәсен кайсыдыр читтәге зиратка күмдерәсе килмәде шул.

—Буыннан буынга бөтен нәсел-ыруыбыз шул зиратта күмелгән,—диде ул.—Ник күңелгә тагын шөбһә кертеп утырасың инде!—Ул ярдәм өмет иткәндәй атасына карап торды.—Әти, син ничек уйлыйсың?

Нәгыйм аксый-аксый өй буйлап йөрергә тотынды:

—Мин үзем ничек дияргә дә белмим. Бер караганда, шушы зиратыбызга күмүдән дә дөресе юктыр. Икенче караганда, су баса башласа, хәлләр хөрти. Зиратны күчерү турында уйлау зарур. Хәзер үк, бүген үк!

Сәетнең тавышында каушау сизелде:

—Иң элек белергә кирәк—су чынлап та нык күтәреләчәкме. Болай гына каберләрне актару яхшыга илтмәс.

## 31

1957 елның язында Кызылъяр авылын Аулаш тавы итәгенә күчерергә күрсәтмә килде. МТСның бөтен техникасы, берничә урман хуҗалыгы, районның барлык балта осталары ашыгыч рәвештә шушы эшкә оештырылды.

Аулаш тавында салына башлаган йортларга беркем дә куанмады, халык су астында калачак туган авыл өчен җан ачысы белән елады. Су астында авыл түгел, әйтерсең лә авылдашларның төп тарихы батып калачак иде. Гүя мәңге кайтарып булмаслык гомерләрнең иң кадерле өлеше югалачак, яшәешнең асылы табылган бер изге урын харап ителәчәк, үткәннәрнең һәм киләчәкнең мәгънәсе мәңгегә гаип булачак иде.

Хәленнән килгәннәр үз йортларын сүтеп яңа төзелүче авылга ташыдылар. Гап-гади авылда кадерле, изге нәрсәләр бихисап күп булган лабаса. Ләкин барысын да күчерерлек түгел иде яңа урынга. Мал-туарны, булган җиһазларны, ата-анадан, әби-бабадан калган истәлекле әйберләрне, вак-төякне яңа авылга ташып булыр да ул... Әмма өянкеләрне, имәннәрне, тупылларны ничек күчерәсең?! Тыкрыкларны, чишмә буйларын, таныш

сукмакларны, туган авылның сүз белән генә анлатып булмаслык чалым-сызыкларын, бакча артларын, читән буендагы кычыткannarын ничек яна урынга күчермәк кирәк?!

Кызылъяр авылы бомбага тотылган кебек сурәттә иде. Үлем җәзасына дучар ителгән авыл белән Аулаш тавы арасында, тузан туздырып, йөк машиналары, арба таккан тракторлар, арба сөйрәүчеләр, җәяүлеләр тәүлек әйләнә йөреп торды. Җигүле атлар белән, уфалла арбаларын тартып, һаман нәрсәдер ташыдылар: араталыклар, такталар, рәшәткәләр, ватык-сынык кирпеч калдыклары, тимер-томыр, савыт-саба, чүпрәк-чапрак... Кайберәүләр үз әйберен генә түгел, нәрсә таба шуны алып кайта башлады, тора-бара тыныч вакытта игътибарга ия булмаган чүп-чарга да чират житте.

... Көзгә, кем ничек булдыра, күченеп беткәннәр иде инде. Дәүләт алга таба да материаллар белән, акчалата, утын ташып, печән бүлеп ярдәм итәргә вәгъдә бирде. Дөрес, акча дигән нәрсәне элек тә күрмәгән халык аны алга таба да дәүләттән ала алмады. Утыны да, печәне дә өлешчә генә бирелде.

Сентябрьнең алтынга төренгән бер таңында Кызылъярның сүтелми калган йортларын, чалыш-молыш каралты-кураларын, җимерелмичә төзек килеш калган моржаларын, агачларын су камап алды. Шул ук вакытта авылдан читтәрәк урнашкан зиратны да су чолгады. Моны авылдашлар «яңа» авылдан тагы да өскәрәк—Аулаш тавының югары өлешенә менеп күзәттеләр.

Иң изге урын булып саналган зират, өч йөз хуҗалыклы авылның Югары очы, Түбән очы, Кәрим очы, Бакалы очы, тыкрыклары белән бергә—барысы коточкыч тиз арада мәңгегә күздән югалды.

Мәңгегә хушыгыз!

Авыл су астында калды. Түбән җирдә, уйсу урында иде шул Кызылъяр. Ерактан караганда хәтта чокырланыбрак та тора иде авыл урнашкан урын. Әйтерсең лә яшел бишектә тирбәлә иде ул. Ләкин кемнәр уйлаган аның тәкъдиренә мондый фаҗигә язылганын? Ерак бабайлар авыл булып монда урнашкан чакта әллә нинди хәвеф-хәтәрләргә әзер булганнардыр, әмма кайчан да булса Идел үз ярларыннан чыгып авылларны йотар дип һич кенә дә башларына китермәгәннәрдер.

Авыл халкы, белгән догаларын укып, бәлки авылдан читтәрәк урнашкан зиратны басмас дигән өмет белән суның көннән көн киңрәк җәйрәгәнен күзәтте. Зиратны күчерү-күчермәү мәсьәләсе буенча каты бәхәсләрдән соң, каберләрне актармыйк дигән нәтиҗәгә килүләре дә, бәлки, су зиратны—изге урынны читләтеп агар дигән теләк-өметтән булгандыр.

Халык тып-тын гына күзәтте.

Юк, өметләр акланмады.

Кызылъярның зираты да су астында калды. Агачларның ябалдашлары гына су өстеннән калкып Аулаш тавына барып сарылган яңа авылга нидер әйтмәкче, аңлатмакчы булып чайкала-чайкала нидер сөйләделәр.

Шулай итеп, кышка Кызылъяр авылы, мәңге сөйләп-елап туймас газап белән, яңа урында салынган яңа йортларга кереп урнашып бетте.

Су өстен боз тоткач, авылның баганалары, таныш өянкеләр, тупыллар, имәннәр, ябалдашлары белән генә калкып, күктән мәрхәмәт сорагандай катып калдылар. Аларның күбесе киләсе язда бөтенләй су астында юкка чыгачаклар әле. Ә хәзер исә әле алар яңа салынган авылга үпкә вә шелтә юллаган сыман игътибарны гел үзләренә тартып тордылар.

Шулай итеп, Кызылъяр авылы, җан саклар өчен, Аулаш тавына таба үрмәләде. Авылның тарихы икегә бүленде—су басканчыга кадәр өлешкә

һәм су басканнан соңга. Күрше-күлән элеккечә бер-берсенә якын урнашырга тырышса да, монда инде урамнар сузылуы, йортлар төзелеше бөтенләй башкача иде. Урамнарны элеккечә итеп төзеп булмады, урыны башка, җайсыз иде. Кешеләр исә үзләренең каралты-курасын мөмкин булганча элеккечә итебрәк кабатлап салырга тырыштылар. Хәтта Әнсар да ата-анасының йортын Сәетләр белән күрше иттереп салдырды. Монда араларында тыкрык булмаса да, шул тыкрыклык ара калдырып урнаштылар.

## 32

Яңа урынга тамыр җәяргә тырышып ятучы авыл халкын кызгангандай, кыш җылы килде.

Җинел һавалы кышкы көннең берсе иде, Сәет белән Нәсимә аркылы пычкы белән кузлага куеп утын кискәндә капкадан Әнсар килеп керде.

Исәнләшеп хәл-әхвәлләрне сорашкач, Әнсар затлы тунының төймәләрен ычкындырды, кыйммәтле бүреген калкытыбрак ян кесәдән алган кульяулык белән маңгай тирен сыпырды.

—Урнашып беттегезме инде?—диде ул, әле һаман төзекләнеп житмәгән каралты-курага күз йөгертеп.

—Юк әле,—дип җавап бирде Сәет.—Хуҗалыкны һич кенә дә рәткә кертеп бетерә алмыйбыз. Әти каты авырый, аны бүлнискә йөрттек.

—Ә-ә-ә, алай икән. Хәзер кайда соң ул?

—Ята.

—Кереп хәлен белимме?

—Йокыга киткәние, йокласын инде. Нәсимә, бар бик тавышланмыйча гына самавырны куй.

—Район үзәгенә күчәсегез килмәде инде алайса?—диде Әнсар, Нәсимә кереп киткәч.

—Юк, калырга булдык,—диде Сәет.—Нигезне сакларга кирәк. Хәер, бу инде хәзер безнең авыл түгел. Исеме Кызылъяр булса да.—Ул каен тумранына утырды, бияләйләрен кырыйга салды. Әнсар янәшә яткан тумранга утыргач, авыр сулап өстәп куйды.—Туган авыл су астында калды, Әнсар Хәлиуллович. Туган нигез!

Бу үпкә-шелтәле сүзләрне Әнсар авылдашларыннан гел ишетеп тора, ул инде акланып-нитеп маташмый, чөнки аклану мөмкин түгел. Райкомда эшли торып та уяулыгын җуйды түгелме соң ул?.. Үзен гаепле санап авылдашларыннан гафу үтенгән чаклары да булды инде аның. Гафу үтенүнең мәгънәсе бармы соң дип тә һәрдаим үз-үзеннән сорый ул. Ләкин барыбер таныш-белешләренә, күрше-күләнгә тынычландыру сүзен әйтми кала алмый ул, чөнки дөнья бетмәде, тормыш дәвам итә, яшәргә кирәк, авыл халкында киләчәккә өмет сүрелмәсен өчен нәрсәдер эшләү мәслихәт.

—Алай димә, Сәет, барыбер бу авыл безнең туган нигезебез булып саналачак.

—Монда без туган нигезебезне тоеп яшәрбезме-юкмы, белмим. Зиратны күчерергә житешә алмадык. Мәңге ярлыкамаслык гөнаһ бу, Әнсар. Хәзер әнә әти шуны уйлап урын өстендә ята. Шыр сөяккә калды, тамагына ашамый. Ничек без шундый коточкыч нәрсәгә юл куйдык?! Син бит, Әнсар, зур кеше, ничек моны абайламадың?!

—Без өстән кушканча гына эшли алабыз. Житешмәдек бит. Мин шәхсән үзем суны болай кинәт күтәрелер дип уйламадым, хәбәр килер дә, өлгерербез дип өметләндем.

Сәетнең тавышында ачу гына түгел, нәфрәт яңгырады:

—Минем анамның кабере калды анда!

Әнсар болай да сөренке кәефле иде, хәзер инде бөтенләй йөзе карангыланды:

—Синең әнкәннеке генә түгел, бөтен авылның каберлеге калды анда. Зыяратны да кызганам, авыл да кызганыч. Их, Сәет, Сәет, без синең белән фронтовиклар, әллә ниләр кичеп кайттык, күрмәгән нәрсә калмады, киләчәгебез шушылай булыр дип кем уйлаган. Мин райкомда эшли башлагач кына аңладым: безнең язмыш, туган җиребез язмышы үзебезнең кулда түгел икән. Син туган ягыңны яклап берәр сүз әйтеп кара—сине җинаятьче диячәкләр, партия сәясәтен дөрес аңламаучы адашкан бер сарык диячәкләр.

—Аны мин райкомда эшләмәсәм дә күптән аңладым һәм хәзер дә аңлап йөрим. МТСтан командировкаларда еш булырга туры килә бит. Кая карама—зур-зур төзелешләр. Кеше яши дип тормыйлар, җирле халыкны санга сукмыйлар, ваталар, җимерәләр, бульдозерлар белән сөрдерәләр... Бер авыл янындагы икешәр метрлы кабер ташларын бульдозерлар белән сөрдереп күмгәннәр. Борынгы каберлек булгандыр, күрәсең. Заводлар, ГЭСлар, калалар төзелсен, ләкин гомер буе шул тарафларда яшәгән халыкның мәетләре өстенә түгел, аларның нигезен таптап түгел! Җирле халыкны санга сукмыйлар бит инде, килешәсеңдер!

Әнсар урыныннан кузгалды:

—Сүзләреңдә хаклык бар.—Ул шактый вакыт өстәп ни әйтергә белми торды.—Ләкин беркайчан да бу сүзләреңне башка беркемгә әйтмә, яме,—дип куйды ул Сәеткә карамыйча гына.

—Ярар,—диде Сәет, утырган урыныннан торып.

Сөйләшер сүзләр күп тә ул, тотрыклы әңгәмә кору һич кенә дә килеп чыкмый шул.

—Туган нигез, туган нигез...—дип борын астына гына мыгырдап уйга калды Әнсар. Шуннан соң кинәт сорап куйды:—Яббардан хат киләме?

—Юк, язмый.—Энесенең исемен ишеткәч, Сәет җанланып китте.—Мин шуны уйлыйм хәзер... Аны кырык икенче елда сугышка алдылар. Ачлыкта үскән малай сугышка китте, менә хәзер бүгенгә кадәр әле ул адәм рәтле тормыш күрмәде. Ә бит тирәнрәк уйлап баксаң, анарда гаеп ул кадәре үк зур түгел. Ана барыбыз да артык каты бәрелдек, мин үзем дә артык каты төртелдем ана.

—Легионерга нинди мөнәсәбәттә буласың инде...—Яббар турында сүз башлаганына Әнсар үкенеп куйды.—Төрмәдән монда кайтыр микән?

—Кайтачак, һичшиксез кайтачак!—диде Сәет, ялкынсынып.—Алай-болай кайтмаса, үзем табып алып кайтам.—Ул тавышын әкренәйтте.—Безнең Нәсимә белән балаларыбыз юк. Нәселне дәвам итүче, нигезне ичмаса күченгән авылыбызда булса да саклаучы дәвам барыбер кирәк. Яббарның улы бар.

—Аны хатыны ташлаган бугай бит?

—Ташласын. Хатын-кыз бетмәгән дөньяда. Яббарның улы бар. Кыяфәткә дә тач Яббар үзе. Ул аның дәвамы. Ул безнең дәвамыбыз!

Әнсар чәйгә чакырулары өчен рәхмәт әйтеп, авылны бер әйләним әле дип, саубуллашып чыгып китте.

...Нәгыйм 1958 елның мартында вафат булды. Үләр алдыннан Әминәсенең кабере су астында калганга чиксез кайгыруын, рәнҗүен белдерде ул.

Авылның яна зиратын Аулаш тавының төньяк өлешендә билгеләгәннәр иде. Нәгыймне күмгәнче монда инде өч кабер бар иде, аныкы дүртенчесе булды. Житмеш дүрт яшендә вафат булган Хисами карт, тумыштан чирле булган өч яшьлек кыз бала, сугышта каты яраланып кайтып савыга алмаган Рәфкать Кызылъярның яна зиратында үз урыннарын алганнар иде инде.

Йортта Сәет белән Нәсимә икесе генә калдылар.

—Әти кырыс булса да, гадел кеше иде,—диде Сәет беркөнне.—Аның йөрәге гаделлеге аркасында таушалды. Бу илдә намуслы кешенең ничекләр йөрәккәе чыдасын?!

—Бер-бер артлы киттеләр дә бардылар,—диде Нәсимә боек тавыш белән.

Сәет тыяла алмады, елап җибәрде:

—Әнкәй бер зиратта, әти икенче зиратта җирләнде. Әнкәй су астында калды, әти тауда.

—Тыңламадың бит мине. Су басуы ихтимал икәнен белә торып... Әнкәйне анда күммик дип еландай телләремне чыгарып ялвардым мин сиңа.

Сәет учы белән дымлы битен сыпырды да кинәт хатынына кычкырды:

—Тик кенә утыр! Вакыт узгач, бөтенесе акыллылана, хаклыга әйләнә!

—Кычкырма миңа!—диде Нәсимә тыныч, ләкин таләпчән тавыш белән.—Шуны әйтәсем килә: миңа карата катыланма, Сәет. Әнкәй әтинең кырыслыгына түзеп яшәде, ләкин мин алай түзмәячәкмен. Мин синең хатының икән, гаебем булган суратта гена кырыслан.

Соңгы вакытта шактый юашланган Сәет хатынына күндәм тавыш белән җавап бирде:

—Минем сиңа тик торганда каты бәрелгәнем юк та.

Нәсимә күптән әйтергә теләп йөргән фикерен дә кызып китеп әйтеп ташлады:

—Син энеңнең дә җелеген суырдың. Бөтенесе аны дошман иткәндә син аны аз гына булса да якларга тиеш идең.

—Үзеңнең: «Мәктәптә ничек патриотизм тәрбиялим, укучыларның ата-аналарыннан оят, иремнең энесе легионер, ә мин балалар укыткан булам!»—дип шыңшыганыңны оныттыңмыни?!

—Ул бер генә тапкыр булды,—диде Нәсимә.—Аптыраганнан гына.

Талаш шуннан ары китмәде. Үзара тату яшәп ятучы ир белән хатын арасында иминлек шундук кире үз урынына кайтты.

—Талашмыйк,—диде Сәет, авыр сулап.—Болай да бик авыр.

Нәсимә иренә тавыш күтәргәненә үкенеп куйды.

—Хәзер ашарга пешерәм,—диде ул, аралар бозылып китмәгәнгә куанып.—Нәрсә пешерим?

—Үзеңә кара,—диде Сәет битарафлык белән.

## 33

Яббар 1960 елның августында кайтып төште.

Туган авылы урынында су җәйрәп ятканын күргәч, үзеге урталай чатнады. Коточкыч тетрәнү белән бергә ул ниндидер сәер шатлык хисе кичерде. Шатлык та түгел иде ул, иң кадерле нәрсәнең юкка чыгуы аны бу вәхши дөньяга, кансыз чынбарлыкка тоташтырып торган элемтә җепселләрен шытыр-шытыр өзде шикелле, шуңа күрә күнелдә барыбер аңлатып булмаслык җиңеллек барлыкка килгән кебек булды. Әйтерсең лә үзәккә асып куелган күтәргесез авыр таш урынына җинелрәген асып куйдылар.

Анда, су астында авыл зираты. Ә зиратта аның әнкәсенең кабере.

Ул туп-туры су буена төшеп китмәкче иде, әмма башта Сәет белән Нәсимәне күреп сөйләшергә кирәк дип тапты.

Аулаш тавына күчереп утыртылган авылга кем булып килеп керергә тиеш соң ул? Чын Кызылъярда, туган авылында да аны кешегә санаучы аз булды лабаса. Ә авылның хәзергесендә?.. Кызылъяр исеме калса да, аның өчен бөтенләй чит-ят авыл бит инде бу. Сәетләр яши торган йорт та аның туган йорты түгел, аның нигезе түгел. Дөрес, урамнарны, тыкрыкларны элекке

чын авылдагы исемнәр белән атаганнар. Ләкин Яббарның туган авылы Кызылъяр түгел инде бу. Бер күршеләре элеккечә Хәлиуллалар икән. Элек икенче якларында күршеләре юк иде, урам очы булганлыктан анда бушлык иде. Хәзер исә икенче күршеләре дә бар—килгән кешеләр, ирле-хатынлы, икесе дә МТСта эшлиләр, өч балалары бар икән.

Сәетләрнен йорты бикле иде. Сәет МТСтан кайтып житмәгән, Нәсимә сеңлесе Сәвияләргә киткән. Моны ана яна күршесе—МТСта диспетчер булып эшләүче сары чәчле, тәбәнәк буйлы хатын әйтте.

Сул як күршеләрнең капка төбендә басып торучы карчыкны Яббар таныды—Зәкия карчык иде ул. Капкадан әкрен генә чыгып Зәкия белән янәшә басучы һичшиксез Хәлиулла карт иде. Ул башта алар белән барып күрешергә уйлаган иде, әмма кире уйлады, үзен танымасалар ярар иде дигән теләк белән күзләреннән югалырга ашыкты.

Яббар ике дә уйлап тормады, су буена төшеп китте. Очраган һәрбер кеше ана туктый-туктый карап калды. Яббар бөтенләй танымаслык дәрәжәдә үзгәргән, бәләкәй генә калган, бөкрәйгән, күзләрендә коточкыч кыргыйлык. Очраган авылдашларнын кайберсе аны танымады, таныганнары исә тизрәк анын яныннан качарга тырышты. Ләкин Яббар алардан элеккечә курыкмый иде инде. Ул һәрбер очраган кешегә туп-туры карады, таныганнары белән авыз тутырып исәнләште. Жавап итеп исәнләшмәсәләр һич кенә дә исе китмәде.

Озак йөрде ул су буенда.

Ирек бирсән, дөньясын басачак бу су. Жәйрәп яткан су түренә карап, ул авыл батып калган урынны дөрес абайлады.

Әйе, шунда иде анын туган авылы.

Ул артка борылып карады. Туып-үскән якны инде танырлык түгел иде. Яббар әллә нишләп китте, үзәгеннән ниндидер аваз чыкканын үзе дә сизми калды. Елауга да, улауга да охшаган тавыш тирә-якны сискәндерде. Еракларга кадәр яңгыраган бу авазны ишеткәч, жәйләүдәге сыер көтүен көтүчеләр бүре улыйдыр дип уйладылар.

Туып-үскән изге жирнен бер өлеше—ин кадерлесе, иң изгесе—беткән, юкка чыккан!

Әнә теге тарафта авылнын зираты су астында калган.

Анда әнкәсенең кабере!

Кичкә кырын аякларын көчкә сөйрәп, Яббар яна авылга таба атлады.

Анын кайтуы хакында бөтен авыл гөр килә иде инде. Хәлиулла белән Зәкия икәүләшеп Сәетләргә кереп, энен кайтты, диделәр.

Нәсимә аш пешерде, Сәет авыл кибетеннән бер шешә аракы алып кайтты.

Өстәлдәге шешә яртылаш бушагач, Яббар су буенда йөргәнен, анда нинди хисләр кичергәнен сөйләргә тотынды. Туган якнын шул кадәре өлеше су астында калуына тора-тора шаккатты. Анын йончыган кыяфәте, күзләренең төссезлеге, картаюы, гыр-гыр килеп йөткерүе, авыр итеп көчкә сулавы—төрмәләрдә утырганнан түгел, ә бәлки туган авылынын, зиратнын, анасы кабереннең су астында калудан дип уйларлык иде.

—Их, энекәш!—дип ыңгырашты Сәет, Яббарның сөйләгәннәрен тын да алмыйча тынлап утырганнан соң.—Кинәт су басты... Әле ничек үзебез исән калдык.

Яббар кинәт кыжрап абыйсына жикерде:

—Исән?! Син исәнмени?! Син тере кешеме соң?!—Анын күгәргән чыраеннан бөтенләй кан качты, ул бөтенләй ап-ак булды.—Авылыннын, бабаннарнын, ананнын каберләрен су астында калдыргач, син, гомумән, кешеме соң?!

—Житешмәдек,—дип акланды Сәет.—Авылны да менә җан-фәрманга тау итәгенә күчердек бит.

Нәсимә Яббарның кыяфәтеннән нык курыкты, соңгы вакытта юашланган иренең бу минутларда бөтенләй көчсез вә рухсыз булып калуын абайлады, шуңа күрә тизрәк сүз катарга кирәк дип тапты:

—Син, Яббар, Сәет белән мин кайгырмыйбыз дип уйласаң, ялгышасың.

Сәет стаканнарга аз-аз гына аракы салып куйды.

—Энекәш, миңа теләсә нәрсә әйт, ачулан, сүк... Мин моңа лаеклыдыр, мөгаен. Ләкин берүк башкаларга, бигрәк тә Әнсарга тавыш күтәрә күрмә, яме.

Яббар авыз чите белән елмайды:

—Ник алай?

—Ник алай дип... Аңлыйсың бит инде.

—Юк, аңламыйм!—диде Яббар, абыйсына текәлеп карап.—Дөресрәге, мин аның гаебе зур икәнне аңлыйм, ә менә нишләп мин аңа тавыш күтәрмәскә тиеш—шуны аңламыйм!

—Нәрсәсен аңламыйсың?—дип янә сүзгә кушылды Нәсимә.—Тагын төрмәгә утыртып куймагайлары дип синең өчен борчыла.

Яббар Нәсимәгә усал итеп карады:

—Анам үлгәч, аның каберен су баскач, минем беркем алдында акланасым килми. Башымны иеп тәүбә итәр өчен минем инде бу дөньяда башка беркемем дә юк.

—Синең улың бар, аның турында онытма,—диде Нәсимә, тавышын күтәреп.

Яббарның шундук кыяфәте үзгәрде.

—Әйе, минем улым бар,—диде ул горурланып.

Нәсимә, Яббарның йөзе яктырып киткәнгә сөенеп, улы турында сөйләшүне дәвам итте:

—Улың белән очрашырга сиңа анасы рөхсәт итәрмен дигән иде...

—Рөхсәт итә,—диде Яббар, елмаеп.—Мин иреккә чыгу белән үк алар янына барып кайттым. Биш яшь инде Вәсимгә, биш яшь. Миңа бик охшаган.

Нәсимә дә моңа ихластан шатланды һәм:

—Вәсимне монда алып кайт,—диде.

Яббарны авыр уйларыннан, кайгысыннан хәтта улы турында сөйләшү дә арындырырлык түгел иде шул. Туган авылы, анасының кабере су астында калгач, ничек ул тыныч кына үзе турында, үзенең баласы хакында сөйләшеп утыра алсын.

—Мондамы?..—диде ул, кинәт тагын усалланып.—Улымны монда алып кайтыргамы?..—Ул стакандагы аракыны йотып куйды, ипи кисәген кабып Сәеткә текәлде.—Абый, синнән мин бер сорау көткәнием.

—Нинди сорау?—диде Сәет, инде әллә нинди сорауларга да әзер булып.

—Сугыштан соң, беренче тапкыр утырып кайткач, миннән: «Нишләргә уйлыйсың, нишләргә җыенасың?»—дип сораган идең. Бу юлысы да сорамассың микән дигәнием. Сорамадың. Хәзер мин сиңа шул сорауны бирим әле: Син, Сәет абый, нишләргә уйлыйсың?

—Ничек инде, «нишләргә»?—диде Сәет, сагаеп.

—Ничек яшәргә уйлыйсың? Су астындагы зират төшләреңә кереп йөдәтмиме соң әле?

Сәет сикереп торып әрле-бирле йөри башлады:

—Ичмаса син күңелгә коткы кертмә! Күңелемдә ниләр кайнаганны

белмисен бит син!

Яббар абыйсын нәфрәт белән күзәтеп утырды:

—Кеше башка кешенең күңелен ничек белсен, ничек күрсен, ничек аңласын! Теләсә нишлә!—Ул ике йодрыгын да төйнәде.—Шуны әйтәсем килә: син мине легионер дип кичермәдең, ә мин сине анам каберә өчен кичермим!

Нәсимә ике бердәрнең болай сөйләшүеннән котсыз калды:

—Туктале, Яббар, алай димә!

Кайнар әңгәмәгә бирелеп, алар капка тавышын ишетми калдылар.

Сәет кинәт сагаеп:

—Өйалдына кемдер керде бугай,—дип кенә өлгерде, өй ишеге киерелеп ачылды һәм бусагада Әнсар пәйда булды.

—Исәннәрмесез!—диде ул мәгърур тавыш белән.

Тавышына вәкарьлекне ясалмалы итеп кирәгеннән артыграк өстәде шикелле. Бу үзенең каушавын күрсәтмәс өчен иде, ахрысы.

Яббарның кайтканын ишетеп керде ул. Очрашу жинел булмаячагын да белә, әмма күрешеп, исәнләшеп, күзгә-күз карашу мәслихәт. Барыбер кайчан да булса очрашырга туры киләчәк. Анын инде Яббарга карата мөнәсәбәте нык үзгәрде, ул ана, анын язмышына хәзер инде башкача карый. Ничәмә еллар буена бәладән котыла алмыйча, гәүдәсен турайта алмыйча иза чигүче авылдашына, күршесенә анын хәзер чын-чынлап ярдәм итәргә исәбе бар.

—Исәнмесез!—дип жавап бирде Сәет.

—Исәнмесез, Әнсар Хәлиуллович!—диде Нәсимә.—Әйдәгез, түргә узыгыз.

Әнсар ишек катыннан кузгалырга ашыкмады.

—Исәнме, Яббар!—диде ул, тавышын кинәт бөтенләй үзгәртеп, хәтта йомшартыбрак.

Яббар тук чырайлы, пөхтә киемле сау-сәламәт күршесенә шактый вакыт карап торды, аннары кыланып, мыскыл иткән сыман:

—О-о-о, Әнсар Хәлиуллович!—дигән булды.—Начальник! Мин бит сине танымый торам! Ай-яй корсак белән янакны кин җәелдергәнсең син.—Һәм шаркылдап көлеп куйды.

Нәсимә өсталне сөрткән булып Яббарнын иненә төртеп пышылдады:

—Яббар!

Әнсар, ниһаять, түргә узды, Яббарны яхшылап күзәтергә мөмкин булсын өчен урындыкны алып анын каршысына утырды:

—Хәл-әхвәлләрегез ничек?

—Аллага шөкер, Әнсар Хәлиуллович,—диде Нәсимә чак кына сизелерлек ялагайлык белән.

Сәет тәкъдим иткән аракыдан Әнсар баш тартты.

Ул сөйләшергә сүз тапмый торган арада Яббар, шатор-шотыр итеп яшел суган чәйни-чәйни, Әнсарга сүз катты:

—Әле бүген Фатыйманны күрдем... Фигурасы бозылган, артык тәмле ашаудандыр инде.—Ул күзләрен челәйтте.—Әллә ир игътибары житмиме? Ха-ха-ха!

Сәет энесенең дорфа шаяруыннан һәм ямьсез итеп көлүеннән чыраен сытты.

—Болай булгач, тагын утыртып куялар сине,—диде ул үзалдына, ләкин барысы да ишетерлек итеп.

Әнсар ник кергәненә үкенде булса кирәк, ул утырган урынында як-якка чайкалып кымшанып алды.

—Тынычлан әле, Яббар,—диде ул, ана туры карамаска тырышып.—Бераз

салгач кайнарлану табигый, ләкин артыгын кыланма, яме.

—Артыгын?!—дип кычкырды Яббар кинәт.—Нәрсәнең артыгын кыланам мин?!—Ул сикереп торып табын янынннан кузгалды.—Мине ташламаган бердәнбер кеше әнкәй иде! Мине бу дөньяда бер генә кеше гомере буе яратты—әнкәй! Мин сезгә аның каберен мәңге гафу итмим! Син, Әнсар—партия күсесе! Сука! Ә син, Сәет, минем туганым түгел!

Яббар гомерендә беренче тапкыр абыйсына абый дип түгел, исеме белән генә эндәште.

Әнсар инде торып чыгып китмәкче иде, шулай да үзен көчкә йөгәнләп урынында утырып калды:

—Яббар, мин махсус сине күрергә дип кердем. Берәр ярдәм кирәк түгел микән, эшкә урнашу буенча, тегесе-монысы... Ә син...

Яббар шундук аның сүзен бүлде:

—Рәхмәт, начальник, миңа сучий кусок кирәкми!

Аралыкка кереп поскан җиреннән Нәсимә түзмәде атылып чыкты.

—Яббар, җитте сиңа!—дип кычкырды тынгысыз гаиләдә яшәп нервылары нык какшаган хатын.

Яббар Нәсимәнең ачыргаланып кычкыруына аз гына да ригая бирмәде, Әнсарга тагы да якынрак килеп чак кына иеленкерәде һәм авызыннан аракы белән суган исен аңкытып эчендәген бушатуын дәвам итте:

—Син коткара ала идең зиратны. Синең бәгырең таштан. Сиңа туган җир, туган як кирәк түгел! Әнә нинди тук чырайлы син! Дөньяны су басса да син үзең батмаячаксың. Чөнки бук батмый, бигрәк тә бу кадәре бук! Син ике аяклы бәдрәф! Передвижной нужник син, падла!

Төрмәдән кайткан кешедән мондый сүзләр ишетү райком секретаренда каушау дигән нәрсәне кинәт юкка чыгарды.

—Ә син кем?—диде ул әкрен генә торып.

Яббар буыла-буыла йөткерергә тотынды. Әнсар чыгып киткәнче әйтеп бетерәсе сүзләре бихисап күп иде аның.

—Мин кеше!—диде ул ишеккә таба юнәлгән Әнсарга ияреп.—Вөҗданыма тап төшермәгән, әмма дә ләкин бәхетсезлеккә дучар булган корбан мин. Мин сугышта үзебезнекеләргә таба бер тапкыр да атмадым. Мин хәтта бер генә көнгә, бер генә минутка да сатлыкҗан булмадым. Мин әнкәйне сагынып, туган авылымны сагынып ашкындым үзебезнекеләр ягына. Мин туган илемә хыянәт итмәс өчен үзебезнекеләр ягына ашыктым. Әгәр дә шунда пленда чакта киләчәктә синең туган авылың, анаң күмелгән зират су астына батырылачак дигән булсалар, мин, мөгаен, атар идем, сәвит армиясенә каршы сугышыр идем.

Әнсар ишек катында аны ахырына кадәр тыңлап торды да:

—Син... чамалабрак!—дип кенә әйтә алды.

Шуннан да катырак әйтә алмады Әнсар, чөнки Яббарның җан газабыннан каралган йөзен, хәсрәт томаны эченнән дөньяда нинди дә булса яктылык табуга өметен җуйган тоныкк күзләрен якыннан күрде ул.

Яббар:

—Мин инде күп чамаладым,—дигәч, кинәт Әнсарның бәхетсез күршесен кочып җылы сүзләр әйтәсе килде. Ләкин әле бу мәлдә җылы сүзләр әйтү табигый булып тоелмас, мөгаен, шуңа күрә Әнсар бераз акланудан башларга кирәк дип уйлады.

—Яббар, каберләрне актару дөрес булыр идеме соң? Мин ничек итеп зират актаруны аңламыйм.

—Ә мин зиратны суга күмүне аңламыйм. Мине кешеләр нык кыйнадылар, җәберләделәр, хәтта аттылар да... Ачлык белән интектерделәр, мыскыл иттеләр, мәсхәрәләделәр, изделәр... Ләкин ни гаҗәп: мин аларның берсенә

дә үпкә-нәфрәт сакламыйм—рас шундый хәлгә төшкәнмен. Ә менә анам каберен, авыл зиратын су астында калдырганыгыз өчен мин сезне мәңге ярлыкамыйм. Син әйтерсен, изменникнын ярлыкавы ниемә кирәк диярсен. Мона мин төкерәм! Бу вәхши дөньяда син мине кешегә санамасан, теге дөньяда мин сине анам кабере өчен барыбер кичермәячәкмен!

Әнсар әнгәмәне тәмамларга кирәк икәнне, хәтта аны башлаунын да кирәге булмаганны анлады.

Ул:

—Ярый, сау булыгыз!—диде дә, артыннан берәрсе озата чыгар дипме, ишекне япмыйча гына чыгып китте.

## 34

Яббарнын көн саен кояш баеганчыга кадәр су буенда авыл баткан тарафка карап утыруын авыл халкы һәрдаим күреп-белеп торды. Ана игътибар итмәскә тырыштылар, чөнки һәрберсенен су басу вакыйгасына үзенен кайгылы мөнәсәбәте бар иде. Яббарны ачыктан-ачык дошман итмәсәләр дә, барыбер анын белән аралашмаска, анардан читкәрәк тайпылырга тырыштылар. Участок инспекторы капитан Кәлимуллин гына туп-туры, махсус рәвештә анын янына килеп, күз-колак булып, отмечать итеп торды. Тизрәк эшкә урнашырга кушты, аракы белән мавыкмаска өндәде. Яббар исә участковый әйткәннәрне колагына да элмәде, анын бөтен игътибары, бөтен уй-хисләре су астында калган тарафта иде. Йортта эш күп булса да, Сәет Яббарга эш кушмады. Яббар да үзе белеп хужалыкта ярдәм итәргә атлыгып тормады, хәтта теләк тә белдермәде.

Әнсар кергәннен икенче көнендә Яббар, гадәттәгечә, су буена төшеп китте.

Әле урак өсте, МТС умарталай гөжләп тора, шулай да Сәет үзенә бер көн ял юллады—сентябрь житкәнче, Нәсимә буш чакта, каралты-кура тирәсендәге эшләрне карарга кирәк иде.

Яббар чыгып киткәч, алар инде әллә ничәнче кат ишегалдын жыештырырга тотындылар—бу эш күченгәннән бирле торымнан-торымга инде кат-кат башкарылса да, чүп-чарнын, йомычканын, агач чүбенен һич кенә дә бетәчәге күренмәде.

Көн уртасына таба участковый килде. Ул: «Яббар район үзәгенә отделга барсын»,—дигәч, Сәет башта куркып китте. Әллә Әнсар шалтыратты микән дип уйлады ул. Участковый Яббарнын надзорда икәнлеген, атнага бер тапкыр отделга барырга тиешлеген әйткәч, Сәет бераз тынычланды.

Участковый чыгып киткәч Сәет, онытылыр өчен, башындагы авыр уйларны таркату нияте белән себеркесен жил-жил селтәп ишегалдын себерергә тотынды.

—Туган як жанлы малай булды ул бала чактан ук,—диде Сәет, хәл алырга туктагач себерке сабын жиргә кагып.—Аннары өстәп куйды.—Әнсар белән бик дорфа сөйләште, шуна эч поша әле.

—Аракы эчмәскә иде сезгә,—диде Нәсимә, йомычка өемен көрәк белән каерып носилкага салгач.—Инде кешеләр анын Әнсарга бәйләнгәнен ишеткәннәр.

Алар шактый алжып, ял итәргә сарай буендагы бүрәнәгә утырдылар. Шул вакытны капкадан Яббар кайтып керде. Аны мондый шат йөзле, күтәренке кәефле итеп кайтканнан бирле беренче тапкыр күрүләре иде. Сәет белән Нәсимә аптырап бер-берсенә карап куйдылар.

—Барыбер әле ямьле урыннарыбыз калган,—диде Яббар, канатланып.—Безнен туган якны су белән генә басып бетерү мөмкин түгел шул. Әле бит без чана шуган таулар калган, әле урманыбыз исән. Бүген һава бик әйбәт,

сихәтле. Су буенда шундый рәхәт! Ниндидер көймә чайкалып тора—талга бау белән эләктереп куйганнар. Кемнеке икән ул?

Сәет беравык уйланып торганнан соң:

—Ә-ә-ә, ул иске көймә, күптән тора ул анда,—диде.—Кайвакыт малай-шалай утырып йөри аңа.

Яббарның тавышында кинәт шом яңгырады:

—Баткан авылыбыздан кемдер көймә белән кайтканмы дигән әкияти бер уй килде башыма.

—Кем кайтсын инде аннан?!—диде Нәсимә басынкы тавыш белән.

Яббардан сәер илһам ташып чыкты:

—Бүген мин анда ниндидер бер гүзәл кош күрдем, нинди кош икәнен әйтә алмыйм, элек андый кош күргәнем юк иде. Шул кош ташка баскан да миңа текәлеп-текәлеп карый. Якынрак килдем. Кош миннән курыкмый, очып китми. Инде бөтенләй якын ук килгәч кенә очып китте. Шунда гына ул кунаклаган ташка игътибар иттем. Нинди таш икән ул—сынчы ясаган сыман—биле бар ул ташның.

—Саташа түгелме бу?—дип пышылдады Нәсимә.

—Юк, юк, саташмый,—диде Сәет, ишегалды уртасында сәхнәдәгедәй басып сөйләгән энесен күзәтеп.

Яббар башын күтәреп күккә карады:

—Һава әйбәт бүген.

—Участковый килде,—диде Сәет, энесен күктән җиргә төшерер өчен.—Сиңа район отделына барырга кушты.

Яббар бер дә исе китмәгән кыяфәт белән:

—Шулаймы?—дигән булды.

—Тузынуыңны бөтен авыл белә,—диде Сәет, шөбһәләнеп.—Әнсарга әллә ниләр әйтеп бетергәнеңне дә ишеткәннәр.

—Алай икән,—диде Яббар битараф тавыш белән.

—Авыл кешеләренең бөтенесе дә сине дошман итә дип уйласаң, ялгышасың, Яббар,—диде Нәсимә.—Сиңа хәзер үз-үзеңне кулда тотарга тырышырга кирәк. Авылны су басканнан соң халык нык үзгәрде.

Яббар моңсу иттереп елмайды:

—Кешеләргә ышанмыйм мин, Нәсимә. Ә шулай да миңа бүген искиткеч рәхәт!

—Участковыйны Әнсар чакыртмагандыр,—дип уйга калды Яббар. Аннары тереләнеп өстәп куйды.—Юк, юк, Әнсар түгел. Беткәнмени стукачлар. Алар гомергә булдылар, һәрбер авылның шикаять язучылары бар.

Күптән булмаган хәл, мөгаен, сугышка озаткан вакыттан бирле—Яббар килеп абыйсының иңенә кулын куйды:

—Абыем! Абыкаем! Төкер син аларга! Көн матур бүген. Табигать әле бөтенләй үк су астына китмәгән. Нинди гүзәл күренеш: су буе... көймә... ниндидер таныш түгел бер гүзәл кош сайрый... сынга охшаган таш ялтырый... һава сихәтле...

Шулай сөйләнә-сөйләнә Яббар капкадан чыгып китте.

—Табигать турында сөйли башлагач тынычлануыйдыр инде,—диде Нәсимә, сөенеп.—Аллага шөкер. Син, Сәет, аңа каты бәрелмә инде. Әйткәннәренә түз. Тиздән тынычланыр. Тагын төрмәгә утыртып куймасыннар инде үзен, ярабби.

Сәет дәшмәде. Энесенең язмышы өчен борчылу күкрәк турысын газап тырнагы белән тырнап куйды. Алга таба ничек булыр? Нишләр бу Яббар, ничек яшәр?

Сәет кинәт эчке сискәнү тойды.

—Юк, Нәсимә!—дип сикереп торды ул утырган урынынннан.—Табигать

турында канатланып сөйләве гади тынычлану түгел ул!—Сәетнең йөзеннән төс качты.—Көймә, таш... Аның нишләргә җыенганын аңладым мин!

... Сәет су буена йөгереп килеп җиткәндә, томан эченнән тоныкк кына булып бер тап күренде. Кемдер көймә белән томан куелыгына йөзеп кереп бара иде. Ишкәкләрнең суны ялкау гына чыпырдатуы ишетелде.

Сәет, томанлы дөньяны ярып, бар көченә кычкырды:

—Яббар!

Томан эченнән җавап көтеп тыңлап торгач тагын кат-кат кычкырып карады:

—Яббар! Яббар! Яббар!

Җавап ишетелмәде. Сәетнең үз тавышы гына әрәмәләр ягыннан кайтаваз булып кабатланып су өстеннән каядыр таралып бетте. Сәет тагын томан эченә колак салып тыңлап торды. Көймәдәге кеше дә, көймә үзе дә томан эчендә тәмам югалды, ишкәкләрнең суны каерганы да инде ишетелми иде.

Әле бик озак карлыккан тавыш тирә-якны тетрәтеп яңгырап торды:

—Яббар! Яббар! Яббар!

## 35

Туып-үскән авылы баткан тарафка Сәет сәгатьләр буе карап утыра. Көн саен диярлек килә ул монда. Бүген су астында калган яшьлек болыннарын, кырларын күз алдына китереп утырганда ул ниндидер улауга охшаган тавыш ишетте. Күп уйланганнан колакка ишетеләме? Әллә саташумы бу?

Күп тә үтмәде, авыл ягыннан су буена таба берәүнең төшеп килгәне күренде. Сәет Әнсарны әллә каян ук таныды.

Кул биреп күрешкәч, Әнсар янәшә урнашып, беркавым дәшми утырганнан соң сорап куйды:

—Нинди улаган тавыш ул? Әллә миңа гына ишетеләме?

—Үзем дә аптырашта—кемдерме, нәрсәдерме улый,—диде Сәет, як-ягына каранып.—Сәер тавыш.—Аннары авыр сулап өстәп куйды.—Сәерлекләр күп инде ул монда.

Әнсар су өстенә ишарәләде:

—Безнең авыл әнә тегендә иде бит.

—Әйе. Аннан арырак зират иде.—Сәет тамагында төен тойды.—Үрмәләп булса да, тырнаклар кубарылып канга бата-бата булса да зиратны күчерергә иде. Ичмаса әнкәмнең каберен күчерергә тиеш идем мин.

—Кем уйлаган... Мин дә җанымның әрнүенә көчкә чыдап йөрим.

—Синең атаң-анаң исәннәр әле ичмаса. Аларның каберләре югалмаслык итеп алдан ук кайгырта аласың.

—Миңа да бик авыр, Сәет. Үземә үзем хуҗа түгел бит мин. Мин партия кешесе, должностьтагы кеше. Мәнә обкомга эшкә чакыралар. Мин сина дөресен әйтәм: күңелем тартмый, үземне лаеклы дип санамыйм шикелле, ә менә баш тартырга йөрәк җитми, куркам.

—Куркасыңмы...

—Син миңа бәлки ышанмыйсыңдыр. Үземә үзем хуҗа түгел мин.

—Ышанам. Без үзебезгә дә, үзебезнең язмышка да, үзебезнең туган туфрагыбызга да хуҗа түгел! Без Туган ил дибез, ә үзебезнең туган җиребезне саклый алмыйбыз. Каһарманнарыбызны да, сатлыкҗаннарыбызны да үзебез билгеләмибез, тегендәгеләргә карап хәл итәбез, алар бизмәнендә үлчәп бәялибез. Без Ватан өчен сугыштык, әмма без үз Ватаныбызның хуҗалары түгел. Безне дә, Ватаныбызны да кемнәрдер үз мәнфәгатьләре өчен файдаланалар. Без зур, бөек төшенчәләр белән сату-алу итәбез, ә бер-беребезнең кадерен белмибез. Туган ил, туган җир дибез... Ә без аны

саклый алабызмы? Күпме корбан биреп туган якны яклый алмыйбыз, хәлебездән килми.

—Нишлисең бит...

Алар шактый вакыт тып-тын суга карап утырдылар.

—Арабызда туган җирен иң нык яратучы Яббар булгандыр,—дип куйды Сәет.

—Мөгаен, шулайдыр.

—Ул сатлыкҗан түгел иде!—диде Сәет катгый тавыш белән.

—Нинди сатлыкҗан булсын ди ул!—дип җөпләде аның сүзен Әнсар.

Әллә каян—сунын күренмәгән ярыннанмы, арттагы, әрәмәләр эченнәнме—янә улаган тавыш ишетелде. Елауга охшаган бу тавышны икесе дә аңларга тырышып киеренкелектә утырдылар.

—Гомер уза-а-а,—дип сузды Әнсар, сәер тавыш ишетелми башлагач.

—Әйе, мең тугыз йөз җитмеш беренче елда, шушы халәттә синең белән икәү шушылай утырырбыз дип кем уйлаган. Улым унсигез яшьтә, кызым уналтыда бит инде.

—Улың кайда укый?

—Авиация институтында. Кызым Сөнбел врач булырга хыяллана.

Алар әңгәмәнең бик четрекле, бик җайсыз, ләкин шул вакытта кагылмыйча үтәргә ярамаган турына килеп җиткәнне икесе дә аңлыйлар.

—Яббарның улы Вәсимгә дә уналты тулды,—диде Сәет беркавым дәшми торганнан соң.

Әнсар үзенең кызы Сөнбел белән Яббарның улы Вәсимнең соңгы вакытта очрашып бергә йөрүләре турында сүз катмакчы иде, шулай да тыелды, әйтмәде. Тып-тын гына суга карап һәрбересе үзенекен һәм икесенә дә кагылганын уйлады.

Кызының Яббар улы белән дуслашып йөри башлауларына чынлап та нык борчыла Әнсар. Ничек була инде бу? Кешедән ару түгел. Казанга, обкомга күчәр алдыннан гына бер дә яхшы яңалык түгел бу. Дөрес, болай начар егеткә охшамаган, шулай да...

Вәсим инде ундүрт яшеннән үк үзе Кызылъярга Сәет абыйларына кайтып йөри башлады. Яббарның улы икәнлеге мәгълүм булгач, авылда ана башта кырын карадылар. Җитмәсә төс-биткә коеп куйган Яббар иде инде менә. Әмма Вәсим бик авыл җанлы, кешеләрне яратучан, тиз аралашучан булганлыктан, аңа авылдашларның мөгамәләсе тиз арада яхшы якка үзгәрде, аны, бәхетсез бала дип, кызгандылар, атасы өчен җавап бирергә тиеш түгел, егетнең бер гаебе дә юк, диделәр. Сәет белән Нәсимәгә исә, балалары булмаганлыктан, Вәсим үз уллары кебек якын иде.

1971 елның сабантуенда Вәсим Сөнбел исемле бер гүзәл кыз белән танышты. Аның Әнсар кызы икәнлеге егетне һич кенә дә пошаманга калдырмады, чөнки кызга ул үлеп гашыйк булды. Авыл халкы аларның кичләрен җитәкләшеп уенныкка баруларын күргәч, әлбәттә, пыш-пыш килделәр, бик каты гайбәт чәйнәделәр. Унҗиде яшьлек егет белән уналты яшьлек кызның арасындагы якынлыкны күреп, кайбер ачы телләләре: «Ходай Әнсарга Яббарның рәнҗүен китерә»,—диделәр. «Әнсар белән Яббар арасындагы дошманлык балаларында дәвам итмәгәе»,—диючеләр дә булды.

Ә ике яшь йөрәк, беркемгә, бернәрсәгә карамыйча, бер көйгә типте, алар бер-берсен ныклап, саф күңелләргә генә хас сөю белән ярата башладылар һәм алар әлегә Вәсимнең әтисен, аның фаҗигале язмышын бер тапкыр да телгә алмадылар.

Сөнбел белән атасы да анасы да сак кына сөйләшеп карадылар. Әмма кыз Яббар белән кача-кача барыбер очрашты. Аптырагач, әле жәй уртасы гына булса да, Сөнбелне авылдан алып киттеләр—район үзәгеннән Казанга күченергә жыенулары бик унай сәбәп булып чыкты. Озакламый Вәсим дә Сөнбелдән башка авылда ямь тапмыйча анасы янына Куйбышевка кайтып китте.

Кыз белән егет хат алыша башладылар. Куйбышев белән Казан арасында хатлар тиз йөргәнлектән, алар хатларында үзләренең хисләрен аңлатып рәхәтләнделәр.

Тиздән Казанда очрашу хыялы икесен дә канатландырып торды—Вәсим университетка керергә жыена иде.

## 36

Су буенда серле һәм изге урын барлыкка килде. Батып калган авылны, зиратны, су астында югалган яшәү рәвешен, харап булган гореф-гадәтләрне, гаип булган тиңсез бер мохитне, изге догаларны, шул догаларга бәйле авыл халкының тарихын сагынып утыра торган мәйданчыкка әверелде бу урын.

Әрәмәлек янындагы бормалы сукмактан, баеп килүче кояшны куып тотарга, тоткарларга, шушы көннен кочагыннан аны беркая да жибәрмәскә ниятләгәндәй, зәңгәр күлмәкле үсмер кызның йөгергәне күренде. Су буендагы яшь егет аны абайлады, каршысына таба омтылды.

Кыз каушанкырап ике-өч адым житәрәк туктады. Егет тә югалыбрак калды шикелле. Тыннар капкан бу мәлдә ике гашыйк арасындагы берничә адым бик якын да, шул ук вакытта мәңге үтә алмаслык та ара иде. Ике йөрәк атылып чыгып, пар кошлардай күккә томырылып очып китәрләр шикелле тоелды.

—Вәсим, сәлам!—диде кыз, көчкә сулыш алып. Аның «Вәсим, сәлам!» дип әйтүен егет бик ярата, кыз моны белә, шуна күрә үзе дә яратып аны гел шулай сәламли.

—Сәлам!—Егет кызны кочаклады, аннары күтәреп алды, кычкырып бөтерелә башлады.—Сәлам, сәлам, сәлам! Сәлам, Сөнбел!

—Булды, булды, төшер, башым әйләнә,—дип ялварды кыз, чәпәләнеп. Аяклары жиргә тию белән, берничә адым артка күчеп, осталык белән үрелгән коңгырт чәч толымын, егет күрсен өчен, жинел хәрәкәт белән алга, түш ягына күчереп салды.—Кайтканымны каян белдең?

—Машинагызны күрдем,—диде егет, кыздан күзләрен алмыйча.

Аның күз карашыннан кыз оялыбрак китте, хәтта тавышы да чак кына ишетелерлек чыкты:

—Сүземдә тордым, чәчемне үстерәм.

—Берүк кистерә күрмә,—диде егет.

Алар култыклашып суга таба атладылар.

—Болай сөйләшик. Син мине үпкәләткән саен бераз кистерәчәкмен.

—Хәйләкәр кызый, чәчеңне кистерәсен килсә, тотасың да үпкәлисең, хәтта үпкәләрлек булмаса да.

—Юк инде, шаярып кына әйтәм. Сиңа ничек ошый, шулай үстерермен чәчемне. Монда киләсемне каян белдең?

—Без бит гел шушында очрашабыз.

—Әйе шул,—диде кыз куанычлы тавыш белән.—Ә кайсы вакытта киләсемне ничек чамаладың?

—Мин инде көндез үк килеп утырдым монда.

—Шундый сагындым сине, Вәсим!—диде кыз, тукталып.

—Минем сине ничек сагынганымны белсән иде, Сөнбел!

Алар су буенда утыручы агайны абайлап алдылар. Һава бөркү булуга карамастан, ул кыршалып, бәсәреп беткән иске плащтан иде. Хәрәкәтсез-кымшанусыз, тирә-якка бернинди ригаясез су өстенә карап ул үз уй-кичерешләре белән мәңге шушында утырырга дучар ителгән кыяфәттә иде. Аны сискәндермәс өчен, тавыш-тын чыгармыйча, яшьләр сак адымнар белән, сулгарак каерылып, таллыклар куерган якка юнәлделәр.

—Син үзең метеор белән кайттыңмы?—диде кыз, егетнең беләгенә ныграк ябышып.

—Әйе.

Сөнбел кинәт җитдиләнде, тавышында хәтта курку да яңгырады:

—Әтием Казанда очрашып йөрүебезне белә. Синең дә авылга кайтканыңны сизсә, хәлләребез мөшкел.

Вәсим туктап кызга текәлде:

—Ник, ул бит әле мине бөтенләй белми. Синең белән инде өч ел таныш булсак та.

Кыз егетне тагын култыклап алды, бернигә исе китмәгән кыяфәт белән алга таба атларга этәрде.

—Синең әтиең белән аның арасында ниләр булып беткәнне беләсең бит инде,—диде ул, әкрен генә, күпмедер ара узгач.—Әтиеннең язмышын тирә-якта белмәүче бар микән?

Вәсим тереләнеп китте:

—Минемчә, монда сәбәп әтиемнең язмышына бәйләнмәгән. Минем әтием белән синең әниең арасында мәхәббәт булган... сугышка кадәр. Шуңа мине өнәмидер.

—Синең ни гаебең бар!—диде Сөнбел уйчан тавыш белән.

—Ярар, алайса...—диде егет, кинәт кәефсезләнеп.

Сөнбел үзендә теләсә кемнең кәефен бер мизгелдә күтәрә алу сәләте барлыгын яхшы сиземли. Аның чибәрлеге, искиткеч ягымлы тавышы, йөзенең пакь сылулыгы, күзенең зәңгәрлеге каршында сулган гөл дә янадан чәчәк атар, мөгаен.

—Аптырама бер дә!—диде кыз, егетнең җилкәсенә йомшак йодрыгы белән сугып.—Төшенкелеккә бирелмә!

—Күңелгә шөбһә керде,—диде Вәсим, кызны иңеннән кочып.

Сөнбел туктап, никтер, як-ягына карап куйды.

—Нинди шөбһә?!—дип пышылдады ул.—Бернинди шик-шөбһәгә урын юк. Мин сине яратам, Вәсим! Син миңа шундый кадерле! Син миңа шул хәтле якын кеше!

Аның бу сүзләрен инде моңарчы ишеткәне булса да, егетнең йөрәге ярсып тибә башлады, эчтә гәүдә буйлап көчле дулкын уйнап үтте. Ул кызның битен ике яктан, кош тоткандай, саклык белән генә тотты, иреннәре белән аның иреннәренә тияр-тимәс кайнар итеп пышылдады:

—Чын әйтәсеңме?

—Чын булмаса, абына-сөртенә сине әрәмәләр арасыннан эзләп йөрер идемме?!—диде кыз, елмаеп.

Кинәт кичке эңгерне яңгыратып әрәмә ягыннан кат-кат яңгырады: «Сөнбел! Кызым! Сөнбел!».

—Әти мине эзләргә чыккан!—диде кыз, сискәнеп.

Тавыш якынайгач, алар таллык арасына кереп качтылар.

## 37

Бу вакытта плащлы кеше исә какшамас кыяфәттә уйга чумып утыра бирде.

Сөнбелнең әтисе, як-ягына карана-карана, аның янына юнәлде.

Читтәрәк туктап беркавым карап торгач:

—Сәет, синме бу?—дип эндәште.

Утыручы башта әкрен генә кайшалды, аннары борылып карады:

—Мин бу, мин. Исәнме, Әнсар!

—Исәнме. Утырасыңмы?

—Утырам,—диде Сәет, кул биреп күрешкәч.—Һава яхшы монда.

—Әйе, һавасы әйбәт,—диде Әнсар, янәшә утырып.—Мондагыдай һава башка беркайда да юктыр. Әллә шулай тоела гынамы.

—Озакка кайттыгызмы?—дип сорады Сәет, еракка караган килеш.

—Берәр атна торырга исәп бар,—диде Әнсар. Шуннан соң авылдашының ниләр уйлаганын аңлап өстәп куйды.—Мин дә шушында уйланып утырыр өчен ашыгып кайтам авылга.

—Әйе, тарта шул, тарта,—диде Сәет авыр сулап.—Көнаралаш шушында килми кала алмыйм.

—Ни хәлләрең бар?—дип кызыксынды Әнсар, шактый вакыт сүзсез утырганнан соң.

—Ничек дип әйтим... Ничә ел үтте, яна урынга тамыр җәя алмый җәфа чигәбез. Менә шундый хәлләр.

Әнсар кашларын җыерып, авылдашын гадәттәгечә тизрәк тынычландырырга, өметләндерергә тырышкандай кызу-кызу әйтеп куйды:

—Алай димә, алай димә. Авыл гөрләп яши бит. Тамырлар җәелеп килә.

—Барыбер без туып-үскән авыл түгел инде ул,—диде Сәет тоныкка кына тавыш белән.

Әнсар, сүзне авыл тирәсеннән югарыракка, дәресрәге, ерагракка кертәсе килеп:

—Гомер уза-а-а,—дигән булды.—Гадәттә, ни әйтергә белмәгәндә ул гел шулай ди.

—Әйе, уза,—дип аның сүзен куәтләде Сәет.—1974 елның да яртысын яшәдек.—Ул арткарак каерылып як-ягына карады.—Син кемгәдер эндәштен, ахрысы?

—Кызымны эзләдем. Иртәгә кунаклар киләсе, әнисе житешә алмый—эш күп.—Әнсар четерекле нәрсә турында сүз башлыйсы булганга тамак кырып куйды.—Очравың әйбәт булды әле. Яшьләребез турында синең белән сөйләшәсем бар.

Сәет әңгәмәнең ни хакында барасын чамалаганга күрә битараф кыяфәт белән үзе башлады:

—Беләм, Яббарның улы белән синең кызың бер-берсен ярата лар. Вәсимгә әйткәләп карадым инде мин. Үз кызың белән үзең яхшылап сөйләшү файдалырактыр.

—Егет кешедән дә күп нәрсә тора,—диде Әнсар, борсалануын яшермичә.—Син аның әтисе урынына калган кеше...

—Тагын бер мәртәбә әйбәтләп сөйләшермен. Аларның хисләре тирәннән, ахрысы, өч ел йөриләр бит инде.—Сәет көлемсерәп куйды.—Син шундый зур кеше, обкомда эшли торып кызыңны гына тыя алырсың, шәт.

—Көлмә,—диде Әнсар коры гына.—Кыз белән егет арасы—четерекле нәрсә.

Сәет күзләрен челәйтеп әңгәмәдәшенә карады:

—Су буена да кәчтүм-чалбардан килгәнсең. Обкомда кия торган кәчтүмеңме әллә?

Әнсар авылдашының чәнчүле сөйләшүенә аз гына да үпкәләмәде.

—Чыннан да, әрәмәдә мондый киемнән йөрү авыл халкы өчен сәердер,

сүз дә юк. Беренчедән, шушындый киемгә мин күнеккән инде, икенчедән, бу юлысы алмаш кием алып кайтырга онытканмын, югыйсә спорт чалбарларым да, җиңел күлмәкләрем дә күп.

Сәет билен язар өчен иеленкерәп куйды:

—Яшьләр өлкәннәрнең сүзенә колак салырга бигүк яратмыйлар инде анысы.

—Болай начар егеткә охшамаган ул үзе,—диде Әнсар көтмәгәндә.

Аның бу сүзе Сәеттә горурлык уятты:

—Менә дигән егет! КГУның тарих факультетына бернинди блатсыз керсен әле!

—Афәрин! Афәрин!—дип хуплады Әнсар.

—Яббар малае булганга борчылма инде син, бик әдәпле, яхшы тәрбия алган егет ул,—диде Сәет үтә житди кыяфәт белән.

—Юк, юк, аның кем малае булуында түгел хикмәт,—диде Әнсар бераз гасабиланып.—Ул да, кызым да бик яшьләр бит әле. Сак булсыннар, йөзгә кызыллык килмәсен дип борчылуым.

—Алар яшендә үзебез дә кызлар белән чуала идек инде,—диде Сәет, елмаеп. Шундук елмаю урынына аның йөзендә сагыш төсе күренде.—Ул вакытта әле Фатыйма киләчәктә синең хатының булыр дип уйга да килми иде.

Әнсарга исә әңгәмәнең бу өлеше, никтер, җылы тәэсир ясады. Коры гына, җанга ятышсыз әңгәмә корырга исәп итүен дә онытып, ул:

—Дөресен әйткәндә, Фатыйма Вәсимны бик ошата,—дип әйтеп салды.—Сөнбелебез бик әйбәт егет белән йөри, сүз әйтмә, ди.

—Шулай булгач!—диде Сәет үзе дә сизмәстән кинәт укталып.

Әнсар уфылдап урыныннан кузгалды:

—Ярар, кайтыйм әле мин. Аларны күрсән, әйт, Сөнбелне әнисе көтә—иртәгәгә кадәр тәмамлыйсы эшләр күп.

—Очрасалар әйтермен,—диде Сәет утырган урыныннан кымшанмыйча.

Әнсар, кулын каш өстенә куеп, кояшны үзенә алган мәгърип ягына карап торганнан соң, салмак кына адымнар белән әрәмәлек буендагы сукмактан авылга таба атлады.

«Менә Әнсар, язмыш ул ничек уйнаклый. Һаман безне бер сукмаклардан йөртә. Инде тормышлар үз калыбына кереп, баштан кичкәннәр бары тик хатирәләрдә генә калгандыр, күңел җәрәхәтләре генә булып сакланадыр дигәндә, араларда яңа бәйләнешләр булырга тора түгелме. Яббар яшәешегездә мәңге катнашачак, ул исән, аннан башка тарихыгыз да, киләчәгегез дә юк дигән билге түгелме соң бу! Яббар, Яббар! Син, энекәшем, бәлки барысын да күрәсеңдер, безне күзәтәсеңдер. Әгәр дә без күз алдында икән, син инде, мөгаен, күрәсеңдер—җан тынычлыгына беребезнең дә әле ирешә алганы юк.»

Вәсимнең килеп чыгуын Сәет сизми дә калды, егет, якты елмаеп абыйсы янына килеп утырды.

—Сөнбелең кайда?—диде Сәет, көлемсерәп.

—Сез Әнсар абый белән сөйләшеп утырган арада озатып куйдым,—диде Вәсим.—Аннары сүзне икенчегә борыр өчен генә:—Күптән утырасыңмы?—дигән булды.

Җавап урынына ул коры гына сорау ишетте:

—Сөнбел белән Казанда да очрашасызмы?

Егет тереләнебрәк китте:

—Әйе.

—Ул медицинскийның нинди факультетында укый?

—Лечебный факультетында. Терапевт булачак.

—О-һо-о-о,—дигән аваз белән Сәет соклануын белдерде.

—Ул әле беренче курсны гына тәмамлады,—диде Вәсим, елмаеп.

—Син үзең инде олыгайдың—икенчене тәмамладың,—дип үчекләде аны Сәет.

—Шулай шул,—дип көлемсерәде Вәсим.

Сәет егеткә шактый вакыт текәлеп карап торды.

—Син аның кем кызы икәнен беләсеңме соң?—дип сорады ул егетнең әллә кичке җиләслектән, әллә абыйсыннан шүрләүдән беләкләрендә бала йоннары кабарганга игътибар итеп.

—Беләм,—дип җавап бирде Вәсим абыйсының күзләренә карарга базмыйча, карашын су өстендәге ераклыкка юнәлтеп.—Минем атам белән Әнсар абый арасында нәрсә булганына гына төшенеп бетмим.

—Мин аларның арасында ниләр булганны сөйләргә телим. Сөнбел инде беләдер. Ана атасы йә анасы сөйләми калмагандыр. Сиңа да сөйләр вакыт җиткәндер.

Вәсим шуны гына көткәндәй кинәт Сәеткә таба борылды:

—Сөйлә!

Сәет озак сөйләде, сөйләгәндә җаны сулык-сулык җылады. Барысын да сөйләде. Инде караңгы төште, төн җитте, ә ул сөйләде дә сөйләде. Яббарның фаҗигасен дә, һәммәсенекен дә, һәрберсенекен дә, яккан учакны янарта-янарта, бәян итте.

Аның сөйләгәннәре Вәсим өчен зур ачыш булмады. Ана мәгълүм булмаган нәрсәләр күп түгел икән ләбаса.

—Сәет абый, мин бит боларны белә идем,—диде Вәсим тыныч кына, абыйсы, ниһаять, бәянен тәмамлагач.—Син сөйләгәннәрнең күбесен әниемнән ишеткән идем инде мин. Әтием бит анардан берни дә яшермәгән.

—Син бит әтием белән Әнсар абый арасында ни булганын белмим дигән идең?

—Белмим түгел, төшенеп бетмим дигән идем мин.

—Ә Сөнбелең беләме соң?

—Белә.

—Беләдер шул, Әнсар сөйләми каламы соң инде.

—Әтием әнигә туган авылы турында, табигать турында, авыл кешеләре турында шундый оста, матур итеп сөйли торган булган. Шунысы кызык, ул һәрвакыт авылыбызда бик яхшы кешеләр, матур, эшчән халык яши дип сөйләгән, гәрчә авылдашлары аны дошман итсә дә. Улыңны Кызылъярга алып кайтачаксыңмы, дигәч, бераз үсә төшсен әле, үскәч алып кайтырмын дигән булган ул әнигә.

Сәет дымланган күзләрен кул арты белән сыпырып алды:

—Син безнең нәселнең дәвамы, синең тамырлар монда, шуны онытма, Вәсим.

—Сәет абый, шулай да... әтием батып үлдеме?

—Төгәл әйтә алмыйм. Бәлки көймәне агым иркенә куеп агып киткәндер.—Аның тавышында кинәт катгыйлык яңгырады:—Юк, юк, юк! Ул батмады, ул китеп барды. Бездән китте. Әнкәй янына китте. Ул үлмәде. Ул әнкәебез янына китте. Әнкәй исән чакта кешеләрнең мыскыллавына да, рәнҗетүләренә дә түзәргә риза иде ул. Әнкәй үлгәч, кимсенүнең генә түгел, яшәвенең мәгънәсен югалтты ул. Иң авыр чагында аны бердәнбер кеше ташламады һәм яратты—әнкәй. Ә без, калганнарыбыз, бары тик

менә шушында килеп, авыл белән зират баткан тарафка карап, Яббар агып киткән тирәне күзләп, офтанып, үкенеп кенә утыра алабыз. Юк! Ул батмады! Синең атаң Яббар батмады, юкка чыкмады! Ул әнкәй янына китте. Бу салкынлыкка, бу вәхшилеккә түзалмыйча, аз гына булса да жылылык өмет итеп әнкәй янына китте ул.

## 38

Әй язмыш! Бигрәк сәер һәм шул ук вакытта кызык бу дөнья. Сөнбелнең әнисе Фатыйма белән Васимнең әтисе Яббар яшь чакта бер-берсен яратканнар. Ә менә хәзер, еллар үткәч, Яббарның улы белән Фатыйманың кызы арасында кайнар мәхәббәт, алар бер-берсен минут саен сагынып яшиләр, киләчәкне фәкать кулга-кул тотышып барган сурәттә генә күзаллыйлар.

Васимнең әтисенә ниләр генә күрергә туры килмәгән, башкайларына ниләр генә төшмәгән һәм Әнсар абый белән аның арасында ниләр генә булып бетмәгән! Ә барыбер әтисе белән Әнсарны дошманнар итеп күз алдына китерәсе килми Васимнең. Әнсар абый бит Сөнбелнең әтисе! Ә Яббар—аның, Васимнең әтисе. Аның күңеленә бу ике кеше дошманнар булып һич кенә дә сыймыйлар, хәтердә дә дошман булып сакланырга тиеш түгел алар һәм элек тә алар дошманнар булганнардыр дип ышанасы килми.

Васим Әнсар белән очрашуны үзе эзли башлады, ничек булса да Сөнбелнең әтисен аулакта очратып сөйләшү теләге аны инде ныклап эләктереп алды. Һәм андый мөмкинлек үзен озак көттермәде.

Авылга кайткач Әнсар кичкә таба су буена төшми калмый—моны Васим яхшы белә һәм ул беркөнне энгер-менгер вакытта ярда ялык-йолык янган учак янына ышанычлы адымнар белән юнәлде.

—Исәнмесез, Әнсар абый!—дип эндәште Васим, читтәрәк туктап, учак янында утыручыга.

Әнсар, егетнең килгәнен күрмәгәнгә, сискәнеп китте.

—Исән,—диде ул, кырын яткан жиреннән чак кына калкынып.

—Мин Васим, Яббарның улы,—диде егет, якын килеп.

—Мин сине беләм. Нишләп йөрисең?

—Сезне эзләп килдем.

—Мине эзлисе юк. Утыр учак янынарак. Калтыранасың.

—Каушаудан ул,—диде Васим, учак янына утырып.

—Каушаудан?!—дип көлемсерәде Әнсар.—Рас минем кызым артыннан йөрисең икән, син, әйдә, каушама инде. Безгә каушый торган кияү кирәкми. Хәер, бераз каушавың ярый анысы.—Ул шактый вакыт егеткә диккать белән карап торды.—Сөнбелне кыерсытма, яме, сак бул.

Васимнең учак жылысыннан кызарган бите тагы да ныграк яна башлады.

—Ничек инде кыерсытыйм мин аны!—диде ул, аптырап.—Яраткан кешеңне ничек кырсытмак кирәк, Әнсар абый!

Әнсар егеткә сынаулы караш белән карап:

—Син аны яратасынмыни?—дип гажәпләнгән булып кыланды.

—Яратам, Әнсар абый!—диде егет ихластан.

Әнсар көлеп куйды:

—Үзе каушыйм ди, үзе авыз тутырып, курыкмыйча, минем кызымны яратам дип утыра.

—Мин дөресен әйттем,—диде Васим, чыннан да нык каушавын көчкә йөгәнләп.

—Кайвакыт дөресен әйткән өчен дә эләктерәләр,—диде Әнсар серле тавыш белән.

Вәсим торып басты, беравык сүзен әйтә алмый торды, аннары кызып-кызып ярды да салды:

—Теләсә нишләтегез. Мин Сөнбелне яратам, аңардан башка яши алмыйм! Теләсә нишләтегез. Бәреп үтерсәгез дә риза!

Әнсар гәүдәсен арткарак каерып рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Вәсим аның көлүен ничек кабул итәргә белми аптырашта калды. Әнсар кинәт җитдиләнеп:

—Бәреп үтерсәң дә...—дип уйга калды.—Юк инде,—диде ул тирән сулыш алып.—Әшәкелекнең дә чиге булырга тиеш. Утыр әле, утыр.—Ул гәүдәсен турайтып, егетне җиңеннән тартып янәшә утыртты.—Шушы хәтле атаңа охшасаң да охшарсың икән. Бөтен килеш-килбәтең атаңныкы.—Егетне аркасыннан кагып куйды.—Маладис!

Вәсим Әнсарның аталарча мөнәсәбәтеннән җаны-тәне буйлап аңлатып булмаслык дулкын йөгергәнен тойды, унайсызланып башын читкә борды.

—Бу Сәет абыйның да яраткан урыны,—дип Вәсим, сүзне җинелрәк агымга кертәсе килеп.—Ул да монда озак-озак утырырга ярата.

Әнсар шактый вакыт куртка кесәләрен капшады, инде берничә тапкыр ян кесәдәге папирос кабына учы белән кагылды кагылуын, әмма кулы берне эшләсә, уйлары башкада иде аның, тәмәкесен һаман эзләде дә эзләде. Ниһаять, папирос кабын кесәсеннән чыгарды да, учак кырыннан башы янган кисәүне алып тәмәкесен кабызды.

—Безнең башка чарабыз юк инде, Вәсим,—диде ул, тирән итеп папиросын суыргач.—Шушылай утырасы гына калды.—Ул егеткә тагын текәлеп карады.—Син атаңа охшагансың. Ул әйбәт кеше иде. Яббар күргәннәрне күрергә язмасын... Сиңа гына түгел, беркемгә дә күрсәтмәсен...

—Нәрсәләр күрергә язгандыр инде, белгән юк,—диде Вәсим, олыларча уйга калып.

—Сезгә миһербанлырак замана килде. Кадерен генә белегез.

—Ярый ла ул заманның кадерен белеп, синең үзеңнең дә кадеренне белсәләр.

—Киләчәк сезнең, яшьләрнең кулына тапшырыла. Кеше кадерен белә торган җәмгыять төзегез. Коммунизм төзүне сез дәвам итәчәксез, хәзер инде калганы сездән тора.—Әнсар башын калкытып су өстенә карады.—Бөтен илне батыра гына күрмәгез.

—Кешенең кадерен ничек белсеннәр... Кеше хәтта үз фикерен дә әйтә алмый бит.

—Үз фикерен дип... Нинди фикер бит... Коммунистлар партиясенең фикеренә каршы булса, ул, әлбәттә, дөрес фикер түгел, аны әйтүнең кирәге юк.

—Зиратларны су астында калдыру фикере кемнеке?—диде Вәсим, ачыргаланып.—Тарихыңны бульдозерлар белән сөздереп, күмеп, суга батырып калдыру аерым кеше ниятеме, әллә партиянекеме?

Әнсар эчке сискәнү тойды. Ул хәтта куркып китте дисәң дә ялгыш булмас. Ул кискен хәрәкәт белән тәмәкесен учакка ташлады.

—О-о-о, Вәсим энем, алай сөйләшмә, үтенеп сорыйм, алай сөйләшмә,—диде ул, пышылдап.—Кирәкмәгән нәрсәне төзергә беркем дә тотынмый. Зур төзелешләр, ГЭСлар идеясе аерым кешеләр башында туа, ләкин ул идеяләр Ленин партиясе, Коммунистлар партиясе таләбе буенча туа. Мәскәүдә, Политбюрода, ЦКда авылларның, зиратларның су астында калуын телиләр дип уйлыйсыңмы әллә син?!

—Аңысы шулай. Ә аерым кешенең кадерен белү?!.

—Соң, шул аерым кеше өчен төзелә бит инде барысы да.

—Кемнедер җәберләп, кемнедер кимсетеп, кемнедер батырып башкалар өчен нәрсәдер төзү дөрес микән?

Әнсар белә—егеткә акыл өйрәтеп, нотык укып утыруда мәгънә юк. Яшь әле ул, ләкин сүзе хак. Шуңа күрә куркып китте Әнсар. Туган якның фаҗигасен, атасының фаҗигасен үз йөрәге аша үткәрүче япь-яшь җан иясе дөрес сүзләр сөйли, бәгырьләргә кадалырлык фикерләр әйтә. Ничек сискәнмисең дә, ничек куркып китмисең?!.

—Бик яшь әле син,—дип салкын гына елмайды Әнсар.—Берүк анда, университетта мондый темалар күтәрмә. Мин тәҗрибәле кеше, утны-суны кичтем. Синең өчен борчылып әйтәм: сак бул, артыгын сөйләшмә.

Вәсим кабаланып курткасының куен кесәсеннән блокнот чыгарды:

—Мин бер справочниктан укыдым, аны язып та алдым.—Ул учак яктысында кирәкле битне табып укырга тотынды.—«Куйбышевское водохранилище, в среднем течении реки Волга. Образовано плотиной Волжской ГЭС им. В. И. Ленина. Заполнено в 1955-57 годах. Площадь 5900 кв. км., объем 56 куб. км, длина 510 км, наибольшая ширина 27 км. Судоходство. Используется для орошения и водоснабжения. Рыболовство. На Куйбышевском водохранилище—порты Ульяновск, Тольятти и др.» Менә Әнсар абый, кыска гына мәгълүмат, коры гына саннар, ә күпме югалту, күпме фаҗига ята шушы су астында—бу хакта бернинди мәгълүмат юк.

—Их, энем, энем!—диде Әнсар, авыр сулап. Аның тавышы калтырый башлады.—Без барыбыз да бу турыда уйлыйбыз, кайгырабыз. Без теләгәнчә генә бармый шул тормышлар. Син тарих факультетында укыйсың, тарихчы булачаксың, күп нәрсәне эзләп, казып табачаксың, аңлаячаксың. Әлбәттә, барысын да әйтергә мөмкин булмас, ярамас... һәм кирәк тә түгел... Сез—яңа буын—безне вакыты җиткәч аңларсыз. Син әле яшь...

—Сез мине ачуланмагыз инде,—диде Вәсим, боек тавыш белән.—Әгәр дә дорфарак сөйләшкәнмен икән, гафу итегез.

—Юк, юк, гафу үтенеп утырма,—диде Әнсар һәм егетне аркасыннан сөеп куйды.—Бик акыллы егет син... Син хаклы, ләкин... сак бул. Үзенә хилафлык кылмасен.

Әнсар кайтып китте, Вәсим учак янында утырып калды. Ул үзе әңгәмәдән бик канәгать иде, Әнсар абыйга да ошады бугай бу сөйләшү дигән тойгы исә учак ялкынынннан да җылырак иде.

Шулай утка текәлеп әле генә узган сөхбәт тәэсирендә утырганда шатлык өстенә шатлык өстәп аның янына Сөнбел килде.

—Төшемме бу, өнемме?!—диде Вәсим, курткасын кызның иңенә салып.

Сөнбел түземсезлек белән егеткә текәлде:

—Нәрсәләр сөйләштегез?

Вәсим кулын өскә күтәреп бормалы хәрәкәтләр ясады:

—Сәясәт, халыкара обстановка... Әнә шундый җитди темаларга.

—Әйт инде.

—Әйттем бит инде.

—Ә безнең турыда?

Вәсим елмаеп кызны иңеннән кочты:

—Юк, сөйләшмәдек.

—Сөйләшкәнсез, сөйләшкәнсез,—дип бармак янады кыз.

—Белгәч, ник сорыйсың?

Сөнбел ярга таба атлады:

—Ә-ә-ә-нә тегендә булган Кызылъяр авылы. Күптән түгел монда

каяндыр укучылар экскурсиягә килгәннәр. Укытучылары сөйли икән: имеш, Кызылъярның бер кешесе читтән кайткан һәм... үзенең туган авылын тапмаган. Су астына киткән зиратта анасының кабере дә калган икән. Бу кеше беркөнне көймәгә утырып шул тарафка агып киткән дә кире кайтмаган. Шуннан соң аны беркайчан беркем күрмәгән. Ул юкка чыккан.

—Ул әнкәсе янына агып киткән,—дип Вәсим кызны кочагына алды.

—Күрәсенме, ул тарафлар Ай калыккач ныграк яктырган сыман,—дип пышылдады кыз.

—Миңа да шулай тоела,—дип пышылдады егет.

—Мин әниемнән бер җыр отып алдым, җырлыйммы?

—Җырла, Сөнбел, син матур җырлыйсың.

Яулыгымның чите белән
Авызымны капладым,
Тын алырга да базмыйча
Әкрен генә атладым.

Авазың ишетмәммe дип
Туктадым. Өнсез торам...
Нинди яулык белән каплыйм,—
Җаным җыларга тора.

—Бигрәк моңлы җыр,—дип егет кызны битеннән үпте.

Вәсим тоз тәмен тойды—кыз елый иде.

Бәхетле күз яшьләрендә үткәннәрнең кайгы тәме бар иде.

Шунда Вәсим аңлады: Сөнбел аның әтисенең, аларның нәселенең кайгысын да үзенекедәй кабул итә. Сөнбел аны ярата, ярата, ярата! Нәселенең барлык кайгы-хәсрәтләре белән, чынбарлыктагы яшәешнең азмы-күпме шатлыклары белән бергә кабул итеп ярата!

### 39

Егерме беренче гасырның бишенче елында Идел сусаклагычына илле ел тулды. Шул уңайдан кемдер экскурсия оештырган—олы яшьтәге укучылар төркеме томан арасыннан су буена килеп чыктылар.

Бу вакытта ярда уңҗиде-унсигез яшьлек бер үсмер егет су өстеннән еракка карап басып тора иде.

Шактый олы яшьтәге җитәкче хатын, күрәсең, класс җитәкчеседер, күп сөйләүдән карлыккан тавышын һаман кызганмыйча нәрсәдер сөйләде дә сөйләде. Су кырында басып торган егеткә аның тавышы отыры ачык ишетелә башлады.

—Балалар! Экскурсиябез дәвам итә. Хәзер инде ике мең бишенче ел. Узган гасырның нәкъ уртасында, илленче елны төзелә башлаган ГЭСның нәтиҗәсе буларак җәелгән бу диңгез. Чынлап та, моны кеше үз кулы белән тудырган диңгез дип атарга мөмкин. Ләкин шуны да онытмаска кирәк: ә-әнә теге калкулыкта урнашкан авыллар алар үз урыныннан күчерелгән авыллар. Алар су астында калган авыллар дип тә әйтергә хакыбыз бар, чөнки тарихи урыннары, зиратлар, бик күп йортлар, каралты-куралар күчерелми кала. Әнә теге Аулаш тавы итәгендә урнашкан авылның исеме Кызылъяр. Шул авылның бер кешесе хакында төрле риваятьләр йөри. Яббар атлы кеше, сугыш ветераны, авылларны, зиратларны су басканчы тизрәк күчерергә кирәк дип югары инстанцияләрдә йөргәне өчен төрмәгә утыртыла. Үзегез беләсез, коммунистлар режимы... Бу кеше төрмәдә чакта аның анасы үлә.

Яббар төрмәдән кайткач күрә—авыл халкын, йортлар салып, Аулаш тавына күчергәннәр, ә туып-үскән авылы, анасы күмелгән зират су астында калган. Бу кеше көймәгә утырып туган авылы баткан тарафка йөзеп китә. Шуннан бирле аны беркемнең күргәне юк. Кемдер әйтә, рәнҗеп, көймәгә утырган килеш агым белән каядыр аска таба агып киткән ди. Кемдер әйтә батып үлгән ди. Кемдер әйтә, үз теләге белән су төбенә киткән ди, кемдер әйтә әнисенең каберен су төбендә табарга маташканда баткан ди.

Шунда бер укучы малайның тавышы ишетелде:

—Ул кеше сугышта сатлыкҗан булган диләр. Имеш, легионер булган.

—Юк, дөрес түгел,—дип җавап бирде класс җитәкчесе.—Мин Кызылъяр кешеләреннән сораштырганым бар. Юк, сатлыкҗан булмаган, диләр. Авыллар, зиратлар турында күп шаулап йөрмәсен өчен, югарыдагы түрәләр аның хакында юри шундый хәбәр таратканнар, дип сөйли халык. Аны хәтта изге кеше дип санаучылар да бар.

—Аны эзләп тә карамадылар микәнни?—дип сорады бер кыз.

—Күрәсең, бу тарафтан китеп барган дигән версиягә күбрәк ышанганнардыр,—диде экскурсия җитәкчесе.

—Эзләргә теләүче булмагандыр инде,—диде берсе.—Мөгаен, батып үлгәндер ул.

Ярда басып торган егет экскурсантларга таба атлады:

—Дөресен мин беләм!—дип эндәште ул экскурсантларга.

—Ә сез кем буласыз?—дип мөрәҗәгать итте аңа класс җитәкчесе.

—Минем исемем Мөнәвир. Чыгышым белән шул Кызылъяр авылыннан.

Класс җитәкчесе егетне җентекләп күзәтте:

—Кем малае буласың, мин ул авылның кайбер кешеләре белән таныш?

—Әтием Вәсим, әнием Сөнбел исемле.

—Хәтерләмим,—диде укытучы, беравык кашларын җыерып Кызылъяр кешеләрен хәтерендә барлап торганнан соң.—Зур авыл бит ул. Дөресен беләм диден, ахрысы?

—Әйе, беләм,—диде Мөнәвир.—Ул Яббар атлы кеше батмаган. Агып та китмәгән. Ул бүгенге көнгә кадәр туып-үскән авылын, әнкәсенең каберен, уйнап үскән болын-кырларын эзләп йөри. Кешеләр үз куллары белән ясаган диңгездә—вәхшилек, битарафлык диңгезендә ерак бабалары күмелгән зиратны мәңге эзләп йөзеп йөриячәк ул.

—Ә сез каян беләсез?—дип гаҗәпләнде класс җитәкчесе.

—Беләм! Чөнки мин Яббарның оныгы!

*2004—2009 еллар.*



Хәмит
Латыйф

# ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

## Нурлы теләк

Җирдә изгелеккә урын бетмәс,
Мәңгелеккә булыр уй-хыял.
Җаның чистарынып яктылыктан,
Яшәүләрдән бары нур җыяр.

## Кеше

Йолдызларга карап, хыялында
Нидер эзли гомер буена.
Миллиард еллар ераклыгы
Сизелми дә хыял уена...

## Яшәү көче

Түзәр хәлең калмый әрнүләрдән,
Үз-үзеңә янып егылгач;
Яшәү көче яңабаштан килә,
Рухына кайтып сыенгач.

## Ачыклык

Иң буталчык мәсьәләләр
Туктата уйның көчен.
Гадилектә яши кеше—
Күпне төшенер өчен.

Хәмит ЛАТЫЙФ (1949) — *шагыйрь, нәкышьче-рәссам; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Туймазыда (Башкортстан) яши.*

* * *

Авыр чакта, җан киселгән чакта
Кеше җиргә ятып уйлана.
Кырык төрле уйлар йөргән башта
Яшәү яме тагын уяна.

* * *

Шикләнүдән башланган эш
Хәерле булмас бер дә.
Очына чыгалмаган уй
Орлык чәчәлмәс җирдә.

## Җан рәхәте

Бу дөньяда үз эшеңнең тәмен табып,
Синең эшкә чит кешеләр хәйран калса,—
Шуннан да зур бәхет юктыр дөньялыкта,
Ләззәтләнеп синең җаның рәхмәт алса.

* * *

Купме эзлә үткәннәрдән,
Чынга ашкан хыялдан—
Чәчеп киткән орлыкларын
Кемнәр кайтып җыялган?

## Чынлык

Һәр кешедә җанның ике чиге—
Ялган белән дөреслекне белү:
Хезмәт куеп көн дә үз җирендә
Чын язмышын үрү...

## Төшенмәү

Бу тормышның серен, мәгънәсен
Төшенмәссең һич тә сорап кына;
Күңел дөньялары җимерелә—
Аңламассың аны юрап кына...

## Үзең булу

Яхшы атлар хак сорамый,
Алар хакы инде билгеле.
Яхшы дуслар табу өчен
Үзең булу кирәк иң элек.

* * *

Хисләр ялкынын саклый бел—
Ул бит безнең җан көче.
Кешелегеңне яклый бел—
Изге булсын аң көче.

* * *

Усаллыкта яман өскә чыга,
Хыялыңны бирмә җимерергә.
Ничек кенә алдан хәстәр күрмә,
Ачу әзер җанны кимерергә.

* * *

Иманыңны күз карасы кебек сакла,
Хак эш өчен дөреслекне якла;
Кыю әйтә белү—кирәк сүзне башта,
Чокып юган төсле аны ташка...

## Үтенү

Ярдәм бирче, Ходам, моңлы булганнарга,
Түзем бирче күңеле тулганнарга!—
Рәхмәтеңне салчы сабыр-уңганнарга,
Өмет бирче ялгыз сулганнарга!..

## Чатлар...

Алда тора төрле-төрле юл чатлары,
Шул чатлардан башланадыр юл башлары;
Анда-монда аунап ята юл ташлары—
Ниләр күрер атлар белән ир башлары...

## Югалту

Җилгә калыр язмышыңда барчасы да,
Гомер тырышып тапкан малы, акчасы да,—
Хәрәм җыйма, кереп кеше бакчасына—
Беркөн килеп югалтырсың барчасын да...

## Татарлык


Изгелекләр ташламасын, Ярабби,
Тормыш үтсен илем күген каралтмый,
Чит кавемнән үзебезне санатмый,
Яшик әле татарлыкны таратмый...

## Саклану

Үзең сакла, и Ходаем, хәрәм малдан,
Дәгъва итмә кеше хакын, торып алдан.
Фәрештәләр гамәлеңне язар актан,
Чын хезмәттә барысын да үзең тапсаң.

## Картлар хәтере

Вакыт атларының дугасыннан
Кыңгыраулар чыңлый өздереп:
Яшьлекләре белән хушлашкандай,
Картлар кала: гомер узды, дип.



Мөнир Вафин

# КЕШЕ АТЛЫ ТУГАННАРГА...

* * *

Мин язлардан нидер көткән идем,
Язлар үтте. Җәйләр җиттеләр.
Өзелепләр көткән һәрберсе
Кысыр гына үтеп киттеләр.

Мин язларга хәзер ышанмыймын,
Бар ышаныч хәзер көзләргә.
...Көз алтындай сары яфрак түши
Язын салган минем эзләргә.

* * *

Сабый чакта әти белән икәү
Читән үреп, койма ныгыттык.
Казыкларын шундый тирән кактык,
Үзебезчә шундый нык иттек.

Әти какты, ә мин комган белән
Казык тишегенә су койдым,
Һәм әтине дәртләндермәк булып:
«Әйдә, манчы»,—диеп тукыдым.

Әй, манчыдык, шундый манчыдык без,
Су чәчрәде, җирләр селкенде.
Планетаның каршы төбәгендә
Җир тетрәгән диләр шул көнне.

«Сулап каксаң, улым, нык була ул»,—
Шушы сүзне тик бер ишеттем.
Мин сабыйга шул сүз җитә калды,
Ныгытам дип көн дә су сиптем.

Бисмиллалап әти каккан иде.
(Су сибүдә мин дә шомарган).

Мөнир ВАФИН (1961) — *шагыйрь, публицист; «Сүзләр чәчтем», «Дөнья — куласа», «Йөрәгем пәрәләре» исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

Ни могҗиза! Чаган казыклары
Бер көн килеп тамыр җибәргән.

Ул читәннәр череп таралдылар,
Ә казыклар үсте югары.
Могҗизалар ясый ала икән
Әтиләре белән уллары.

Бер көн килеп үзем әти булдым,
(Һәр нәрсәнең җирдә үз мәле)...
Нәни улым, нидер кылмак булып,
Чаган башларына үрмәли.

## Язу

Комга таяк белән яздым,—
Бу шәп шөгыль тоелды.
Әмма ләкин ул язулар
Озак тормый җуелды.

Агач, коймалар калмады,
Кыялар да, ташлар да.
Карны... кәгазь итеп «яздым»
Малай-шалай чакларда.

Күпме сөю хаты яздым
Кичләрен мыштым-мыштым.
Язып-сызып туйган чакта
Әнигә май язьштым.

Барлык гомерне үткәрдем
Ниләрдер яза-яза.
Әллә бу язу дигәнең
Тәкъдирем язган җәза?!

Инде хәзер шигырь язам.
(Монысы күңел мазам).
Әллә мазам, әллә казам,
Әллә акылдан язам?..

## Бу дөньяда бар да вакытлыча

Бу дөньяда бар да вакытлыча,
Үлемсезлек бирер юк дога:
Имән кадәр имәннәр дә чери,
Тимер кадәр тимер тутыга.

Имән, тимер, ташларны да узып,
Кеше заты туза иң элек.
Бу дөньяда бар да вакытлыча,
Гаделсезлек нигә мәңгелек?!.

* * *

Табигатьнең үзгә мәле,
Көннәр кышларга авыш.
Мал-туар, кош-кортлы йортта
Пычак кайраган тавыш.

Арыда чаж-чож, биредә чаж-чож,
Чаж-чожлар тагы, тагы.
Маллар күзе мөлдерәмә,
Малларның моңсу чагы.

Коймак-тәбикмәкләр чажлый,
Ир-ат пычак уйната.
Муллык-туклыкны уйлатмый,
Әллә ниләр уйлата.

Чырайларга туклык куна
Казанга ит салынса.
...Ә миндә каз йоны калка
Күзгә пычак чалынса.

* * *

Болай итеп ник яраттың, Ходай?
Миңа калган бүре буласы:
Ай кадәрле айның котын алып,
Рәхәтләнеп килә уласы.

Бүреләргә рәхәт, кан эчәләр,
Дүрт аякта ныклы торалар.
Тамак өчен тәмугларга кереп,
Үзләренчә дөнья куалар.

Үз тормышым белән үз дөньямда
Мин яшәр дә идем уйламый,
Кешеләр арасында гомер итеп,
Түзүләре авыр уламый...

* * *

Бу урында Алып батыр
Куккә карап яткан, диләр.
Аннан торып чабатасын
Рәхәтләнеп каккан, диләр.

Кеше әйтеп ышанмаслык,
Чабатага тулгач, тулган!
Дөбер-шатыр аккан туфрак
Мәгърур-мәгърур таулар булган.

Ул тауларга кешеләрнең
Карашлары төбәлгәннәр.
Кайберәүләр гомер буе
Үрмәләп тик менәлгәннәр...

Уңыш телим бакый-бакый
Кеше атлы туганнарга,
Җан-тир түгеп үрләгәндә
Миннән калган тузаннарга.

Рахман
Шәфигуллин

# ГАЙСӘ ЙОЗАГЫ

КЫЙССА

Мондый буранлы көннәрнең күптән булганы юк иде. Тегермәнлек авылының инеш буендагы йортларын кар күмеп китте. Иртәләрен күршекүлән бер-берен казып ишекләрен ачты. Тик менә җитмешенче яше белән баручы Сабира карчыкка гына килүче күренмәде. Хәер, ул көннәрдә сәгатен, тәүлеген санарлык булдымыни...

Сабира Ямашта иң матур һәм уңган кызларның берсе иде. Унсигез яше тулгач Тегермәнлек егете тракторчы Хаҗиәхмәткә кияүгә чыкты. Аның ир туганнары бик күп иде. Җыелышып инеш буена йорт салып бирделәр. Лапаскураларын үзләре җиткезде. Тормышларын матурлап, беренче балалары Гайсә дөньяга килде. Әмма яшь гаиләгә бер-берсен сөеп озак яшәргә язмаган булып чыкты. Сугыш башланды. Типсә тимер өзәрлек ир-егетләр бер-бер артлы китә торды. Күзгә каләр Хаҗиәхмәтне дә өч туганы белән фронтка алдылар. Танкист буларак ул Мәскәү янындагы каты бәрелешләрдә катнашты. Ара-тирә өчпочмаклы хатлары килгәләп торды. Ә 1942 елның гыйнварында рядовой Хаҗиәхмәт Мусинның батырларча һәлак булуы турында похоронка килде.

Сугыш елларында авыл итен-маен, ашлыгын кырып-себереп фронтка озата торды. Әле ир назын татырга өлгерә дә алмаган зәңгәр күзле, биленә кадәр төшкән кара толымлы Сабира сыер сауды. Ферма мөдире аксак Хәйри кырыс булса да, хатын-кызның иртә-кичен яртышар литр сөт алып кайтуына каршы килмәде. Шуңа күрә бәләкәй Гайсә катыктан-сөттән өзелмәде. Нык булып үсте.

Ирсез калган авылда тормыш бик нык үзгәрде. Табигый халәт үзенекен итте. Элек кешегә дә саналмаган кәкре-бөкре, чулак-аксак ирләр авылның карап торган таянычына әйләнде. Бөтен вак-төяк йомыш белән аларга барды халык. Хатын-кызларга да сүзләре үтә башлады. Авыл халкы моны күрде. Ләкин ни эшлисең, яшәргә кирәк...

> Өч аяклы Хәйри кергән
> Шәмсия капкасыннан,—кебек

яки

> Фронтка да йөз кукәй,
> Сәвиткә дә йөз кукәй.

Чыдар хәлләрем калмады,
Асылынам, түтекәй

—кебек җырлар телдән-телгә йөрде. Халык авыз иҗатына әйләнде.

Сабира да ир-егетләр күзеннән читтә калмады. Әмма ул тәкъдимнәргә катгый рәвештә: «Хаҗиәхмәтем сезнең өчен гомерен бирде, ничек оят түгел?!»—дия иде.

Сугыш бетте. Матур язлар килде. Гайсә үсте, 1947 нче елда беренче класска керде. Яхшы укыды. Әнисенә һәрчак ярдәм итте. Малайның куллары тимер эшенә бик хирыс булып чыкты. Инеш буендагы тимерче алачыгыннан кайтып кермәде. Бер күзле Габдрахманга булышты. Әгәр Тегермәнлектә генә калса, Гайсә язмышы бөтенләй башкача булыр иде.

Җидееллык мәктәпне бетергәч ул Казанга ФЗӨга китәргә теләде. Сабира карышмады. Әгәр белгән булса, ул үзенең йөрәк җимешен беркая да җибәрмәс иде. Менә егерме биш ел инде Сабира Гайсәне күргәне юк. Бик сагынды ул аны. Хәзер кырык дүрт тулгандыр, бәлки өйләнгәндер дә. Балалары да бардыр. Дөрес, ул ай саен әнисенә йөзәр сум акча җибәреп тора. Ләкин аны һәрчак төрле җирдән салалар. Төгәл адресы да билгеле түгел. Фәлән шәһәр. Главпочтамт.

Сабира хатлар да язып карады. Ләкин җавап килмәде. Милициядән эзләткәч: «Синең улың хәбәрсез югалды»,—дип җавап бирделәр. Сабираның тормышы, гомере менә шундый зур кайгы-хәсрәттә үтте. Озак та яшисе калмагандыр. Гайсәсен бер генә тапкыр күрсә дә дөньядан китәргә риза булыр иде. Ул кайчандыр әбисеннән бер гыйбарә ишеткән иде: имеш, бер акылдан язган ана үзенең баласын өзелеп көтә. Ул җомга намазы вакытында түбәгә менеп морҗа тишегенә дога укып, бөек Аллаһыдан, аның күктәге фәрештәләреннән һәм өй хуҗаларыннан малаенын кайтуын үтенә.

Авылдашлар моңа көлеп карый. Юләр хатын ни генә эшләмәс. Көннәрнен берендә авылга читек-кәвешен, өстенә матур күлмәк, башына чигүле кызыл түбәтәй кигән берәү кайтып төшә. Кыегаеп беткән кечкенә генә туган йортына турыдан-туры килә. Нигез туфрагын, әнисен үбә-үбә үксеп елый.

Рус-Төрек сугышына алынып, төрекләрдә пленда булган ди. Анда эшләп акча җыйган, баеп авылына кайткан. Әнисен дәвалап аякка бастырган. Калган гомерләрен бик матур дәвам иттергәннәр, ди.

Сабира моңа ышанмаган иде. Тик сагынудан, чарасызлыктан түзәр хәле калмагач, җомга намазы вакытында түбәгә менде. Морҗаны кочаклап, белгән догаларын укыды. Кыйблага карап бөек Аллаһыдан, аның фәрештәләреннән, йорт хуҗаларыннан Гайсәне кайтаруын үтенде. Шул арада каяндыр җил чыкты. Башындагы шәлен очыртып алып китте, чал чәчләрен тузгытты, болай да хәлсез куллар үзе суккан кызыл кирпечләрдән ычкынды. Ул түбәдән кар өстенә егылып төште. Аңын югалтты. Сабира күпме ятканын да, өйгә ничек кергәнен дә белми, хәтерләми.

***

Воркута шәһәре.

Колония өстендә колония. Кесә караклары да, кеше үтерүче рецидивистлар да биредә утыра. Үзенең өченче срогын тутыручы почетлы бур, медвежатник Гайсә дә шулар арасында. Төрмә, тоткыннар тормышына ияләнгән булса да, ара-тирә әнисен, туган авылын искә төшерә. Зонада утыручылар белән житәкчелек итә торган бурлар командасына кергәнлектән, тормышы зарланырлык түгел. Ләкин читлектә нинди бәхет булсын ди! Аның тоткынлыктан чыгу көннәре санаулы. Алда күпмедер вакытка ирекле тормыш, иректәге коллегалары көтә. Ә аннан соң кая барырга? Ничек яшәргә?

Гайсә бу сорауга җавапны озак эзләде.

Бер көнне төш күрде ул: имеш, туган авылы Тегермәнлек икән. Аның

өстеннән яктылык күтәрелә. Ә алда ап-ак чәчле хатын-кыз. Ул елый-елый Гайсәгә нидер сөйли. Артта хәрби киемле бер ир кеше елмаеп тора. Алар икесе дә Гайсәне үзләре янына чакыра. Ул саташып йокыдан уяна. Ни бу?! Нәрсә бу?!

...Гайсәнең дә киләчәккә планнары зурдан иде. Ләкин язмыш аның өчен башка юл әзерләгән булып чыкты. Бер ел ФЗӨда укыгач, Гайсәләр группасын ату кораллары житештерә торган хәрби заводка билгеләделәр.

Немец милләтеннән булган Август Рейхман житәкчелегендәге бәләкәй генә коллектив хәрби частьләр өчен сейфлар эшләп чыгара. Жиде үлчәм белән ачыла торган сейф йозакларын монда ике-өч кеше генә башкара. Өлкәннәр арасына сәләтле татар малае, Тегермәнлек егете Гайсә дә өстәлде. Тулай торакта урын, яхшы хезмәт хакы, кичке мәктәп—яшүсмер өчен ни кирәк тагын! Буш вакыты яки ялы булса, пароход белән Тегермәнлеккә әнисе янына кайта.

Көннәрнең берендә Август Рейхман Гайсәне бүлмәсенә чакырып алды. Казанның бер заводында баш бухгалтер ачкычын югалткан икән. Мәскәүдән дә белгечләр чакырткannar. Тик булдыра алмаганнар. Менә шуларга ярдәм итәргә кирәк ди. Немец останың остасы булса да, Германиядә эшләнгән трофейный сейфны ача алмаган. Йозак монарчы билгеле булмаган белгеч тарафыннан эшләнгән икән. Келәймәсендә өч XXX һәм ике ++ тора. Гайсә, йозакның ачкыч тишегенә махсус пластинка тыгып, дүрт юнәлештә аның формасын кәгазьгә төшерде. Аннан соң үзе эшли торган завод цехында ачкычын да ясап куйды. Ни хикмәт, серле немец белгече ясаган катлаулы йозак Гайсәгә бирешtе. Сейф ачылды. Бу эшне күзәтеп торган НКВД һәм милиция кешеләре шул ук көнне Гайсә Мусинга махсус «Дело» ачтылар. Мондый талантларның саны илдә берничә генә булып чыкты. Банклар, зур предприятиеләрне баса торган бурлар дөньясында да Гайсә кебекләргә бик хөрмәт ди.

Пенсия яшендәге Август Рейхман эшләгән заводны сугыш вакытында Ленинградтан Казанга күчерделәр. Балалары кабат үзе туган шәһәргә кире кайтып китсә дә ул биредә калган. Ата-бабалары да Идел буенда тормыш иткән. Немец шуна күрә: «Бу якларны яратам»,—дия иде хезмәттәшләренә.

Тормыш акрын гына үз жае белән бара. Гайсәгә Армиягә китәргә ике ай калганда, остазы Август Рейхман бик күңелсез йөри башлады. Тиздән аның сәбәбе дә ачыкланды. Сейф белгечен Ленинград авторитетлары гаять жаваплы «эшкә» чакырганнар. Әгәр каршы килсә, балаларына көн бетәчәк, дигәннәр. Ни эшләргә? Әгәр, ризалык биреп тә, ярдәм итә алмаса? Аны шунда ук теге дөньяга озатачаклар! Ул бу хакта Гайсәгә елый-елый сөйләде.

—Синең югалтыр кешең юк. Кулыңнан да килә. Бәлки тәвәккәлләрсең, Питер бурлары бик гаделләр. Авырлыкка тарыганнарны беркайчан да ташламыйлар, ди ул.

Яшьлек юләрлеге беләнме, әллә татарлык күндәмлегеме—Гайсә ризалык бирә һәм авылга әнисе белән саубуллашу өчен дип бер атнага ял ала. Кая барасы, кемгә мөрәжәгать итү хакында немец телдән әйткән була. Кулына чит кеше исеменә бирелгән паспорт һәм акча тоттыра.

Ленинградның тимер юл вокзалына килеп туктауга, Гайсәне юантык гәүдәле ике ир каршылады. Икесе дә мыеклы. Икесенең дә кулларында алтын печатка, авызларында берәр алтын теш.

—Безнең вакыт бик чикле,—диде Гарри дигәне.—Сина иң жаваплы вазыйфа йөкләнә. Иртәгә кичен бер объектта өч сейфны ачарга кирәк. Исәп-хисап соныннан. Не обидим.

Смольныйдан, ерак түгел бер бик бай фатирда ял итте ул. Сейфларның фотоларын карады. Эшкә кирәкле инструментларын барлады.

Объект дигәне диңгез портының бухгалтериясе икән. Соныннан гына белде—анда чит ил акчалары саклана ди. Эшкә керешер алдыннан берничә мәртәбә репетиция ясап карады.

Гайсә «команданың» төгәл һәм пөхтә эшләвенә бик нык гажәпләнде, һәр

кеше үз эшен белә. Сөйләшү дә, артык хәрәкәт тә юк. «Эшнен» үзенчәлегеи истә тотып, һәр кеше дингезче киемен киде. Алар объектка ремонтчылар буларак үтеп керделәр. «Балыкчылар» бу эш белән шөгыльләнгәндә, өчесе бик тиз генә бухгалтериянең пультка тоташтырылган ишекләрен ачтылар. Аннан сейфларга чират житте.

Гарри Гайсәне ашыктырып торды. «Шеф, безнен вакыт чикле. Өч сейфка 10 минут»,—диде. Биредә дә трофейлы сейфлар Казандагыларнын «игезәкләре» булып чыкты. «Остазнын» кинәшләре ярап куйды, Гайсә заводтагы жайланмаларны да алган иде. Тиз арада сейфлар ачылды. Аның эчендәге пачкалы долларлар махсус капчыкларга тутырылды. Гайсәгә дә беразын салдылар. Сөйләшенгәнчә, бинаны чыгуга «дингезчеләр» төрлесе-төрле якка таралышты.

Инструкция буенча алар иртәгесен Гарик фатирында очрашырга тиеш иде. Порттан чыккач, Гайсә үз киемнәрен киде. Төнне Восстание урамында урнашкан тимер юл вокзалында үткәрде. Пачка-пачка долларлы рюкзагын асып Невский проспектында йөрде. Борынгы биналарны, колонналарны карап сокланды. Тик үзенең олы жинаять эшләгәне аңа тынгы бирмәде. Кемгәдер яхшылык эшлим дип, үзенең харап булуы бар бит? Кем ул Гарик? Аңарга ышанырга буламы? Туган авыл, әнисе...

Гайсә иртәгесен билгеләнгән фатирга барды. Өченче катка менде. Звонок төймәсенә кат-кат басты, әмма ачучы булмады. Күп булса, биш-ун минут узгандыр, астан йөгергән тавышлар ишетелде.

—Руки вверх! Ноги на ширине плеч!—дигән команда Гайсәне һушыннан яздырды. Ул арада пүнәтәйләр чакыртылды. Рюкзактагы әйберләр тикшерелде. Кыскасы, Гайсә кулга алынды. Аеруча куркыныч жинаятьче буларак, аны Литейный проспектында урнашкан «Серый дом»га китереп яптылар. Әлеге бина 20 нче елларда салынган икән. Өстә сигез этаж булса, жир астындагысын да шул кадәр диләр.

Тикшерүче, озын буйлы, сары чәчле кысыграк күзле ир уртасы кеше өстән-өстән генә сорады да: «Сиңа адвокат кирәк булыр. Мин Давид Прицкер дигән юристны тәкъдим итәм. Калганын соңыннан сөйләшербез»,—диде. Прицкер дигәне чал чәчле, урта буйлы, бик ыспай киенгән яһүд кешесе икән.

—Мин синең «Дело»ң белән таныштым. Әгәр барлык гаепне үзеңә генә алсаң, хәлең төрмәдә дә яхшы булыр, шуңа күрә син бер кешенең дә исем-фамилиясен атамыйсың, берни белмисең! «Казаннан килеп, дингез порты бухгалтериясен бастым. Сейфларны ачу буенча белгеч булгач, максатка ирешү авыр булмады. Белдем—бардым—алдым...» Синең легенда шуннан гыйбарәт.

Күп нәрсә сатылганлыктан суд, милиция, төрмә хезмәткәрләренең дә күбесе акча коллары иде. Дөньяны дер селкетеп торган СССР державасында да халыкара, дәүләтара караклар системасы ул елларда чәчәк атты. Илнең иң зур шәһәрләрендә «Законлы бурлар» идарә итте. Төрле юллар белән «общак»ка килгән акча дәүләт хезмәткәрләренә түләргә, төрмәләрдә утыручы «братвалар»ның хәлен яхшыртуга тотылды. Гайсә хезмәт күрсәткән Гарик командасы да шуларның берсе иде.

Чит илләргә китәсе дингез теплоходларының хәрәкәтен тәэмин итү өчен тотылачак долларның күп булуы (бәлки ул башка максатларга да бирелгәндер?), бу «ЧП» аркасында зур-зур чиновникларның жавапка тартылачагын истә тотып булса кирәк, процесс ябык ишекләр артында барды.

Әлеге хәтәр эшне башкару өчен айлар буена әзерлек алып барылды, кирәкле кешеләр табылды; шул ук вакытта эзсез генә акчаны яшерү һәм жинаятьтән читтә калу кебек мөһим оештыру чаралары да башкарылды.

Ә жавапны гөнаһсыз тотты. Гайсәгә ун ел чәпеделәр. Ул ике ел

Новгород төрмәсендә булды. «Кум»га (төрмә начальнигына) акча өзлексез түләнгәнлектән Гайсә биредә авторитетлар арасында иде. Ни теләсә, шуны ашады, китапханәгә йөрде, калган вакыты зонада үтте.

Иреккә чыгуга, шул ук команда кешесе каршылады. Бераз ял иткәннән соң, Таллинда банк бастылар... Унбиш ел Вильянди төрмәсе... Хәзер Воркута...

***

Сабира карчык бердәнбер җан иясе—мәчесе Каракайның ишекне тырный-тырный кычкыруыннан уянып киткәндәй булды. Күзен ачса—өйдә караңгы, салкын. Сул ягы бөтенләй җансыз. Уң кулы белән битен сыпырды, чәчләрен тарагандай итте. Көч-хәл белән генә ут кабызды. Мичне тотып карады—анысы бөтенләй салкын иде. Алдан әзерләнгән утыннарны барлап, ут тергезеп җибәрде, ләкин янмады. Төтене кире килде...

...Сабира карчыкның йортын бер атнадан соң гына килеп ачтылар. Мәетне аның кануннарына туры китереп җир куенына иңдерделәр. Мәрхүмә егерме биш ел буена Гайсәдән килгән акчаны яна өй салырга җыеп барган икән, аны яңа мәчет тергезергә тотарга дигән карарга килделәр. Сабира карчыкның яраткан мәчесе Каракай да хуҗасы җирләнгәч читкә китеп югалды...

Егерме биш ел гомерен төрмәдә уздырган почетлы зэкны иректә коллегалары кадер-хөрмәт белән каршылады. Баштанаяк яңа кием бирделәр. Воркутаның иң кыйммәтле «Север» ресторанында мәҗлес оештырылды. Ленинградтан килгән законлы бур—«Седой» сүз алып, Гайсәнең керткән өлешен, бурлар законына тугры булып калуын истә тотып, бриллиантлар белән бизәлгән платина печаткасын бүләк итте.

—Сине бүтән беркем дә борчымас. Менә монда компенсация,—дип кара дипломатны кулына тоттырды.—Документлар чиста. Теләсә кая бара аласың. Гаилә кор. Яшә. Тик шулай да Казанга кермәсәң яхшырак булыр...

Гайсә тоткынлыкта булса да тәмәке тарту, хәмер эчү, кеше кимсетү кебек хәрәм сыйфатлардан сакланды. Күпләп китап уку, дингә тартылу аны үз кыйбласыннан аермады. Ул сынмады. Рухы белән, эчке дөньясы белән чиста-саф калды. Егерме биш ел эчендә авылы, туганнары, офыклар артындагы манзарага әйләнсә дә, күптән түгел күргән төше, ап-ак чәчле әнисе һәм хәрби киемдәге әтисе исеннән чыкмады. Әгәр әнисе исән булса, аннан тизләнеп гафу үтенергә, үзенең исәнлеген белдерергә дигән карарга килде.

...Ата-бабаларыбызның каны тамган Казан, чирек гасыр үтсә дә әле үзгәрмәгән. Шул ук «Кольцо», Кремль, ул яшәгән Ягодный бистәсендәге соры төстәге ямьсез ике катлы агач йортлар...

Тәтеш кызы Гөлдания белән шушы урамнардан йөргәндә зур планнар корган иделәр. Бер ялгыш адым барын да юкка чыгарды. Гайсә Гөлданиянең язмышын бозмас өчен хат та язмады. Кая киткәнен дә сизлермәде. Китте, бетте, юкка чыкты. Төрмәдә дә ул Август Рейхман биргән паспорттагы Мавлин Илдар Алиевич исеме белән утырды. Хәзер ул, егерме биш ел Воркутада шахтер булып пенсиягә чыккан, Салиев Азат Кәбирович. Туган җире дә—Саратов өлкәсе.

Гайсә төрмәнең озын төннәрен, ямьсез көннәрен кичергәндә, үзенең гомерен кат-кат сүтте, барлады. Тайгак юлга этәргән остазына бәддога укыды. Кемнәрнеңдер бай һәм мул тормышын тәэмин итәр өчен үзенең корбан булуына йөрәге сыкранды. Үткән эшкә салават диләр. Аннан фәкать киләчәккә сабак кына алып була. Хәзер Гайсә яңа тормыш башларга тиеш.

Беренче буларак, ул остазы яшәгән фатирга кереп чыгарга булды. Немец Восстание урамындагы йортларның берсендә яши иде. Фатир ишеген чал чәчле әби ачты. Нелли Ефимовна, дип таныштырды ул үзе белән.
Гайсә ана Август Робертович белән кайчандыр бергә эшләвен, егерме биш ел командировкада булуын әйтте.

—Сез Гайсә буласыздыр дип беләм. Август гомер буе Сезнең алда үзен гаепле санады. Безнең балаларны коткарып калуыгыз өчен рәхмәт Сезгә. Үпкәли дә торгансыздыр. Ләкин аннан хәзер файда юк. Яшәргә кирәк. Тормыш корыгыз, балалар үстерегез...

Августны әле үткән ел гына җирләдек. Ул Сезгә менә боларны бирергә кушты. Анда бары да язылган булырга тиеш.

Гайсә, әби белән саубуллашып, урамга чыкты. Остазы биргән төргәкне сүтте. Анда Гайсәнең элек тоткан эш коралы, үз исеменә бирелгән беренче паспорты, хезмәт кенәгәсе һәм акчалар иде. Август Рейхман язган бер битлек хатны ул кат-кат укыды. Анда алга табаниләр эшләргә кирәклеге хакында киңәшләр дә язылган иде. Казанда танырлар, шуна күрә Кырымга, Ялта шәһәренә барып төпләнергә тәкъдим итә ул. Акчаң җитәрлек. Иртәме-соңмы СССР таркалыр, яна мөстәкыйль дәүләтләр барлыкка килер. Сине белүче дә, эзләүче дә табылмас. Яңа тормыш корырга минем дустым Яков Самуилович Постыляк ярдәм итәр...

Гайсә шул ук көнне такси яллап туган авылына, Тегермәнлеккә китте. Бәлки әле әнисе дә исәндер...

Таныш юллар, урман, тәмле сулы чишмәләр, инешләр—әйтерсең лә егерме биш ел буе бер үзгәрешсез шулай сакланган. Ә гомер, кеше гомере үзгәрә. Адәм баласы туа, үсә, чәчәк ата һәм җирдә ниндидер эз калдырып, фани дөньядан китеп тә бара... Гайсә ни эшләде соң? Әнисенә кайгы-хәсрәттән башка ни кылды ул шушы яшенә? Туган җире, туган ягы Гайсәне үткәненә кире алып кайтты. Йөрәген телгәләде: «Әни-әти, туган җирем, зинһар өчен, кичер мине... Гафу ит...»

Тегермәнлеккә керү юлында зират. Биредәге мәңгелек йортка күпме кеше күчкән?

Гайсә таксины туктатып, зират капкасыннан эчкә узды. Кабер ташларында таныш исемнәр. Туганнары Минлешаһ белән Миңсылу җиңгәсе, күршеләре Хәлил абый белән Гайнелхәят апасы, бергә үскән Ризван, Харис, Мәксуд, Мирсәетләр...

Зират уртасында аларның туган-тумачалары җирләнгән урын.

Өчпочмаклы нәсел тамгалары. Әле ике-өч ай элек күмелгән кабер Гайсәне үзенә җәлеп итте. Шунда гына ул... әнисенең төшкә керүенең сәбәбен аңлады.

Ул кабер алдына тезләнде. Күзләреннән яшь акты. Газиз әнисе рухына белгән догаларын укыды.

Гайсә зираттан чыгуга ук кире китәргә уйлаган иде, ләкин аяклары инеш буендагы туган йортына таба атлады. Өй бәләкәй булса да бүрәнәләре әле нык күренә. Тәрәзәләрдә чиста пәрдәләр. Ишектә кайчандыр ул ясаган йозак.

Шулчак каяндыр Сабира карчыкның югалган мәчесе Каракай килеп чыкты да мыраулый-мыраулый Гайсәнең аяк араларында бертуктаусыз буталды. Гайсә өйгә узды. Биредә элек ничек булган, бары да шулай сакланган. Димәк, әнисе аның исән булуына, кайтачагына ышанган. Бәлки аны әнисенең изге догалары исән-имин йорткандер дә!

Гайсә ишекне ябып кире китәргә капкага таба атлады. Шул вакытта «Каракай» аның юлын ике-өч мәртәбә кисте. Ниндидер адымнан сакланырга кушты бугай. Гайсә таксида калдырган әйберләрен алды да янадан туган нигезенә үтте.

Эх, Каракай, Каракай. Элегрәк юлларыма кире төшкән булсаң, минем тормыш нинди бәхетле булыр иде, дип өзгәләнде Гайсә.

Бу мизгелдә ул инде әнисенең изге догалары, туган нигезе аңа тормышын өр-яңадан башларга ярдәм итәчәгенә никтер ышана, өметләнә иде.



Фәнзаман
Баттал

# КА-АШ-МАР!..

КУРКЫНЫЧ ХИКӘЯТ

Иртәнге сәгатьләрдә мин аның чикерткә ботын хәтерләтүче нечкә дә, озын да кулларына, очлы терсәкләренә сокланып утырам. Бирсә бирә бит Ходай адәм баласына үз һөнәренә килешеп торган гәүдәне һәм шул гәүдәнең бу дөньяга тикмәгә генә килмәгәнлеген раслап торучы жинел дә, төгәл дә хәрәкәтләрне, камытланыбрак торган аякларны! Ул эшләгәндә, ни хикмәттер, себеркесе—ишкәк, ә унга-сулга селтәнә-селтәнә себереп барган юллары елга булып тоела миңа. Әле мондыйрак уй да килә башка: әгәр дә ул көймәче булса, әлеге терсәкләре, тезләре теләсә кайсы көймә читеннән дә чыгып торырлар иде сыман...

Ул себерә, ә мин—кайчакларда төннәр буе язып утырган язучы—кызыгып та куям аның хезмәтенә. Ичмасам, ул бер—ике сәгатьтән үз тырышлыгының нәтиҗәсен күреп куаначак: мин эшкә чыкканчы бу ишек алды нинди пычрак иде, хәзер әнә ялт итеп тора, диячәк үз-үзенә. Ә миңа андый куаныч бер чакта да килмәде һәм килмәячәк. Дөньяны аз булса да кабәхәтлекләрдән, гаделсезлекләрдән, кансызлыктан һәм башка бик күп яман гадәтләрдән чистартып булмасмы, ди-ди гомер буе язам бит инде, югыйсә—тырышам, жан-фәрман киләм, үземчә!... ә ул пычрана гына бара...

Безнең ишек алдына караган йортларда әллә кемнәр яши: сугышлар үткән полковник та, авиаконструктор һәм табиплар да, галимнәр һәм сәнгать кешеләре дә бар. Аларның һәркайсы үз үткәне, үзе уйлап тапканы, үз хезмәте белән мактана—берсендә дә дөнья кайгысы, тормыш фәлсәфәсе юк. Бөрешкән картларның һәм сорау билгеседәй бөкрәйгән карчыкларның да бар белгәне пенсия дә субсидия... Яратмыйм мин алар белән сүз куертырга! Күпме генә сөйләшмә, зиһененә бер тамчы да файдалы фикер таммаячак... Ә менә шушы себерке хуҗасының бераз ял итеп алуын, яныма килеп утыруын яратам. Ул, гадәттә, себергән чүпләрен өч-дүрт урынга өеп куйгач килә мин утырган эскәмиягә. Беренче сүзләре көндәлек эшләре, тау-тау чүпләре турында булса да, уйлары, фикерләре тора-бара тормышның төрле якларына кереп китә:

—Мына, малай, үзем эшлим, ә баш диган бу нәмәкәй гүпчим дә кирәкмәгән нәрсәләр уйлап мәтәшә. Мына, үзең дә беләсең бит инде, безнең Казан ул берчакта да чистарып бетми, иеме... Ә халык, ул хакта сүз чыкса, зур

җитәкчеләрне, шәһәр башлыкларын сүгә. Янәсе, алар эшли, кайгырта белмәгәнгә пычрак яшибез. Мин үзем дә яратмыйм ул түрәләрне. Егерме ел урам себереп тә фатирсыз калдырдылар, яптырмалахайлар! Ну бит, ни бит... Мына син ана теге чүп өемнәренә кара әле. Ни генә юк аларда! Кайбер хайваннар утыз адымдагы мусоркага да илтергә иренәләр чүп капчыкларын—төнлә подъезд төбенә чыгарып ташлыйлар. Мына шулар инде халык дип атала... Югыйсә, вак-төяк чүпләрне ташлау өчен подъезд төбе саен урналар да куелган!..

Монысы әле аның сүз башы гына. Ул туктап калуга һәм кесәләрен капшый башлауга мин инде бер карыш читкәрәк шуышырга тиеш булам. Чөнки, кесәсеннән сигарет, шырпы чыгарганда аның очлы терсәге һичшиксез кабыргама кадалып алачак. Тәмәкесен кабызып, тирән итеп суыргач, бераз тынып утыргач, ул яңадан сүз башлаячак:

—Мына, малай, без инде туып торган, үсеп торган алкашлар пычраткан ишек алдын гына себерәбез. Ну бит, ни бит... аның белән генә Рәчәй чистармаячак. Туып торган, үсеп торган, һәр буыны дөньяны пычратып торган политикларыннан соң чистартулар млиун мәртәбә авыррак бит әле! Һәр патша, һәр президент киткән саен тормыш тагын да авыррак булып кала... Шул ук пычрак урынга яңалары килеп утыра, адәм мәсхәрәсе.

Икәүдән-икәү генә сөйләшеп утырсак та, безнең әңгәмәне тагын берничә җан иясе тыңлап тора. Алары—күгәрченнәр. Бер-икесе шушы Нәһирнең тезенә, башкалары йә җилкәсенә, йә түшенә кунып, елтин-елтин уйнап торган күзләре белән сөйләүченең йөзенә, әледән-әле авызыннан ургып чыгучы төтененә карап утыралар. Башына да менеп кунаклыйлар, хәтта. Әлбәттә, аларга безнең сүз бөтенләй кирәкми. Бер бөртек тары ярмасының бәясе дә тормый безнең акыл сату алар өчен—Нәһирнең кесәсеннән чыккалап торучы чеметем-чеметем көнбагышны өмет итеп утырулары...

—Мына бу мәхлукларны—Ходай кошларын күр инде син... Карап торышка матурлар, гөнаһсызлар. Ә бит, ирек куйсаң, алар да хәзерге Казан байлары кебек комсыз. Тыгынып шартлаячакларын белмиләр. Башта, кулга ияләштергән айларда, күпләп ашаттым мин аларны. Карап торам, кайберсе туя, йоткан хәтлесе ашказанына сыймый башлагач, көнбагышлары авызыннан коела. Коса инде... Ләх исерек кешенекедәй күзләре тонып кала. Ә үзе барыбер ашый! Чаманы белми. Шуннан соң күрәм: икенче көнне юк теге... Күренми... Күп ашаса, үлә икән ул мескен. Хәзер инде чама белән генә ашатам үзләрен... Кызганыч... Ә теге кеше талап баеган капсайотарларны чуртым да кызганмыйм. Яшәсеннәр, әйдә, шулай бер-берсен кырып, теге дөньяга аткарып. Әнә, минем бер коллега шундый бер байның ишек алдын себереп яши. Нәрсә ди... Хак сөйли микән, өч катлы йортында яши торган бүлмәләре генә дә унтугыз икән! Карап торасы иде, хатыны, бер баласы белән нәрсә эшләп йөри икән ул бай шундый йортта?! Саташмыйлар микән?

Бер-бер артлы туып торган үз фәлсәфәләреннән каны да кызып китә тегенең. Инде мондый чакта әлеге озын куллары, җил тегермәне канатлары кебек, күз алдында әйләнә башлый. Тотлыгып-тотлыгып та куя:

—Барысы да тегеннән—өстән, Мәскәүдән башлана, аналарын се... се... селсәвиткә чакыртып өшкертәсе нәрсәләр! Язган законнары аңлашылмый, гамәлгә ярамый, вәгъдәләре—ялган, фәрманнары «алтын» фургоны да җирәнерлек. Югыйсә бит анда себерке асты саен министр! Әз генә булса да башлары эшләргә тиештер бит инде, югыйсә! Алар да без чыккан җирдән чыккан лабаса! Авылдан яки шәһәрдән дип әйтүем инде...

Ахыргы сүзләре көн саен бер чама була:

—Шунда бер айга гына президент итеп куйсалармы мине!.. Беренче көнне үк Кремль дигән шайтан оясын пыр туздырып себерер идем дә, кеше хәлен аңлый

белгән бәндәләрне утыртып куяр идем андагылар урынына. Ә тегеләрен, һайт-двага бастырып, чеченнар иленә җибәрер идем. Кире кайтмаслык итеп!..

Яки:

—Президент булсаммы?! Бөтен байлыкны имә торган сугышларны бетерер идем дә, халыкның зарплатын, пенсиясен өч-дүрт мәртәбә арттырыр идем. Бөтен халык: «Яшәсен иптәш Мутин!» дип, кул чабар иде.

Гәпләшеп утыруларның берсендә, үзем дә сизмәстән, кәефен боздым тегенең. Җилләнеп-җилләнеп сөйләвен бүлдереп, сорау бирәсе иттем:

—Карале, Нәһир, бер дә сораган юк... Кайдан килеп чыккан сиңа Мутин дигән фамилия? Мут исемле булды микәнни бабаң?

Чынлап торып рәнҗеде теге. Тилмергәндәй күзләрен йөземә терәп торды-торды да кул селтәде:

—Мин сине белекле кеше дип уйлыйдырыем бит сөйләшкәндә... Ә син безнең нәселдән чыккан Мөхтәр Мутин дигән атаклы артистны да белмисең икән, над... нада... надо же! Син әле тагын, урыслар шикелле: «Синең исемең ни өчен Нахир?» дип тә сора инде. Нәһир ул—елга, киң елга дигән сүз!

Әйтәсен әйтеп бетерде дә, батыр сугышка ыргылган кебек, себеркесе белән ишек алдының икенче тарафына китеп тә барды.

Әйе, үпкәләде бугай шул. Икенче көнне, «хәлләрең ничек» дип соравыма да «сорап та торма!» дигәндәй кистереп кул гына селтәде. Борылып та карамады, ичмасам—тагын да җиллерәк себерергә кереште. Тагын бер сүзе чалынды колакка: «Ка-аш-мар!» диде. Борын астыннан сүгенә-сүгенә җилфердәп бара: «Бөтенесен дә аякларыннан асып куймадым бит җае чыкканда шул яп-ялан-аякларны! Ка-аш-мар!»

Күңелсез булып китте. Шундый кызыклы әңгәмәдәшнең хәтерен калдыр да син, боекмый кара! Эскәмиямнән кузгалдым да урам аркылы гына чыгасы базарга тәпиләдем. Әйләнеп кайткач, төбенә вак-төяк салынган пакетымны тотып, кабат урыныма кунакладым: юк, болай гына кереп китү ярамас фатирга. Бөтенләй үпкәләгәнме бу, әллә вакытлымы? Белергә кирәк. Һич кенә дә югалтасы килми мондый ихлас адәмне...

Менә ул, ниһаять, миңа якын гына өеп куйган чүпләренең бер «чүмәләсен» каралып, таушалып беткән кәгазь капчыкка тутырып маташа. Бөгелгәндә-иелгәндә дә арт саны гелләрем минем тарафка «карый». «Нык үпкәләгән, каты рәнҗегән булырга тиеш... Белә идем бит инде, юкса, ул танылган актер Мутинны. Никләремә дип кенә шул фамилия белән тел чайкадым инде, ә?!» Ниһаять, түземим, эндәшәм моңа:

—Җә инде, үпкәләвеңне бетер инде. Кеше ялгышмый гына яшәми бит...

Ул, айнып киткәндәй турайды да, гаҗәпсенгән карашын төбәп, килә дә башлады. Килеп җитә-житешкә үк:

—Нәрсә дисең, кордаш? «Үпкәләдең» диденме? Каян килсен ул миңа үпкәләү?!—дип, кул бирде.

—Сөйләшмисең дә бит...

—Сөйләшерлек тә аң юк әле башымда, малай, үткән төнге кашмардан соң.

—Катырак җибәргән идеңме әллә?

— Анысы булмый торган хәл түгел-лә инде аның... Илгизәрнең самагунын салып чыккан идем бераз...

—Шул бутагандыр инде башыңны?

—Хикмәт анда түгел. Самагуны әйбәт аның. Төне буе саташып чыктым. Бер төнем бер елга сузылган кебек булды. Куркыныч төшләр күрдем—ка-аш-мар, парин!

—Соң, куркыныч төшләр керми булмый инде. Мин үзем, мәсәлән, үз

башымны үземнең култык астына кыстырып, кап-караңгы төндә Бауман урамы буйлап барганымны күрдем бервакыт,—дигән булдым, шыттырып.

—Минеке ул гына түгел шул... Коточкыч!

Күтәрелеп карасам, мангаеннан шыбыр су ага Нәһирнең. Җиң очы белән сөртеп алуы була, борчактай эре тирләре янадан бәреп чыга... Тез буыны тотмагандай, эскәмиягә түнде бахыр. Башын салындырып, кулларын тезләре арасына кыстырып, тынып калды. Тирән генә уфылдады да, инде менә ничәнче кат:

—Ка-аш-мар!—дип куйды.—Теленне тыймасаң, шулай була икән ул!..

Тел кычыткannan кебек кенә сүз кыстыруны кирәк таптым:

—Домоуправ белән талашкан иденме әллә?

—Кәкүй монда домоуправ!.. Тагын да куркынычрак кешеләр белән замайтсы килеп беттем...

Аннан соң Ходай Нәһиргә тел ачкычы биргәндәй булды.

—Хәтерендәдер бит инде, мин сиңа көн саен «Эх, президент булсам!» дип такылдадым. Менә шул бәхетсезлекне татырга туры килде төштә. Төн буе президент булып баш кайнаттым.

—Шәп булган бит инде. Нинди кошмар булсын, кызык кына бит бу!

—Сиңа кызык, атаң башы! Ә минем косасым килә тегеләрнең кыланмышыннан. Ялагай да бит әле үзләре!

—Кемнәр?

—Кремль кешеләрен әйтәм бит инде.

—Аларын да күрдеңмени?

—Президент булгач, Кремльгә барып кергәч, ничек күрми каласың инде аларны?!

—Сөйләп җибәр булмаса, ялындырып торма.

Ул башта, сүзенең юлын-җилемен таба алмагандай, әле моннан, әле тегеннән җөмлә йолкыган сыман төртелә-төртелә сөйләргә керешге. Имеш, төшендә халык диңгезедәй митинг бара икән. Шундагы миллион-миллион кешеләр, кинәт кенә күккә күтәрелеп киткәннәр дә, кара болытларга әверелеп: «Яшәсен президент Мутин!» дип акыра башлаганнар икән дә, Нәһир үзен кинәт кенә президент сараенда күргән. Болындай киң, һәр стенасы күз явын алырдай итеп алтынга манылган бүлмә түрендәге өстәл артында утыра икән бу, патша таҗы киеп...

Шул кадәресен күз алдына килерлек итеп аңлаткач, теле ачылып китте моның—җинел генә сөйләп китте. Әйтерсең лә сазлы юлларда буксовать итеп җәфалаган машинасы башта—тигез юлга, аннары көзгедәй асфальтка чыкты. Миңа бары тик: «Һе, гаҗәп икән... Кызык, кызык... Шәп иткәнсен кабәхәтне!.. Һай, рәхмәт, мине дә кайгырткансың!..» кебегрәк сүзләр белән җөпләп утырасы гына калды.

—Президент булып эшли башлагач ук, мин бернәрсәне аңлап өлгердем, малай: ул Кремльдә тере кешеләр турында уйлый да белмиләр икән. Бөтен кайгырткannары— мәетләр. Кинәшкәннәре дә—мәетләр язмышы... Әйтик, берсе керә дә, Николай патшаның сөякләрен эзләү, исемен изгеләштерү өчен расхутлык акча сорый. Икенчесенең Рәсәй буйлап кеше үтереп йөргән Колчак белән Юденичка бик тә һәйкәл куясы килә икән...

—Ярый, изгеләштерербез... Һәйкәлләр дә куярбыз...—димен.

И сөенәләр, парин! «Мең яшә, Нахир Тахирыч!» диләр. Түшәмгә хәтле сикерәләр, валлаһи. Тегеләр тына башлауга әйтеп куям:

—Түлке гаделлек булсын... Миллион-миллион кешеләрнең җанын кыйганнарны изге дип санныйсыз икән, Гитлерны да мәхрүм итмәбез. Аңа да һәйкәл куярбыз!—димен. Күзләре акаепката, малай, шулай дигәч! Җан кыючыларның берләре—изге, икенчеләре фашист була икән, аларча. Чуртым

да логика дигән нәрсә юк икән ул Кремльдә... Ну дурдом, парин!..

Берәүләре империянең җимерелүен мавзолейда яткан Лениннан күрә, мәетен ботыннан тотып чыгарып ташлау, аннан соң җирләү турында указ паппсайт итүемне сорый. Шуның эзенә үк басып, дигәндәй, Зюганов сыманрак кемсә килеп керә дә: «Менә болар Ленинга һөҗүм итмәкчеләр! Ленин урынында ятмаса, Рәсәй җитмеш дәүләткә таркала!», дип куркытмакчы була.

Икесенә дә карап алам да:

—Ә үзе нәрсә тели? Үз кулы белән язган гариза китерсен,—мин әйтәм,—шуннан соң разбирумся,—димен. Аңламаудан авызлары ачылып ката, теге ни кебек...

Мин бит, башкалар да шулай сөйләп торгач, ул Кремльдә гелләрем генә җәбрәйләр эшли дип уйлаган идем, парин. Түгел икән! Күбесе татарлар икән анда! Каян белдем, дисенме? Президент булып утыруга ук үзләре керә башладылар минем янга. Приемга инде... Иң башта Черномырдин килеп керде. Керә-керешкә үк «Әссәләмегалайкум, Нәһир әфәнде!» дип, саф үзебезчә күрешә бу, әттәгенәсе! Үзе көлә:

—Әллә, гел урысча сөйләшеп йөргәч тә, син мине урыс дип белгәниенме?!—дип, хәйләкәр елмая.—Жу-ук, әби-бабайлар Мидәлә ягыннан чыккан бик бай мырдалар, ягъни «мурзы» булганнар. Кап-кара татарлар инде. Сөргенгә куылгач, Карамырда дигән кушамат-фамилияләрен Черномырдин дип үдгәртергә мәҗбүр булганнар, урыслар эдәрлекләгәнгә чыдыйлары беткәч...

Ниндидер хөкүмәт мәсьәләләрен хәл иткәч, ишеккә хәтле озаттым тегене. Ни дисәң дә, карт кеше бит... Кадер-хөрмәт күрсен, диюем инде. Чыга-чыгышка, минзәләчә итеп, сорап та куйдым әле, җитмәсә:

—Картайгансың инде, Карамырдин абдый, ялга китәргә әдерләнмисенме әле?—дип.

—И, эштән куа күрмә инде, Нәһир апаем, эшләмәсәм, ашарга акча җиткереп булмый. Карчыкка төрле дарулар да кирәк. Биш-алты миллиард доллар булса да юнәтим инде тагын, яме? Аннан соң, үдебеднең Мидәләгә кайтып егылырбыд, Аллаһ боерган булса...—ди-ди ялвара, мескен... Үзем дә ятимлекләрне, фәкыйрьлекләрне күп күргән кеше буларак, кызгандым инде. Ни дисәң дә, үзебезнең татар икән бит. Бәлки әле, мулла булып куймасмы шунда берәр авылда. Ашарлык сәмәне калмаса, хәер җыеп яшәр...

Аннан соң Галимҗан дигән мин күргән бер язучыга охшаган бик ыспай да, шома да егет килеп керде. Мыегы да бик кәттә моның. Бә-рә-кәт!.. Анысы да татар икән бит! Мин тегенә фамилиясе белән эндәшүгә үк:

—Берүк, ялгыша күрмәгез, Нәһир әзи, чын фамилиям Греф түгел минем! Горефоф булам мин. Ерак бабам милләтебезнең гореф-гадәтләрен бик төгәл үти торган кеше булган. Рәсәйдә фамилияләр бирү тәртибе башлангач, мулла метрикәгә гарәп хәрефләре белән шулай язган. Үзегез дә беләсез инде, кәнишне, гарәпчә язганда сүз уртасында сузык авазлар кулланылмый диярлек бит. Гарәп хәрефен аз-маз таныган керәшен пубы фамилиябезне урысчага шулай күчергән...

Тыңлап бетердем дә бабасы хакындагы сүзләрен, сорау бирдем Горефофка:

—Ярый,—мәйтәм,—хәзер җавап бир: акча күпме казнада?

—Рубльләр бик күп. Тын океанга да сыймастыр. Чөнки Ходай бирмеш һәр тәүлектә көн-төн пыр туздырып басып ятабыз шул сыек акчаларны. Ә долларларны, үзегез дә беләсездер инде, монда эшләүчеләр белән бүлешеп, чит ил банкыларына салып барабыз. Һичьюгы, егерме буынга җиткереп булмасмы, дип тырышабыз инде... Оныкларның да яшисе килер бит... Телисез икән, Швицар банкына егерме миллиард булса да салып. Сезгә дә

счет ачарбыз. Ә инде агач рубльләрне халыкка җибәрәбез, бер күзле камбала балыгы да җитмеш сум торган илдә туалет кәгазе кебек арзан бит инде ул.

Тагын берсе керә, тегесе чыгып киткәч инде... Анысының да татарлыгы тиз ачылды. Баксаң, Явыз Иванга кадәр үк нәселендәге берәүне «Зур абый» дип хөрмәтләп йөрткәннәр икән дә, шул исем, бераз үзгәреп, Зурабовка әйләнгән имеш. Әнә шул Зур абыйның оныгы белән сөйләшеп утырганда...

Нәһир, шулчак, төртелеп калды, аннары, күземә туп-туры карап, дәвам итте:

—... ышансаң—ышан, ышанмасаң—юк, күрше, син искә төштең бит, әкәмәт! Мин әйтәм Зур абый токымына, пачаму Фәлән Фәләнов дигән язучыны мең ярым рубль пенсия белән тилмертәсез, мин әйтәм. Аның стажы гына да 91 ел бит, пнимаеш, димен тегенәргә: писателский стажы гына да 50 ел, әле шул һөнәре белән беррәттән 41 ел буе төрле кантурларда, разаксияләрдә эшләгән, димен. Шапылдатып өстәл суккан идем, куркып калды теге, утырган урынында туп кебек сикереп куйды. Башын иеп мыңгыр-мыңгыр килә:

—Беләбез, бик беләбез ул язучыны... Ну бит ул, ни бит ул... безнең Кремльнең дә тетмәсен тетеп яза бит ул...

— Элек бирмәгәннәрен дә исәпләп, аена ким дигәндә егерме мең бирә башлагыз, ыштубы!—дип җикергән идем бер, «Ярый, абзыкаем, ярый!!» дип чыгып та йөгерде.

Һе... Ие... Торна кебек чәндер, дөя муенлы, гәрәнкә башлы тагын бер бәндә килеп керә кабинетка. Монысы да татар булмакчы монын! Үзен бөтен генераллар башлыгы Иманов дип таныштыра, ишектән килеп кереп, үрә каткач. Телевизордан күргәндә дә күнелем болгана иде ул бәндәнен күркәдәй кукраюына, түргә дә үткәрмичә, усал итеп сорыйм тегеннән:

—Арагызда мие булган берәр генерал бармы Рәсәйдә?

—Бар!—ди.—Менә мин бар!

—Соң, атаң башы,—димен тегенә,—миең дә булгач, ни өчен Кавказда сугышып, үзебезнең халыкларны кырдырып ятасың анда?! Иманың кайда?! Сиңа ышансаң, татар башың белән Татарстанга да килеп керүең бар сугыш белән! Күземнән югал, бүгеннән үк ефрейтор ясап, шул ук Кавказга мылтык тоттырып җибәрәм үзеңне. Указ әзер!

Ул генералларны әйтәм әле, малай, яшь егетләребез сугышта сентябрь чебеннәре кебек кырылганда кызлар белән типтереп ята беләләр, мөртәтләр, ә үзләренең сугыш күргәннәре дә юк... Указ әзер, дип әйтүем булды, тегенен һушы китеп егылуы булды. Идәнне тырмый-тырмый, ишек алды себергәндә пычранып беткән кирзачымны үбә-үбә, үкерә-үкерә елый, сабакы:

—Җәллә, үлемгә тыкма, гаспадин президент, минем үләсем килми!—дип ялвара.—Балаларым хакына кызган!..

—Әһе!—мәйтәм.—Синең генә балаларың кадерле икән! Ә теге егетләр кемнәрнендер кадерле балалары түгелмени?!

Кыскасы, эшеннән себереп чыгардым тегене.

Тагын берсенең тере утыргычына типтем, кан кызып киткәч... Аягым тегенен ике бот арасына батып калгандай булды—көч-хәл белән тартып алдым. Анысы инде тегесе сыман кипкән килки түгел, күрше. Корсагы аркылыга үскән, карбыз кебек чыраендагы күзләре чучканыкы сыман. Шулхәтле симергән, суярга салган сыер кебек интегеп мыш-мыш килә. Ка-аш-мар!.. Ишшу җитмәсә, монысы да керә-керешкә үк: «Мин дә татар. Фамилиям—Үстемов. Баш прокурор булам», дип маташтыра. Алдый, ысбулыч!

—Үскәнсең шул! Инең белән буең тигезләнгән. Ә менә җинаятьләрне ача белмисең. Гөнаһсыз кешеләрне тутырасың төрмәгә!—дигән идем, шундук мыркылдап куйды:

—Какая разница?! Кемне атып, кемнәрне утыртсаң да барыбер—воздух

чище будет!

Әйттем бит инде, ул жирбиткә дә типтем.

... Шулай диюгә, Нәһирнен күзләре түгәрәкләнеп китте, кеше ишетмәсен тагы, дигәндәй, як-ягына куркынып каранды. Аннан соң гына авызын колагыма тыкты:

—Мына бүген, йокымнан уянып китеп, шайтан тартмасын ачып җибәрсәм, малай, ни күрим, шул прокурор чынлап торып эшсез калган! Әллә соң, мин чынлап торып президент булдым микән үткән төндә? Минем указ белән куылган булып чыга бит инде ул! Ка-аш-мар бит, әйеме? Ә-ә... Әйе! Шуларның сафсата чәйнәвен тынлап туйгач, кинәт кенә тамагым ачып китте. Секретаршаны чакырып керттем дә, приказ бирдем: «Живо, ашаргә китер! Бер аягын—монда, икенчесе тегендә булсын!»

—Юк, булмый,—ди.—Сез ашаганга кадәр ул ризыкны башта пувырлар үзләре, аннары медик-академиклар консилиумы ашап карарга тиеш!—ди, әйтмәсәм дә булмады!

—Мин үзем дә ашый алам аны,—димен.—Китер!

Тагын каршы килә. Юк, ди, Сез ашыйсы ризыкны агулаган булырга мужытлар, бу йортта кешеләр бер-берсенең ашына агу салу турында гына уйлап йөриләр, ди. Алып төштеләр сталавайга, утырттылар бә-әк зур өстәлнең түренә. Мина дип тәлинкәгә салынган кәтлитнең бер читен пувырлар кимерде, яртысын академиклар кымтырыкылады, калдык-постыгын, лупылар белән дә карап тикшергәч, үземнең алга эттеләр, рәхим итеп ашагыз, гаспадин президент, дип. Менә шул эткән ризыкны эт кебек ашасаң гына президент булырга ярыйсын икән.

... Тагын... Әйе, тагын мондыйрагы да истә калган әле төшнең. Мына без, яшерен-батырын түгел, көнгә өч-дүрт мәртәбә туалетка керәбез бит инде, э-эеме? Шунадыр инде, төшкә дә керде шул хәл. Унитаздан калкынуым булды, сөйли башламасынмы теге! Шул инде, шул—унитаз үзе сөйли! Япунчарак тавыш белән сибепме сибә, тишеге тыгылгыры:

—Эчендә самагун матдәләре бар...

—Бабасырлары күренә...

—Казан колбасаларының составын тәшкил итүче туалет кәгазьләре, эшкәртелми калган сенерләр, пычкы чүпләре, чучка йоннары һәм бизләре юан эчәгесенә тыгылган...

—Сукыр эчәгесе балык тәнкәләре, кылчыклар, суган кабыклары белән тулган...

Сөйләп тә бетерүе булды унитазның, бер көтү академикның туалетка чәчрәп керүе булды. Баксан, унитазның чупырдавын, аның докладын күрше бүлмәдәге радиудан тыңлап утыралар икән алар. Килеп тә керделәр, ыштанымны күтәрергә дә ирек бирмичә, носилкага салып, йөгерә башладылар. Бер палатага алып кереп, клизма куюлары булды, колакны ярып, яшелле-зәңгәрле тавышлар улатып, гудок чыйный башлады. Ниндидер вәянниләр йөгереп керделәр дә, мин яткан носилканы эләктереп, тагын да озынрак коридор буйлап дәлше йөгерәләр. Терек-терек йөгерәләр шулай, ә минем, бытыр-бытыр килеп, эч бушый башлады. Вәянниләр сүзеннән аңладым, Кремльнең подвалына террористлар ун тонна тротилл салганнар да, мине шартлатмакчы булалар икән, имеш. Болай чаптырып барулары президентны, ягъни мине коткарырга тырышулары икән. Шартлаткыч турындагы хәбәрләре дөрескә чыкмагач, мине урамнан кире алып кереп, кәлсүнне алыштырып, кабат тәхеткә утыртып куйдылар.

Утыруым булды, күземә Жириновский күренде. Өсталемә таба атлый, ләгыйн, ишшу житмәсә. Өстал суктым да кычкырып җибәрдем мин моңа: «Йөрмә монда дурака валәйт итеп! Синең тузга язмаган сафсаталарыңны телевизордан күрә-

күрә дә гайрәт чиккән инде монда. Марш отсуды!» димен тегенә. Ә ул барыбер килә! Юан суалчанга охшаган иреннәрен калфакландырып сүз башлый:

—Ялгышмагыз, Нахир Тахирыч... Монда минем кебек юләрләрдән башка эш бармый. Аңламыйсызмыни: мин нинди ахмак фикер әйтсәм, бу йортта шул фикерне атна-ун көннән үк күтәреп алалар. Алалар да тормышка ашырып та куялар! Вертикаль дәүләтне кем уйлап тапты дип беләсез? Мин! Губерналарны бер-берсенә кушарга кирәклеген иң элек кем әйтте? Мин!—ди. Аннан соң болай дип кызрачлана тагын:—Теләсәгез, иртәгә үк телевизордан: «Татарларга суверинетет бирмәгән өчен, урысларны сифилисны Монголиягә куып черетәбез!» дип кычкырам. Телисез икән, вертикаль Россияне төртеп аударып, Сезнең аяк астына сузып салам! Минемчә генә, туест, юләрләрчә генә барса-бара монда эшләр! Россию умом не понять!

Үзем указларга кул куеп утырсам да, ни хикмәттер, өстәлемә шушы себеркемне сөяп куйганмын, имеш. Шуны эләктереп алам да, давай тегенә... кайсы төше кычыта... унлы-суллы җиппәрәм! Өтәләнә, малай, утлы калайга төшкән борча кебек үрле-кырлы сикерә бу!

И-и!.. Анда акыл өйрәтеп торучылар дачурта икән. Саклаучылар да йөзләрчә икән... Бермәлне, шулай, кармак таягына җеп урыйм, калкавыч тагам, имеш. Балык тотарга бармакчы булам инде үземчә... Шуннан, минсинайтим, бөтен Кремль урыныннан купты бит, әй!

—Гаспадин-тауариш Мутин!.. Нахир Тахирыч!..—дип өзгәләнәләр.— Бүгенгә бармагыз инде, зинһар! Чөнки Сезне балыкка озата бару өчен кимендә бер дивизия солдатны кузгатасы бар бит. Әле бер-ике мең ФСБ генералын, инструктаж биреп, Сезнең тәнегезне сакларга өйрәтергә кирәк. Самолетлар кабызасы, йөзләп танкы заправит итәсе бар. Зенитный батареяларсыз да булмый!—диешәләр.

—Чурту-матр, сезнең армиягез!—дип җикерәм тегеләргә.—Мин япа-ялгыз тотарга яратам балыкны. Ник мине тыясыз?!Кая монда демократия?!—димен бит инде, парин, теңкәм корудан аптырагач...

—Демократия бар, бик бар бездә!—диләр.—Демократия булмаса, теш казнасын да күтәрә алмаган Брежневлар, черек-чирле Черненколар, алкаш Ельциннар, чекист-мекистлар, дворниклар ил башлыгы була алыр идеме Россиядә?!

Шулай да, сүземне ничек өскә чыгарганмындыр—хәтерләмим—киттем балыкка. Бранираванный машинада дүрт генерал, гәүдәләре белән төреп дигәндәй, алып киттеләр су буена. Яр читенә утыргач та дүртесе дүрт ягыма утырды. Ялгыш әйтәм икән, алдагысы алдыма басты. Чечен террористлары, имеш, мылтыкларын һәркайдан төбәп кенә торалар икән... Шулай итеп, малай, алда торган генералның бот арасыннан кармак таягын сузып, адәм рисвае булып, балык тотып утырам бит инде, адәм тәганәсе!.. Илнең иң зур, иң гөнаһлы приступнигы итеп... алай гына да түгел, арестант номер один итеп тоям үземне. Әйтәм бит, төрмәдә утырганда мине тудый-судый бер генә конвой йөртә иде. Ә монда артымнан әллә ничә мең конвой иярә... Ә, әйе... Бер мәлне калкавычым бии-бии бата башлады бит, рәхмәт төшкере! Тартып чыгаруым булды, чәнчә бармак хәтле шыртлаканы кулыма алуым булды,—уф-ф!—дөнья җимерелә дип торам: урман эчендә, чокырларда качып яткан әрмисләр танклардан, пушкалардан салют бирә башламасыннармы!.. «Безнең галавнокамандушший—герой! Акула тотты! Яшәсен дарагой прензидент Мутин! Ул безне җиңүләрдән-җиңүләргә алып бара! Ул булганда, чукчаларның йөз миллионлы армиясен дә җиңәчәкбез! Үррә! Үррә!..» дип, дистә меңләп кеше залпом кычкыра, малай. Ка-аш-мар инде! Тамаклары ертылды микән, юк микән—белмим, тагын Кремльгә кайттым, имеш. Ашыга-ашыга су буенда баткан кирза итекләремне салдыралар.

—План буенча, фәлән губернаның башлыгы килде Сезнең алда мактанырга, теге бүлмәгә чыгып утырыгыз, икенче яктан ул килеп керер. Ул утыруга ук, Сез: «Эшләрегез стабильны барамы, Фәлән Фәләнеч? Халык турында кайгыртасызмы?—дип сораган булыгыз. Ул Сезгә: «Стабильны, кайгыртып кына торабыз, Нахир Тахирович!» дияр.

—Туктагыз әле, идрит-кудритләр,—дим тегеләргә,—бернәрсә дә стабильны түгел бит бу илдә! Әнә, халыкның аркасын бет ашый, эшләп тапканын эт ашый—түрәләр кимерә. Алдау була бит андый сөйләшү! Авыз дигән савыттан борчак сибеп кенә туендырып булмый бит аларны!

—Беләбез, бик беләбез!—диешәләр.—Ләкин халыкка шулай күрсәтергә кирәк! Телевизордан көн саен шундый әңгәмә үткәргән булып кылану традициясен бозарга ярамый! Фәкыйрьлектән котыра башлаган халыкны юаткалап торырга кирәк бит инде...—дип ялваралар.

—Юата-юата алдаганчы, ашатырга кирәк халыкны! Нефть, газ долларлары да шалуны-шалуны белән сасып ята, әнә. Өләшергә кирәк. Аларның да өлеше бар бит анда!—дим бит инде мин юләр тегеләргә. Әйе-әйе, чын ахмак икәнмен. Алар, исәрлегемне күреп, акыл бирәләр миңа:

—Этне күзенә каратып торасың килсә, аны ачыктырып тотарга кирәк. Кремльнең мәңгелек законы шундый.

Теге губернатор белән корыны бушка әйләндереп утыргач, кабинетыма чыккач, ишекне бикләп килдем дә, башымны учларыма салып, елап җибәрдем. Казан сагындыра, малай! И газиз башкаем, димен, нинди гонаһларым аркасында мондый хурлыкка төштең?! Шунысын да уйлыйм: Казанда биш ай инде хезмәт хакым алынмаган, бәлки бирел яталардыр... Житте монда буш сүз чәйнәп, юк-бар җиргә чабата кайтарып яту, димен. Домоуправ та эзләп йөридер бөтен Казан буйлап, эчеп егылмады микән алай-болай дип... Качарга кирәк бу иблисләр йортыннан!

Шулай елап утырганда уянып китсәм, алты квадрат метрлы «пожарный» бүлмәмдә ятам! Әй, сөендем, малай, үземнең бу илдә иң каһәрле арестант түгеллегемне, кабат иректә икәнлегемне аңлагач! Рәхәт!

—Президент булырга теләмисең, димәк?

—Аллам сакласын!

...Елмаеп утырган җиреннән, карашына кабат шом йөгерде Нәһирнең. Як-ягына каранып алды да, янә түгәрәкләнеп киткән күзләрен төбәп, калтыранган тавыш белән колагыма елышты:

—Күрүен-күрдем дә бит бу төшне... Менә тагын шүрләтә инде... Хәзерге политика ничегрәк ул хәзер? Мондый төш күргәнем өчен төрмәгә тыкмаслар микән, малай?!. Атмаслар микән?! Россия кешеләренең төш күрергә правалары бар микән хәзер дип әйтүем инде...

Инде бу төш белән ни кыласымны уйлап утырган мин, әйтеп куйдым:

—Монысына минем генә акыл җитми, Нәһир туган. Шулай булгач, үземнән бик күпкә акыллырак редакторлардан сорармын. Белсә, алар белер инде...

*2006 ел*



# Дәрдемәнд

## Караб

***

**Шаулый диңгез...**
**Җил өрәдер...**
**Җилкәнен киргән кораб!**
**Төн вә көндез**
**Ул йөрәдер:**
**Юл бара ят ил карап...**

**Чыкты җилләр,**
**Купты тулкын—**
**Ил карабын җил сөрә!..**
**Кайсы юллар,**
**Нинди упкын**
**Тарта безне җан сорап?!.**

## Каләмгә хитаб[1]

**Каләм! Кальбеңдә[2] ни сер бар—гаян ит[3],**
**Килеп кичмешләр әхвален бәян ит[4].**
**Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,**
**Ни моңлы уйларың бар—сөйлә безгә!**
**Бабалар кабре янында күңел зар,**
**Аталар рухының армандәсе[5] бар...**
**Кара тупрак тулы мәзлум[6] нидасы[7],**
**Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы[8]?..**

---

[1] Хитаб—эндәшү, мөрәҗәгать.
[2] Кальб (калеб)—күңел, йөрәк.
[3] Гаян итү—ачып салу, аныклау.
[4] Бәян итү—сөйләп бирү.
[5] Армандә—теләк, өмет.
[6] Мәзлум—җәберләнгән, рәнҗетелгән.
[7] Нида—зар-ыңгырашу.
[8] Фида—корбан.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар—гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар—сөйлә безгә!..

## Рәсем

*(Нәвоидан)*

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында миң яраткан;
Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан!

***

Сеңеп җиргә, менеп җилгә, булып бу,
Агып кичмәктәдер гөрләп агымсу.

Агач, ташлар тынып, таулар да тыңлар,
Менеп таштан, очып ташка, төшеп су,

Ага гөрләп, ага зарлап агымсу,
Китә йомгакланып-йомгакланып бу.

Качан, балкып, җиһанга тулды якты,
Килеп, нур агълаган тауларны бакты,—

Дәриигъ[9], нур күз яшен бәллүр[10] санды,
Кереп әлванга[11], ал канга буянды.

Ишет төннәрдәге былбыл фиганен[12],
Аның да бакчы, залим, якты җанын.

Очып, чүлләр кичеп, таулар ашып,
Килеп төшкән микән, башкай адашып?

Ят илнең яд итеп якты кояшын,
Камышлы суларын, кырчынлы ташын,

Тавышлар чыңрауын ул саф һавада,
Сагышлар яңратып иркен далада,

Ерак диңгездә ул кышлар кичергән,
Чит илләрдән гариб[13] моңлар китергән.

***

Исәрме җил тугай буйлап,
Җыларны кыз моңын сөйләп,
Көләрме шатланып, көйләп,—
Агач, таш эчләре шаңрап,
Киләдер бер нида[14] яңрап!..

---

9 Дәриигъ (дәригъ) – үкенеч, кызганыч.
10 Бәллүр (биллүр) – хрусталь.
11 Әлван – төсләр.
12 Фиган (фөган, фәган) – ярдәм сорап ялвару.
13 Гариб моң – чит-ят моң.
14 Нида – зар-ыңгырашу.

***

Хәялдан[15] сүз ачып, берничә галим
Ачык күрсәттеләр... аларда барны:
Очырдылар «тат»ын татар башыннан,
Чыгардылар бит «ар»лыкка татарны...
Гаҗәп түгел сабый—итә сабыйлык,
Гаҗәптер әмма галәмдә габилек[16]

***

Куанды ил, канат какты мәләкләр,
Шашып, аң-таң булып шайтан тәкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!
Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урның—үлекләр аймагында.

***

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр—
Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр
Моң-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
Рәнҗемим, зинһар, кутәр!
Рәнҗемим, зинһар, кутәр!

Ни газизрәк—бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

***

Урамнан һәм базардан чүплә сүзне,
Алар бетмәс борын—барма еракка!
Тупаста булса тел илнең колагы,
Уеңны уйдырып сал шул колакка.

***

Урысча күп сүзең, азы татарча,
Белалмыйм, кем син—урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шарифең:
Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?..

***

Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

***

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

[15] Хәял – буш хыял (дөньясы).
[16] Габилек – аңгыралык.

Лирон
Хәмидуллин

# «МИЛЛӘТ УЯНСЫН ДИСӘҢ...»

## 1

Хәзер без: «Мәгълүматка ия булу—дәүләткә ия булу»,—дигән әйтемне еш ишетәбез. Элек тә ул шулай булган. Халык арасында мәгълүмат тарату өчен вакытлы матбугат чаралары уйлап чыгарылган. Матбугат исә халыкнын үзаңын күтәрүгә ярдәм итә.

«Милләт уянсын дисәң, анын үз матбугатын булдыру кирәк», дигән фикер безнең татар зыялылары арасында унтугызынчы йөз башларында ук барлыкка килә. Әмма патша түрәләренең колониаль сәясәте татарга үз матбугатын ачарга ирек бирми. Йөз еллык көрәш фәкать егерменче гасыр башында гына унай хәл ителә.

Шундый көрәш агымында торучылар арасында элекке морзалар нәселеннән чыккан Рәмиев байлар да бар. Бертуган Шакир белән Закир Рәмиевләр XIX гасырнын сиксәненче елларында ук матбага ачарга теләкләре барлыгын сиздерәләр. Закир Рәмиев Төркиядә белем эстәп йөргән вакытта ук ике бертуганнын шул хакта үзара хәбәрләшүләре мәгълүм. Шакирнын энесенә язган хатларында китап басу эше белән кызыксынырга кирәклеге дә әйтелә. Закир исә абыйсына Төркиядә чыккан газеталарны җибәргәләп тора. Мәсәлән, Исмәгыйль Рәми искә алган, 1881 елга караган бер хатында Шакир энесенә түбәндәге сүзләрне яза: «Тәрҗемәне хакыйкать» гәҗите күптән килә башлады, укып бик рәхәтләнәм. Туктамый җибәреп тор. Мөмкин булса, атналык бирәр журнал... җибәрсәң яхшы булыр иде... Безнең халык өстендә чапан, башында чалмасы булмаган кешенең сүзенә һич игътибар бирми. Халыкка һәртөрле әхвалне аңлата торган китапларны укытырга кирәк. Шунар күрә дә фәһем алырдай китаплар, романнарны күбрәк алып кайта күр...Типография шрифтләре мәсьәләсен ни эшләтәсең? Нинди бәягә алырга мөмкин, яз. Бу сәфәреңдә алып кайтасынмы, әллә соңыннан алдыру яхшы булырмы? Алган китапларынны да җибәрә алмассыңмы? Цензура мәшәкате күп булмаса җибәр... Гәҗитләрне цензурада карап, бәгъзе җирләрен кара буяу белән буяп җибәрәләр...» (Кара: «Дәрдмәнд әсәрләре», 1929 ел, 13 бит.)

Төркиядән кайтышлый Закир, Бакчасарайга кереп, «Кырым бәге» Исмәгыйль Гаспринский белән дә очрашкан булса кирәк. Татарча газета чыгару уенда булган Исмәгыйль морза белән киләсе көздә үк Казанда бергә туры килүләре очраклы түгелдер. Газета чыгара башлауны хуплаучыларны ачыклар һәм хәлдән килгәнчә матди ярдәм итүчеләрне барлар өчен дип, 1882 елнын көзендә Гаспринский морза Казанга килә. Монда аны бертуган Рәмиевләр каршы ала. Кырым морзасы белән очрашу өчен алар Оренбургтан махсус килгән бугай. Исмәгыйль бәйне Казан укымышлылары һәм яшьләре белән очраштыру өчен дип, алар монда зур гына бинаны үз исәпләренә арендага алалар. Ләкин чакырылган вакытка очрашырга килүче булмый. Казан татарларын ни өчендер Кырым морзасынын эш-гамәлләре кызыксындырмый. Буш залда алар дүртәү—Исмәгыйль бәй, Шакир белән Закир Рәмиевләр һәм очраклы рәвештә Казанга килеп чыккан бер Кавказлы мөселман гына кич дәвамында гаплэшеп утыралар. Шул рәвешле, киләсе елдан элекке Кырым ханнары башкаласы Бакчасарайда чыга башлаячак «Тәрҗеман»нын тәүге иганәче һәм әбүнәчеләре исемлегендә фәкать Рәмиевләр фамилиясе генә теркәлә.

Сонрак алар да үз газеталарын чыгарырга талпынып карыйлар. Ләкин патша түрәләре Идел—Урал төбәге татарларына андый мөмкинлек бирүдән тыела. Галимҗан Ибраһимов, «Революция тарихына материаллар» исемле хезмәтендә (1922)

шундый фактларга тукталып, түбәндәге сүзләрне китерә: «Безнен Идел—Урал буенда газета чыгару өмиде ул заманда байтак кешеләрнең башларында булган. Рәшид казый (Ибраһимов), Һади Максуди, мәрхүм Шакир вә Закир Рәмиевләр, тагын әллә кемнәр ул караңгы вакытларда төрлечә исемнәр белән бер газета булдыру турында кузгалганнар. Ләкин хөкүмәт рөхсәт бирмәгән». Әйе, газета-журнал чыгарырга рөхсәт бирү—басып алынган халыкка утлы корал бирүгә тиң ич инде. Халыкның үзаны үскән саен аны коллыкта тоту кыенлаша гына барачак. Моның шулай икәнлеген патша дәвере сәясәтенә йөз тотучы хәзерге заман түрәләре дә бик яхшы аңлый. Һәм матбугат иреген «богауларга» дип төрле чаралар уйлап табарга тырышалар ич.

Дөрес, XIX йөз Россия хөкүмәтенең шул ук дәвердә кайбер башка милләтләргә карата башкачарак мөнәсәбәттә торганлыгы да мәгълүм. Әйе, колониаль сәясәтне алга сөргән шул ук хөкүмәтнең, империядәге төп халыкларның берсе саналган татарларга карата кырыслык күрсәтеп тә, безгә кардәш кайбер милләтләрне төрлечә юмаларга теләгәнлегенә дә мисаллар бар. Рус мәкалендә тасвирланганча, «берәүләр өстенә камчы күтәргәндә, икенче берәүләргә прәннек сузу» сәясәте үрнәге инде ул. Үзәк Россиядә яшәгән, башка төрки халыклар арасында заманча мәдәни үсеше ягыннан күпкә югары булган татарларның үз телләрендә газета чыгарырга тырышулары кат-кат кире кагылган бер заманда, Россия кочагына янарак алынган Урта Азия, Кавказ һәм Кырым «мөселманнарына» карата мәрхәмәтлелек күрсәтелә. Янәсе, Россия аларны «тиң күрә», аерылып чыгарга дип талпына күрмәсеннәр. Шул рәвешле, 1865 елда гына Россия кочагына алынган Ташкентта иң әүвәл үзбәк һәм казакъ телләрендә беренче төрки газетаны нәшер итәргә рөхсәт бирелә. Әйе, 1870 елның апрель аеннан анда ике телдә чиратлашып атналык «Төркестан вилаяте гәжите» чыга башлый. Ул 1917 елгы үзгәрешләргә чаклы даими рәвештә нәшер ителә. Аның беренче мөхәррире милләттәшебез, Төркестан генерал-губернаторының жирле халыклар арасында эш алып баручы ярдәмчесе Ибраһимов Шаһимәрдән Мирас улы була. 1881 елда Шәркый Төркестандагы Жәркәнт шәһәренә Россия дипломаты вазифасын үтәргә җибәрелгәнче ул газетаны чыгару эшен дә башкарып килә. Кавказда «татар телендә» беренче газеталар да шул чордарак чыга башлыйлар. Дөресрәге, алар Кавказ төбәгендә яшәүче барлык халыклар өчен бердәм аралашу теле буларак кабул ителгән уртак төрки телдә нәшер ителгәннәр. Һәм Революциягә каләрге рус әдәбиятында алар «татар телендә» чыгучы газеталар буларак теркәлгәннәр. Әдип һәм тарихчы Габделбари Баттал, Кавказда чыгучы беренче төрки газета дип, 1875 елдан Бакуда нәшер ителгән «Игенче» газетасын атый. Әзәрбайжанлы Хәсән бәк Зәрбаби тарафыннан чыгарылган бу газетаны хөкүмәт бераздан соң яптыра, дип хәбәр итә тарихи «Казан төрекләре» китабында Г.Баттал. Өч елдан соң «Зыя—и Кафказия» газетасы Тифлис шәһәрендә чыга башлый. Ул да кыска гомерле була. Озынрак гомерлесе, 1905 елга чаклы яшәгәне «Шәркый рус» дип аталганы. Ул газетада «Казан татарлары»ның язмалары да еш басылган. Мәсәлән, язучы Шакир Мөхәммәдевнең Оренбургтан җибәргәләп торган аерым хикәя һәм мәкаләләренең «Шәркый рус»та XIX гасыр ахырларыннан ук чыга башлавы мәгълүм.

1905 елгы халык күтәрелешеннән соң илдәге вәзгыять бераз үзгәрә. Россиядәге төп халыкларның берсе булган татарларга да үз телләрендә газета-журналлар нәшер итү мөмкинлеге тудырыла. Шушы форсаттан иң әүвәл империянең башкаласында яшәүче, патша җәнапларына сакчы хезмәтен үтәүче мөселман гаскәриләренең дин башлыгы булып торган хәрби ахун Гатаулла Баязитов файдалана. 1905 елның 2 сентябрендә аның «Нур» газетасының тәүге саны басылып чыга. (Мәгълүм «Патша манифесты» игълан ителүдән бер ай чамасы алдарак. Милли телләрдә газета—журналлар нәшер итүгә рөхсәт бирүче рәсми фәрманга шул елның 24 ноябрендә кул куела.) Әйтергә кирәк, Гатаулла хәзрәт тә 1880 еллар башында ук «Хәфтә» («Атна») исемендә бер газета чыгарырга омтылып караган күренекле шәхесләребезнең берсе. Ләкин аңа да ул вакытта рөхсәт бирелми. Саф татар телендәге икенче газета булган «Фикер» шул ук елның 26 ноябрендә ерак Жаек каласында борын төртә.

1906 елның 16 февралендә Рәмиевләрнең «Вакыт» газетасын Оренбургта нәшер итәргә дә рөхсәт бирелә. (Оренбург генерал-губернаторы канцеляриясендә теркәлгән документ номеры 367.) Бу документта «газетаның нашире Мөхәммәтзакир

Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев. Мөхәррире Мөхәммәтфатыйх Гыйльман улы Кәримов» дип язылган. Ягъни, кайбер матбугат чараларында бәян ителгәнчә, Шакир Рәмиев бу очракта наширлар исемлегендә күрсәтелмәгән. Ә инде «Шура» журналын чыгаруга рөхсәт биргән документта ике бертуган да нашир дип билгеләнгән.

Мөхәррирлеккә ни өчен Фатыйх Кәрими сайланган? Беренчедән, ул инде танылып килүче язучы, өч-дүрт китап авторы. Аның «Бер шәкерт илә студент» дип исемләнгән повесте 1899 ук Казанда басылып чыга. Төркиядә югары уку йортын тәмамлап кайткан. Андагы матбугат эшчәнлеге белән дә бераз танышкан була. Икенчедән, ул дәвердә Оренбург губернасындагы бердән-бер татар басмаханәсенең хуҗаларыннан берсе. Дөрес, аның атасы, Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман Кәримов 1890 еллар ахырында типография ачарга ниятләгәндә, ана беренче булып матди ярдәм итүчеләр, «хәлгә керүчеләр» дә бертуган Рәмиевләр белән Хөсәенев байлар булган. Шулай итеп, Кәримовлар белән Рәмиевләр арасындагы иҗади дуслык дистә еллар элек үк башланган дигән сүз. 1899 елда Шакир Рәмиев Европа илләре буйлап сәяхәт кыла. Парижда уздырылган Бөтендөнья сәнәгать күргәзмәсендә дә катнаша. Тәрҗемәче һәм юлдаш сыйфатында аны Фатыйх Кәрими озата йөри. (Аның күләмле «Аурупа сәяхәтнамәсе» китабы 1902 елда С.—Петербургта басылачак.) «Вакыт» газетасы һәм соңрак нәшер ителә башлаган «Шура» журналы башлангыч чорда мәрхүм Гыйльман хәзрәтнең уллары Фатыйх белән Камил һәм кияве Тимерша Соловьев карамагында калган «Кәримовлар басмаханәсе»ндә басылалар.



*Рәмиевләр гаиләсе 1914 елда Европа илләренә зур сәяхәт ясый. Шул вакыт Бельгиянең Льеж шәһәрендә төшкән фотографиядә (уңнан сулга): Закир Рәмиев, Садри Максуди хатыны Камилә белән (Шакир Рәмиевнең кызы); Гариф, Зәйнәп, Искәндәр—Закир балалары; Әхмәт-Мидхәт—Шакир улы*

Газетаның беренче саны типографиядән 21 февральдә чыга. Исмәгыйль Рәмиевнең «Вакытлы татар матбугаты. 1905-1925» исемле энциклопедик хезмәтендә: «Вакыт»—милли—либерал газета. Оренбургта чыга. Барысы 2309 сан чыкканнан соң, 1918 елның 26 гыйнварында туктатыла... (Оренбургны большевиклар яулап алгач, ике-өч көн үтүгә, «буржуаз газета-журналлар», шул исәптән «Вакыт» белән «Шура» да чыгудан туктатыла.) Сәяси мәсьәләдә сак, дини һәм милли мәсьәләләрдә үз артыннан ияргән милли матбугатка юнәлеш биреп барды. Уку-укыту эше, тел һәм әдәбият, мәдәният мәсьәләләренә киң урын бирә, милли театр, музыка сәнгатен җәелдерүгә теләктәшлек күрсәтә, дәүләт мәктәпләренә кереп укуны өзлекле яклый иде», диелә.

1917 елның октябрь, 1918нең гыйнвар айлары аралыгында «Вакыт»ның мөхәррире язучы, Дәрдемәнднең кияве Ярулла Вәлиев була. Ярулла элгрәк Бозаулык шәһәрендә сәүдә эше белән шөгыльләнә. Берничә хикәя һәм пьеса бастырып, телгә керә башлаган яшь каләм әһеле санала. «Бай кияве булганчы», 1906 елда ук Ф.Кәрими аны газетада эшләргә дип чакырып китерә. 1908 елдан, Рәмиевләрнең үз типографиясе сафка бастырылгач, Я.Вәли аның мөдире вазифасын да үти. Тумышчыгышы белән Буа шәһәре янәшәсендәге Бикмураз авылы кешесе.

Рәмиевләр 1907 елның декабрендә «Шура» журналын чыгаруга да рөхсәт алалар. Ул айга ике мәртәбә, елына 24 сан булып чыга. Беренче саны 1908 елның гыйнвар башында дөнья күрә. «Наширлары Мөхәммәтшакир һәм Мөхәммәтзакир Рәмиевләр». Шул ук документта мөхәррире дип Ризаэддин Фәхретдинов күрсәтелгән. Риза казый 1906 елның җәй ахырларында ук Уфадан Оренбург каласына чакырып

китерелгән һәм октябрь аеннан «Вакыт» газетасының мөхәррир урынбасары итеп билгеләнгән була. Аны гаиләсе белән бу шәһәргә чакырып китерүчеләр бертуган Шакир белән Закир Рәмиевләр. Риза хәзрәт тә мөфтияттәге югары дәрәҗәле эшен калдырып, үз халкының белемен, аңын үстерүгә зур өметләр баглап, матбугат эшенә керешергә батырчылык иткән. Һәм Оренбургта яшәү, «Вакыт» белән «Шура»да эшләү дәверендә аның үзалдына куйган максатына ирешкәнлегеп яхшы беләбез. Бу елларда ул аеруча яшьтәше Дәрдемәнд белән бер фикердә булып, рухланып эшли. Җизнәсе Гыйльман ахун һәм соңрак Рәмиевләр ачкан типографияләрдә аның иллеләп китабы дөнья күрә. Совет хакимияте тарафыннан журнал ябылгач исә кабат Уфага кайтып, мөфтияттәге эшен дәвам иттерәчәк.



*Закир Рәмиевнең хатыны Мәхүбҗамал*

И.Рәмиевнең «Вакытлы татар матбугаты» китабында «Шура» журналының 1918 елның башына чаклы нәшер ителүе, барлыгы 240 саны чыкканлыгы әйтелә. Һәр саны зур форматта 36 битле булып, вакыт-вакыт рәсемнәр белән баетылып басылган. «Әдәби, гыйльми, тарихи журнал. Татар журналлары арасында иң күренеклесе. Дәвамлы, тәртипле чыгып торуы белән дә абруй казанды, күп таралды, күп укылды... Техник эшләнеше ягыннан да үз заманында һичшиксез беренче урынны тотты», дип яза Исмәгыйль Рәмиев. Журнал беренче елында шулай ук «Кәримов, Хөсәенев вә шөрәкәсе» басмаханәсендә басыла.

Бу газета һәм журнал редакцияләрендә шул чорның танылган журналист вә әдипләре Борһан Шәрәф, Габделбари Баттал, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Кәбир Бәкер, Ярулла Вәли һ.б. эшлиләр. Читтән торып алар эшендә Галимҗан Ибраһимов, Йосыф Акчура, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Ярулла Биги, Зәки Вәлиди, Һади Атласи, Галиәсгар Гафуров—Чыгътай һ.б. язучылар, шагыйрьләр, «җәмәгать хадимнәре һәммәсе диярлек үзләренең каләмнәре белән катнашалар». Ул чор матбугатын тәфсилләп өйрәнгән галимнәр фикеренчә, Рәмиевләр нәшер иткән «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы битләрендә бөек Тукаебызның йөзгә якын әсәре урын алган икән.

Газета һәм журнал битләрендә әдәби, гыйльми, дини эчтәлекле әсәр һәм хезмәтләр байтак урын алган, алар арасында үзара ярышлар уздырылган. Ярышларда җиңеп чыккан әсәрләр, газета һәм журнал кушымталары рәвешендә, Рәмиевләр тарафыннан аерым китап итеп тә бастырылганнар. Редакцияләргә килеп тә, төрле сәбәпләр белән аларда урын ала алмаган шигырь, хикәяләр дә еш кына аерым җыентыкларга тупланып, «Шура» журналы кушымтасы» рәвешендә чыгарыла торган була.

«Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләре... яшәүләре ягына нык күз сала, аларга, ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә, зур жалованье—«Вакыт» газетасы редакторы Фатыйх Кәримов белән «Шура» журналы редакторы Риза казыйга аена 130 сум бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованьесе» дип йөртә торганнар иде», дип яза 1908-09 елларда Оренбургта «Чүкеч», «Шура» журналларында эшләп алган әдип Зариф Бәшири («Замандашларым белән очрашулар», 1968). Ә 1917 елның башында «Закир әфәнде әмере белән расланган« бер исемлектән күренгәнчә, Фатыйх Кәриминең эш хакы 325, Риза Фәхретдиновныкы 275, Ярулла Вәлинеке 250, корректор Шәриф Камалныкы 180 сум булган. (Ул чорда гади редакторлар «корректор» дип йөртелгән.)

«Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, бу эшкә сәүдә-табыш ягыннан килмәделәр... Үткән елларда «Вакыт» һәм «Шура»дан, алтын хисабы белән, ун мең сумлап зарар күрделәр,» дип яза З.Бәшири.. Әлбәттә инде, Рәмиев байлар мондый зур чыгымны үз милләтләренә хезмәт итүнең изге бер үрнәге буларак кабул иткән.

«Вакыт» газетасын чыгара башлау белән бер үк вакытта Рәмиевләр, редакция хезмәткәрләре өчен дип, Шакирның йорт-утары янәшәсендә бер этажлы, өч секцияле йорт булдыралар. Анын бер секциясендә төрле елларда төрле кешеләр яшәсә (мәсәлән, 1914-1917 елларда журнал мөхәрриренең урынбасары итеп билгеләнгән Кәбир Бәкер гаиләсе), калган өлешендә Ризаэддин хәзрәтнең ишле гаиләсе урнаша. Шунда ук анын эш кабинеты да була. Ул өй урынында хәзер биш этажлы торак бина. Сиксәненче елларда анын диварына: «1906-1918 елларда... бу урында Ризаэддин Фәхретдинов яшәде,» диелгән истәлек тактасы куелды. Риза хәзрәтнең кызы Әсма апа Шәрәфнең атасына багышланган истәлегендә мондый юллар теркәлгән: «1906 елда Оренбургта бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр «Вакыт» исемендәге газета чыгара башлагач, әткәйгә шунда эшләргә тәкъдим итеп, берничә чакыру хаты килгән. Гыйлем өлкәсендә эш башлау өчен казый хезмәтеннән китү кирәклеген белеп, Рәмиевләр белән аңлашып, эшләргә риза була... Күчеп урнашкач та әткәй һәм Габдерахман абзый «Вакыт» газетасында эшли башлаганнар... Без торган квартираның зур ишегалдының бүлеп алынган яртысында зур бакча иде. Шул бакча эчендә безнең беседка бар иде. Май аеның башыннан сентябрь аена хәтле без шунда ашап, эчеп тора идек». Бу очракта ул бакчаның Шакир Рәмиев йорты белән ике арада урнашуын, ягъни, анын ике гаилә өчен дә уртак булуын да әйтеп китү кирәктер. Әссен урамындагы шушы йортта элегрәк елларда Борһан Шәрәф тә берникадәр вакыт яшәп ала. Ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә кагылышлы вакыйгага бәйле рәвештә Казаннан сөрелеп, Оренбургка җибәрелгән була. Рәмиевләр аны «Вакыт» газетасына эшкә алалар, фатир биреп торалар. Фатих Кәрими сеңлесенә өйләнгәнче ул шунда яши.

Шул ук китабында З.Бәшири билгеләп үткәнчә, Кәримовларның басмаханәсе ярыйсы ук таушалган була. Хәрефләр еш алышынмый, арзанлы кәгазь һәм начар буяулар кулланыла. (Истәлекләрендә Зариф Бәшири ул типографияне үз кулында тоткан Гыйльман ахун кияве Тимерша Соловьевтан еш зарлана, анын саранлыгы турында байтак дәлилләр китерә.) Рәмиевләр дә бу басмаханә эшеннән бик үк канәгать булмыйлар һәм үз типо-литографияләрен ачу хәстәренә керешәләр. Дәрдемәнд йорт-утарының иркен ишегалды почмагында, арттагы Вороная урамында бина сатып алына, заманча типография җиһазлары урнаштырыла, мөхәррир һәм корректорлар өчен эш бүлмәләре булдырыла. 1908 елнын декабрь башында ул басмаханәдә тәүге китап—Ризаэддин хәзрәтнең «Мөхәммәд галәйһиссәлам...» хезмәте басыла. «Вакыт» белән «Шура» 1909 елның 1 гыйнварыннан шунда ярыйсы ук сыйфатландырылган рәвештә чыга башлыйлар. «Вакыт» басмаханәсе» мөһере сугылган әдәби, мәдәни, тарихи эчтәлекле китапларны һәм дәреслекләрне нәшер итүгә дә керешелә. Басмаханә 1918 елның гыйнвар ахырларына кадәр Рәмиевләр карамагында эшли. Аннары Совет дәвере матбугатын нәшер итүдә кулланыла. 1920-1925 елларда, Оренбург Казакъ Совет Автономияле республикасынын башкаласы булып торганда, шул басмаханәдә кардәш казакъ халкы телендә чыккан газета-журналлар һәм китаплар басыла.

Мондый басмаханә булдыру хакында Шакир Рәмиев 1899 елда Санкт—Петербургта, Кырым морзасы Ильяс Бораганский типографиясен карап йөргән вакытта ук ниятләгән була. Ул басмаханәдә эшләүче «Госман Нури Акчукраклы әфәнде» белән якыннан танышып китүләре дә шул елгы март көненнән башлана. Ф.Кәрими «Ауропага сәяхәт» китабында бәян итүенчә, «бу зат исламча вә русчадан гүзәл хәбәрдәр булып.., язучы буларак «Бакчасарай чишмәсе» вә «Тәнкәжан ханым» илә «Мөләхаза» нам әсәрләреннән мәгълүмдер». Шушы өч тарихи эчтәлекле китап авторы да, басмаханә башлыгы кебек үк, тумышы белән Бакчасарай каласыннан була. Тәнкәжан ханым исә кайчандыр шул шәһәр зиратында җирләнгән тарихи зат—Мамай ханның кызы буладыр. Үз типографияләрен җиһазландыруга керешкәч бертуган Рәмиевләр бу язучы һәм оста куллы Нури Акчукраклыны да Оренбургка чакырып китерәчәкләр. «Вакыт» басмаханәсе»н оештырып җибәрүдә анын да өлеше бардыр.

1910 елларда Оренбургта нәшер ителгән кайбер рус һәм казакъ вакытлы матбугаты да шул басмаханәдә чыккан. «Казакъ» газетасы (Оренбург, 1913-1918), казакъ телендә сигез исемдә китап та (шулар арасында казакъча беренче повесть «Көргенде бала» да) «Вакыт» типографиясендә басыла. Ул дәвердә Оренбургта русча алты-жиде журнал,

шул чамада ук газеталар чыга, ә берданбер хосусый Бреслин типографиясе 1915 елда ябыла. Губерна идарәсе басмаханәсе исә күбрәк рәсми материаллар бастыруга йөз тота. Совет хакимияте дәверендә Рәмиевләр эшчәнлеген барлау бик хупланмаганга күрә, «Вакыт» басмаханәсе»нә кагылышлы төпле фәнни тикшеренүләр булмады. Анда басылып чыккан китаплар саны да, бер үк авторның хезмәтләрендә дә төрлечә күрсәтелә (Әбрар ага Кәримуллин хезмәтләре күздә тотыла). Журнал эшчәнлеген җентекләп өйрәнгән галим Раиф Мәрдәновның «Шура» журналы» китабында *(Казан, 2001 ел)* һәм «Рухият» фонды нәшер иткән «Ризаэддин Фәхретдин» җыентыгында *(Казан, 1999)* «Вакыт» басмаханәсе» эшчәнлеге дә беркадәр тасвир ителгән. Бу басмаханәдә чыккан кайбер китаплар исемлеге дә китерелгән.

Оренбург хәйрия җәмгыятенең «Белек» китапханәсе, Орскидагы «Шәрекъ китапханәсе», Троицк, Чиләбе, Кустанай һ.б. якын шәһәрләрдәге китап-газета сәүдәсе ширкәт һәм җәмгыятьләре ул заманда нәшрият вазифасын да үтәгәннәр, кирәк дип санаган китапларын бастырып чыгару өчен Казан һәм Оренбург басмаханәләренә даими рәвештә заказлар җибәреп торганнар. Андый заказларны «Вакыт» типографиясе дә үтәгән.

«Вакыт» басмаханәсе»ндә кайсы әдип вә галимнәребезнең китаплары нәшер ителгән соң? Кемнәр Рәмиевләр матбагасына якын торган? Беренче урында, әлбәттә, Рәмиевләр тарафыннан бик ихтирам ителгән, Дәрдемәндкә яшьтәш булган Риза хәзрәт Фәхретдинов хезмәтләре. Аның дини, әхлакый-тәрбияви һәм тарихи эчтәлекле 35 китабы «Вакыт»та дөнья күргән (Ә.Кәримуллин хезмәтләрендә алар саны шактый ким күрсәтелә). Бу авторның җизнәсе Гыйльман ахун оештырган, энеләре Фатих, Камил Кәримовлар һәм кияү тиешле Тимерша Соловьевлар тоткан «Кәримовлар басмаханәсе»ндә чыккан китаплары саны күпкә кимрәк. Икенче, өченче урында Шәриф Камал белән Галимҗан Ибраһимов китаплары тора. Ш.Камалның революциягә чаклы дөнья күргән барлык әсәләре дә диярлек башта «Шура» белән «Вакыт» битләрендә урын алган, аннары аерым китап итеп басылганнар. 1910 елда «Козгыннар оясында» исемендә озын хикәясе, 1914 тә унбиш әсәрен берләштергән «Хикәяләр төркеме», 1915 тә «Акчарлаклар» повесте, Рәмиевләр басмаханәсендә китап рәвешенә китерелеп, укучыга тәкъдим ителгән. Г.Ибраһимовның да беренче иҗат дәвере хикәяләренең күпчелеге әүвәл «Вакыт» белән «Шура» битләрендә, аннары аерым китап буларак басылган. «Дингездә»(1911), «Йөз ел элек» (1911), «Уты сүнгән җәһәннәм»(1912), «Карт ялчы»(1912) хикәяләре һәм күләмле «Татар шагыйрьләре» (1913) очеркы шулай нәшер ителгәннәр. Үз басмаханәсе булган Ф.Кәриминең дә кайбер хезмәтләре «Вакыт» типографиясендә чыга. Мәсәлән, «Истанбул мәктүпләре» исемле калын китабы (450 бит) һәм «Дөнья халыклары» исемендәге берничә китапчыгының язмышы шундый. Иҗтимагый, мәдәни, әдәби хәл-әхвәлне күзалларга ярдәм иткән Г.Сәгъдинең «Әдәбият кануннары», Г.Батталның «Габделвәли Яушев» китаплары, «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» исемендә нәшер ителгән күмәк җыентык, Җ.Вәлидинең «Татар әдәбияты хакында», «Таңчылар» төркеменең актив әгъзасы Шакир Мөхәммәдьяровның «Алпавытлар заманы», казакъ әдәбияты классигы Абайның икенче китабы саналган «Абай тирмәсе» җыентыгы (1916), Н.И. Ашмаринның XIX йөз ахыры татар әдәбиятына багышланган очеркының татарчага тәрҗемәсе һ.б. хезмәтләр дә «Вакыт» җимеше. Тәрҗемә китапларыннан тагын Төркиянең күренекле әдибе Әхмәт Мидхәт, инглиз язучысы Конан Дойль, рус әдипләре Александр Пушкин, Николай Гоголь, Леонид Андреев һ.б. әсәрләрен өстәргә кирәктер. «Вакыт» басмаханәсе»ндә дөнья күргән дәреслекләр саны да ишле генә. Казакъ халкының милли азатлыгы өчен көрәшүчеләр даирәсенә кергән Миржакыйп Дулатовның беренче шигырь китабы «Уян, казакъ» (1909) белән казакъ телендәге беренче роман саналган «Бәхетсез Жамал» (1910) Казанда басылган булсалар, бу авторның шуннан соңгы ике шигырь китабы—«Азамат» (1913) белән «Тирмә» (1915) Оренбург шәһәрендә яшәгән дәверендә Рәмиевләр басмаханәсендә дөнья күргән булса кирәк.

Шул рәвешле, ул басмаханә һәм бертуган Рәмиевләр нәшер иткән журнал белән газета татарга һәм аңа карындаш булган халыкларга унышлы гына хезмәт иткән. Ул халыкларның мәдәни вә иҗтимагый үсеше өчен көрәшкән. Оештыручыларының изге ниятен үтәгән. Рәмиевләрнең матбугат эшчәнлеге өстәмә керем—табыш алу нияте

белән башкарылмаганлыгын байтак замандашлары билгеләп үтә. Аларның бу эшкә керешкәндәге төп максаты милләт мәнфәгатен кайгыртуга, татар халкының узанын үстерүгә юнәлтелгән була. Һәм алар үз максатларына ирешәләр дә: «Вакыт» белән «Шура» татар халкы арасында гына түгел, безгә кардәш казакъ, каракалпак, үзбәк һәм Кавказ төбәге төрки милләтләре арасында да абруйлы матбага үрнәкләренең алгы сафында була.

## 2

Рәмиевләрнең милләт мәнфәгатен истә тотып эшләгән байтак кына башка гамәлләре дә бар. Әйтик, алар элекке Оренбург губернасының көнчыгыш тарафындарак урнашкан дистәләгән авылда мәчетләр төзеткән, мәктәп-мәдрәсәләр ачканнар. (Ул заманнарда мәктәп-мәдрәсәләрне мөстәкыйль ачу рөхсәт ителми, алар фәкать мәчете булган мәхәллә халкы өчен генә ачылганнар.) Кыз балалар өчен кул эшенә өйрәнү сыйныфлары да булдырылган. Мәктәп-мәдрәсә укытучылары яллан-ган. Кайбер авылларда китапханәләр оештырылган. Мәсәлән, элекке Орск өязендәге Юлык авылындагы китапханә Рәмиевләр төзегән мәчет мәззине карамагында була. Аерым эш хакы исәбенә мәззин һәм аның җәмәгате ул китапханәне бергә тоталар. Алар аны атнага дүрт көн ир-ат заты өчен, ике көн хатын-кызларга гына ача торган була. (1919 елның февралендә Совет хакимияте шушы китапханәне тәртиптә тоту өчен 150 чакрымдагы Орск шәһәреннән драматург Мирхәйдәр Фәйзине җибәрә дә инде.)



*Закир Рәмиевнең гаиләсе өчен Оренбургның үзәгендә (Введенская урамы, 27 йорт) аерым утар итеп матур таш йорт салына. Хәзерге Ленин урамы, 31 йорт.*

Оренбург һәм Орск шәһәрләрендә яшәү чорында ( 1883-1921 еллар) Дәрдемәнд халык мәнфәгатен күздә тоткан байтак кына җәмгыяви эшләр дә башкарган. Берничә тапкыр Оренбург шәһәр думасына сайланган. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенең тышкы идарәчеләре һәм иганәчеләре исемлегендә бертуган Рәмиевләр фамилиясе янәшә килә. Алар шулай ук үз төбәкләрендәге берничә хәйрия җәмгыятенә сайланган. Ул җәмгыятьләргә акчалата ярдәм итеп торганнар. Дәрдемәнд ярдәмгә мохтаҗ укытучылар һәм шәкертләргә хәйрия кылучы җәмгыятьнең рәисе вазифасын да башкара. Хатын-кызларга ярдәм кылучы шундый ук оешманың башында аның кызы Зәйнәп Вәлиева тора. (Мондый эшләр һәм ул чараларга кемнең күпме мал тапшыруын барлау Совет хакимияте елларында үткәрелмәгәнлектән, бүген без төгәл цифрларны китерә алмыйбыз.) 1905 елның февралендә мөселман халкына тигез хокук һәм ирек бирү кирәклеге турында Николай патша җәнаплары исеменә хат-петиция языла. Ана татарның күренекле шәхесләреннән Йосыф һәм Ибраһим Акчуриннар, Сәетгәрәй Алкин, Габдулла Апанаев, Әбүсогуд Әхтәмев, бертуган Дибердиев, Хөсәенев байлар һ.б. кул куя. Ул хатта Закир Рәмиев—Дәрдемәнд имзасы да була. Шул елның октябрендә мәгълүм «патша «Манифест»ы чыгуда әлеге «петиция»нең дә өлеше бар, әлбәттә. Шул ук елда Россия мөселманнары мәнфәгатен төрле трибуналардан торып якларга тиешле «Иттифакъ әл-мөслимин» сәяси партиясен оештыруга керешәләр. Бу партиянең төп сәяси юнәлеше Россиядә көч алып килүче кадетлар партиясе устав—программасына таянып эшләнә. Кадетлар программасында исә Россиядә яшәүче барлык халыклар тигез хокуклы булырга

тиеш диелә. Мондый таләп башка бер генә партия программасында да, шул исәптән большевиклар программасында да каралмаган була.

«Иттифакъ...» партиясен оештыруда катнашучылар, патша түрәләре тарафыннан эзәрлекләнүенә дә карамастан, бу эштән читләшмиләр. Дәрдемәнд тә бу партияне оештыру өчен яшерен рәвештә 1906 елның гыйнварында Санкт-Петербургта уздырылган корылтайда катнаша. Моңа чаклы инде ул кадетлар партиясенең Оренбург губернасындагы бюросына кергән була.



*Җәйләрен Рәмиевләр гаиләләре белән Оренбургтан китеп, приискалары янындагы шушындый йортларда уздырганнар. Аларның мондый йортлары хәзерге Башкортстанның Күсәй авылы янында да булган.*

1906 елда Закир Рәмиев—Дәрдемәндне Оренбург халкы Россиянең Дәүләт думасы депутаты итеп сайлый. Дөрес, Думаның бу Беренче чакырылыш депутатлары озак эшләми—беренче утырышлары шул елның 27 апрелендә, соңгысы июль башында үткәрелә. Бу чакырылышта катнашкан биш йөз чамасы депутат барлыгы утыз тугыз мәртәбә бергә җыела. Трибунадан ил башлыкларының башбаштаклыклары турында күп сүз сөйләнә. Мәгәр, алар мөһим карарлар кабул итәргә өлгермиләр. Николай IIнче шул елның 8 июлендә бу «тотнаксыз» депутатлар төркемен тарату, Думага яңа сайлаулар уздыру турында фәрман бирә.

Дәрдемәнд Дума утырышларының барысында да катнаша алганмы—әлегә ачыкланмаган. «Дело»сында кайбер документлары да сакланмаган, дип хәбәр итә тарих фәне докторы, ул чор Россия Думасы депутатлары эшчәнлегенә багышланган хезмәтләр авторы Диләрә Усманова. Эш кәгазьләре арасында депутатлыкка сайлангач Петербургта төшкән фотосы да бар икән. Ә менә мөселман депутатлар белән бергә төшкән фотосы әлегә табылмаган. Ни сәбәпледер рәсми рәвештә теркәлергә өлгермәгән Мөселманнар фракциясенә керүе, аның җитәкче бюросына сайлануы хак. Депутат ярдәмчесе һәм «Вакыт» редакциясе вәкиле сыйфатында башкалага аның белән бергә язучы Фатих Кәрими килгән булырга тиеш. Башкаладагы шул көннәрдәге хәлләрне беркадәр күзалдына китерердәй «Хыялмы? Хакыйкатьме?» повестенең нәкъ шул вакытта языла башлаган булуы шиксездер. Бу китап 1908 елда Казанда нәшер ителгән. Дөрес, андагы вакыйгалар Икенче чакырылыш Дума депутаты белән булган хәл дип тасвирлана. Монысы инде аның автор уйдырмасы, вакыйганы төп каһарманнан чак кына читләштерергә теләү теләге булса кирәк. Шагыйрьнең замандашы, Икенче чакырылыш депутатлары эшләгән вакытта «Дума» газетасының мөхәррире булган Фоат Туктаровның «Беренче, Икенче вә Өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре» дип исемләнгән китабы 1909 елда Казанда басылып чыга. Анда Дәрдемәндкә багышланган мәгълүмат һәм шагыйрьнең фотосы урнаштырылган.

1917 ел якынлаша. Шул елның февралендә оештырылган «буржуаз революция»дән соң Дәрдемәнднең янә дәртләнеп китүе, милли хәрәкәт вакыйгаларында бик теләп катнаша башлавы күзәтелә. Ул яшәреп киткәндәй була. Казан халкы өчен җәһәннәм читендәрәк саналган ерак Оренбург, Орск калаларыннан ике-өч мәртәбә милли башкалабызга килә. Шул елның июль аенда Казанда уздырылган Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае эшендә катнаша. Анда аны Вакытлы Милли идарәнең малия (финанс) нәзарәтенә (министрлыгына) әгъза итеп сайлыйлар. Ул чорда Оренбург шәһәрендә уздырылган барлык милли вакыйгаларның үзәгендә олы

яшьтәге шәхесләрдән Фатыйх Кәрими, Борһан Шәрәф, Дәрдемәнд актив катнашып киләләр. Ләкин зур өметләр баглап каршы алынган Февраль революциясе хөррияте көннәре озакка бармый. Шул елның октябрь ахырында большевиклар тарафыннан оештырылган яна түнтәреш исә бу олы яшьтәге зыялыларны читкә чыгарып ташлый. Рәмиевләр дәрәҗәсендәге кешеләр өчен бик авыр көннәр башлана. 1918 елның февраль урталарында Дәрдемәнд, хатыны Мәхүбҗамал белән бергә, Оренбургтан өч йөз илле чакрымга көнчыгыштарак, Себер тарафындарак булган Орск каласына чыгып китә. Һәм инде кабат үз йортына әйләнеп кайта алмый. 1921 елның 9 октябрь көнендә тиф авыруыннан вафат була. Шул ук авырудан гомере өзелгән өлкән кызы Өммегөлсемне Оренбург шәһәрендә җирләп кайтканнан соң берничә көн үтүгә...

Дәрдемәнд соңгы тапкыр Казанда 1919 елның гыйнвар аенда булып китә. Татар язуын камилләштерүгә багышланган конференция эшендә катнаша. Унынчы елларда ук гарәп язуын камилләштерүгә карата үз фикерен матбугатта белдергән Дәрдемәнд бу чарадан читтә кала алмагандыр, күрәсен. Милләтнең киләчәк язмышын җиңеләйтү өчен дип байтак уң эшләр башкарган куш йөрәкле зыялы затның соңгы изге гамәле шушы буладыр...

## 3

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд 1859 елның 23 ноябрендә Оренбург губернасына кергән Җиргән авылында дөньяга килә. Бабаларының туган җире Татарстанның хәзерге Әлмәт районындагы Тайсуган авылы. Бабасы Габделкәрим шушы Зәй төбәгендә берникадәр вакыт мәчет имамы вазифасын да үти. Аннары Агыйдел елгасы буенда яна төзелә башлаган Эстәрлетамак, Җиргән тарафларына китеп, шунда сәүдә эшенә керешә. 1851 елда Җиргәндә вафат була. Аның улы Мөхәммәдсадыйк (1828-1892) Җиргәндә сәүдә итә. 1869 елда шул ук губернаның Орск өязендә бөлгенлеккә төшкән бер рус кешесеннән алтын приискасы (кечерәк шахта) сатып ала. 1850 елда шул төбәк морзасы Әбелмөхәммәд Дашков кызы Ханифәгә өйләнә. Аларның биш баласы туган. Шулардан халык теленә кергәннәре Шакир (Мөхәммәдшакир, 1857-1912) белән Мөхәммәдзакир була. Садыйк хаҗи алар мирасына егермеләп прииска калдыра. 1917 елга кергәндә Шакир варислары белән Закир кулында да шул чама алтын шахталары теркәлгән. Гадәттә алар искергәннәрен ябып, яна приискалар да ачканнар. Мәсәлән, Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестенда тасвирланган вакыйгалар шундый яна ачылган алтын чыганаклары җирлегендә бара. Повестьта әйтеп үтелгән «ат башы хәтле» алтын түнтәре рәсми документларда 24,3 килолы самородок дип языла. 1896 елдан башлап ул җирдә алты прииска ачыла, Балкан исемендә зур авыл барлыкка килә.

Закир Төркиядән кайтканнан соң, 1882 елның кышында Мәхүбҗамал Борнаевага өйләнә. Борнаевлар Орск шәһәренең иң эре сәүдәгәрләре. Шагыйрьнең каенатасы Мостафа Мәскәү фабрикантлары Морозовлар белән дә эш йөрткән. Урал төбәгенең Эрбет ярминкәсендә үз кеше саналган. Рәмиевләр дә ул елларда Орскида кызыл мал (галантерея, тукыма) белән сату итәләр. Димәк, Борнаевлар белән бәйләнештә торалар.

Мәхүбҗамал (1863-1943) үз чоры өчен ярыйсы ук укыган кыз була. Соңрак ул Оренбург янәшәсендәге Каргалыда, приискаларга караган авылларда мәктәпләр ачуга һәм тотуга турыдан-туры катнаша. Сеңлесе Маһруй да соңрак Орск каласында махсус кызлар мәктәбе оештыра һәм шунда укыта.

Закир белән Мәхүбәнең сигез баласы туган. Шулардай ин кечесе «Фоат 1903 елда тугач та вафат була», дип язган иде миңа шагыйрьнең онычкасы, укытучы Зөбәрҗәт. Менә ул балалар исемлеге: Өммегөлсем Камалова (1883-1921), Искәндәр (1886-1943), Рауза Яушева (?-1938), Зәйнәп Вәлиева (1891-1977), Гариф (1893-1971), Җәгъфәр (1895-1976), Морад (1898-1918).

Мәхүбҗамал, ире үлгәч, 1938 елга чаклы Искәндәр, аннары Зәйнәп тәрбиясендә Баймакта һәм Уфада яши. Шунда 1943 елда вафат була. Кызганыч ки, ун-унбиш еллап бер шәһәрдә гомер иткән язучылардан һәм әдәбият белгечләреннән аның язмышы белән кызыксынучылар, Дәрдемәндкә багышлап истәлекләр язып алучылар булмаган.

Кызларыннан Өммегөлсем белән Рауза үз чорының житешле сәүдәгәрләре йортына кияүгә бирелә. Өлкәне Оренбург сәүдәгәре Гариф Камаловка, кечесе Троицки байлары нәселеннән Мөхәммәдвәли Яушевка. Өммегөлсем 1921 елның көзендә Оренбургта тиф авыруыннан үлә. Дүрт кызы кала. Иң кечеләре, Галия, 1948 елда Ашхабадта жир тетрәү вакытында улы белән бергә һәлак була. Аннан өч яшькә олырак булган Кафия апа Усманова белән 1993 елның кышында Мәскәүдә хәбәрләшкән идек. Галия белән Кафия Искәндәр абыйлары гаиләсендә тәрбияләнәләр. Рауза 1930 елларда әнисе һәм абыйсы белән бергә Баймакта яши. Шунда 1938 елда вафат була.

Шагыйрь йортына иң күп борчу, кайгы-хәсрәт китергән балаларыннан Гариф белән Морад булгандыр, мөгаен. Гарифне Дәрдемәнд үзе 1914 елның җәй башында Белгьиянең Льеж шәһәрендәге техник университетка илтеп урнаштыра. Шакир агасының улы Әхмәт-Мидхәт шул югары уку йортында инде ике ел укыган була. 1914 елның августында Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, бу балалар чит илдә аерылып калалар. Рәмиевләрнең ике йорты да алар өчен бик борчыла, ләкин бернинди чара да күрә алмыйлар. Дәрдемәнд алар язмышыннан бихәбәр рәвештә бу дөньядан китеп тә бара. Студент Рәмиевләр исә ике сугыштан да исән-аман котылалар. Гариф 1945 елдан соң Финляндиядә яши, балалар укыта. Өйләнми. Садри Максудида кияүдә булган туганнан-туган апасы Камилә белән ара-тирә очрашкалап тора. Соңгы очраашулары 1971 елның җәендә була. Бу вакытта Камилә кызы Гадилә Айда Римда Төркия илчелегендә эшли. Әнисе кунакка килгәч, Гарифны да үзләренә чакырып алалар, Ләкин 78 яшьлек буйдак картка Римның эссе һавасы ошамый. Ике атна дигәндә ул шунда вафат була. Римдагы мөселман зиратына җирләнә. Гадилә шул вакыйгаларны Төркиядә чыгучы «Казан» журналының 1974 елгы май санында тасвир итә.

Кече уллары Морадның язмышы исә тагын да аянычрак. Сөйләүләренә һәм истәлек язмаларына караганда, Морад Закир белән Мәхүбәнең генә түгел, барлык Рәмиевләрнең диярлек иң сөекле заты булып үсә. Бик иркә була. Гражданнар сугышы башлангач унтугыз яше тулмаган Морад үз теләге беләнме, яки иптәшләренә ияреме, атаман Дутов оештырган казачий полкларның берсенә килеп эләгә. Оренбург, Орск төбәкләрендә барган каты сугышларда катнаша. Соңгы елларда Бәшир Рәмиев тә, башкалар да аның турында искә алырга теләк белдермәделәр. «Егерме-егерме ике яшьләрендә авырып үлгән»,—дип кенә җавап бирерләр иде. Советларга каршы корал тотып сугышкан кешене ул елларда искә алу бик тә җайсыз иде шул. Дөрес, аның гомерен дә утлы ук та, зәһәр кылыч та чикләми. Орск өязендә барган сугыш-бәрелешләр вакытында ул авырып госпитальгә эләгә, шунда тифтән үлә. Әти-әнисе ул җәйне Балкан авылында уздыралар. 1918 елның көзендә аларга Морадның госпитальгә эләгүе турында хәбәр итәләр. Шул җәйдә Балканда яшәгән Маһруй кызы Әсма бу вакыйганы шулай искә ала: Морад абыйның авырып китүен белгәч тә җизни анда атлы кеше җибәрә. Иртәгесен ул кеше әйләнеп кайта. «Морад тифтән вафат булган. Бик рәнҗеп үлгән», дип белдерә, ди.

Дәрдемәнд белән Мәхүбҗамалның 1918 елның февралендә, ашыгып, Орск тарафына дип чыгып китүләренең төп сәбәбе дә, нигездә, балалар язмышына бәйле булган. Орск шәһәре картлары сөйләвенчә, Җәгъфәр Рәмиев тә ул вакытта шул тирәләрдә «большевикларга каршы сугышып йөри». Морадтан ике-өч яшькә өлкәнрәк булган Җәгъфәрне «башкорт армиясенә мобилизацияләнгән иде», дип искә алалар. Ләкин ул анда озак сугышмый. Зәки Вәлиди житәкчелегендә оешкан «мөстәкыйль Башкорт Республикасы» тиздән Советлар ягына чыккач, аның полклары элекке аркадашлары Дутовчыларга каршы ябырыла. Җәгъфәр Муса Мортазин җитәкчелегендәге кавалерия бригадасы белән башта Оренбург төбәгендә «акларга», ә 1920 елның җәендә көнбатыш тарафта полякларга каршы көрәштә катнаша. Киев шәһәре өчен барган сугышларның берсендә каты яралана—дошман кылычы аның сул кулын төптән үк өзеп ташлый. 1921 елда ул Орскига, ата-анасы янына кайта. Анасына кардәш тиешле Гөлнур Борнаевага өйләнә. Берникадәр вакыт «Башкирзолото» трестының хәзерге Учалы районы тирәләрендәге алтын чыгару идарәләрендә эшли. Сугыштан соң Чиләбе өлкәсендәге бер колхозда хисапчы булып тора, 1976 елда вафат була. Бер кыз һәм

Морад белән Фоат исемле уллар үстерәләр. Физика-математика юнәлешендә галим дәрәҗәсенә ирешкән уллары сиксәненче-туксанынчы елларда бер-бер артлы вафат булалар. Берсе Чиләбедә, икенчесе Новосибирскида. Аларнын Бәшир агалары белән бәйләнеш тотканлыгы шиксез.

Җәгъфәр ике мәртәбә атасынын иҗади мирасына бәйле гамәлләрдә унышсызлыкка ирешә. Егерменче еллар ахырында Искәндәр абыйсы ана аталарынын барлык кулъязмаларын туплап Уфага алып килергә куша. Чулак Җәгъфәр шул кулъязмалар, документлар тулы чемоданны поезддан-поездга күчеп утырган арада урлаттыра. Ә Сталин вафат булгач, илленче еллар урталарында ул Дәрдемәндкә багышлы истәлек язмаларын туплап Казанга килә. Ул вакытта аны күреп белгән Вил Ганиевнен сонрак мина: «Калын бер папка тотып килгән иде. Буржуй баласы дип, этеп-төртеп кире кайтарып җибәрделәр», дип сөйләве хәтердә. Әйе, Язучылар берлегендә дә, китап нәшриятында да аны теләп каршы алмыйлар, кире боралар. Алтмышынчы елларда шул вакыйганы искә төшергәч, Гомәр ага Бәширов: «Мин ана Мөхәммәт Гайнуллинга мөрәҗәгать итеп карарга киңәш иткән идем,—диде. Аннары:—Ул папкада бит анын үз шигырьләре дә бар иде»,—дип өстәгән иде. Әйе, Җәгъфәр ага да ара-тирә шигырь язгалаган. Әлбәттә, атасы иҗатына тиң тотырдай тирән фикерле шигырьләр түгел инде. Шулай да кайберләрен кабул итәрлектер, мөгаен. Мәсәлән, Искәндәр агасынын фаҗигалы язмышын чагылдырган егерме юллык шигырен...



*Бәшир Рәмиев*

Искәндәр Рәмиев, Германиядә җирнен казылма байлыклары белгечләрен әзерләүче югары уку йортын тәмамлап, 1914 елда иленә кайта. Бертуган Рәмиевләрнен ир балалары барысы да «Хөсения» мәдрәсәсенен рөшди өлешен тәмамлыйлар. Шуннан сон кайсылары гимназиядә, бер ишесе реаль училищеларда белем үзләштерә. Искәндәр, мәсәлән, Петербург гимназиясенә укырга җибәрелә. Немец телен яхшырак үзләштерү өчен анда бер немец гаиләсендә яши. Иленә кайткач Искәндәр 1914-1919 елларда үз прискаларында эшли. Оренбург төбәгендә Совет хакимияте урнашкач—дәүләт карамагындагы оешмаларга эшкә күчә. 1925 елда аны «Башкирзолото» трестынын Баймактагы бакыр рудасын һәм алтын комын эретү заводына баш белгеч (технорук) итеп билгелиләр. 1938 елда икенче мәртәбә кулга алынганчы ул шул трестнын төрле оешмаларында эшли. 1943 елда Томь елгасы буендагы бер лагерьда вафат булуы турындагы белешмәнен копиясен улы Бәшир мина да җибәргән иде.

Рәмиевләр варисларынын беренче мәртәбә кулга алынуы 1929 елга карый. Сонрак ачыкланганча, анын төп сәбәбе—Балкан авылында җиргә күмелгән яртышар потлы ике алтын «кирпече»нен табылуы булса кирәк. Чиләбе төрмәсендә сигез-тугыз ай чамасы утыручылар Искәндәр белән Зәйнәп, аннан ин иртә котылучы Җәгъфәр була. Элекке дивизия командиры, «кызыл генерал» Муса Мортазиннын аны азат итүне үтенеп язган хат күчермәсен кызы Зөбәрҗәт мина җибәрде.

Искәндәрнен ике хатынынннан ике улы—Бәшир белән Равил туган. (Икесе белән дә хатлар алыштым, аралаштым.) Берничә ел элек кенә вафат булган Равил (1927 туган) геология белгечлеге буенча югары белем алган, байтак еллар Себердә һәм Башкортстанда үз белгечлеге буенча эшләгән кеше. Өч улы Уфада яши.

Бәшир ага катлаулырак язмышлы шәхес. 1918 елда Оренбургта туа. 1920дә анасы Шәрифзадә Дашкова Орскида вафат булганнан сон, ул үги ана кулында үсә. Сонрак туу таныклыгына да үги ана исемен—Минсафаны язалар. Мәскәү энергетика институтында радио белгечлеген үзләштерә башлаган Бәширне 1938 елда, әтисе кулга алыну сәбәпле, укудан куалар. Икенче курсны тәмамлар алдыннан. Шуннан сон ул төрле эшне сынап карый. 1940 елнын маенда ул, ниһаять, Мәскәүдәге радио белгечлегенә бәйле бер оешмага эшкә урнаша. Шул анын киләчәк язмышын хәл итә. 1941нен июлендә сугышка да үз белгечлеге буенча алына. Ике ел чамасы Башкомандуюший карамагындагы махсус элемтә батальонында хезмәт итә. 1943 елнын ахырында хәрби радиобелгечлек буенча бер институт ачылгач, аны Мәскәүгә чакырып

кайтаралар. Ул анда 1948 елга чаклы радиолокаторлык белгечлеге буенча инженер, бер тармакның баш конструкторы вазифаларын үти. Шул чорда ул берничә радиотехник ачышка таныклык ала. (Дөрес, радиобелгечлек буенча беренче таныклыгы аңа 1941 елның май аенда ук бирелгән. Ул барлыгы 74 уйлап табучы таныклыгына ия шәхес иде.) Биографиясенә бәйле рәвештә ул институттан китәргә мәҗбүр ителгәч тә кайбер хезмәттәшләре ташламый. Аны Фәннәр академиясе карамагындагы бик үк яшерен серле булмаган икенче институтка урнаштыралар. Шул рәвешле ул СССРның электрон хисаплау машиналарын эшләп чыгаручы төп белгечкә әверелә. «Стрела», «Кристалл», биш-алты төрдәге «Урал» ЭВМнарының Баш конструкторы урынбасары була. Шуларны җыючы бер заводка баш белгеч итеп эшкә күчерелә. Бәшир Рәмиев ике мәртәбә СССР дәүләт бүләгенә лаек булган. Аның күкрәген ике «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены, унлап төрле дәрәҗәдәге медаль бизи иде. 1963 елда аңа техник фәннәр докторы дипломы тапшырыла. 1971-1990 елларда ул СССРның иң югары дәүләт оешмасында—Фән һәм техника Дәүләт Комитетында радиотехникага бәйле идарә башлыгының урынбасары булды. Шул дәвердә ул космоска бәйле күп кенә элемтә һәм идарә аппаратларын житештерүгә җитәкчелек итә. 1994 елда аның вафатыннан соң язган некрологта мәгълүм галим һәм мәшһүр шахматчы Михаил Ботвинник Бәшир аганы «космоска бәйле күп кенә яңа җайланмалар эшләүдә әйдәп баручы белгеч иде. Шахмат уйнаучы беренче аппаратны да ул эшләде», дип язды. Бәшир Рәмиев эшчәнлегенә бәйле мәгълүмат СССРда һәм чит илләрдә нәшер ителгән байтак хезмәтләрдә һәм 1974 елда чыгарылган «Энциклопедия кибернетики» китабының 2нче томы, 462-464 битләрендә дә ул телгә алына.

1993 елның декабрендәге очрашуда мин аңардан:

«Сугыштан соң Оренбургта булганыгыз бармы?»—дип сорадым. «Юк,—дип җавап бирде ул.—Байконурга берничә мәртәбә поезда бардык; поезда кайткан чаклар да булды. Вагон тәрәзәсеннән кызыгып карап китә идем... Төшәргә туры килмәде.»

Атасының туганнары Зәйнәп, Җәгъфәр белән дә алтмышынчы елларда, Пенза шәһәрендә хисаплау машиналары заводында эшли башлагач кына якыннан аралашу мөмкинлеге туа. Шуның дәлиле буларак өендә алар белән бергә төшкән ике-өч фотосурәт саклаңган иде. Хәзер Мәскәүдә икенче хатынына ияреп килгән кызлары һәм уртак уллары яши.

Зәйнәп белән Ярулла Вәлиевне 1926 елда Оренбургтагы төп йорттан чыгаралар. (Шагыйрь төзеткән, 1884-1918 елларда үзе яшәгән йорт-утар.) Алар ике бала белән Уфага барып төпләнә. Риза Фәхретдинов Ярулланы мөфтияткә хисапчы итеп эшкә ала. Берникадәр вакыт мөфтият идарәсе урнашкан йортта яшиләр. Аннары мөфтияткә якындагы Цюрупа урамында кечерәк бер өй сатып алалар. Шул елларда Бәшир аларда торып, Уфада 8-10 сыйныфларда укый. «Җизни мине Агыйделдә йөзәргә өйрәтте. Бик ярдәмчел иде. Күп укый, күп белә. Белмәгәнеңне бик җайлап төшендереп сөйли иде. Аны этидән бер-ике ел алдан кулга алдылар»,—дип сөйләгән иде ул. Зәйнәп Вәлиева 1958 елда Башкорстан дәүләт музеена Ханифә әбисенең бәрхет күлмәген, этисенең камзолын, алтын бөртекләрен үлчи торган кечкенә бизмәнчеген һәм заводта ук тоткасы сыртына «ЗР» хәрефләре коелган, алтын йөгертелгән берничә көмеш аш кашыгы белән чәнечкене бүләк итә. (Берничә данә шундый ук кашык-чәнечкене Бәшир Рәмиев өендә дә фотога төшереп алдык. Шундый ук бер пар кашык-чәнечкене Зәйнәп апа житмешенче елларда Татарстан дәүләт музеена да биреп җибәргән иде.) Үләренә берничә ай калганда Зәйнәп Вәлиева тагын нәрсәләрнедер, шул исәптән әнисеннән калган көмеш самавырны да музейга тапшырырга дип әзерли. Ләкин ул ятып авырган арада бу әйберләр юкка чыга. Аның өендә 1994 елда әле ата-анасы заманыннан калган рояль һәм тагын берничә әйбер сакланганлыгын Равил ага сөйләгән иде. Ләкин ул вакытта без ул фатирга керә алмадык. Зәйнәп апаның оныклары икесе дә хастаханәдә ята, диде безгә Равил Рәмиев.

# ДӘРДЕМӘНД ИҖАТЫНЫҢ МИФОЛОГИК ТАМЫРЛАРЫ

Татар әдәбиятының алтын фондына кергән шагыйрьләрнең берсе—Дәрдемәнднең талант тамырлары халык авыз иҗатына килеп тоташуы бәхәссез. Аның шигъриятендә халык җырларының поэтикасына хас үзенчәлекләрне дә, халык афоризмнарының яңа яңгыраш алуын да, традицион фольклор образларының, мотивларының кучемлелеген дә ачык сизәргә була. Ул гына да түгел, шагыйрь иҗатында милли фольклорыбызның, фәлсәфәбезнең, гомумән, рухиятебезнең нигезе—тәңречелек диненә нигезләнгән мифологиянең дә җимешле тәэсирен тоемларга мөмкин. Белүебезчә, фольклор, халыкның иҗади фантазиясе җимеше буларак, нигездә, эстетик вазыйфа үти, ә мифология исә борынгы кеше аңындагы дөнья моделе буларак, гамәли—дөньяны танып-белү функциясен башкара.

Дөрес, шагыйрь үзе борынгы төркиләрдә киң таралган тотемга—сынга, потка табынуны, аны изгеләштерүне зур хата дип саный һәм моны «чәчәклек» дип уйлап, «чүплеккә абыну»га тиңли. Бу хакта ул «Тәңрем!» шигырендә болай дип яза:

*Тәңрем! диде,—агачка табынды,*  
*Чәчәклек гөман кылды—чүплеккә абынды!*

Ләкин шул ук вакытта Дәрдемәнд иҗатына күз салсаң, анда борынгы тәңречелек диненә нигезләнгән мифологиягә хас образларның кучемлелеген күрергә була. Мәсәлән, бирелә тулпар һәм шоңкар параллеле аеруча еш кабатлана:

*...Борын-борын бар икән, ди,*  
*Хан баласы яшь солтан.*  
*Менгәне тулпар икән, ди.*  
*Чөйгәне шоңкар булган...*

(«Әни, әкият сөйләче»)

яки:

*Гыйшрәт мәйданының бәдәви тулпары,*  
*Һава һавәс галәменең очкыр шоңкары.*

(«Гыйшрәт»)

яки:

*Кыеп күкнең йөзен очканда шонкар,*  
*Сала күз авына таулардан аша,*  
*Ничек юлдаш аңа байгыш, ничек яр,*  
*Күзе нур очкыны күргәндә шаша.*

(«Кыеп күкнең»)

яки:

*Мөгезе бар куйның бары да кучкар түгел,*
*Очкан кошның барысы да шоңкар түгел,*
*Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берук,*
*Чукаңлаган аксак ишәк тулпар түгел.*
(«Кемнәр әйтмәс шигырьне»)

яки:

*Үшәнләнде даланың тулпар аты—*
*Урал шоңкарының сынды канаты.*
(«Үшәнләнде»)

Китерелгән мисаллардан күренүенчә, тулпар һәм шонкар Дәрдемәнд иҗатында идеальлек үрнәге, соң дәрәҗәдәге абсолют камиллек сыйфатында чыгыш ясыйлар. «Тулпар ат»ның үшәнләнүе, «Урал шонкарының» канаты сынуы шагыйрь өчен, чын мәгънәсендә, трагедия, чөнки ул халкыбызның меңъеллыклар дәвамында тупланып килгән рухи кыйммәтләренең юкка чыгуын, милли менталитет җуелуын аңлата. Дәрдемәнднең әлеге фаҗигане гәүдәләндерү өчен тулпар һәм шонкар символларын файдалануы, безнең фикеребезчә, бер дә очраклы түгел, чөнки әлеге затлар милли мифологик иерархиядә аерым урын били. Танылган мифолог, язучы Галимҗан Гыйльманов билгеләвенчә, «Тулпар ат мифологиядә Кояшны символлаштыра... Ул, гадәттә, ак төстә була. Диңгезгә дә җиңел генә кереп китә, аны кичеп, хәтта Диңгез патшасын да бик тиз генә җиңеп чыга. Шуңа күрә, борынгы ышану буенча, тулпарга атлана алган, аны үзенә буйсындыра алган кеше изге максатына ирешә—җир астына да төшә, утлы таулар аша да чыга, бер төн эчендә дөньяның читенә дә барып житә ала». Нурихан Фәттах аны хәтта Атлантида башкаласындагы, диңгез патшасы Посейдон гыйбадәтханәсендәге канатлы атлар белән дә тәңгәл куя.

Шонкар да төрки мифологиядә магик сыйфатларга ия зат. Галимҗан Гыйльманов аны Күк һәм Җир дөньялары арасында илче-хәбәрче вазыйфасын үтәп, кешеләрнең теләк-ялваруларын—Тәңреләргә, ә Тәңреләрнең ихтыярын кешеләргә житкерүе турында яза. Ягъни борынгы мифологиябездә атлар һәм кошлар культы үзәк урыннарның берсен били, өч дөньяны (Җир асты, Җир һәм Күк дөньяларын) берләштереп тора, аларның гармониядә яшәвен тәэмин итә. Шулай итеп, Дәрдемәнд шигъриятендә әлеге образларның еш урын алуы һич тә очраклы түгел—бу борынгы мифологик традицияләрнең көчлелеге белән аңлатыла. Тулпар һәм шонкар образларының мифологик мәгънәсе, эчтәлеге дә Дәрдемәнд шигъриятендә әлеге затларга хас булган сыйфатлар белән тәңгәл килә. «Тулпар ат»ның үшәнләнүе, «Урал шонкары»ның канаты сынуы шагыйрь өчен дөнья гармониясенең югалуы белән бер.

Дәрдемәнд иҗатында урын алган мифологик персонажларның янә берсе—Ай. Шагыйрь:

*Тегәп моңлы күзем күкнең йөзенә*
*Хикәят сөйләдем айның үзенә,—ди.*

Инде шушы кыска гына шигырьдән дә Дәрдемәнднең Айны изгеләштереп, ана илаһи сыйфатлар биреп каравын күрергә мөмкин. Безгә калса, моны гади поэтик сурәтләү алымы дип кенә исәпләү дөреслеккә туры килмәскә тиеш. Сүзебезне дәлилләп, шагыйрьнең «Тиң булырмы...» исемле шигыренә дә мөрәҗәгать итик. Биредә Дәрдемәнд үз алдына:

*Тиң булырмы йолдыз тулган айга?—*

дигән сорау куя.

Нәрсә соң ул тулган ай? Аның мифологик эчтәлеге нидән гыйбарәт? Галимҗан Гыйльманов, Ләйсән Кәриева кебек танылган мифологлар билгеләвенчә, «Ай төн символы булып тора. Ә төн карангылык, шомлылык, кайгы билгесе. Ай шушы карангылыкта бердәнбер өмет чаткысы.» Димәк, шагыйрьнең Айга мөрәҗәгать итүе дә бер дә юкка түгел. Ул әйләнә-тирәсен чолгап алган Төннән—гамьсезлектән, карангылыктан, гомумән, ялгызлыктан котылу өчен бердәнбер яктылык, нур чыганагы—Айга мөрәҗәгать итә. Айның тулы булуы әлеге фикеребезне тагын да куәтли, чөнки «халык ышануы буенча, тулы Ай—Ай тәңресенең иң мәрхәмәтле чагы». Димәк, шагыйрь Айга үз кайгы-зарларын сөйләп, аның теләктәшлегенә өмет итә булып чыга. Бу инде, чын мәгънәсендә, халкыбызның мифологик карашлары чагылышы булып тора һәм шул ук вакытта Дәрдемәнднең эчке күңел халәтен дә ачып сала.

Кайвакыт Дәрдемәнд иҗатында мифологик картиналар бар тулылыгы, бар драматизмы белән чагыла башлый:

*Куанды ил, канат какты мәләкләр,*
*Шашып, аң-таң булып, шайтан төкерде!...*
*Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,*
*Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!*
*Җиһан тормыш туен иткән чагында,*
*Синең урының үлекләр аймагында...*

(«Куанды ил»)

Әлеге үрнәккә охшаш шигырьләрен укыгач, ирексездән, ә бит Такташ иҗатындагы «мифологик поэзия» дәвере (1916—1923) тамырлары белән Дәрдемәнд шигъриятенә барып тоташа, дигән нәтиҗәгә киләсең. Төсләрнең куелыгы, ялгыз күңелнең яктылык эзләп бәргәләнүе, мифологик төсмерләрнең ифрат та бай булуы—болар барысы да татар халкының ике даһиенең иҗатын бер-берсенә якынайта, алар өчен уртак булып тора. Безгә калса, Такташ шигърияте Дәрдемәнд иҗатыннан үсеп чыккан булырга тиеш.

Мифологиянең «җимеше»—милли фольклорыбыз да шагыйрь иҗатына билгеле йогынты ясый. Дөрес, бу бәйләнеш ике яклы булган—бер яктан, Дәрдемәнд үзе татар халык иҗаты традицияләренә таянып, аларны үз шигъриятендә үстерсә, икенче яктан, шагыйрь үзе үк канатлы гыйбарәләре, афоризмнары белән милли фольклорыбызны баета. Аның шигырьләрендәге аерым юллар тиз арада фольклорлашып, халыкның үзенеке итеп кабул ителә башлыйлар. Мәсәлән:

*Сөт калыр, ватан китәр!*

(«Гөрләгән сулар»)

яки:

*Илдә бер дус булмаса гәр,*
*Ил бөтен дошман түгел.*

(«Илдә»)

яки:

*Ата-анам йорты өчен*
*Булса мең җаным фида;*
*Туган-үскән җирем өчен*
*Соң тамчы каным фида.*

(«Туган-үскән җир»)

яки:

*Күңел һәр җирдә гөл эзли,*
*Кадәр һәр җирдә тикән төзли.*

(«Күңел»)

яки:

*Бертуганың чит тибәдер,*
*Дәүләт тигез булмаса;*
*Ана сөтен аеры имә,*
*Бала игез булмаса.*

(«Бертуганың чит тибәдер»)

яки:

*Тел—илнең колагы,*
*Уеңны уйдырып сал шул колакка...*

(«Тел—илнең колагы»)

Әлеге юлларны укыгач, хәтергә күренекле шагыйрь Равил Фәйзуллинның узган гасырның 60нчы елларында күп бәхәсләр тудырган атаклы кыска шигырьләре—«Нюанслар иле» циклы килеп төште. Заманында тәнкыйтьчеләр бу бер, ике, өч юллык шигырьләрнең тамырларын эзләп, әллә кайларга—япон поэзиясенә кадәр барып җиткәннәр иде. Ә бит уйлап баксаң, аларны читтән эзләргә ярамый. Бу шигырьләр Дәрдемәнд шигърияте͏ннән, меңьеллык әдәби мирасыбыздан, халык авыз иҗатыннан, милли мифологиядән үсеп чыккан. Ягъни биредә традицияләр күчемлелеген ачык күрергә мөмкин.

Кыскасы, Дәрдемәнд шигърияте җиде катлы Күкләрнең мәңгелек серен үз эченә сыйдырган гаять тирән фәлсәфи эчтәлеккә ия иҗат ул. Әлегә кадәр аны бар тулылыгы белән өйрәнелгән дип әйтеп булмый. Әдәбият белгечләре өчен ачыласы серләр күп әле...

**Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Уфа.*

*Дәрдемәндкә тәкълид-нәзыйрәләр, багышлаулар*

## ХӘСӘН ТУФАН

*1900—1981*

### Җилкәнен киерә...

*Төн вә көндез*
*ул йөзәдер...*
Дәрдемәнд

**Җайга искән**
**Таңгы җилдә**
**Җилкәнен киргән караб—**
**Иске өйдән**
**Ишле илгә**
**Юл яра, йолдыз карап...**

**Дау кубарды**
**Азмы давыл...**
**Тик караб көрсенмәде.**
**Юлбасарлы булса да юл,**
**Җилкәнен төшермәде.**

**Азмы җанны**
**Упты диңгез...**
**Сау ләкин кораб һаман!**
**Гомере—мәңге,**
**Бәхете—чиксез,**
**Юл яра алга табан!**

**Алга илткән юл иңендә**
**Батырлар маяк-маяк...**
**Җайга искән**
**Алсу җилдә**
**Җилкәнен киргән караб.**

*1967*

# СИБГАТ ХӘКИМ

*(1911—1986)*

* * *

Безгә хәтле йөз мәртәбә сынап,
Иләгеннән иләп йөз кабат,
Дәрдемәнднең шигырьләрен Вакыт
Җыйган юллап, җыйган мыскаллап.
Үлчәр өчен бизмән алган Вакыт,
Вакыт—судья, Вакыт хәл итә:
Тоткан, үлчи, кыл уртада—бизмән,
Ике якта—ике тәлинкә.

Бер ягында—шигырь, бер ягында—
Алъяпкычы тулы, ал тулы
Дәрдемәнднең Урал тауларыннан,
Комнан арчып алган алтыны.

Китерә, сала, алтын баса кайчак,
Карап торган кебек ул моны,
Очып килеп шунда тәлинкәгә
Дәрдемәнднең куна былбылы.

Тигезләнә үлчәү, алтыннарга
Шигырьләре аның бәрабәр,
Уза еллар, арта бәяләре,
Заман белән бергә баралар.

*1976*

---

# РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Дәрдемәндкә тәкълидән*

Нинди мәхшәр!
Кайдан бу ут?
Җилкәннәр дөрләп яна.
Дулкын шаша.
Каек тулук,—
Кайда Ул, кайда Ана...

Караб баткан.
Каек эзсез.
Нинди ярдан аңгырык?
Кайсы якта
Илсез, күзсез
Кемнәр йөри каңгырып?..

*1968*

# РЕНАТ ХАРИС

## Гөрләгән сулар

Гөрләгән сулар төбендә
Җир чокырлы, авышлы...
Саңгыраулар гына суның
Ишетә шатлык тавышын.
И җәрәхәтле дулкыннар,
Кешене кичерегез!
Кешене кичерегез!

Таркалган сулар әрнүен
Кем дә кем шатлык саный—
Тау елгаларының төбен
Кан тамырына күчерегез...
Сез нәрсә кичерерсез?
Сез нәрсә кичерерсез?..

*1968*

---

# РӘДИФ ГАТАШ

## Дәрдемәнд аһәңе

*Кемдә син, Дәрдемәнд аһәңе?*
*Һәм кемдә—Рами бунты?..*

### Бүгенгебез...

Илаһ саз, син тоташ моңнан гыйбарәт,
Нинди көч ул кылларында, Тәңреме, әйт?!
Сезнең шул саз да уятмый—таш җаннар...
Шундый без бүген, әй Тукай, Дәрдемәнд!

### Сөйләшү

—Тукай, Дәрдемәнд бер очрашкан булсалар,
Бер илаһи гәп, дим, алар корсалар?
—Шәп манзара... Тик ул табынга, Гаташ,
Без сыймасак әгәр—чакырмасалар?

### Үз-үземә аптырыйм...

Гомер узган саен күрәм: начар мин.
Язгым беләм—язмыштан качалмыйм:
Бер дивана гариб мин—Дәрдемәнд язган...
Кемнәргә гашыйк булмадым... Нахал мин!

*1990—1992*

# ГАЗИНУР МОРАТ

## Дәрдемәнд кабере

*Сүнеп, вәйран булып мәгъмур тияклар,*
*Җир астында тезелде ку сөякләр!..*

Дәрдемәнд

**Кара йөзләр кабат ил өстенә**
**Кызыл бурзайларын өстергән.**
**Империя дигән каток узган**
**Бакый йортның таптап өстеннән.**

**Җилләр генә түгел—**
**Зилзиләләр**
**Юган эзне... юган хәтерне.**
**Ярый әле Вакыт отып калган**
**Шигърендәге һәр юл-сәтырны.**

**Комнар гына түгел—**
**Кубарылып**
**Ташлар күчкән... кабер ташлары.**
**Ку сөякләр түшәп ил багына,**
**Илгәсәрләр җирне ашлады.**

**Илдә калган Гариб...**
**Байгыш Сагыш**
**Тоткандыр шул... илдә туңса да.**
**Шагыйрьләрнең язмышлары уртак**
**Бай булса да, гидай булса да.**

*1995*

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

Миркасыйм
Госманов

# РЕЖИССЕР ХЫЯЛЫ ҺӘМ КЫРЫС ЧЫНБАРЛЫК*

Бу истәлегемне чагыштырмача аз вакыт—нибары тулыр-тулмас ун ел чамасы—таныш булган, аралашкан, хезмәттәшлек иткән бер шәхес хакында кыскача гына язармын дип башлаган идем. Тик, хәтер янчыкларында актарынып, булып узган хәлләр, аларның әһәмияте хакында уйлана торгач, хикәямнең киңрәк буласын аңладым. Кайбер вакыйгалар, фактлар тәфсилләбрәк тасвирлауны сораса, гомум иҗтимагый күренешләр дә тиешле игътибарга лаек булып чыктылар.



Шулай ук аның үтенече, хәтта басымы астында диярлек, ягъни үзем әллә ни теләмичә, ниятләрнең аклануына ышанып бетмәгән хәлдә икеләнеп кенә тотынган бер эшем, дөресрәге, эшчәнлегем юнәлеше ул үзе арадан киткәч тә дәвам итте, кәсебемнең бер өлешенә, хәтта тормышымның бер мәгънәсенә дә әйләнә язды. Махсус проектка әверелде...

Ул сәхнәгә куйган спектакльләрнең, тамашаларның кайберләре безнең буын кешеләре күңелләрендә хәзергә кадәр саклануы да шик тудырмый. Әмма аның иң зур мөмкинлекләре тормышка ашмаган хыял рәвешендә үзе белән бергә китеп барды.

Аның актив ярдәме белән дөнья күргән кайбер китаплар хакында укучыларның: «Карале, татар тарихын болай да язып булган икән бит!»—дип соклanулары һаман истә.

Димәк, Дамир (Раид) Равил улы Сиражиев (1954—1998) турында тәфсилләбрәк сөйләргә кирәк икән.

Әлбәттә, үземә яхшырак таныш сыйфатлары хакында сөйләргә тырышырмын.

* * *

Ректораттагы эш бүлмәмә алар дүртәү килеп керделәр. Алдан телефоннан сөйләшеп куйган Разил Вәлиев, егетләр күрешеп, утыруга ук, алар белән таныштырып чыкты:

—Режиссер, депутат Дамир Сиражиев,—диде ул әүвәл.

Күпереп торган чем кара чәчле, шундый ук кап-кара кырыкма сакаллысы вәкарь белән генә башын изәп куйды.

---

* Журнал варианты.

Режиссерның исемен элек тә ишеткәләгән, кайбер спектакльләрен караган булсам да, үзен, чандыр гәүдәле җыйнак кыяфәтен беренче мәртәбә күрүем иде. Чем кара күзләре көч һәм җегәр чаткылары белән янып, кыяфәтендә тәвәккәллек, кискенлек чагылса да, бер үк вакытта үзендә шикләнгәнлек сыман нәрсә дә сизелеп ала иде.

Килүчеләрдән калган ике егетне—Рәшит Баһаветдинов белән Фәрит Хәмидуллинны, элекке комсомол хезмәткәрләрен—беренче мәртәбә күрүем иде.

Яна танышларның өчесе дә утыз белән кырык арасындагы, ягъни ир-атларның иң өлгергән, җитлеккән чорындагы кешеләрдән булуы игътибарымны җәлеп итте. Болар юк-бар белән генә йөрмиләрдер дип уйлап куйдым.

Хәер, Разил Вәлиев үзе дә вак-төяк белән йөрүчеләрдән түгел. Аның белән моңарчы да беркадәре аралашкан идем, ул Казанга килгәнче бөтенләй тузып, тәмам таркалып бетә язган республика китапханәсен аякка бастыра башлаганлыгын, хәтта аның рәсми статусын Милли китапханә дәрәҗәсенә күтәрүгә ирешүен дә яхшы белә идем. Берничә мәртәбә шул китапханәдә яна бүлекләр, җөмләдән, сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеген оештыру буенча киңәшләшкән, фикер алышкан да идек.

Очрашуны оештырган кеше буларак, Разил, үгезне мөгезеннән тотып дигәндәй, сүзне турыдан башлады. «Хәзерге форсаттан файдаланып, халык, милләт өчен файдалырак берәр конкрет эшкә тотынасы иде. Мәсәлән, татар мәдәниятен, туган телебезне, сәнгатебезне саклау, яклау һәм үстерүне максат итеп куя торган, шул юнәлештә инициатива күрсәтеп, кайбер конкрет эшләр белән шөгыльләнә торган бер хәйрия вакыфы—махсус фонд оештырасы иде,—диде ул.—XX гасыр башында да мәдәниятебез хәйриячеләр ярдәмендә үскән бит! Патша хөкүмәтеннән берниндри ярдәм булмаган хәлдә. Мәсьәләне «алай кирәк, болай кирәк!» дип коры сөйләүләргә генә кайтарып калдырмыйча, нәрсәләр һәм ничек эшләргә кирәклекне эштә, гамәлдә күрсәтәсе иде...

«Менә бу егетләр,—диде Разил, тагын йомгаклап,—шундый изге ният белән йөриләр. Алар билләрен буып, җиңнәрен сызганып эшкә тотынырга әзерләр!»

Ниятнең изгелеген таныган хәлдә, аның нечкәлекләрен белеп бетермәвемне әйтеп, берничә сорау бирдем:

—Элекке вакыфлар хәйрия юлы белән төрле байлардан җыелган зур милеккә таянып эш иткән. Ә сезнең фондыгызның андый байлыгы бармы соң? Аннары, элек мәктәп-мәгарифкә, матбугат һәм сәнгатькә конкрет байлар реаль ярдәм күрсәткән, ә безнең хәзер андый байларыбыз кайда, булса, кемнәр алар?.. Һәм хәзер, гомумән, андый киң күңелле, ихлас юмарт кешеләребез бармы соң? Безнең халык исә, турысын әйткәндә, тулаемы белән милексез, ярлы кешеләрдән тора. Өстәвенә рухан люмпенлашкан кешеләрдән гыйбарәт түгелме соң?!

Сорауларым сагаеп кына утырган егетләрне бераз аптыратыр, аларны татлы иллюзияләрдән айныта төшәр дип уйлаган идем. Тик, моңарчы кыска-кыска репликалар белән чикләнеп утырган Дамир Сиражиев, шул сорауларны гына көткән шикелле, кызып-кызып, хәтта очынып-очынып дигәндәй, сөйләргә керешә, фикерләрен куәтләп төрле дәлилләр китерә башлады. Мәсьәләнең матди ягы да төрле яктан уйланылган икән. Әгәр акыл белән эшләнелсә, акчасы да табылачак икән. Ничекме? Мәсәлән, фонд янында, аның канаты астында алу-сату буенча берәр сәүдә ширкәтеме яки җитештерү цехымы булдырылачак. Шул оешма кергән файданың бер өлешен фондка бирәчәк. Димәк, яхшы китаплар чыгарырга, концерт-спектакльләр куярга мөмкинлекләр туачак дигән сүз. Ә акча, һичшиксез, булачак, мөмкинлекләр бар хәзер!..

«Алу-сату дигәч, хәрәмләшү дә китә дигән сүз...»—дип, Дамирны бүлдереп, сәвитчәрәк акыл сата башлаган идем, Разил шунда ук җавабын тапты:

—Ә Хөсәеневләр, Акчуриннар, Апанаевлар, Яушевлар сәүдә итмәгәннәрме соң? Гомумән, сәүдәдән башка татар баен—татар хәйриячесен күз алдына китереп буламы? Кулына кергән акчаның бер өлешен ихлас күңелдән хәйрия юлына, халкын мәнфәгатенә тотсаң, сәүдәгәрлектән кергән мал да хәләлгә әвереләдер инде!

Мин тагын икеле-микеле шикләнүләр белдерергә теләгән идем, Разил мәсьәләнең башка ягына басым ясады:

—Эшләп карамыйча торып идеяне кире кагарга кирәкмәстер. Эшләп карасыннар әле! Барып чыкмаса, туктарга бер вакытта да соң булмастыр, минемчә. Ният әйбәт, теләк изге бит!

Мин барыбер егетләрнең ни өчен университет ректоратына, нәкъ минем янга килүләренең сәбәбен аңлап бетерми идем әле, шуны да ачык итеп әйттем. Разил аңлатты:

—Берәр фонд оештырыр өчен бездә, канун буенча, андый фондның кирәклеген таныган, шуны раслый торган, иң мөһиме, аның эшчәнлеге өчен үз өстенә беркадәре җаваплылык та ала торган рәсми учреждениеләр, оешмалардан хуплау кирәк икән. Бер гарантияне Милли китапханә бирә. Бирде дә инде! Әгәр мәшһүр император университетында татар факультетын оештыруны хәл иткән галимнәр дә унай сүз әйтсә, мәсьәлә җиңел чишелер иде. Менә шундый үтенеч белән нәкъ сезнең янга килеп утырыубыз. Иң зур, иң абруйлы уку йортыннан ярдәм өмет итеп, ярдәмгә ышанып килдек.

Шулай итеп, визитнең төп сәбәбе аңлашылды. Мин исә, алар идея, ягъни фонд-вакыф хакында миннән тарихи белешмә сорыйлар дип уйлап, үземчә әлләкемсенеп, «югары материялар» хакында акыл сатып утырган булам. «Ярар,—дидем,—теләк ихлас, ният катгый булса, университет гыйльми советының карарын алырга тырышырбыз. Шундыйрак юнәлештә бер тәҗрибәбез бар инде. Тик фонд өчен акча бирү хакында сүз булмасын иде: үзебез дә авызны ачсак, үпкәбез күренерлек хәлдә, штатларны кыскартып, лабораторияларны яба башладык инде... Тагын андый эшләр артыннан йөрергә үземнең дә шәхсән мөмкинлекләрем, вакытым булмаячак...»

Шул сүзләрне генә көтеп торгандай, Разил, тиз-тиз сөйләп, миннән бернинди башка эшләр кирәк булмавын, калганнарын егетләрнең үзләре башкарачагын әйтте. Дамир исә, Разилнең һәр сүзе саен «әйе, әйе!» дигән сыман ияк кагып, кулларын изәп, сүз барышыннан канәгать булып утырды. Калган ике егет, Рәшит белән Фәрит тә, елмая төшеп, сизелер-сизелмәс кенә баш кагалар иде.

Егетләрнең болай сүздә генә бирелгән, әле сәнәк белән суга язылган ризалыктан шулкадәре сөенүләренең сәбәбен мин соңрак белдем. Разилнең әйтүенә караганда, башта «Татар йорты» дигән берәр зур мәдәни үзәк дәрәҗәсендә сәүдә фирмасы оештыру планы туган икән. Тик ул идея кайбер дәрәҗәле җитәкчеләрдә, югары оешмаларда хуплау тапмаган. Яңалыктан курыкканнар, күрәсең. Ни дисән дә, совет хакимиятенең ажгырып торырлык көче калмаса да, кыҗырынып маташкан еллары иде бит әле. Шуңа күрә егетләр әлеге идеядән өлешчә баш тартып, шушы фикергә—Милли китапханә, Университет ярдәмендә икенчерәк юнәлештәге фонд оештыру фикеренә килгәннәр һәм ректоратка кергәннәр икән.

* * *

Гыйльми советта (аның утырышына Разил белән Дамир да килгәннәр иде) мәсьәлә, кайбер вак-төяк сорауларны исәпкә алмаганда, җиңел хәл ителде. Чөнки күптән түгел, 1986 елда, КДУда татар филологиясе, тарихы һәм шәрекъ телләре факультетын ачуны бертавыштан хәл иткән (университет тарихында сирәк күренеш) гыйльми совет ул елларда милли мәсьәләгә карата сизгерлек күрсәтеп килде. Безнең кайбер садә, наив романтикларыбызның урамнарда «татар университеты ачып», дәресләр уздырыр өчен аудиторияләр эзләп йөргән еллары иде бит. КДУда татар факультеты ачылуга карата бер профессорның (акыллы яһүд кешесенең) елмаеп: «Кайчакларын паровоз алдыннан чабуы да файдалы» дигәне хәтердә. Кыскасы, фонд оештыруга фатиха бирү мәсьәләсе тиз һәм унай хәл ителде.

Әйе, Разил әйткәнчә, моннан соң миңа фондны оештыру буенча әллә ни мәшәкатьләр күрергә туры килмәде. Ара-тирә егетләрнең кайберләре яки Дамир үзе килеп кинәшеп, әйтик, фондның уставы, аның кайбер үзгәрешләре һәм гомумән эшләрнең ни дәрәҗәдә баруы белән таныштырып киткәли иде. Мәсьәлә юридик яктан тәмам хәл ителер алдыннан Дамир тагын килеп чыкты һәм миннән «Татар теле

һәм мәдәнияте» («Татарский язык и культура») дип исемләнә торган яңа фондның рәисе булуга ризалыгымны сорады.

Мин икеләндем, хәтта каршы да булдым. Чөнки ректоратта болай да исәпсез-хисапсыз административ эшләргә күмелеп утыруым артыгы белән житкән иде. Дамир исә чигенергә һич тә уйламый. Шомырт төсле күзләрен ялтырата-ялтырата туры карап, минем кандидатурамның иң лаек, хәтта «бердәнбер» икәнлеген кабатлый; тарихны, культурабызның узган чорын белүемне искәртә, «нык принципиаль» булуымны да әйтә. Ниһаять, фонд башында университет профессоры торуның да фонд өчен горурлык икәнлеген искәртә. Мактаганны кем яратмый? Минем дә йомшара башлавымны, әле генә олылап телгә алынган «нык принципиальлекнең» дә тупсалары бушый баруын сизгән Дамир һөҗүмгә икенче яктан күчә:

—Финанс, акча-макча мәсьәләсенә килгәндә, бер дә борчылмагыз, сез генә түгел, хәтта фондның үзе дә финанс-хуҗалык проблемалары белән шөгыльләнмәячәк. Сәүдә эшләрен фонд канаты астында оештырылачак «ТатАрт», ягъни «татар сәнгате» дип исемләнәчәк махсус үзәк башкарачак. Алу-сату белән эш итү, акча табу, аның кеременнән фондка өлеш чыгару бары «ТатАрт»ның гына өстендә булачак. Димәк, дәүләт алдындагы исәп-хисапны, тиешле салым-налогны да, кирәге чыкса, юридик җавапны да шул «ТатАрт» үзе бирәчәк! Сез бары идеолог кына булырсыз. Идеолог кына! Без сез кушканнарны гына эшләрбез. Сез кирәк дигән эшләрне йөгереп йөреп башкарырбыз. Сез әйткән кирәкле китапларны бастырырбыз, бушлай халык арасында таратырбыз. Төп максатыбыз туган телебезне саклау, үстерү, милли мәнфәгатебезне яклау булыр! Телисез икән, ипи тотып ант итәрмен! Риза гына булыгыз!..

Минем яхшы ук йомшара башлавымны тоеп алган Дамир тагын да дәртләнә төшеп болай дип өстәде:

—Фонд өчен кирәкле ике-өч кешенең хезмәт хакы «ТатАрт» тарафыннан түләнәчәк. Алар, ширкәт штатында исәпләнсәләр дә, фонд өчен генә эшләячәкләр... Сезгә дә хезмәт хакын шуннан билгеләрбез!

Соңгы тәкъдимнән мин шунда ук кискен рәвештә баш тарттым (ул елларда «профессорлар хәерчелеге» башланмаган иде әле). Кеше җәмгыятькә вә үз кавеме өчен нәрсәнедер бөтенләй бушка эшләргә тиеш—бу минем иманым, дидем. Үзем эчтән генә «рәте-ние булмаса, тәртәгә тибеп китеп барырга да җайлырак булыр» дип уйлап куйдым. Дамир исә нәрсә уйлагандыр, анысын белмим, әмма бу сүзне сөенеп дигәндәй кабул итте, хәтта «профессорлар хәерчелеге» башлангач та әлеге мәсьәләгә кайтып тормады.

Хезмәт хакына дигән нәрсәгә болай махсус тукталуым тикмәгә түгел. Ара-тирә тормыш шартлары, матди мөмкинлекләр хакында сүз чыкса, кайберәүләр, «синең фондың бар», дип, мәгънәле рәвештә төрттереп куялар. Ләкин фонд оешкан көннән алып бүгенгә кадәр аннан бер тиен дә хезмәт хакы алганым булмады. Үземнең хезмәтләрем кергән (редакторлык итүем һәм мәкаләләрем басылган) китаплар чыкканда да акча өмет итмәдем. Бары унбиш-егерме, кайчакларын утыз-кырык нөсхә китап алып, аларны иң элек кафедрам хезмәткәрләренә, аспирантларга, кирәксенгән, кызыксынган каләмдәшләргә, дусларга өләшүдән, хәтта чит илләрдәге коллегаларга җибәрүдән тәм таптым. Кыскасы, «гонорарым»—шул китаплар, өләшүләрем исә чын бәйрәмнәрем булды. Бу гадәтем һаман да дәвам итә...

Болар хакында тәфсилләбрәк язуым тикмәгә түгел: мөнәсәбәтләрнең шулай акча-макчадан өстенрәк урнашуы бөтен яктан да уңайлы, файдалы булып чыкты. Дамир Сираҗиның үзе белән дә, «ТатАрт»тагы башка егетләр белән дә акча хакында сүзгә килү, ямьсезләнү, рәнҗешү күренешләре булмады. Аллага шөкер! Дамир вафат булып, аның мирасы тирәсендә туганнары, варислары арасында беркадәре ыгы-зыгылар чыккан вакытта да миңа җил-янгыр тимәде.

Димәк, җыеп әйткәндә, татар телен, мәдәниятен яклау, үстерү буенча махсус фонд оештыру хакындагы фикер-идеянең барлыкка килүендә минем турыдан-туры катнашым юк икән. Бу хакта махсус әйтергә теләвем очраклы түгел. Берничә мәртәбә матбугатта «М.Госманов оештырган махсус фонд»ише фикерләр яңгырап алгалаган иде. Дөреслектә идея тәүбашта бүтән кешеләр—Дамир Сираҗи һәм Разил

Вәлиевләр башында туып, аларның тырышлыклары, үҗәтлекләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән, тормышка ашкан иде. Болардан да төп инициаторның һәм иң нык жигелеп эшләүченең, йөгереп йөрүченең Дамир Сиражи булуы, Разилнең исә идеолог, киңәшче, әйдәп баручы икәнлеге сизелеп торды миңа. Үзем исә хәрәкәткә бары юл башында гына, ягъни фикер-идея туып, оешып өлгергәннән соң, дөресен әйткәндә, теләр-теләмәс рәвештә, икеләнеп кенә кушылучы, аның баштагы чор эшчәнлегенә чамалы гына өлеш кертүче булдым.

Хәзер уйлап, анализлап карасам, хәйриячелек эшен җанландырыр өчен Дамир тәкъдим иткән юл—фонд янында сәүдә үзәге, ширкәт сыман бер нәрсә оештыру моделе—ул чор, халыкта хосусый милек булмаган шартлар өчен бердәнбер мөмкин, шунысы белән шактый дөрес алым булган икән. Иҗтимагый активлыкның бу моделе үзен аклады дип әйтергә мөмкин.

Әлбәттә, фондның шулай әкренләп тәмам оешып җитүенә, махсус исем алуына миңа да актив катнашырга туры килде. Әгәр фонд тарафыннан чыгарылган беренче басмаларда нашир сыйфатында аның исемен белдергән сүзләр кыскартылган рәвештә «ТЯК» (янәсе «Татарский язык и культура») дип бирелгән булса, бераз соңрак рәсми исем «Җыен»га үзгәрде. Сәбәбен алга таба күрербез.

* * *

Фондның актив эшли башлаган, хезмәттәшлекнең нәтиҗәлерәк барган чоры аның офисы Чехов белән Лесгафт урамнары чатындагы йортның беренче катында булган чагына туры килде бугай.

Фонд алдына куелган бурычлардан башкарылган беренче эш сыйфатында 1990 елда Михаил Худяков китабының яңа басмасы чыгарылуын атарга кирәк...

Шулай итеп, милли хәрәкәтнең шактый көчәйгән, киң канат җәйгән чорында Михаил Георгиевич Худяковның хезмәте дә иҗтимагый аңыбыз үсүгә үз өлешен кертте дип әйтергә мөмкин...

Ниһаять, Худяков китабын бастыруның республикабызда үзешчәнлек юлы белән китап чыгару хәрәкәтенең беренче карлыгачларыннан икәнлеген дә әйтү артык булмастыр. Моннан соң андый китаплар чыгару киң колач җәйде.

* * *

М. Худяков китабының 1990 елгы басмасы тудырган тәэсирдән канәгатьләнү безне 1991 елда Карл Фуксның татарлар хакындагы хезмәтләрен җыеп, «Казанские татары» исемендә аерым китап рәвешендә чыгаруга китерде. Китапка галимнең төп ике әсәре: «Краткая история города Казани» һәм «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях» дигән хезмәтләре кергән иде.)

Бу юлы инде китапның яңа басмасын чын-чынлап репринт (ягъни төгәл фотокүчермә) ысулы белән бастыру мөмкинлеген таба алдык. Техник җайланмалары булган типографияне, тырышып эзли торгач, Дамир тапты. Хәтта басманың кәгазен дә сайлау, аны XIX гасыр кәгазенә охшаганрак итүгә ирешү дә аның идеясе булды.

Күп тираж белән басылган, нигездә бушлай таратылган китап тиз арада күпләгән укучыларын тапты, аларның ихтирамын казанды...

Табигате буенча гадел, гел дөреслеккә омтылучан чын гуманист Карл Фукс татарлар турында язган чакта читтән торып яки өстән аска карап, кайбер авторлар сыман үзе өчен аңлаешсызрак күренешләр хакында борын җыерып яисә мыскыллап сөйләми, бәлки предметны белеп, вәзгыятьне аңлап яза. Гореф-гадәтләрдәге үзенчәлекләрне күрә белүдән тыш, унай сыйфатларны, өстенлекләрне махсус билгеләргә онытмый, кимчелек, җитешсезлек дип исәпләгән нәрсәләр хакында да гап-гади итеп әйтү осталыгына ирешә. Кайбер сәеррәк күренешләрдән җинелчә, дустанә рухта көлә дә белә. Ләкин мондый юлларны укыган чакта синдә ризасызлык яки хурлану хисе тумый. Баксаң, татарлар турында кешечә дә язып була икән!

Җыеп әйткәндә, К. Фукс—рус һәм европалы авторлар арасыннан тәүгеләрдән диярлек булып Казан шәһәре һәм андагы татарлар хакында беренче гыйльми объектив, гуманистик рухлы тарихи, этнографик хезмәтләрнең үрнәкләрен биргән үзенчәлекле галим ул...

Алга йөгереп шуны әйтәсе килә: 1991 елгы башлангычны дәвам итеп, «Жыен» фонды 2005 елда Карл Фукс хезмәтләренең күпкә тулырак җыентыгын бастырып чыгарды. Элекке китабы нибары 210 биттән генә гыйбарәт булса, соңгысы 480 битле булып, галимнең тормыш юлына, эшчәнлегенә караган документлар, фоторәсемнәр белән истәлекләрне дә эченә алган. Матур бизәлештә чыккан китапны җәмәгатьчелек шулай булырга тиеш дигән төсле тыныч һәм җылы кабул итте. Хәзер фонд галимнең төп хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итүне оештырып, аны «Шәхесләребез» сериясендә чыгаруны планлаштыра.

90нчы елларның беренче яртысы һәм урталарында нәшер ителгән төрле китаплар арасында заманасында күренекле, ләкин соңрак билгеле сәбәпләр аркасында исеме онытттырылган тарихчыбыз Һади Атласиның «Сөенбикә»се дә бар (1992). Элекке чор язуыбызны өйрәнергә теләүче яшьләребез өчен күнекмә кулланмасы да булсын дигән ният белән текст биткә-бит янәшә урнашкан ике язуда—гарәпчә дә, кирилицада да бирелгән иде.

Шул елларда чыгарылган китапларның мөһимнәреннән берсе сыйфатында бөек мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспринскийның үз чорында ук русча язылган «Россия и Восток» исемле китабын атарга мөмкин (1993). Совет чорында авторның гел пантюркизмда, ягъни төрки халыкларны башка милләтләргә каршы куюда, башкаларга карата дошманлык анын уздыруда гаепләнүе хөкем сөргән иде. Баксаң, беренче төркичә гәзит «Тәрҗеман»ның нашире Русия шартларында төрки халыкларның да, башкалар кебек үк, тигез хокукка хаклы булуын теләгән, шул теләген алга сөргән, раслаган фикер иясе икән.

Китап басылып чыккач, аны Мәскәү һәм Петербурглардан, Симферопольдән соратып алдылар. Димәк, китап үзенең әһәмияте белән милли кысалардан чыккан икән.

Кырымлы кардәшләребезнең соңрак хәбәр итүләренә караганда, Кырымга кайтып, анда нормаль хәлдә урнаша алмаган кешеләргә «җирле» рус-украин түрәләре белән сөйләшүләр алып барган, аңлашкан чакларда әлеге китап шактый ярдәм иткән икән. Кырым татарларын гел «хаиннар» дип гаепләргә, И. Гаспралыны исә «ата дошман» рәвешендә танырга, танытырга күнеккән чиновникларның, «Россия и Восток» китабын укып карагач, тупсалары бераз йомшарып, позицияләре дә беркадәр үзгәрә төшкән...

Дөрес, «Жыен» фонды тарафыннан чыгарылган китапларның кайберләре аерым укучыларга ошап та бетмәде. Мәсәлән, Австралиягә барып, Аделаида шәһәрендә кунак булып кайткан Президент аппараты җитәкчесенең тәкъдиме буенча (Мәдәният фонды исәбенә) чыгарылган «Ихлас дога» исемле кечкенә җыентык (1995). Ләйлә Садрыйның шигырь-мөнәҗәтләрен эченә алган, ләкин шул чор өчен шактый күркәм итеп чыгарылган китапчыкка карата бер шагыйрәбез көнләшеп, «бай хатын китабын чыгаргансыз икән», дип төрттереп куйган иде. Икенче бер мәгълүм шагыйрәбез исә китапка кергән әйберләрнең уртакул булуын әйтеп, «Мондый матур китабым чыкса, үләргә дә риза булыр идем»,—диде. Хәер, авторның үзенә дә аны һәвәскәр дип атавым ошамады шикелле.

* * *

90нчы елларның беренче яртысында эшләр шулай, әкрен генә булса да, алга бара дип әйтерлек иде. «ТатАрт» үзәгенең Дамир Сиражи тырышлыгы белән вакыт-вакыт гөрләп эшләве сизелә. Андагы егетләрнең, кызларның саны кайвакытлар уннан артып китсә, берара дүрт-бишкә генә калган була. Дамир үзе исә гел хәрәкәттә, тыз-быз чаба: Мәскәүгә, Киевкә, Ташкентларга барып кайткалый. Татарстан шәһәрләрен әйтәсе дә юк. Сәфәрләре, чапкалаулары гел «ТатАрт» буенча. Кыскасы, Дамирның төп кызыксынганы фондтан бигрәк «ТатАрт» эшчәнлеге икәнлеге ачык күренә иде.

Фонд офисы Лесгафт урамында, ягъни безнең йортыбыздан нибары йөз адым чамасы гына күршедә булган чакта, Дамир безгә еш кергәли, тәмәкесен тарта-тарта чәй, кофе эчеп гәпләшеп, кинәшеп утырырга ярата иде. Бер темадан икенчесенә күчә-күчә, кыска җаваплардан да канәгатьләнеп, кайбер тарихи вакыйгалар,

эшчәнлекләре бездә аз өйрәнелгән, начар яктыртылган элекке чор татар әдипләре, җәмәгать эшлеклеләре хакында сораштыра иде. Дөрес, Дамирның үзен дә белемсез, тарихтан хәбәрсез дип әйтмәс идем. Тик милли тарихыбыз буенча белгәннәренә система, эзлеклелек җитмәве сизелеп куя иде. Аның каруы рус һәм европалы халыкларның мәдәниятләре, бигрәк тә театр һәм сәхнә сәнгатьләре, режиссер вә артистлары хакында шактый белә, яратып сөйли торган иде. Фикерләве оригиналь һәм кыю дип әйтер идем.

Офистагы бүлмәләргә абстракт рухта ясалган берничә рәсемнен килеп керүе зәвык һәм мәнфәгатьнен кайлардарак йөрүенә ишарә итсә кирәк.

Бер көнне, алдан шалтыратып, вакыт мөмкинлеген ачыклагач, кофе эчәргә, беркадәре ял да итеп алырга дип өебезгә килде. Кәнәфидә җәелеп утырган, чылемен суыра-суыра кофе чөмереп ләззәтләнгән чакта, җаен китереп, үземне кызыксындырган нәрсәләр хакында сорауларымны бирдем. Өркетмәс өчен ерактанрак сүз каттым. Хезмәттәшлек итә башлаганда,—дидем,—төп максат фонд эшчәнлеге, ә сәүдә оешмасы ярдәмчел урында булырга тиеш кебек иде. Хәзер исә киресенчәрәк килеп чыга, фонд үзе ярдәмчел чарага әйләнеп калды шикелле. Беренче урында «ТатАрт» эшчәнлеге, аның мәнфәгатьләре торганлыгы бәхәссез. Ярар, бүлмичә тынлап тор, әйтеп бетерим,—дидем.— Мин боларны үпкә рәвешендә яки гаепләп әйтмим. Әгәр дә матди мөмкинлекләр тудыра торган «ТатАрт» булмаса, фондның үзе булуы да бәхәсле икәнлеген яхшы аңлыйм хәзер... Шулай ук сине бары байлык булдыру өчен генә тырышасың дип тә раслый алмыйм. Дөресен әйткәндә, син бары байлык комфорты өчен тырышучы кешегә охшамагансың. Җыеп ял да итә белмисең, зиннәт-бизәкләр белән дә мавыкмыйсың. Шулай да синең әллә нинди бер омтылышың, максатың, стратегик максатың барлыгы миндә шик тудырмый хәзер. Шулай бит, Дамир?— дидем.


*Әти-әнисе һәм энекәше Рэм (арткы рәттә уңнан беренче) белән.*

Ул тартылып бетмәгән сигаретын сүндерде, шунда ук икенчесен алып кабызды, бер миңа, бер идәнгә карап, тиз-тиз чылемен суыргалап алды. «Әгәр бик яшерен сер, яки тегендирәк, ягъни интимрак ният булмаса, миңа да әйтерсең. Белеп кенә торырмын, башкаларга сөйләмәм сереңне... Бәлкем, киңәш-уңаш та кирәк булуы мөмкин. Һич югы комачауламам»,—дидем.

Дамир беравык сүзсез утырды. Аннары яртылаш тартылган чылемен сүндереп тормыйча савытына ыргытты да, миңа күтәрелеп карады:

—Бар андый хыялым,—диде.—Монарчы ачык итеп әйтеп йөрмәгән серем бар, Миркасыйм абый. Ярар, әйтим инде, сез сорагач. Мин бик нык баерга телим. Тик байлык эчендә күмелеп, кыйммәтле җиһазлар арасында адашып яшәү өчен түгел! Андый байлыкның юк нәрсә, мәгънәсез икәнлеген яхшы аңлыйм... Әгәр әйбәт баесам, мин үземнең шәхси театрымны булдырыр идем!..

—Ничек «үземнең»?—дидем аңлап бетермичә.—Хосусый театр дигәнеңме бу? Мөмкинме соң ул?

—Бик мөмкин,—диде Дамир, күзләрен ялтырата-ялтырата елмаеп.—Үз акчама бинасы салынган, үзем бирә торган хезмәт хакына эшләп, мул, нормаль яши торган труппасы булган, иң әйбәт техника, заманча җиһаз белән тәэмин ителгән үземнең шәхси, ягъни личный театрымны булдырырга теләр идем!..—дип беразга

туктап калды, аннары тагын бер сигарет кабызып, уйчанрак рәвештә дәвам итте.—Хәзер бездәге кебек артистлары хәерче хәлдәге, директор белән режиссерның бугазларыннан чиновниклар тоткан кол театр түгел, үзем теләгәнчә чын сәнгать әсәрләрен уйный торган ирекле театр булдырыр идем...

Мин әңгәмәнең болай таба борыласын көтмәгән идем. Бераз уйланып утыргач:

—Барып чыгар микән бу?—дип шик белдердем.

—Ник чыкмасын?!—диде Дамир, янадан дәртләнеп.—Нормаль илләрдә ул гел шулай бит! Белмисезмени: иң әйбәт опера, драма театрлары бездә түгел, Италиядә, Франциядә, Америкада, Германиядә, Англиядә. Иң әйбәт кинолар да шуларда куела. Иң мәгънәле спектакльләр хосусый театрларда уйнала.

—Аның каруы безнең балет көчле бит,—дидем, үземнең дә төшеп калганнардан булмавымны күрсәтергә теләгәндәй.

—Әйе, —диде Дамир, беркадәре ачырак елмая төшеп,—революциягә кадәр язылган һәм чит ил композиторлары музыкасына куелган балетларыбыз бар барын. Әйбәт биючеләр дә юк түгел... Тик, Миркасыйм абый, Рудольф Нуриев белән Ирек Мөхәммәдевләрнең ни өчен чит илләргә качулары, шунда дөньякүләм танылып, миллионер булулары хакында уйлаганыгыз бармы сезнең? Ни өчен, нигә?!. Бездәге кебек режиссер белән артист якаларына чиновниклар ябышкан шартларда сәхнә сәнгате үсә алмый шул! Чак кына ирекләрәк, иҗатчарак кылана башлаган режиссерның артына тибәләр. Артистның да... Хөкүмәт карамагында булган, аның акчасына яшәгән театрларда торгынлык хөкем сөрә, анда тынчу атмосфера хөкем сөрә, гомумән алганда шулай ул. Ара-тирә генә, ялгышып дигәндәй, җинел сулап куясың...

Мин бу сүзләрне тыңлаганда Дамирның еш-еш эш урыннарын алмаштыруы хакында уйлап алдым. Атмосфераны бераз булса да йомшартырга теләдем:

—Хыялың әйбәт әйбәтен,—дидем,—тик безнең Русия шартларында андый планнар эшкә аша алыр микән? Бездә бит халык та, түрәләр дә башкачарак тәрбияләнгән, шуңа күрә бүтәнчәрәк уйлыйлар.

—Үзгәрәчәк, барсы да үзгәрәчәк!—диде ул, янадан күзләрен очкынландырган хәлдә миңа төбәлеп дәвам итте.—Ә беләсезме, мин нәрсәдән өмет итәм? Көлмәгез, Миркасыйм абый, мин хәзерге түрәләребезнең сатлык булуларына зур өмет баглыйм! Алар хәзер элекке, идеяле, принципиаль начальниклар түгел инде. Аларның күпчелеге, кирәк тапсалар, аналарын да сатачак! Гаҗәпләнмәгез, хәзер үсеп чыккан байларның күпчелеге иман алыштырган кичәге партия лидерлары, комсомол вожаклары ул. Житәкче урыннар белән дә рәхәтләнеп сату итәләр. Акча булса, менә шуларны сатып алып, теләгән кадәр яналык кертергә мөмкин. Ә ирекккә чыккан бер яналык ул шешәдән чыккан җен шикелле. Бөтенесен аздыра-аздыра киң тарала... Кыскасы, бөтен тәртипләр үзгәрәчәк, киләчәктә догматик принциплар түгел, акча хәзрәтләре хакимлек итәчәк!.. Димәк, шәхси театрлар да туачак!

—Хыял гына булып калмагае...—дидем мин. Ул исә көлеп сабыр гына җавап бирде:

—Әйе, хәзергә хыял гына шул. Ә хыялсыз яшәп буламы соң бу дөньяда?!

Әңгәмәбез нәкъ шул төштә өзелеп калды: шаулап-гөрләп балалар кайтып кергән иде.

Икенче мәртәбә бу темага сөйләшү насыйп булмады безгә. Миңа сүз кузгатырга туры килмәгән төсле, Дамирның үзенә дә аңа кагылу уңайлы түгел иде, күрәсең. Ул, бәлкем, шулай ачылып сөйләшүе өчен үкенеп тә йөргәндер әле...

* * *

Дамир Сиражиның киң колачлы, хыялга бай, хәтта кодрәтле мөмкинлекләргә ия режиссер икәнлегенә миңа 1991 елның җәендә (20-25 июнь көннәрендә) Казан шәһәрендә уздырылган «Җыен» бәйрәмендә чын-чынлап ышанырга туры килде. «Татар теле һәм мәдәнияте» фонды исеменнән оештырылган иң зур чаралардан булган иде ул «Җыен» бәйрәме. Мин башта гадәти генә концертлар, чираттагы шоу җыелмасы гына булыр бу дип уйлаган идем. Ләкин Дамир хәзерге заман концерт

номерларына ерак тарихка күргәзмәле сәяхәт ясау алымнарын да кушкан, шәһәрнең үзәгендә—Кремль һәм аның тирәләрендә, хәтта күгендә дә—бер үк вакытта бара торган «уеннардан», хәзергечә әйтсәк, моңарчы бездә күрелмәгән галаспектакльдән гыйбарәт булды әлеге «Жыен».

Башта, 20 июньдә, стадионда, ачык һавада, зур артистлар катнашлыгында жырбию, акробатика номерлары, самолетлар «концерты», парашюттан сикерүләр белән башланып киткән иде. Тамаша икенче көнне (21ендә) Кирмәндә—Кремльдә барды. Анда, караңгы төшә башлауга, Казанны яулауны, аны саклаучылар каршылыгын, диварлар шартлау, мөдһиш «каратуннар» баскынын, аннары нарасыен күкрәгенә кыскан Сөембикәнең әсир алынуын, сөргенгә озатылуын гәүдәләндергән күренешләр күз алдыннан кичте, аннары тагын туплар шартлады... Мәсгудә Шәмсетдинова музыкасы белән баетылган «Сөембикә кыйссасы» иде бу...

Тамаша идеясенең иң элек кем башында тууын, сценарие кем тарафыннан язылуын, репетицияләрнең ничек, кайларда уздырылуын, кызганычка каршы, белмәдем. Йөзләгән кеше катнашкан, һәрберсенә гонорар бирелгән, транспорт, самолетлар өчен дә түләнгән тамашаның күпмегә төшүе белән дә, гадәтемчә, кызыксынмадым. Әмма тамашаның шундый киң колачлы планда оештырылуы режиссураның эзлекле, һәр тарафтан уйланылган, бөтен чараларның житди рәвештә оештырылган булуы мине шаккатырды. Мондый бер урында карап, күреп торып, турыдан-туры житәкчелек итеп булмый торган шартларда да зур «сәхнә» белән шулай уңышлы идарә итә алу житәкченең, бу очракта режиссерның, гажәеп күрә белү, булачак хәрәкәтләрне дә күз алдына китерә алу сәләтенә ия булуын раслый иде, әлбәттә.

Мине чын-чынлап тетрәндергәне, төрле яклап уйландырганы, хәзергәчә уйландыра торганы асылда әлеге шау-шулар, эффектлы манзаралар түгел, бәлки бөтенләй башка нәрсә булды. Ул нәрсә 1552 елның октябрендә Кирмәнне саклап бихисап кан коелганнан, башлар киселгәннән, жирле халык шәһәрдән бөтенләй сөрелгәннән соң дүрт йөз дә кырык (440!) ел узгач, әлеге фажигале туфракта шул вакыйгаларны хәтердә яңарту, шул хакта ачыктан-ачык игълан итү иде.

1919 елга кадәр татар кешеләренә Кирмәнгә керү тыелган булуын, шул елда гына Сөембикә манарасына ай куябыз дип бер талпынып алуны искә төшердем. Совет чоры татар куштаннарының әлеге вакыйгаларны бөтенләй онытырга тырышулары, манараның кемнеке булуы хакында сүз әйтүләрне катгый тыюлуы әле дә хәтердә. Димәк, күпне күргән, күпне кичергән тарихи Кремль туфрагында оештырылган әлеге «Жыен» дигәннәре гадәти генә уен-тамаша түгел, бәлки милли-азатлык хәрәкәтенең бер мөһим күренеше дә икән!

Фонд тарафыннан «Жыен» бәйрәменең дүртенче көнендә (23 июнь) Болгарда уздырылган Сабан туе да оештырылу сыйфаты ягыннан истә калырлык вакыйга булган иде. Анда да Дамир үзенең киң колачлы оештыручы, күп нәрсәләрне алдан күрә белүгә сәләтле сизгер режиссер икәнлеген раслады. Мине аерата кызыксындырганы шул булды: Казаннан килгән фонд егетләре, махсус чакырылган артистлар гына түгел, жирле Спас районы кешеләре дә, жөмләдән, шәһәрдәге урыс түрәләре дә актив катнашып, кирәге чыкканда йөгереп йөреп хезмәт иттеләр. Мона, ихтимал, милли хәрәкәтнең ул еллардагы көче, куәте дә тәэсир иткәндер.

«Жыен» бәйрәме шулай шаулап узгач, мин фондыбызның исемен «Жыен» дип үзгәртергә тәкъдим иттем. Иптәшләр килештеләр. Шул рәвешчә, яна басмаларда элекке килешсезрәк ТЯК урынын «Жыен» нәшрияты» дигән гыйбарә ала башлады.

Дамир Сиражиның режиссерлык куәте, таланты аның профессиональ театр сәхнәләрендә куелган спектакльләрендә дә чагылгалап алган иде. Шулардан мине (мине генә микән?!) искитәрлек дәрәжәдә гажәпләндергәне, хәтта шаклар катырганы, әлбәттә, «Ахырзаман» спектакле булды. Чыңгыз Айтматовның болай да тирән фәлсәфә һәм үтемле әдәби чаралар белән язылган бик тә катлаулы, гажәеп талантлы әсәрен ул, Дамир, искитәрлек бер осталык белән сәхнәләштергән иде. Сәхнәдәге вакыйгалар әллә кайлардагы ерак Тянь-Шань таулары арасында, безнең өчен ят дип әйтерлек кешеләр, хәтта жан-жанварлар, бүреләр катнашында барса да,

әсәрдәге ситуацияләр һәммәбез өчен дә якын, уртак итеп бирелгән. Көчекләрен, ягъни балаларын җуйган ана бүренең үкси-үкси улаган тавышы һаман да колакта янгырый кебек.

* * *

«Җыен» фонды оештырган чираттагы зур чараларның берсе 1993 елда уздырылган «Балалар җыры» конкурсы иде. Кечкенә генә булса да, анын шактый гыйбрәтле тарихы бар.

1987-1989 еллардан алып, милли-азатлык хәрәкәте көчәю аркасында СССР дигән зур дәүләт таркалу процессын кичерә башлаган дәвердә бер «сәер» яналык барлыкка килгән иде. Монарчы илдә татар дигән халык барлыгын үзе дә оныта язган, башкаларны да оныттырырга теләгән Мәскәү, дөресрәге, анын үзәк радиосы, көн саен диярлек төш вакытларында, хәтта кайбер көннәрне иртә-кичләрен дә, татар җырларын бирә башлады. Ректораттагы эш бүлмәмдә радионы, вакыйгалардан хәбәрдар булып торыр өчен, гел ачык тотам, шуна күрә Мәскәүдән тапшырылган татар җырларын ишетеп тора идем.

Ләкин шул ук елларда безнең Казанда элек атнасына ике-өч мәртәбә диярлек балалар өчен махсус тапшырулар бирә торган татар радиосы аларны бөтенләй оныта язды. Бераздан исә, балалар программасын кайтарырга теләп, балаларның үзләреннән дә мәхәббәт җырларын җырлатырга тотынды. «Тала-тала беләгем, яна-яна йөрәгем» ише. Күрәсен, элекке пионер җырлары вакыт рухына туры килмәгәнлектән, яналары язылмаганлыктандыр инде.

Һәрхәлдә, бик сәер, гайре табигый хәл иде бу. Шуңа күрә бер очрашуда борчылуларымны Дамирга да әйттем. Берәр композиторга заказ биреп, балалар өчен махсус җырлар яздырмаскамы микән, дидем. Дамир уйга калды, учлары белән кара сакалын капшап, ияклəрен кашып алды, аннары:

—Бик дөрес фикер бит бу!—диде.—Әйдәгез, балалар җырына конкурс оештырабыз! Ә сез шуны нигезләп бер мәкалә языгыз!

Һәм мин «Ник янмасын бала йөрәге» дигән текстны яздым. Фондта карап чыккач, ана конкурс шартлары да өстәлде. Мәкалә-игълан өч гәзиттә басылып чыкты (1993). Күп тә узмый җырлар да килә башлады. Бер Казаннан гына түгел, Себердән дә, хәтта Америкадан да бар иде җырлар. Димәк, җәмәгатьчелек ихтыяҗны дөрес анлаган. Әмма профессиональ композиторларыбыз исә—ләм-мим. Ягъни берни бирмәделәр конкурска. Һәвәскәрләрдән генә килде җырлар...

Дамир да канәгать түгеллеген яшермәде: «Кыен чакта торткан чыгымнар акланмады бит»,—дип мыгырдады.

Мин исә күпмедер еллар узгач кына әлеге сүлпәнлекнең сәбәбен анладым: гел дәүләт, хөкүмәт кулыннан ашарга өйрәнгән, шулай күнеккән, шул рәвешчә рухан люмпенлашкан совет композиторлары шәхси инициативага, хосусый чараларга ышанып бетмәгән икән. Аларга югарыдан төшә торган күсәкле-кәнфитле күрсәтмә җитмәгән икән...

Ләкин яна шартларда оештырылган беренче конкурс, үз максатына ирешмәсә дә, бөтенләй үк эзсез узмады. Шуннан соң республикада җыр сәнгате буенча төрле конкурслар уздырыла башлады. Бүген дә дәвам итә алар. Яна талантлар ачылуга да, бармак белән «йолдызлар» әвәләүгә дә өлеш кертеп киләләр, шөкер...

* * *

90нчы елларның урталарына таба эшләр авырая төште. Илдә барлыкка килгән кайбер икътисади кыенлыклар «ТатАрт» эшчәнлегенә дә тәэсир итте. Дөрес, вак-төяк уңышсызлыклар элек тә булгалый иде. Мәсәлән, 91-92 елда кышын «ТатАрт» үзәге, киләсе елда Идел буенча круизлар оештырырга дип, теплоходлар өчен күпләп төрле җиһазлар сатып алган иде. Тик язга таба ягулыкларның кинәт кыйммәтләнүе, халык кулындагы акчаларның да «дөрләп януы» аркасында бөтен планнар челпәрәмә килде, «ТатАрт» зур зыян күрде. Әмма 90нчы еллар уртасыннан алып андый уңышсызлыклар системага әверелә башлады. Ләкин гомумән алганда нинди конкрет уңышсызлыклар булганын мин җүнләп белмәдем һәм белергә дә

тырышмадым. Фонд буенча нәрсәләр һәм ничегрәк эшләргә кирәклеген әйтү, шулар хакында киңәшүдән ары узмаска тырыштым. Дамирның үзе белән якыннан аралашып, дуслашып китмәгән кебек, «ТатАрт» эшләренә дә бик тыгылмадым.

Үзәк эшләренең авырая, начарлана баруының бер нәтиҗәсе компаньон Фәрит Хәмидуллинның «ТатАрт»тан бүленеп чыгуы булды.

«ТатАрт»ның конкрет эшчәнлегенә килгәндә, ул, башта ук планлаштырылганча, алу-сатудан, ягъни сәүдәдә арадашчылык итүдән гыйбарәт иде. Бу урында шуна да басым ясап махсус әйтергә кирәк, сәүдә эшләре гомумән мондый арадашлыктан башка бармый, бара да алмый. Мәсәлән, төрле тауар житештерүче белән кулланучы арасында аларның берсен икенчесе белән «кавыштыручы» булмаса, кулланучының вакыты, көче тауар эзләүгә китеп, төп эшчәнлеге ахыр чиктә туктальш калачак.

Шул рәвешчә, тауар әйләнешендә «үз урынын» таба алган арадашчы, әйтик, завод-фабрикалардан бер тауарны күпләп «үз бәясенә» (монысын житештерүче билгели) ала да, аны кулланучыга базар бәясенә сата. Ике бәя арасындагы аермадан арадашчының файдасы барлыкка килә. Шундый файдадан «ТатАрт» төрле салым-налогларны, бина арендасы, транспорт, ут-су, почта, телефон чыгымнарын түли. Шулай ук үзәкнең үзендә һәм «Жыен»да эшләүчеләрнең хезмәт хаклары түләнә. Ниһаять, әлеге чыгымнардан соң гына «Жыен» чараларына да өлеш чыгарыла. Тик алдан тәгаенләнгән ныклы өлеш—процентлар рәвешендә түгел, бәлки планлаштырылган, уздырылуы кирәк табылган чараларга, чыгарылуы хәл ителгән китапларга яисә башкарылуы тиеш бүтән эшләргә кирәкле күләмдә генә. Кыскасы, аяк-кулны әлләни иркен сузарга мөмкинлек юк иде. Шулай да, шөкер, жай гына эшләп ята идек әле.

Мондый базар шартларында уңышлы эшләп, файда казанып торыр өчен, әлбәттә, гел туктамыйча, бәйрәм-ялны белмичә гамәл кылырга, эзләнергә, башкалар (көндәшләр) белән ярыша-ярыша хәрәкәт итәргә кирәк иде. Баштагы елларда Дамирның тырышлыгы, активлыгы нәтиҗәсендә «ТатАрт» ярыйсы гына эшләп калды.

Шулай ару гына эш майтарып яткан бер мәлдә Дамир «ТатАрт»ның дүрт-биш хезмәткәре белән Таиландка барып кыска вакытлы ял итеп кайтуны оештырган иде. Бу аның беренче рәсми ялы иде бугай, ләкин ул аннан нык авырып кайтты (бу чир хакында соңрак сүз булыр әле).

Шул ук елларда Дамирның салынып бетмәгән бер йорт алып, шунын белән маташуы да билгеле. «Башкача мөмкин түгел! Менә кырыкка житкәнче бер ел да нормаль шартларда яшәгәнем булмады, гел общежитиедә, гел частный фатирда, алачык кебек караңгы почмакларда интектем. Ичмасам бераз вакыт булса да, адәмчә яшәп каласы иде!» дигәне истә.

Мин моны һич гаепләмәдем. Һәркемнең дә үзен кайгыртырга хакы бар. Үзенең тормыш шартларын рәтләргә теләмәгән кеше башкаларның хәленә керергә дә сәләтле булмый бит. Ә Дамир чыннан да ярдәмчел, башкаларны да кайгырта белә торган зат иде. Ул мохтаҗ кешеләргә матди ярдәм оештырды, талантлы студентларга стипендияләр биргәләүне гамәлгә кертергә тырышты.

Дамир Сиражи чыннан да күп эшли иде. Ул гел хәрәкәттә, гел юлда булды, тегендә барып тауар табып кайтса, монысына барып сата. Тауарлары исә төрле-төрле. Кием-салым ише «вак-төякләр»дән алып химия продукцияләре, «КамАЗ» автомашиналары, цистерна-цистерна нефть продуктларына кадәр. Дөресен әйткәндә, мин боларны тикшереп, белеп тормадым. Минем өчен моның әһәмияте аз иде. Шуңа күрә, кайчакларын бераз кызмачарак була торган Дамир чак кына жәелебрәк сөйли башлады исә, башны артык авырттырмас өчен сүзне бүтән якка борырга ашыга идем.

«ТатАрт» эшләре шулай жайга салынсын өчен анын житәкчесенең бетмәс-төкәнмәс жегәргә, искитмәле активлыкка, һәм, ниһаять, кыюлыкка, хәтта әрсезлеккә дә ия булуы шарт иде. Ә Дамирда боларның барысы да житәрлек иде. Холкы буенча ул ишектән кусаң, тәрәзәдән керергә күп сорап тормый торган максатчан кеше иде.

Бу сыйфатлары өстенә Дамирның әлеге эшләр башланган елларда Югары Совет

депутаты булуы да, һичшиксез, зур роль уйнагандыр. Чөнки түшендә депутатлык билгесе булган кешене һәр җирдә аягүрә торып каршы алалар. Моңа дәлил рәвешендә, мина соңрак Разил Вәлиев сөйләгән бер хатирәне язып үтәсем килә.

Алар икәү «ТатАрт»ка берәр тауар алу нияте белән Түбән Камага барып, андагы зур химик предприятие җитәкчесенең кабул итү бүлмәсенә керәләр. Анда папка кочаклаган ун-унбиш кеше хуҗа янына керер өчен нәүбәт көтеп утырган була. Түргә үк узган Дамир, эчке бүлмәнең ишеге янына киләрәк, секретарь ханымнан: «Кем бар анда?»—дип сорый. Ханым: «Ярдәмчесе»,—дип җавап бирә. Бер кулы белән ишек тоткасына ябышкан Дамир: «Мне кофе, ему чай!»—дип, секретарьга боерык бирә-бирә кабинетка кереп тә китә. Чират көтеп утыручылар да, секретарь ханым да авызларын ачып кала. «Кунаклар» хуҗа белән күрешеп, исәнлек-саулык сорашкан арада кофе-чәйләре белән чибәр ханым да килеп керә. Сөйләшүләр җайлы уза, «ТатАрт» җитәкчесе теләгенә артыгы белән ирешә.

Баштагы елларда Д. Сиражиевның дәүләт, хөкүмәт җитәкчеләре белән уртак тел таба алуы шик тудырмый. Бигрәк тә ул вакыттагы хөкүмәт башлыгы Мөхәммәт Сабиров чын теләктәшлек күрсәтте бугай. Премьер-министрның инициаторларны яратуын беләбез бит.

* * *

Инде әйткәнемчә, 90нчы елларның урталарында «ТатАрт» эшчәнлегендә кыенлыклар барлыкка килә башлады. Моңа, илдәге икътисади үзгәрешләрдән тыш, Д. Сиражиның депутатлык статусы үзгәрүе, ягъни икенче срокка депутат булып сайлана алмавы да сәбәп булгандыр. Син югары урында утырганыңда фәлән җиреңне яларга омтылучыларның, син аннан төшкәч, нәкъ шул җиренә тибәргә мөмкин икәнен беләбез бит.

Яңа сайлау кампаниясе башлангач, Дамир, зур түрәләр ярдәм кулын сузмагангамы, бераз аптырап калды, шуңа күрә киләчәге шөбһәлерәк булган Иван Рыбкин тарафдарларына кушылды һәм, табигый ки, берни дә барып чыкмады. Өстәвенә, ул вакытта сәясәттә оппозициядә торучы тынгысыз җаннардан һәм башка төрле «балласт»тан котылу тенденциясе көчәйгән, шуның аркасында, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, милли хәрәкәт идеяләренең үсентеләренә, тамырларына балта чабыла башлаган иде. Бер үк вакытта республика парламентына «ләббәйкәле» чиновниклар һәм теләсә нинди шартларга яраклаша белгән «сыгылмалы» демагогларга юл кин ачылган иде. Нәтиҗәдә «тотрыклы» парламент оешып, халык-милләт мәнфәгате өчен чын-чынлап кайгыртучылар, тырышучылар парламентта бик аз калган иде.

Шунысы да бар: Дамирның депутат буларак үзен әллә ни күрсәтә дә алмады кебек. Сәяси планда берәр конкрет эш майтаруын да, истә калырлык, бигрәк тә зур түрәләр күңеленә хуш килерлек нотык сөйләвен дә хәтерләмим. Ә синең сәүдә эшләрен үстерү юлындагы тырышуларыңның да, мәдәнияткә ярдәм иткәләвеңнең дә кемгә хаҗәте бар ди хәзер?! Ниһаять, Дамирның әче теллелеге, турыдан ярып әйтү гадәте дә, бәлки, кайберәүләргә ошап бетмәгәндер.

* * *

Әле генә чыгарылган нәтиҗәләргә мин, татар акылы төш узгач дигәндәй, соңрак килдем. Элек исә эшләрнең начараюында күбрәк Дамирның үзе гаепледер дип уйлый идем. Чөнки ул соңгы вакытларда кызмача хәлдә күбрәк күренә башлады. Әүвәлләре кәефле килеш йөрсә, хәзер инде яхшы ук кызган хәлдә дә очрый иде. (Депутатлык статусы аны тыеп торган булса кирәк.) Фонд ихтыяҗларына бармак аша каравы да үзен ныграк сиздерә башлады. Минем кайбер тәкъдимнәрем, сүздә кабул ителсә дә, асылда хәрәкәтсез ята бирде. Кайвакытларны моңа ачуым да килә иде. Шундый мәлләрнең берсендә мин Дамирга аны күрәсем килүем, мөһим мәсьәлә барлыгы хакында егетләр аша хәбәр җибәрдем.

Бераз кәефле рәвештә килеп керде ул. Кәнәфигә җәелеп утырып, гадәттәгечә исәнлек-саулык сорашкач, ашыкмыйча челемен кабызды, хозурланып кына ике-өч төтен «алкасы» чыгарды. Аннары, башын чак кына артка чөеп, беркадәр вәкарьле, эреләнгән кыяфәт белән:

—Йә, Миркасыйм абый, тынлыйм сезне!—диде.

Аның үзен болай тотышы мина ошамады, әлбәттә. Аңа туры төбәлгән күзләремне чак кына кыса төшеп, алгарак иелеп, әкрен тавыш белән ижекләп-ижекләп кенә:

—Юк, Да-мир,—дидем,—хәзер мин си-не тын-ларга ти-еш!

Ачыла төшкән авызы ябылып та өлгермәде, баягы вәкарьле кыяфәт эреп юкка чыкты. Үзе дә шинеп, бөрешкән төсле кечерәеп калды. Нәрсәдән ул шулай шүрләп, шикләнеп калгандыр әлеге мизгелдә—моны хәзер дә анлый алмыйм. Ә башка вакытларда ул үзе белән килешмәүне ишетүгә үк, кагыйдә буларак, ин элек, кем әйтмешли, күтәрелеп бәрелә, аннары тавышын күтәргәннән-күтәрә барып, үзенен хаклылыгын раслый башлый иде. Бу юлы исә ул янып торган тәмәкесен дә онытып, башын игән килеш сүзсез утыра бирде. Ул мина кызганыч булып тоела башлады. Баягы ачуым да юкка чыкты. Һәм мин Дамирнын чынлыкта тиз яраланучан нечкә күнелле, нәзберек табигатьле кеше икәнлеген тойдым.

Сүзне иплән кенә башка якка борунын кирәклеген анладым. «Жыен» фонды исеменә рәхмәт сүзләре ишетүемне әйткән булдым, тагын бер-ике әйбәт китап чыгара алсак, шулай мөһимрәк эш күрсәтсәк, «Жыен»нын да, «ТатАрт»нын да абруе һичшиксез артачак дигән булдым. Жаен китереп, сәламәтлеген саклаунын кирәклеге, хәмершәрабнын зарары хакында да акыл сатып алдым. Шул рәвешчә ачулануым аны кайгырту кебегрәк килеп чыкты. Бер-ике чынаяк кофе эчкәч (ул чынаягына гадәттә икеөч кашык кофе порошогы сала, шикәргә кагылып та тормый иде), Дамир янадан үз кыяфәтенә кайта башлаган, баягы кызмачалыкнын әсәре дә калмаган иде инде. Анын шул көнге сонгы сүзе иртәгәдән үк авызына бер тамчы да алмаячаклыгы хакында булды.


*М. Госманов һәм Д. Сираҗиев. 1990 еллар башы.*

Икенче бер очрашуда, тыныч кына барган әнгәмә дәвамында, Дамир «ТатАрт» эшләренен авыраюы, гомумән, эшмәкәрлекнен гел кысрыклана баруы хакында сөйләде. Шулар аркасында фонд эшчәнлегенен дә сүлпәнләнүен таныды. Матди керемнен азаюы хакында әйтеп, үз йортынын да әле тәмам төзелеп, эшләнеп бетмәгән жирләре булуын искә төшерде. Шунда ук ул үзенә бер үк вакытта «ТатАрт» житәкчесе дә, «Жыен» фонды рәисенен урынбасары, ягъни фонд директоры да булунын авыргарак килүен әйтеп, фондка хезмәт хакы алып эшли торган башка директор билгеләүнен кирәклеген әйтте. Мин анын фикерен хупладым. Күптән түгел Кыргызстаннан күченеп килгән, хәзер «ТатАрт»та эшләүче Фуат Рәфиковнын кандидатурасын тәкъдим иттем. Бу кешенен, сәнгатьтән махсус әзерлеге, белеме булмаса да, артистларны, театрны ихлас күнелдән яратуы, Илһам Шакировка бөтенләй мөкиббән китүе күптән игътибарымны жәлеп иткән иде. Дамир тәкъдим белән шунда ук килеште.

«ТатАрт»та исә штатларны кыскарту күздә тотыла, чөнки эш күләме кими бара икән. «Их, нинди әйбәт башлап жибәргән идек!.. Тагын бер дүрт-биш ел гына житмәде шул!..»—дип уфтанып алды ул. Бурычка биргән акчаларын кайтара алмавын да әйтте. «Ул бурычларнын куркыныч яклары да бар бит әле. Түләп тормас өчен... Әнә бер-берләренә юкка гына атмыйлар шул...»—үзе белән үзе сөйләшкән төсле, шулай дип тә өстәп куйды, хәтта.

Ахырда, уй-хәсрәтләренә йомгак ясагандай:

—Бик ышанып, теләкләремә тиз ирешермен дип өметләнеп башлаган идем, барып чыкмый шул хәзергә,—диде.

Чем кара күзләре яшьләнеп тә алган төсле булды...

Сонрак ишетүемә караганда, аны кайбер көндәш эшмәкәрләр төп башына утырткан булса кирәк.

Аның өчен хәзер элекке ачык ишекләр дә ябык иде бугай. Һәм бу шулай булырга тиеш иде, минемчә. Күбрәк кызмача хәлдә йөргән, вакыт-вакыт бөтенләй онытылып эчә башлаган кешегә ышаныч һәм хөрмәт кимүе табигый инде ул.

* * *

Шулай да Дамир тырышудан, талпынудан тукталмады. Запойдан чыккан араларда өзелеп калган эшләрен кузгатып җибәрергә, кирегә киткәннәрен төзәтергә тырышты. Берара башкарак, иҗадирак юнәлешкә керү хакында хыяллана башлады. Мәсәлән, музыкаль студия булдыру ише проектлар турында да сөйләп йөргән иде. Тәҗрибәләр дә эшләп караганы да булды бугай. Кыска метражлы кинофильмнар да төшергәне мәгълүм. Телефильмнар хакында да уйланды. Ләкин көндәшләре бу юнәлештә дә йоклап ятмаган. Бер гәзиттә «ТатАрт»ны хурлаган, әлеге «Ихлас дога» китабын чәйнәү юлы белән «Җыен»га да таш аткан мәкалә басылып чыкты. Аның кемнәр заказы буенча һәм кемнәрнең «консультацияләре» белән язылганлыгы әлләни сер түгел иде.

Мин башта Дамирны, аны элегрәк бөтенләй белмәгәнгә, хәмер-шәраб белән шаяртып кына маташадыр дип уйлаган идем. Бераз кәккәләп йөргәләү ул үз тормышыннан канәгатьлекне, «булдыклы ир-егетлекне» күрсәтү уены сыманрак та гадәткә кергән бит. Әмма сонрак, аны озаграк күзәткән саен, эшнен уен-муеннан узып киткәнлеген, егетнең куркыныч чиргә сабышканлыгын аңладым.

Шунысы да бар: берәр эшлекле очрашуга айнык хәлдә китеп, аннан исереп тә кайткалый башлады. Димәк, махсус эчертеп җибәрәләр. Көндәшләр арасында кин таралган күренеш, хәтәр чирне көчәйтү алымы.

Әйе, куркыныч тырнакларыннан бик сирәк кешеләр генә котыла ала торган мәкерле чиргә тарыган иде Дамирыбыз...

Айнык чагында мөстәкыйль фикергә ия кызыклы әңгәмәдәш булган Д. Сиражиев нык исергән чакта башкалар кебек үк бик ямьсезләнә, холкы тәмам бозыла иде. Өч мәртәбә гаиләсе таркалуга да шул сыйфаты сәбәп икәнлеге шик тудырмый.

Дамир торган саен чиргә ныграк бирелде. Аның язмышы өчен чын-чынлап борчылган театр җитәкчеләре, мәсәлән, Шамил Закиров аны табибка, шул чир белгеченә дә күрсәтеп карый. Марсель Сәлимҗанов исә көчләп дигәндәй кардиологка алып бара. «Тагын ике-өч запойдан соң бөтенләй чыга алмас» дигән нәтиҗәне үзенә дә әйтә. Дамир исә: «Ә нигә берсеннән соң ук үлмәм икән?!»—дип җикеренә. Һаман ышанмый ул чиренең чынлыгына...

Чираттагы бер кризистан ул чыннан да чыга алмый—йөрәге башка түзми...

Дөньяга килгәч Раид дигән исем кушылган, үзенә ошамаган шул исем урынына Дамир тәхәллүсен алган, исемен генә түгел, кәсебенең дә бер юнәлешенә үзгәрешләр кертергә теләгән гайрәт егет әлеге исемнәрен дә, якты хыялларын да, җәмгыятебез чиренең бер кечтеки өлешен дә үзе белән бергә алып арадан китеп барды...

* * *

Кеше китә—җыры кала, дигән канатлы әйтем бар. Аннан «эше кала» дигән вариант та ясарга мөмкин. Әмма чын җыр, чын эш бик сирәкләрдән кала шул.

Дамир Сиражи белән ничегрәк булыр икән, анысын өздереп әйтүе кыен хәзергә. Режиссер, артист, театр белгече буларак сәхнә сәнгатебез тарихында аның үз урыны, «үз сүзе» булганлыгы бәхәссез, әлбәттә. Бу хакта Юныс Сафиуллин тарафыннан бер китап та язылды инде. «Чәчәкләр һәм күз яшьләре» дип атала.

Әмма эшчәнлегенең бу сыйфаты буенча вафатына кадәр үк Дамир «сәхнәдән төшкән», дөресрәге, башкарак юнәлешкә кереп киткән, шуңа күрә ул даирәләрдә «онытыла да башлаган» иде (мәсәлән, «Татар энциклопедия сүзлеге»нә исеме кертелмәве шуңа ишарә.) Әйе, ул бер карауга җинел булып күренгән, ләкин чынлыкта гаҗәеп дәрәҗәдә кыен, өметле һәм шул ук вакытта шөбһәле, сирәкләрне генә елмаеп, күпләрне исә ачы ырҗаеп озата торган мавыктыргыч юнәлешкә кергән иде. Дуслардан бигрәк дошманнары—көндәшләре күбрәк булган, шуларның

күпчелеге дус булып кылана торган, шунысы белән мәкерле юнәлешкә череп баер өчен түгел, бәлки матди мөмкинлекләр тудырып, үзе теләгән, «шулай булырга тиеш» дип исәпләгән мөстәкыйль рухлы, ирекле театр сәхнәсен «әйләндерергә» омтылган иде Дамир.

Язмышы исә бөтенләй башкача хөкем чыгарган икән.

Әмма ләкин нәкъ шушы юнәлештә ярдәмчел чара рәвешендә башлаган, дөресрәге, башлануына сәбәп булган, гамәлгә ашуына шактый өлеше кергән эшләре аның исемен хәтерләрдә озаграк саклар кебек. Шуңа күрә мәсьәләнең шушы ягына да махсус тукталу зарурдыр.

Дамирдан соң дүрт-биш ай чамасы узгач, хуҗасыз калган «ТатАрт» башына, дәвамчы сыйфатында, мәрхүмнең туганнары, варислары чакыруы буенча, Ринат Мингалиев дигән берәү килде. Элек мина бу тирәләрдә күренмәгән, һәрхәлдә, минем өчен бөтенләй таныш түгел кеше иде ул... Әмма, «ТатАрт»ның яңа җитәкчесе белән хезмәттәшлек озак дәвам итә алмады. Ул мескен дә әлеге мәгълүм социаль чир белән интегә икән: чираттагы бер кризистан ул да чыга алмаган... Нәтиҗәдә күп серләре Дамир белән бергә үк киткән, күп йомгакларының очлары буталып беткән «ТатАрт» ширкәте дә яшәүдән туктады...

Шул рәвешчә, бушлыктан тап-такыр янчыгын гына тотып төп башына утырып калган «Җыен» фондын инде нишләтергә дип белмичә йөргән вакытта, көтмәгәндә диярлек, «Татнефть» тарафыннан оештырылган «Рухият» фонды белән хезмәттәшлек барлыкка килде. Моның да үзенә күрә, кечкенә генә булса да, гыйбрәтле тарихы бар.

Шәкертләремнән Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллиннар үз инициативалары белән, «Рухият» фондының матди ярдәмендә, Шиһабеддин Мәрҗани һәм Риза казый Фәхреддиннәргә багышланган ике җыентык чыгаруга ирешәләр (1998 һәм 1999). Аларга Сөләйман Рәхимев тә кушылып әзерләнгән өченче китап—бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе тарихын яктырткан җыентык та эшләнеп бетәр алдыннан Раиф минем янга киңәшкә килде һәм яңа китапка редактор булуымны сорады (1999).

Сөйләшә-киңәшә торгач, шундый рухтагы тагын берничә җыентык чыгару мөмкин дигән фикер туды. Бубыйлардан соң Фатыйх Кәримигә тотынырга, аннары Газиз Гобәйдуллин һәм бертуган Рәмиевләр хакында уйларга кирәк таптык. Күз уңында тагын ун-унбиш күренекле шәхесебез бар иде. Әгәр барып чыкса, ягъни «Рухият» фонды кабул итсә, бер махсус серия чыгарырга мөмкин булыр дип уйладык. Серия булгач, аңа исем дә кирәк бит инде. Шул әңгәмә вакытында ук мин ул сериягә «Шәхесләребез» дигән исем бирүне лаек таптым.

Фатыйх Кәримигә багышланган китапта (2000) серия исеме махсус рәвештә игълан да ителде.

Шул рәвешчә «Рухият» фонды ярдәме белән әлеге сериядә тагын өч китап дөнья күрде (2002 елда Г. Гобәйдуллин, Бертуган Рәмиевләр һәм Г. Гомәригә багышланган җыентыклар; димәк, «Шәхесләребез» сериясендә «Рухият» ярдәмендә барлыгы җиде китап дөнья күргән иде).

Моннан соң «Рухият» фонды иң элек хәзерге исән әдипләрнең, беренче нәүбәттә Кама аръягында туып-үскән кешеләрнең әсәрләрен чыгаруны төп бурычы итеп сайлады. Әйтергә кирәк, бу юнәлештә ул аз вакыт эчендә һәрьяклап хуплауга лаек зур нәтиҗәләргә ирешә алды. «Афәрин!» дип әйтәсе генә кала.

* * *

Басылып чыккан, халык кулына кергән китап ул хәтер юлындагы багана сыман гел күренеп, гел искәртеп торачак.

Дамир Сираҗиның фонд эшчәнлегенә ясаган икенче бер тәэсире дә бар. Ул тәэсир «Җыен» фондының театрыбыз тарихы, бигрәк тә Галиәсгар Камал исемендәге академик театрның эшчәнлеге белән якыннан кызыксынуыннан гыйбарәт.

Бу процесс бер кечкенә публикациядән башланды. Дамирның инициативасы белән «Җыен» фонды Вәлиулла Мортазин-Иманский белән Төхфәт Ченәкәйләр тарафыннан язылып, 1926 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Татар театры тарихыннан» исемле кечкенә генә күләмле, ләкин эчтәлеге ягыннан әһәмиятле истәлек китабын

яңадан бастырып чыгарган иде (1996). Анда бер төгәлсезлек тә киткән: яна басманың Д.Сиражиев инициативасы белән басылуы әйтелмәгән, аның фамилиясе редакция шурасына да кертелми калган. Менә, ихтимал, китап эшләнеп бетәр вакытында минем сырхаулап (бер-бер артлы ике инфаркт сугып), хастаханәләрдә яткалавым сәбәп булгандыр. Һәрхәлдә, ничек кенә булмасын, төгәлсезлек өчен гаепне мин үз өстемә алдым. Һәм, Илтани ханым Илалова тәкъдиме белән 1926 елда чыккан «Татар театры (1906-1926)» дигән зур күләмле, бай эчтәлекле китапның 2003 елда чыккан икенче басмасын әзерләгән чакта (текстны басмага Әнвәр Хәйри әзерләде), «Алтын баганаларыбызның берсе» дип исемләнгән кереш мәкаләдә мин әлеге төгәлсезлекне төзәтергә тырыштым (9нчы бит).

Узган гасырның 30-80нче елларында, ягъни большевистик субъективлык хөкем сөргән чорда, театрыбыз тарихы буенча махсус рәвештә бозып бирелгән ялгыш мәгълүматларны, аңлы рәвештә тарих «үзгәртүләрне» төзәтергә сәләтле иде бу китап. Ул, өстәмә фотоматериаллар белән тәэмин ителгән хәлдә, затлы бизәлештә шулай яңадан «Мәгариф» нәшриятында басылып чыкты. Камал театры белән «Җыен» фонды арасындагы актив хезмәттәшлек җимеше буларак дөньяга чыккан бу китап тәҗрибәсе нәтиҗәле хезмәттәшлекнең яңа төрләренә дә сәбәпче булды.

Менә бишенче ел инде театр җитәкчеләре инициативасы белән уздырыла башлаган «Яңа татар пьесасы» конкурсын оештыруга, җиңгән әсәрләрне бүләкләүгә, игътибарга лаеклы пьеса текстларын бастырып чыгару эшенә «Җыен» фонды да якыннан катнашып килә. Соңгы елларда бу чарага Татарстан Мәдәният министрлыгы да кушылды. Яңа пьесалар текстларын эченә алган җиде том дөньяга чыкты инде, сигезенчесе эшләнеп ята. Димәк, башка театрлар, һәвәскәр коллективлар өчен дә сайларга, файдаланырга материаллар ишәя дигән сүз.

Һәр елның 12 декабренә, Дамирның арадан киткән көненә туры китереп, Камал театры коллективы, «Җыен» фонды катнашуында, аның истәлегенә багышланган хәтер кичәсе уздыра. Шул көнне хәзерге чор сәхнә сәнгатебез үсүгә өлеш керткән режиссерларга, сәхнә осталарына Дамир Сиражиев исемендәге махсус бүләкләр тапшырыла...

Шулай итеп, Дамир Сиражиев эшчәнлеге, аның кайбер идеяләре, иҗат һәм тормыш юлының чагыштырмача кыска булуына карамастан, замандашларының, хезмәттәшләренең хәтерләрен гел очып бара торган якты метеорит сыман һаман ымсындырып, яктыртып тора икән...

*2006 ел, август; 2007 ел, июль.*
*Наратлы, Казан.*

# ӘБРАР КӘРИМУЛЛИННЫҢ ТУГАН ЯГЫНА ЯЗГАН ХАТЛАРЫ

*2000 елның унсигез сентябрендә мәшһүр якташыбыз Әбрар Кәримуллин вафат булып, җәсәде икенче көнне туган авылы Чәбия-Чүрчи зиратына, әтисе кабере янындагы җир куенына иңдерелде. Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, филология фәннәре докторы, профессор, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Халыкара библиография ассоциациясенең халыкара Биографик үзәгенең гыйльми советы әгъзасы...—Исем-дәрәҗәләре күп иде якташыбызның. Халкыбыз-милләтебезгә кылган игелекләре дә иксез-чиксез иде шул.*

*Шөкер, Әбрар аганы 70 һәм 75 яшьлек юбилейлары уңаеннан исеме борынгы «Идегәй» дастанына «Урмандагы Саба» дип кереп калган газиз җирендә олылый алдык.*

*Академик Әбрар Кәримуллин туган авылның исеме дә үзенчәлекле: Чәбия-Чүрчи. Алтмышынчы елларда ул, башка бәләкәй авыллар белән беррәттән, бетерелүгә хөкем ителә. Казан университетының фәнни китапханәсендә директор урынбасары булып эшләүче яшь галим Әбрарга күп михнәтләр күрсәткән, хәтта эшеннән кудырган Хрущев заманы аның туган авылын да «перспективасыз»лар исемлегенә кертеп, ул урынга кукуруз чәчәргә планлаштырыла. Әмма алай булып чыкмады шул. Үзгәреш җилләре кечкенә авылларга яңадан җан иңдерде. Газ кертелде, яңа йортлар төзелде, ясле-мәктәп комплексы сафка басты.*

*...Авылның аягында булган олысы-кечесе атаклы китап галименең нигез каршына җыйналган.*

*—Карале, Фәрит туган, монда кемдер яңа өй салган бит,—диде Әбрар ага район хакимияте башлыгы Гыйльмиевкә.*

*—Юк, Әбрар абый, сезнең үз йортыгызны яңарттык,—дигән җавап алды ул.*

*Менә Америка, Канада, Австралия, Төркия, Германия кебек илләрдә булып, дәрәҗәле мөнбәрләрдән лекцияләр укыган Әбрар ага Кәримуллин кабат үзенең нигезендә, кендек каны тамган урында...*

*Район газетасы редакторы буларак, миңа күренекле якташыбыз белән күп тапкырлар очрашу, аралашу насыйп булды. Миндә аның изге теләкләрен язып бүләк иткән дистәгә якын китабы да саклана. Беркөнне шуларны карап утырдым. Берсенең эченнән унбишләп хат килеп чыкты. Әйдәгез, шул хатларны, кайсын тулаем, кайсын өлешчә дигәндәй, бергәләп укып карыйк әле. Язганда миңа атап язылсалар да, хәзер аларны үземдә яшереп саклау дөрес булмас шикелле.*

**Тәлгат НӘҖМИЕВ**

* * *

Хөрмәтле Тәлгат туган!

Саба якларыннан, туган җир булмаса да, инде күнелгә якын булган Казаныма кайтып җиттем. Ике-өч көн генә булуга карамастан, шактый кешеләр белән танышып, байтак җирләрдә булып, күп кенә нәрсәләр күреп кайттым, башка вакытта моңа атна-ун көн дә җитмәс иде. Якташларыма зур рәхмәт инде. Бик тә канәгать булдым. Дөрес, әле тагын да күрәсе кешеләр, очрашасылар күп иде.

Инде ничә еллар сезне ишетеп, укып белүемә карамастан, моңа хәтле күргәнем, аралашканым юк иде. Шәт, бу теләгем дә тормышка ашты. Инде бу элемтәләр өзелмәс дип ышанам. Редакциядә беренче очраган кеше Револь Раковка миннән сәлам әйтерсез. Бер иркенләбрәк кайткач, редакция егетләре белән очрашып та алырбыз әле...

...Сезгә зур игътибарыгыз өчен, шуның өстенә безнең гидыбыз кебек озатып, күп нәрсәләр һәм кешеләр белән таныштырып йөрүегез өчен дә зур рәхмәт.

Сезне үзебездә, безнең өйдә-квартирада күрермен, күрешербез әле дип ышанып калам.

Чын күнелдән ихтирам һәм рәхмәтләр белән,

*Әбрар абыең.*
*15.07.86.*

* * *



Хөрмәтле Тәлгат туган!

Сездән хат-бандероль килеп төште, минем өчен зур бәйрәм булды. Ничек кенә булмасын—без барыбыз да кешеләр, аларга хас бар нәрсәләр минем өчен дә ят түгел—мине зурлап, мактап язган очеркыгыз күнелләремне нечкәртеп җибәрде. Аның өчен Сезгә чын күнелдән бик зур рәхмәт, мең рәхмәт. Очерк гаять эчтәлекле һәм гаять матур, оста, образлы язылган. Миңа бик ошады. Җылы итеп, күнелгә үтәрдәй язылган. Бераз рәсмиләштереп язу кирәк иде, анысының да формасын бик оста тапкансыз очрашулар, сөйләшүләрне өстәп.

Түбән Шытсу авылы музее уңае белән Сезнең тәкъдим буенча берничә китап җибәрәм. Кызганычка каршы, әлегерәк чыккан китапларымның запасы юк. Минемчә, болары да җитәр, күбрәк җибәрсәң, мактану кебек килеп чыгуы бар. Аларга багышлама да язган булдым. Бәлки музейга дигән өч китапның барысын да бирү кирәк түгелдер, анысын үзегез карагыз инде, килештекме? Музейны баетасы иде, дип язасыз. Мин ни белән ярдәм итә алам? Башта ул музейның профиле белән танышсам,ниләр белән баету буенча фикер туар иде. Шунда барып, аны күрергә кирәк. Бәлки әле аны оештыручылар искә алмаган якларын да баету турында уйланырга булыр иде. Бу сөйләшүне киләчәккә калдырыйк, конкрет фикерләшер өчен.

Мине бик борчыган нәрсә—авылымның киләчәге. Хәзер аның хәле бик авыр. Анда кешеләргә эш юк, шуңа күрә барысы да читкә китә. Ә бит безнең авылның табигате шундый гүзәл, андый урын районда юк. Ул таулар белән әйләндерелгән, шунда яшел нарат урманнары, авылда, аның кырларындагы калкулыкларда дистәләгән чишмәләр гөрләп агып ята, төрле якта—урман, яшеллек.

Элек анда юкка гына алпавыт имениеләре, монастыр, Апанаевның һәм Глазковның (халык мәгарифе министрлыгыннан) дачалары, бакчалары булмаган. Безнең авыл җирлегендә, аның болын, сулары буенда менә дигән ял йорты, балык күлләре ясап була (элек ике балык күле бар иде). Халык өчен тагын башка эш тә табып булыр иде: ферма, нинди булса да остаханә h. б. Мин бу турыда сезнең җитәкчеләр белән сөйләштем, элемтәгә кердем. Берсе дә каршы түгел. Кемдер бу эшкә алынырга һәм аны башкарып чыгарырга тиеш. Мин халык белән сөйләшү

өчен (кирәк булса), бүген үк авылга кайтып килә алам. Бәлки августта шул мәсьәлә буенча кайтыргадыр? Бу турыда райкомның икенче секретаре Зөфәр Шәйхетдинов белән сөйләшегез әле. Ни өчендер аннан хат килмәде. Шунда Шытсуга да кереп чыгар идек, безнең авылның табигате, матурлыгы белән дә танышырбыз, вакыт күбрәк булса, «Саба» совхозы турында да очеркка материал тупларга мөмкинлек булыр иде. Бәлки, ул очеркны икебез бергә хәзерләп язар идек?

Менә ни хәтле сораулар, тәкъдимнәр. Сездән беренче үтенеч—бу турыда Зөфәр белән килешеп, миңа тизрәк хәбәр итүегезне сорыйм. Ашыгуның сәбәбе—мин 29 августтан Кисловодскига китәм, аннан кайткач, Мәскәүгә, октябрьдә Бөтенсоюз күләмендәге фәнни конференция була, аннан Дубулты дигән Иҗат йортына—кыскасы, Казанда сирәк булачакмын. Көз һәм кыш авылга кайту уңайсыз...

*Әбрар.*
*4 август, 86.*

* * *

Хөрмәтле Тәлгат туган!

Халкыбызның теле һәм килеп чыгышы турында рус телендә язган мәкаләмне җибәрәм. Кирәк тапсагыз, «Җиңү байрагы»нда («Знамя Победы»да) басуыгызны сорар идем.

16 мартта Киевка китәм. Анда оешкан Татар җәмгыяте чакыруы буенча очрашуга барам. Соңгы китап чыккач («Прототюрки и индейцы Америки. По следам одной гипотезы»), бик күп җирләргә чакыра башладылар. Вакыт юк, шуның өстенә сәламәтлек әйбәт түгел. Саба урта мәктәбенә дә кайтасы бар.

Ул китап-хезмәт татарча да хәзерләнә. Бер җыентыкка кертеләчәк, апрель-майда дөнья күрәчәк.

Тагын бер илдән конференциягә чакыралар.

Сезгә чын күңелдән ихтирам белән, Саба якларын сагынып:

*Әбрар.*
*8 март, 1989 ел.*

**P. S.** Сезгә «Суверенитет—не предмет торговли» дигән мәкаләмне җибәрәм. Бу әйбер Татар радиосы аша халыкка җиткерелде. Аннан, район газетасының исемен дә үзгәртергә кирәк. Нинди «Җиңү байрагы» ул? Сталинизм җиңүеме? Бу исем нонсенс. Тотыгыз да «Саба ягы», йә «Саба җиле», «Сабакул», «Байлар Сабасы»... менә шуларга охшаш исем табыгыз да кушыгыз.[1]

* * *

Кадерле Тәлгат туган!

Миңа бәйрәм алып килгән хатыгызны, хат эчендә «Җиңү байрагы»ның ике санын алдым. Инде аны рәсемем белән дә басып чыгару бәйрәм өстенә бәйрәм кебек булды.

Сабага күңел гел тарта. Менә шушы кыска гына вакытка кайтып, якташларны күреп китү, аларның мине онытмаулары яшәргә, эшләргә көч бирә булса кирәк. Сабадан кайткач Мәхмүт Нигъмәтҗановны күргән идем, ул бит Олы Арташтан, билгеле музыка белгече (беләсездер дип уйлыйм)—белгән булсам, мин дә кайткан булыр идем, диде.

Быел яңадан чит илгә барырга җыенабыз. Бер Халыкара конгресска чакыру килде, шуңа документлар әзерләп йөрибез.

Эш күп, хәзер барысына да житешеп булмый. Ә планнар зур. Минем хәзер төп теләгем—революциягә хәтле чыккан бай татар китабы репертуарының тулы, фәнни, аннотацияле каталогын төзү. Быел бер кеше бирәләр, киләчәктә аерым группа төзеп, шул эшне юлга салырга иде. Революциягә хәтле 14 меңгә якын китап чыккан—татар китабы—менә шуларның фәнни тасвирламасын төзеп, халыкка җиткерә алсак, күп нәрсәләрнең кире кайтуы җиңеләер иде. Ул хезмәт минем исәпләвем буенча бер

[1] 1991 елдан Әбрар абый сүзен тотып, «Саба таңнары» дип чыгара башладык.

15 зур томнан торачак. Аны төзү буенча Финляндия, Төркия, Австриягә дә фәнни командировкалар күздә тотыла. Бу илләрдә дә шактый татар китаплары тупланган. Әгәр үзгәреш заманнары мин яшьрәк вакытта килсә, бу эшне активрак башкара алган булыр идем дә бит...

*Әбрар.*
*29 апрель, 1989.*

**P. S.** Сезгә безнең филиал газетасының бер номерын җибәрәм, Овруцкий мәкаләсенә игътибар итегез.

* * *

Хөрмәтле Тәлгат туган!

Үзем турында бер-ике сүз. Әле генә Ленинградта булып кайттым, Анна Ахматованың улы, минем якын дустым профессор Лев Николаевич Гумилев чакырган иде. Анда булдым. Аның турында бер хезмәт төгәлләп бетердем, шәт, тиздән басылыр дигән өметтә. Профессор якташыбыз Яхья Абдуллин һәм минем чакыру буенча Америкадан Рифат Тәби, Надир Дәүләт исемле ике татар галиме килә, шуларны каршы алуга хәзерлек белән дә бик мәшгуль. Шулай ук «Идел буе татарлары» дигән монография язган Азадә-Гайшә Рорлих ханым—профессор да килә. Аның китабы турында үткән ел «Казан утлары» журналының 5нче яки 6нчы саннарында[2] язып та чыккан идем. Аларны каршы алу, урнаштыру һәм татарлар, аларның мәдәнияте, Казан һәм аның кешеләре белән таныштыру буенча да эшләр җитәрлек булачак.

«Идел»дә (5 һәм 6 саннарында) Ерак Көнчыгыштагы илләрдәге милләттәшләребезнең язмышы буенча минем язмалар басылачак, бәлки, кызыксынырсыз. Миннән Зөфәр Шәйхетдиновка сәлам әйтегез, газета редакциясендә мине белүчеләргә дә миннән сәлам тапшырыгыз...

Бүген-иртәгә «Аваз» газетасында минем Гумилевта булуым уңае белән кечкенә информация һәм аның бер мәкаләсе басылачак, рәсемен дә алып кайткан идем, кертерләрдер дип торам. Борчуым өчен гафу итегез, чын күңелдән иң изге теләкләр теләп, якташыгыз, дустыгыз

*Әбрар.*
*16 май, 1990.*

* * *

Хөрмәтле Тәлгат туган!

«Җиңү байрагы»ның ике данәсен җибәргәнсез: Һ. Мәхмүтов мәкаләсен басуыгыз һәм ул санны җибәрүегез—ихтирам һәм изгелегегез өчен зур рәхмәт. Сабада минем хәзер ике генә якын кешем бар: Сез һәм Зөфәр Шәйхетдинов. Районнан чыгып киткәнгә кырык елдан артык вакыт узып китте. Элекке җепләр өзелде: кем мәңгелеккә китте, кем кая таралды. Мине Саба белән менә сез икегез бәйләп торасыз, монсы зур бәхет аның.

Һәнүс отпускада, ул кайткач, аңа газетаның бер санын тапшырырмын. Аның Сезнең дустыгыз Мөҗәһит Шәйхетдинов белән бергә укыганлыгын да белешермен. Һәнүс әле күптән түгел, Кәрим Тинчурин турында бер җыентык әзерләп, нәшриятка тапшырды. Ул—бик тырыш, эшчән, намуслы егет, булган кеше, чын галим.

Сез Петрау сабан туена чакырып язгансыз хатыгызда. Ул вакытта бу бәйрәмне мин беренче күрдем, бик ошаган иде. Тик бу юлы кайта алмадым. Шәт, исән-сау булсак, киләсе елга дип калдырыйк.

Җәйнең шактый өлеше чит ил кунаклары белән мәшгуль булып үтте. Июньдә Америкадан өч татар профессоры килде: алар белән Мин Америкада танышкан идем. Алар безнең чакыру буенча килделәр. Берсе—Надир Дәүләт исемлесе—миндә, Рифат Тәби—Яхья Абдуллинда, Азадә-Гайшә Рорлих Мирфатыйх Зәкиевтә торды. Алар архивларда һәм китапханәләрдә эшләделәр. Аларны галимнәр, журналистлар,

[2] 6нчы санда. Ред.

язучылар белән дә очраштырдык, студентлар белән дә күрештеләр. Чаллы, Түбән Кама, Болгар-Йорт җирләрен дә күрсәттек. Бик разый булып киттеләр. Надир Дәүләт бөтендөнья төрки халыклар тарихы буенча эшли, шул исәптән татар тарихына да зур игътибар итә. Азадә-Гайшә ханым хәзер күренекле татар хатын-кызлары турында монография яза, киләчәктә татар сәүдәгәрләре һәм аларның халык мәгарифенә керткән өлеше турында эшләргә җыена. Ул—Көньяк Калифорния университетында профессор. Аннан, «Ватан» җәмгыяте чакыруы буенча Япония, Австралия, Германия, Төркия, Финляндиядән татарлар килде. Ул җәмгыятьнең бер комиссиясе рәисе буларак, мина да алар белән бергә эшлисе булды. Айга якын вакыт шулар белән үтте. Хәзер үзем бер 15-20 көнгә ялга чыктым, бакчада бераз эшләгән булып йөрим шунда. Август ахырында путевка булмасмы дип көтәм, санаторийга, аяк авырта, дәваланасы бар.

Әйе, Төркиядән бер төрек профессоры булып китте. Ул минем «Татары: этнос и этноним» дигән әйберне төрек теленә тәрҗемә иткән, шуны басарга дип рөхсәт сорады. Киләсе елга Төркиядә (Анкарада) үткәреләчәк фәнни конгресска чакырды.

Эшлисе килгән нәрсәләр күп-күбен дә, инде бик эшлисе килеп тормый. Шулай да әзрәк селкенәм инде шунда. Сәламәтлек җитми, шул тота, ә әйтәсе сүзләр күп...

*Әбрар.*
*20 июль, 1990.*

* * *

Тәлгат дус!

Сезнең 1 августта язган хатыгызны алдым, анда Сез «Саба районының 60 еллыгын билгеләп үтәргә җыенабыз», дигәнсез, шул унай белән котлау сүзе яисә шул вакыйга белән бәйле берәр язма җибәрүне сорагансыз.

Сүз Сабаны административ үзәк итеп билгеләү турында барамы? Мин бу турыда беренче мәртәбә ишетәм. Элек ул як ничек аталган, кемгә караган? Волостьмы, кантонмы булган? Минем Чәбия-Чүрчи авылы элек Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостена караган 20нче еллар башында. Сатыш волосте да булган кебек. Күрәсез, мин бу 60 еллык унае белән ана бәйле берни белмим, димәк, яза да алмыйм.

Котлау дигәч, нәрсә әйтергә дә белмим диярлек. Бу 60 ел Саба районы кешеләренә нәрсә алып килде? Гомумән, сталинизм заманы, аннан брежневщина елларына караган бу 60 ел эчендә мактанырлык нәрсә булды икән? Нинди котлау сүзләре язарга соң?

Бердән-бер шулай дип язарга мөмкиндер:

«Якташларымны Саба районы оештырылуга 60 ел тулу уңае белән чын күңелдән котлыйм. Киләчәктә районның икътисады, милли мәдәният ягыннан Татарстан Республикасының (ә ул һичшиксез тулы хокуклы мөстәкыйль дәүләт булыр) мактаулы төбәге булуын телим.

Сталинчылар, үз ялагайларыбыз җимергән мәчетләр торгызылыр, халыкка әдәп, әхлак нурлары сибелер, корытылган чишмә, инеш-елгаларыбызның сулары мулланыр, сукаланган болыннарыбызда шайтан таягы урынына мул үлән-чәчәкләр үсә башлар, җимерелгән күперләребез янадан эшләнер, басуларны машиналар таптап юллар салып йөрүгә чик куелыр, кырларыбызны талау урынына аларны акыллы файдалана башларбыз. Мәктәпләребездә элеккечә Тукай теле сөйләшер, балаларыбыз Альберт та, Роберт та түгел, янадан Рөстәм вә Рәшитләшер, а Фаялаша, Маялаша, Раялаша башлаган кызларыбыз ата-аналары биргән изге исемнәренең кадерен белә башларлар иде диясе килә киләчәктә.

Кайчан Өчнарат «Три сосны», Ике басу Арташ «Два поля Арташ», Байлар Сабасы «Богатые Сабы»лар булып яшәүдән туктап, үзләренең чын исемнәре белән йөртелә башлар, кадерле сабалылар, бу турыда да уйларга кирәк юбилей көннәрендә.

Бу 60 ел эчендә «матур тормышта» яшәгән күпме Саба районының әзмәвер кебек батыр егетләре туган йортларын ташлап ерак Шпицберген атавы, Донбасс, Кузбасс шахталарына кузгалмады да, күпмеләре Карелия, Себер якларына урман

кисүгә юл алмады, китте, югалды, кире кайтмады. 60 еллыкны үткәргәндә менә боларны да онытмыйк. Саба якларының меңеллардан артык гыйбрәтле тарихы булуында, аның Болгар дәүләте чорында ук даны зур төбәк икәнен дә онытмыйк. Ш. Мәрҗанинының «Мөстәфәдел әхбәр» китабында гына Саба якларында даны ерак Көнчыгыш илләренә яхшы билгеле булган галимнәр искә алынган. Безнең төбәктә даны киң таралган күпме мәдрәсәләр эшләп торган, ә Сатыш мәдрәсәсенә нинди генә шәрык мөселман илләреннән укырга шәкертләр килмәгән? Безнең төбәк кешеләре эшкә дә, һөнәргә дә, гыйлемгә дә оста булганнар. Оренбург якларына барып бистәләр салганнар, Урта Азия, Кытай, Һиндстан, гарәпләр белән сәүдә итеп йөргәннәр, чит илләргә йөргәннәр. Истанбул, Каһирә уку йортларында белем алучылар да шактый булган (минем үземнең бабам Гата Ихсанов Истанбул университетында гыйлем алган, Мөхетдин Корбангалиев белән Ике басу Арташ, Чәбия-Чүрчи, Язлы Арташ авылларында Земство хисабына татар дөньяви мәктәпләре оештыруда актив катнашкан), Саба ягыннан чыккан кешеләр арасында Россиядән чит илләрдә илче булып йөргән затлар да билгеле...



*Әбрар Кәримуллин һәм Шәүкәт Биктимеров.*

Болар әле өстә яткан фактлар гына. Саба районына 60 ел тулуны билгеләп үткәндә аның тарихын өйрәнүне дә киләчәктә эш планнарына кертү кирәктер, аерым авыл тарихын чагылдырган авыл музейлары да бар, ә безнең хәтта аерым бинада район музеебыз да юк бит. Монсын да онытмыйк шушы юбилей көннәрендә.

Туган авыл, туган як һәркем өчен иң изге, иң кадерле, иң газиз хис. Мең еллык тарихы булган Саба төбәгенең киләчәге, аның милли теле, милли моңы тагын да меңләгән гасырлар дәвам итүен кайсыбыз гына теләми, ә бу нәрсә бүгенге эшебез, гамәлебез белән дә нык бәйләнгән».

Менә шундый сүзләр әйтер идем. Инде ярамый дип тапсагыз, басмагыз, артык шомартуны теләмәс идем. Үзегезгә карагыз, Сез сорагач, язарга булдым. 60 еллыкка Яхъя Абдуллинны, мине дә чакырырбыз дигәнсез. Яхъя өйдә түгел, Казан тирәсендә ялда, ул кайтып йөри. Мин риза, шәт ул да кайтырга ризадыр дип беләм. «Шәһри Казан» газетасының пробный саны чыгачак бүген-иртәгә, игътибар итегез, анда минем бер әйбер басыла, шулай ук «Комсомолец Татарии»да да—икесе дә, минә калса, бик проблемалы һәм нык кыю нәрсәләр.

Сәламнәр белән, тиздән очрашуга хәтле

*Әбрар.*
*7 август, 1990.*

**P. S.** Саба РК КПССта 11 кеше генә калды дип язасыз. Озакламый ул үзе калырмы икән әле? Демократия белән берпартиялек бергә яши алмый бит...

* * *

Тәлгат туган!

12 сентябрь көнне ИЯЛИнең Гыйльми Советы дүрт кешене, шул исәптән мине—СССР ФАнең Член-корреспондентына тәкъдим итте. Мәскәүнең 73 елга әле бер генә татарга да академик исеме биргәне юк—ТАССРда эшләүчеләргә. Бу юлы да бирмәячәк...

Мине искә алучыларга сәлам әйтегез. Машинкам эшләми, шуна күрә кулдан язам.

Иң изге теләкләр белән,

*Әбрар.*
*14.IX. 1990.*

* * *

Мөхтәрәм Тәлгат туган!

Бүген больницадан чыгуыма хат һәм Сезнең «Саба таңнары»нда басылган «Китап галиме» дигән мәкаләгез белән ул газета саны көтеп тора иде. Мина булган даими игътибарыгыз өчен чиксез күп, зур рәхмәтләрем Сезгә. Инде уйлап та куям: район газетасы битләрендә минем турыда еш язып, укучыларны туйдырмадыгыз микән, йә инде бу Кәримуллин бик әрсез, ахры, гел аны басалар, үзе сорый торгандыр, мөгаен, диючеләр дә бардыр...

Больницага керүемнең сәбәбе: аяклар белән эш шәп түгел, йөреп булмый вакыты белән, кан тамыры (артерия канны өчтән икесен җибәрми, шуның өстенә буыннар да гел сызларга ярата—фронтта суык тигән, өшегән иде аяклар (аннан атеросклероз нижних конечностей).

Мина елына ике тапкыр шифаханәгә-сырхауханәгә керергә кирәк, профилактика йөзеннән. Врачлар шулай кушалар. Ә минем вакытым булмый, шуннан кризис килеп чыга.

«Шәһри Казан»да инде язганнар иде: мин Канадага җыенам. Анда июнь ахырында һәм июль башында XVIII Халыкара конгресс була—«Сәнгать һәм мәдәни һәм фәнни элемтәләр» дигән темага. Аны Англиядәге Халыкара Биографик Мәркәз белән АКШтагы Халыкара Биографик Институт үткәрә. Шулар мине персональ чакыралар. Минем турында шушы ике Халыкара Энциклопедияләр үзәге булган фәнни оешмалар үзләренең дүрт энциклопедияләрендә зур-зур биографик белешмәләр бирделәр. Тик хәзергә валюта ягы гына хәл ителеп бетмәгән. Татарстан Министрлар Советы валюта табарга, бирергә дип тора. Юл Монреальга самолет белән 1990 сум иде—совет акчасына, хәзер 6000 меңгә күтәрелде. Бару мәсьәләсе катлауланды. Мин анда «Татар халкының мәдәнияты» дигән темага доклад белән катнашып, күренекле татар әдипләре, галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре, бизнесменнары турында сөйләргә һәм аларны энциклопедияләргә кертү турында сүз алып барырга тиеш идем. Мин, Австралиядә штабы булган Халыкара Рыцарьлар Конференциясенең Үзәк шурасы әгъзасы буларак, анда да берничә татар кешесен рыцарьлыкка тәкъдим иттем. С. Алишевны инде үткәрә алдым. Тиздән Разил Вәлиев белән Равил Фәйзуллинны да кертерләр дип уйлыйм. Аларны кабул итүне сорап, тиешле документлар җибәрдем. Канадага бара алсам, ул энциклопедияләргә дә үз милләтебезнең күренекле кешеләрен үткәрүгә юл ачылыр иде.

Больницадан кайтуга, чит илләрдән берничә бандероль һәм хатлар көтеп тора икән. Берсе—Румыниядән. 17-19 майда Констанца шәһәрендә румын татарлары Мәхмүт Ниязи дигән румын татар шагыйренең вафат булуына 60 ел тулу уңае белән Халыкара симпозиум үткәрәләр икән. Шуңа катнашырга чакырып программа җибәргәннәр. Анда барып, Румыния татарлары белән элемтәне ныгыту бик кирәк тә, тик валюта дигән нәрсә тота, белешеп карыйм, нәрсә чыгар?

Мин үткән елны пенсиягә чыгып караган идем, яңадан кире чакырып алдылар. Хәзер хәтта ике урында эшлим: ИЯЛИдә һәм Үзәк фәнни китапханәдә консультант булып. Аннан бик күп җәмәгать эшләре, төрле җирләргә очрашуларга бару... Язасы нәрсәләргә тотынып та булмый диярлек, язылганнары «Идел» журналында, газеталарда озак ята... Минем язганнар төерле, әчкелт, шуңа күрә бик басабыз дип тормыйлар, курку әле дә яши аларда...

Иң ярамаганы: саулык җитеп бетми, шуңа күрә язасы әйберләр озакка сузыла.

Газета өчен кәгазь табу авыр дигәнсез, моңа Казанда да зарланалар. Төрле-төрле газеталар, халтуралар чыгып тора, аларга кәгазь бар... Монда мәсьәлә тирәнрәк ята дип уйлыйм. Ил зур киеренкелек алдында, аның законнары эшләми,

консерваторлар, партократия каты һөҗүмгә күчте. Куркам, тора-бара хәлләр тагын да кискенләшәчәк. Шундый заманнарга калдык, Тәлгат туган, ахыры гына уң булсын иде татар өчен, милләтебез өчен.

Хатым озынга китте.

Бар изгелекләрегез өчен кабат рәхмәт, эшегездә, тормышыгызда уңышлар, сөенечләр генә теләп калам,

*Әбрар.*
*19 апрель, 1991.*

* * *

Мөхтәрәм Тәлгат туган!

Кичә Күк-Түбәдән кайтып төштем. Язучыларның Иҗат йортында булдым. Зәки Зәйнуллин, шагыйрә Эльмира Шәрифуллина, Фоат Галимуллин, Мәхмүт Хөсәен, Мәгъсүм Насыйбуллин бер зур команда белән булдык. Болай яхшы гына ял иттек, эшләдек, Кырым туганнарыбыз—татарлар белән дә аралаштык, андагы хәлләрне белештек.

Кайтуга Сездән хат һәм «Саба таңнары» мине көтеп тора иде. Минем әйберне бастыруыгыз өчен, игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт.

Августта булган фетнә бер яктан кайбер мәсьәләләр буенча, бигрәк тә безнең, татарлар өчен авырлыклар тудырса да, СССР дигән империяне өч көн эчендә җимерелүгә китерде. Бу фетнә булмаса, СССР кайчан әле җимерелеп бетәр иде, моңа дистә ел кирәк булачак иде.

КПССның таркалуы да зур прогресс. Бу, әлбәттә, һәр КПСС әгъзасы начар кеше дигән сүз түгел. Сүз КПССның идеологлары, КПСС аппараты турында, аның эшчәнлеге турында бара.

Сез райком секретарьлары Зөфәр Шәйхетдинов һәм минем сабакташым Гөлбикәнең улы хәзер ял итәләр, күңелләре тыныч түгел дип язасыз. Мин аларны аңлыйм. Алар яшь, таза, белемле кешеләр. Башларыннан коммунизм идеологиясе сөремен куалап чыгарсыннар да, милли азатлык һәм халык ихтыяҗларына хезмәт итүгә керешсеннәр. Зөфәр—ул татар теле һәм әдәбияты укытучысы, тотынсын шушы эшкә. Бүген татар мәктәпләре өчен иң авыр нәрсә—кадрлар җитешми. Җаннарында иманнары булса, алар шуңа керешсеннәр. Башка өлкәдә дә аларга урын бетмәгән, ләкин мин халык мәгарифе бүген иң актуаль нәрсә дип саныйм. Түрә булган кешеләргә гади эшкә күчүе авырдыр, бәлки, ләкин мин монда бернинди яман нәрсә күрмим.

Бүген татар милләтенең язмышы хәл ителгән вакыт. Милли җаны булган һәр кеше шул турыда уйларга, шуңа хезмәт итәргә тиеш.

«Шәһри Казан»га язылырга үгетләп мәкалә язарга җитешмәм дип куркам. Кайтуыма бик күп эшләр җыелган. Җитешсәм, язам, әлбәттә.

«Шәһри Казан» хәзер прогрессиврак. «Социалистик Татарстан» да хәзер җанга якын әйберләр бик аз. Исеме ни тора—»Социалистик» бит.

Мина булган игътибаргыз өчен, изгелекләрегез өчен чук-чук рәхмәт, иң изге теләкләрдә калам.

*Әбрар.*
*17 октябрь, 1991.*

* * *

Мөхтәрәм Тәлгат туган, якташым!

Сездән «Саба таңнары» (13 октябрь, 1994) килде. Анда Сез минем турында «Татарстан Фәннәр академиясе»ндә чыккан биографик белешмәне бастыргансыз. Бу, әлбәттә, Сезнең эш, үзегезнең инициатива буенча башкарылган. Сезгә мең рәхмәт. Кызганыч, Саба урта мәктәбенең юбилеена кайта алмадым. Тантана буласы көнне Төркиягә китәргә туры килде. Әле Мәгъсүм Хуҗинны күргән идем. Ул да бу юбилейга кайта алмаган. Күптән түгел Сабада булган. «Сөйләштем: икәүләп бер кайтып килербез, чакырып калдылар»,—диде. Мәктәп чакырган дип аңладым.

Анда бер очрашу үткәреп килергә рәхәтләнеп әзер. Көннәр язга авышкач, йә яз башында, йә язның үзендә. Аннан соң да, тагын Төркиягә—1995 елда чакыралар, фәнни конференциягә. Шулай ук Измир шәһәрендәге Эгей университетына да чакыралар, лекция укырга. Бу киләсе уку елында булыр.

Төркиягә бару турында «Заман»да минем информация чыкты, шуның ксероксын җибәрәм. Сез «Заман» газетасын алмыйсыздыр. Бик кыска гына яздым ул информацияне. Безнең белән барган Фатыйх Урманчеевка зуррак итеп язарга кушылган иде, матбугатта күренмәде.

Якташ сынчыбыз Кадим Җәмитнең күргәзмәсендә озак була алмадык. Ашыгыч эш бар иде—Мирфатыйх Зәкиев тизрәк алып китте. Саба хәлләрен дә сораша алмадым.

Миңа киләсе елның май аенда 70 тула. Шул уңай белән Татарстан китап нәшриятында «Язмыш, язмыш...» дигән әсәрем ята. Нәшрият акча юк, басылуы икеле дип тора. Спонсор эзләргә кушалар. Эшләр гел шулай торса, әллә район башлыгыбыз Фәрит Гыйльмиевкә мөрәҗәгать итәргәме? Сез ничек карыйсыз? Минем гомеремдә кешедән бернәрсә сораганым юк, аңа мөрәҗәгать итү минем өчен үлем белән бер кебек.

Ни эшлисең, чыгармасалар чыгармаслар. Инде аның ише нәрсәгә күнеккән. Хәзергә көндә өч китабым басылмый ята, берни эшләп булмый.

Эшлисе эшләр күп, тик вакыт җитми, аннан сәламәтлек тә мактанырлык түгел. Дөньяны агартам, милләтне уятам дип йөреп, үзем каралып беттем инде. Тамагы тук булса, халыкка ике дөнья—бер морҗа, бигрәк тә безнең татар халкына.

«Саба таңнары»н очраганда карарга тырышам. Аның яңа саннарын укыгач, туган якларга кайткан кебек булам. Газета үзенең эчтәлеге белән шактый мавыктыргыч чыга. Сезгә «Афәрин»нән башка сүз юк. Республика газеталарында да сезнең мәкаләләрегез күренеп тора, моның өчен дә рәхмәт. Тик кенә ятмыйсыз, Саба патриотизмы тәрбиялисез. Сезгә яңа уңышлар, сөенечләр теләп, рәхмәт белән,

*Әбрар Кәримуллин.*
*10 ноябрь, 1994.*

* * *

Тәлгат туган!

Крутушкадан язган хатыгызны алдым. Минекен дә алгансыз икән. Мин аны ашыгыбрак язган булып чыктым. Минем «Язмыш, язмыш...» дигән кульязманы Татарстан китап нәшрияты 1995 ел планына керткән. Президентыбыз киләсе елга Ватан сугышы тәмамлануга 50 ел тулу уңае белән барлык фронтовик язучыларның нәшриятка тапшырган әсәрләрен басарга акча бүлеп бирәчәген белдерде. Нәшрият директоры, шәт, инде, Президент кушканны эшләр дип уйлыйм.

Шуңа күрә Фәрит әфәнде Гыйльмиевкә мөрәҗәгать итеп торуның кирәге бетте...

...Милләт, милләт дип янып йөрүләремнең нәтиҗәсе күренмәгәч, матбугатта аны яклап язуларның кирәге, файдасы күренми дип бу эштән читләшә башладым. Бу соңгы өч-дүрт елда публицистика белән генә диярлек шөгыльләндем, күпме фәнни хезмәтләр языламыйча калды. Аларны язып та татарны уятып булмый, булмас, ахры. Хәзер күңелнең ин төшенке вакыты. Шартнамә милләтне элекке коллык хәлгә кайтарды.

Бәлки, истәлекләр язарга керешермен. Минем тормыш гаять авыр һәм гаять катлаулы булды, әле дә шулай. Әйтер сүзләр өелеп тора. Бу өлкәдә бер тәҗрибә да ясап караган булдым. Октябрьдә мин дә ялда, Бәкер санаториясендә булдым. Шунда Табеев белән «дуслыгыбыз» турында бер истәлек язып, бер журналга тапшырдым. Кешеләргә ошаса, истәлекләр язуга кучәрмен, бәлки. Анда, әлбәттә, Сабага да урын булыр, чөнки ул минем тормышымда шактый зур роль уйнады.

Алдан кычкырган күкенең башы авыртa диләр. Шулай булып чыкмаса ярар иде. Сәламәтлек кирәк...

Олы ихтирам белән,

*районташыгыз Әбрар.*
*Декабрь. 1994.*

* * *

Мөхтәрәм Тәлгат туган!

Күптән түгел генә бер китабым басылган иде, шуны Сезгә юлларга ашыгам. Шактый гына вакыт больницада ятып чыктым, шуңа күрә соңгарак калдым җибәрергә...

1997 ел минем һәм гаиләм өчен бик авыр булды. Терекөмеш белән агуларга тырышулар һәм аның нәтиҗәләре әле дә нык сиздерә «Туры әйткән туганына ярамаган» дигән мәкальнең ни хәтле хак икәненә тагын бер мисал бу хәл.

Сез Саба районына багышланган китап әзерлисез икән. Бик кирәк эш башлагансыз. Миңа бер фотосурәтче шалтыраткан иде, районташ артистыбыз Шәүкәт Биктимеров белән бергә рәсемгә төшерербез дигән иде. Шул кеше әйтте. Шуннан белдем. Башка районнарның кайберләре хәтта энциклопедияләренә керешкән икән, сезнең эшне дә мин шуның белән тиңлим. Аңлыйм, мондый эш башкару өчен ой-ой күп хезмәт кирәк, күп тикшеренүләр кирәк. Башлап җибәрү үзе үк зур каһарманлык, моның өчен зур рәхмәт.

«Саба районташлык җәмгыяте»н төзүгә керешүдә актив катнаша башлаган идем, чирләп киту, килеп чыккан фаҗигадәй хәлләр аркасында читләшергә мәҗбүр булдым: авырып торгач, ни эшли аласың. Шәт, киләчәктә гел шулай булмас дип ышанасы килә.

Соңгы вакытта «Мы не пыль на ветру» («Без тарихта эзлебез») дигән хезмәт өстендә эшлим. Инде кырыйлары күренә башлады. Бер 400-450 бит чыгар, ахры. Бастыру өчен спонсор эзлим. «Тел—милләтнең сакчысы» дигән китап та спонсор ярдәме белән басылды.

Ул китапны яратып каршы алдылар. Әгәр кирәк тапсагыз, «Саба таңнары»нда шуның берәр өлешен бастыра аласыз, анда күтәрелгән мәсьәлә милләтебезнең ин авырткан җире турында...

...АКШтан Яңа Орлеан шәһәреннән Халыкара конгресска чакырганнар, август ахыры, сентябрь башында булачак. Аны энциклопедик белешмәләр чыгаручы ике Халыкара оешма үткәрә. Катнашу өчен һәм юл өчен шактый долларлар кирәк, ярдәм итүче килеп чыкса, барырга дип торам. Анда ясаячак докладның тезисларын җибәрдем...

*Тирән ихтирам белән,*
*Әбрар.*
*12.01.1998.*

* * *

## Йомгаклау сүзе

Менә, хөрмәтле укучыларыбыз, халкыбызның йөзек кашы булган академигыбыз Әбрар Кәримуллинның туган ягына язылган хатлары белән таныштыгыз. Алар тәүге тапкыр матбугатта басылдылар. Үзе китте, әмма Әбрар ага өчен төп кыйбласы—туган теле—байлыгы да, Ватаны да, мәгарифе дә, мәдәнияте дә, дине дә булган күпләгән китаплары, меңләгән кульязмалары, хатлары калды... Мин җай килгән саен, ягъни юлым Чәбия-Чүрчи якларына төшкәндә Аның янына сугылам. Һәм шунда—тып-тын зиратта якташ шагыйрәбез Флёра Тарханованың (әнисе Байлар Сабасыныкы) шигъри юллары искә төшә.

*...Әле кичә генә көлә-көлә*
*Кайтып киттең бит син югыйсә.*
*Ә бүгеннән сине суырып алган*
*Кабер өсләрендә гөл үсә...*

# СУГЫШЛАРНЫ КИЧКӘН ДОГАЛЫК...

Гаҗәп хәл: язучы Марат Әмирханов елның елында повесть һәм романнар иҗат итә тора, китап та чыгара. Аларның һәммәсе, билгеле инде, иң әүвәле төп әдәби журналыбыз «Казан утлары»ында басылды. Ләкин... ләкин аның әсәрләре хакында җәмәгатьчелек ләм-мим, матбугатта рецензияләр дә күренмәде шикелле. Татар әллә укымый, әллә... безнең тәнкыйть үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? Кемдер әйтмешли, бетте бит безнең заманда тәнкыйть дигән татлы җимеш яки әче торма...




Әдәбиятка һәр язучы үзенчә, үз юлы белән килә. Әйтик, Мөхәммәт Мәһдиев 40 яшен тутырганнан соң гына һәркем яратып-сокланып-гаҗәпләнеп укырлык әсәрләрен иҗат итә башлады. Баштарак Арча-Саба мәктәпләрендә укытучылык итү, аннары Казан дәүләт университетында мөгаллим булу, гыйлем-галимлек өлкәсендә төптән җигелеп эшләү дисенме—болар бар да аның вакытын йоткандыр, әдәби иҗат мәйданында ачылып китәргә ирек бирмәгәндер, күрәсең.

Марат Әмирханов иҗатында да әнә шундыйрак нәрсәләр булды шикелле. Мәктәптә укытучы, республикабызның төп газетасы—Социалистик Татарстан»да журналист сыйфатында яна буразналар еру һәм башкалар. Ялгышмасам, ул да нәкъ менә 40 яшьләрдән соң гына әдәбият дигән олуг сарайның ишекләрен кага башлады...

Менә кулымда М. Әмирхановның яна китабы. («И кылган догам минем». Татарстан китап нәшрияты, 2008 ел. 430 бит, тиражы—3000 данә.) Анда бер роман һәм бер повесть урын алган.

Китап «Үрбәт ханәкә гыйшкы» исемле роман белән ачыла. Исеменнән үк күренгәнчә, әсәрнең егәр-тукымасын, композицион бөтенлеген мәхәббәт тәшкил итә.

Мәхәббәт—дөнья әдәбиятының төп объекты. Бу гүзәл хис турында күп язылган. Ромео-Джулетта, Таһир-Зөһрә, Фәрхад-Ширин кебек классик һәм дә башка меңләгән образларга өстәп тагын нинди яңалык әйтеп булыр икән? Иң элек башка шушы уй килә. Әмма әлеге олуг хиснең тылсымы да шунда—ул һәр гыйшык иясендә яңача төсмерләр белән балкый. Бер-берсенә тулысынча тәңгәл килгән чәчәк тажы булмаган кебек, мәхәббәт тә һәркемнеке—үзенчә.

Романда сурәтләнгән Үрбәт ханәкә белән Мөхәммәдәмин ханга мәхәббәт кырык яшьләр тирәсендә килә. Бу бәхетле дә, шуның белән бергә, фаҗигале дә мәхәббәт. Үрбәт ханбикәне үз-үзенә кул салырга да мәхәббәт этәрә. Хәлбуки, әлеге хәл ярату тойгысының никадәр көчле булуына да ишарә. Чөнки мөселман дөньясында үз-үзенә кул салу зур гөнаһ. Ә Үрбәт—диндар зат.

Үрбәт ханәкә—тарихи шәхес. Маңгыт-нугай якларында туып-үскән бу чибәрне, атасы Ибраһим хан вафатыннан соң, Казан тәхетенә утырган Илһам

ханга килен итеп төшерәләр. Илһам хан йомшак торыклы, кәеф-сафа корырга һәвәс кеше була. Шуның аркасында яу белән килгән мәскәүлеләргә әллә ни каршы тора алмый. Үз кешеләре үк аны олуг кенәзгә тотып бирә.

Шул рәвешле ханның гаиләсе, туган-тумачасы, якыннары урыс сөргененә эләгә. Илһам хан үлә, кайбер туганнары христиан динен кабул итә. Үрбәт ханбикәне дә чукындырып, бер-бер боярга кияүгә бирергә телиләр. Көрәш ундүрт ел дәвамында бара. Кечерәк кенә буйлы, юка гәүдәле бу ханәкә-чибәр көч-дәрманны каян алгандыр, әмма бирешми. Олуг кенәз Иван III Мөхәммәдәминне Казан тәхетенә тәгаенләгәндә: «Сиңа нык куллы хатын кирәк»,—дип, Үрбәтне өч хатын өстенә димли. Күрәсез ки, хәтта патша да ханбикәнең ныклыгын танырга мәҗбүр була.

Мөхәммәдәмин мәхәббәте хакына үзен тәрбия иткән «туганы» Иван IIIкә сырты белән борыла. Чөнки Үрбәт гүзәл искиткеч милләтпәрвәр ханбикә булып чыга. Иренә: «Син бәйсез барча Казан җиренең бәйсез ханы булырга, Олуг Мөхәммәд сызып калдырган юлдан барырга тиешсен»,—дип һаман тукып тора.

Иван патша терсәген бик тешләр иде дә, инде соң. Мәскәү кубызына гына биергә тиешле Мөхәммәдәмин чын татар ханына әверелә, шигырьләр яза башлый, яшь Мөхәммәдъярны күреп алып, иҗат өчен аңа юл ача. Бу чор—чын мәгънәсендә Казан ханлыгының көмеш гасыры.

Романның үзәген тәшкил иткән Үрбәт ханәкә һәм Мөхәммәдәмин образларын язучының зур уңышы дип бәяләү дөрес булыр. Бу образлар истә кала, дулкынландыра, хисләндерә, уйландыра. Алар белән килешәсең, бәхәсләшәсең, ачуланышасың, яратышасың яки кайгырасың...

Марат Әмирханов—сюжет остасы. Вакыйгаларны композицион яктан шундый мавыктыргыч итеп кора ки, әсәрне, кем әйтмешли, бер сулышта укып чыгасың. Һәр җөмлә, һәр метафора, һәр деталь образларның кичерешләрен, уй-тойгыларын, эш-гамәлләрен расларга, мотивлаштыруга юнәлтелгән. Шуңа күрә ышандыру көче дә югары.

Танылган әдәбият белгече Мәхмүт Әхмәтҗанов та үзенең «Мәдәни җомга» газетасында («Мәхәббәт һәм сәясәт», 19.12.2008) басылып чыккан бәянамәсендә әлеге үзенчәлеккә игътибар итә: «Автор моннан ярты мең еллар элек булган вакыйгаларны киң панорамада, эпик киңлектә шул дәрәҗәдә тасвирлый ки, әйтерсен, лә ул аларның замандашы булган. Бу инде—талант». Әлеге фикер белән килешергә генә кала.

Романның яңалыгы шунда: ул татар әдәбиятына тарихыбызда Нурсолтан ханбикә, Сөембикә ханбикә, Гәүһәршад тәнәкәләр белән тиң булырдай Үрбәт ханәкә образын бирде.

Әсәр геройлары үз даирәсенә, үз чорына хас вакыйгалар, эш-гамәлләр процессында тасвирлана. Без романны укып, анда сурәтләнгән XIV-XV гасыр хәлләре белән якыннан танышабыз, мәгълүмат алабыз. Чөнки образлар конкрет тарихи контекст аша тасвир ителә. Әсәрдә тарихыйлык белән әдәби дөреслек мөнәсәбәте төгәл сакланган. Бу бик мөһим.

Татар—бай тарихлы халык. «Теге яки бу илдә яшәүчеләрне халык итеп укмаштыручы иң көчле җилем, ул тарихи хәтер җилеме», дип яза бер француз галиме. Әйе, тарих ошамаска да мөмкин, тарихны шулай ук яратырга да кирәкми, иң әһәмиятлесе—тарихлы һәм хәтерле булу.

Марат Әмирхановның «Үрбәт ханәкә гыйшкы» романы укучыларны милләт Хәтерен саклау аша милли үзаңны үстерергә өнди, буыннар арасына күпер сала. Ул бүгенге көн көйгән бурычлар белән дә тәңгәл, аваздаш.

Кояшта да таплар була, ди халык мәкале. Шуның кебек, уңышлы дип саналган бу романда да кимчелекләр, житешсезлекләр бар, әлбәттә. Мин моны, беренче чиратта, җыйнаклык мәсьәләсендә күрәм. Сюжетка, төп юнәлешкә зыян китермичә генә кайбер эпизодларны кыскартырга мөмкин булыр иде дип саныйм. Мәсәлән, Нурсолтан ханбикәгә кагылышлы романтик-мистик характердагы ау кыйссалары, Мөхәммәдәминнең күнел ачу хәлләре, аерым мәзәки күренешләр шуңа карый. Мәскәү патшалары тормышын сурәтләү белән дә кирәгеннән артык мавыгу үзен сиздерә. Китапның икенче басмасында бу мәсьәләгә игътибар бирелердер, шәт.

Китапның исеменә үк куелган «И кылган догам минем» повесте турында

кайбер уй-фикерләремне, тәэсирләремне дә уртаклашасы килә. Ягъни «Менә шундый китап чыккан, күрми калмагыз!»—дип, укучыдан, әдәбият сөючеләрдән бары сөенче аласым килә...

Повестьның баш герое сиксән яшьлек Хисаметдин карт, Ватан сугышы ветераны. Сугыш дигәндә, мин һәрчак алга куела торган «бөек» сүзен ничек тә кулланмаска тырышам. Сәбәбе. Әлеге канлы бәрелештә илнең 20 миллионнан артык кешесе кырылган икән(!), мондый сугыш ничек инде бөек була алсын, ди?!. «Миллионнар үлеме статистика, ә бер кешенең үлеме фаҗига»,—дигән кайсыдыр акыл иясе. Хак сүзләр.

Әйе, 1941 елда башланган дәһшәтле сугыш күпме кешеләрнең язмышын челпәрәмә китерде, дөньяның астын өскә әйләндерде! Мондый мәхшәр, кара тамга Хисаметдин атлы егетнең язмышын да читләп узмый. Сугышның беренче бәрелешләре... дезертирлыкта гаепләнү... Немецлар кулында әсирлектә... Исән кайткач, совет төрмәсендәге тоткынлык... һ. б.

Бер кеше өчен, ай-һай, күпкә җыела түгелме? Адәм баласы менә шуларның барысына да түзәргә, үзенең кешелеген ахыргача саклап кала белергә дә тиеш бит әле. Ә мондый сыйфат, төптән уйласак, теләсә кемгә бирелмәгән...

Сугыш турында безнең әдәбиятта күп язылган. Вакыйгалар, гадәттә, сөйләү-тасвир рәвешендәрәк бара. М. Әмирханов исә героеның тормыш юлын күрсәтеп бирүдә яңа алым тапкан. Әсәрдә тереисән бер ветеран үзе сөйли. Теләсә кемгә түгел, журналист буласы оныгы Гүзәлиягә. Анда да теләсә кая түгел, диктофон тасмасына.

Барлыгы сигез тасма язылган. Ягъни әсәр сигез бүлектән тора дип әйтергә мөмкин. Башыннан кичкәннәрне ашыкмыйча, халыкчан тел белән сөйли бу карт. Хәтере яхшы. Өч ел немец әсирлегендә, сигез ел буе совет тоткынлыгында күргәннәре тере, җанлы, гыйбрәтле картина булып күз алдыбызга килеп баса.

Ике илдә ике төрле әсирлек... Болар барысы да конкрет вакыйгалар, төрле холыктагы кешеләр, бәхәс-бәрелешләр, күңелдәге эчке кичерешләр һәм, билгеле ки, мәхәббәт мажаралары аша үтемле, ышандырырлык итеп тасвирлана. Мин махсус рәвештә әсәрнең эчтәлеген сөйләмәскә, андагы төп вакыйгаларга тукталмаска булдым. Әсәр белән танышканда укучы боларны үзе эзләп табачак.

Шулай да немец кызы Эрна белән булган «сәер» мәхәббәте хакында бер кәлимә сүз әйтеп узасы килә. Яшь, әле мәхәббәт эшләрен юньләп белеп тә бетермәгән әсир Хисамны бер немец фермерына ялчылыкка бирәләр. Ул үзенең тырышлыгы, яхшы мөгаләмәсе белән хуҗаның ихтирамын яулый. Аның кызы, «гитлерюнген» оешмасында торган Эрнаның да игътибарын яулый ул. Тик бу мәхәббәт (әгәр шулай әйтергә яраса) Хисам өчен бик кыйммәткә төшә. Очраклы вакыйгалар гына аны бу очракта үлем элмәгеннән коткарып кала. Әйтергә кирәк, төрле милләттән булган ике яшь кешенең мөнәсәбәтләре табигый, ышандырырлык итеп бирелгән...

Әсәрнең башына бүтән геройлар килеп керә дә, аннары югала икән, бу теләсә кайсы проза әсәренең төзеклегенә зыян сала, композицион бөтенлеген каксата. Бу җәһәттән әлеге повестьта геройлар «югалмый», әсәрнең урта һәм азаккы өлешләрендә янәдән калкып чыга. Сюжет түгәрәге ныграк тоташа дигән сүз, димәк. Моны авторның әдәби уңышы дип бәяләргә мөмкин. Без сержанттан полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән Мөнир Исламов һәм Хисамның беренче мәхәббәте Рабига белән алдагы сәхифәләрдә янәдән очрашабыз...

Утлар-сулар кичкән, сугыш мәхшәре чоңгылына эләккән яшь офицер Хисаметдин ничек исән кала соң? Сугыштан соң туган авылына кайтып, ул әле зиратның череп ауган яисә мич ягарга дип тотылган койма-киртәләрен өр-яңадан торгыза, авылдашларының ихтирамын казана.

Сугышта нинди генә кискен, яман хәлләргә юлыкмасын, Хисамны... әнисе язып биргән бөти, ягъни догалык коткара. Анда гарәп хәрефләре белән «Аятел көрси» сүрәсе күчереп язылган була. Солдат Хисам аны сугыш буена әле гимнастерканың яшерен кесәсендә, әле муенына тагып саклый. Гомеренә үлем кизәнә башлаганда ул яттан белгән «Аятел көрси» сүрәләрен укый башлый: «Әллаһү ләәәә иләәһә илләә һүвәлхәййүл кайййүм...»

Дин, чыннан да, зур көч. Тарихның

сикәлтәле юлларында безнең милләтне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне фәкать дин саклап калган, моны исбатлап торасы юк. Шулай итеп, гап-гади бер догалык, юк, алай түгел, тылсымлы бөти мөселман баласы Хисамны һәрчак үлемнән коткарып кала. Менә шушы идея, диннең мәрхәмәте турындагы фәлсәфи юнәлеш әсәрнең буеннан-буена диярлек кызыл җеп булып сузылып бара.

Әсәр әгәр дә ике илдәге ике төрле әсирлек белән генә чикләнсә, анда яңалык һәм тәэсир көче әллә ни булмас иде. Юк, автор үзенең дин һәм аның шифалы йогынтысы турындагы фәлсәфәсен мөһим бер вакыйга белән тагын да тирәнәйтә, өскәрәк калкытып куя. Ерак Себердә, совет концлагерында, ул (ветфельдшер) бала табасы хатынга операция ясауга дучар ителә. Тик бер шарт белән: әнкәсеннән калган бөти-догалыкны укып, аны куенында саклаган хәлдә... Марҗа хатын, исемен үзгәртеп, мөселман диненә күчә калган очракта... Алга таба вакыйгалар әнә шулай көтелмәгәнчә киеренке төйнәлә, тормыш мантыйгы җинеп чыга. Иң мөһиме—хатын үзе дә, аның сабые да исән кала.

Тагын бер үзенчәлекне әйтеп китик. Әсәрдә бүгенге көннәрнең «мәхәббәт өчпочмагы» Илһан-Гүзәлия-Кәбир линиясе аерым бер тема булып, әсәрнең тукымасына үрелеп бара. Инде килеп, повестька безнең арада яшәп яткан замандашларыбыздан профессор Хатип Миңнегулов һәм язучы Камил Кәримовның килеп керүе повестька тормышчанлык, ниндидер яна төсмер өсти.

Кимчелекләрме? Бик тырышсаң, аларын да табарга мөмкин. Әйтик, гап-гади бер әсир Хисаметдиннын атаклы маршал Жуков турында, сугыштан аның фәлән-фәлән ганимәтләрне вагоны белән илгә төяп кайтуы хакында педантларча төп-төгәл саннар-мәгълүматлар белән сөйләп бирүе ышандырып бетерми. Автор бу материалны әсәргә «көчләп» үзе керткән дигәнрәк тәэсир кала. Ә менә Муса Җәлил һәм аның язмышы турындагы уйлanулары бик табигый һәм ышандыра да.

Чуарбикә, сөтбикә, җилбикә дигән ясалма сүзләр әсәргә ятышмый, алар ничектер төче янгырый, кыланчыклык төсмере сиземләнә.

Повесть азагында менә мондый юллар бар: «Син кичергән авырлыклар, бәндә, доганның могҗизалы көчен дәлилләү өчен зарур иде...» Күктән ингән вәхи әнә шулай дип йомгак ясый.

Кыскасы, бу әсәрне мин сугышларны кичкән догалык турындагы бер кыйсса дип кабул иттем.

**Рәшат НИЗАМИ**

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# УЙЛАНДЫРА ДА, КИСӘТӘ ДӘ

Галим-педагог һәм язучы-публицист Мәхмүт Әхмәтҗанов кайчандыр бер мәкаләсендә: «Әгәр Марат Әхмәтов министр итеп элегрәк куелса, авылларыбыз бу хәлгә үк төшмәгән булыр иде» дип язган иде. Әмма вәзгыять тискәре якка шулкадәр тиз үзгәрә, авыл һәм игенче тормышының отыры мөшкелләнә баруын бик игелекле Татарстан вәзире дә туктата алмый кебек инде. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки бүген республикабызның авыл хуҗалыгында Марат әфәнде кебек үк дәрәҗәле, кайвакыт аннан да йогынтылы өч-дүрт «министр» шайлана. Аларның берсе авылны төрле юллар белән якларга һәм сакларга тырышып бәргәләнсә, бүтәннәре жирне сыгу, авыл кешеләрен бушка эшләтү бәрабәренә үзенә зур табыш алырга гына омтыла. Әле кайчан гына, дәүләткә (төгәлрәге, дәүләтне гәүдәләндерүче һәм беркемгә буйсынмаучы «яңа байлар»га) сатыла торган сөт белән дәүләттән алына торган дизель ягулыгының бәясе тигезләнгәч, Марат әфәнде: «Без бу хакта хыяллана гына ала идек» дип сөенеч белдергән, бик авыр чорда да сыерлар санын саклап кала алучылар бик дөрес эшләделәр, алар хәзер сөт сатып табыш алачаклар, дип җиңел сулаган, телеэкран аша, халыкны да куандырган иде. Әмма каршы яктагылар «ялгышларын» тиз төзәттеләр: ягулыкның да, энергия чыганакларының һәм авыл хуҗалыгына бүтән кирәк-яракның да бәясен кискен күтәреп, терлекчелекне кабат авыр хәлдә калдырдылар.




Мәхмүт ага Әхмәтҗановның күптән түгел (2008 ел) Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Яманны юлдаш итмә» исемле мәкаләләр, очерклар, эсселар жыентыгыннан «Сәяси уйланулар» язмасын укый башлагач та, авылларның менә шундый аяныч хәле күз алдына килә. Бервакыт, әле Балтач районын җитәкләгәндә үк, Марат Әхмәтовның: «Реформаларның монысы да авыллар файдасына булмады» дип әйткәне хәтердә калган. Мәхмүт Әхмәтҗанов исә, сүзен шактый ерак чорлардан башлап, болай яза: «Россиядә 1861 елда крепостное право бетерелсә дә... крестьяннар һаман да бик авыр шартларда яшиләр. Жир аларныкы түгел, алпавытлар, латифундистлар кулында». Бу юлларны укыган кеше, хәлне хәзерге белән чагыштырып, «карасана, автор язган вакыйгалардан соң бер гасыр ярым вакыт узгач, шул ук вәзгыять кабатлана түгелме?» дип уйламыйча кала алмыйдыр. Хәзер дә бит авылның тормыш дилбегәсе эре жирбиләүчеләргә, заман алпавытларына күчә бара, хакимият тә аларны хуплый, аларга булыша. Ягулыгы-фәләне тагын һәм тагын кыйммәтләнгәндә дә болар әле беркадәр яши

Мәхмүт Әхмәтҗанов. «Яманны юлдаш итмә». Татарстан китап нәшрияты, 2007 ел.

алачак, чөнки аларга бүтән төрле табыш чыганаклары да бирелгән, алар банк һәм башка структуралар белән үрелеп, закон чыгару органнарына сайланып беткән, авырга килсә, эшләүчеләренә түләүне киметеп яки туктатып та жан саклый алалар. «Алпавытлар»ның, хөкүмәт хуплавы һәм ярдәме белән, авыллардагы вак фермаларны бетереп, ягъни, андагы халыкны эшсез калдырып, «шәһәрчә» эре комплекслар төзергә дә хәленнән килә һәм бу эш җәелә бара. Ә бит монa кадәр бездә җитештерелгән авыл хужалыгы продуктлары табигыйрак, экологик чистарак булулары белән аерылып тордылар һәм без бу өстенлеккә нәкъ менә артык зур булмаган фермаларда ирешеп килдек. Эре комплекслар исә зур химиясез яши алмыйлар. Без комплекслар төзү белән монарчы да бер мавыккан идек, тик алар ул чакта да үзләрен акламадылар, ә авыллар санын киметергә генә булыштылар. Менә тагын эшсезашсыз калган, алпавытлар тарафыннан жире тартып алынган (авылларны бетерү шуның өчен кирәктер дә!) халык яна комплексларга яки Алабуга кебек шәһәрләргә йөреп эшләргә тиеш булыр. Шуннан—катнаш никахлар (дөресрәге, никахсыз катнаш гаиләләр), шәһәрләшү-урыслашу—һәммәсе нәкъ Мәскәү теләгәнчә барачак, болай да хәл эчендә булган татар мәктәпләренең дә, татар теленең һәм башка милли эшләрнең дә хаҗәте калмаячак.

Мәхмүт ага бер мәкаләсен, педагог һәм язучы К. Д. Ушинский сүзләрен файдаланып, «Милли тәрбия генә көткән нәтиҗәне бирә» дип исемләгән. Көенечебезгә, милли булмаган тәрбия һәм эшләр дә «көткән» нәтиҗәне бирәчәк шул. Без көткәнне түгел, «заманча булмаган» милли мәктәпләрне, күпмилләтлелекне «бөек» дәүләт өчен артык йөккә санаучы Путиннар, Жириновскийлар көткәнне! «Урыслаштыру процессын көчәйтү өчен,—дип дәвам иттерә китап авторы, күп меңнәрчә татар егетен, кызын «бөек коммунизм төзелешләренә» озаттылар, алар шунда—урыс мохитендә—ассимиляцияләштеләр; үз чиратында Татарстандагы төзелешләргә ун меңнәрчә ятлар килеп тулды, күпчелек очракта алар катнаш гаилә төзеделәр... Казанда, башка шәһәрләрдә, күп кенә район үзәкләрендә, эшчеләр бистәләрендә татар мәктәпләре, балалар бакчалары калмады» («Туган илем, ана телем» исемле мәкалә). Ә халыкның милли мәнфәгатен кайгыртмау—дәүләтнең киләчәгенә төкереп карау, аш таркалуҗимерелүдән сакламау, дигән сүз инде ул. Бер төн эчендә ишелеп кенә төшкән СССР язмышы моңа нык дәлил була ала. Тик, кызганыч, тәкәббер түрәләр илендә мондый гыйбрәтле һәм аяныч сабаклар да, халык ризасызлыгы аркасында кабатланып торган революцияләр дә беркемне бернигә өйрәтми. Заманында хәтта большевиклар да милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын яклап чыкканнар, югыйсә. Сүздә генә калмаганнар, өлешчә гамәлгә дә ашырганнар. Йөгәнләнгән илнең йөгән бавын кансыз һәм милләтсез Сталин эләктермәгән булса (нәкъ шул чорда «милләтче» иң куркыныч сәяси гаепләү сүзенә әверелгән), кем белә, вәзгыять, бәлки, тагын да унайлангaн булыр иде. Сүз уңаеннан әйткәндә, «Яманны юлдаш итмә» китабындагы байтак язмаларда бу үчлекле Тиран һәм аның даирәсе кылган явызлыклар еш телгә алына, ике мәкалә махсус шуңа багышлана, чөнки ил сәясәтенең кайсы ягы турында сүз алып барсаң да, аның коточкыч йогынтысын күрмичә калып, әйләнеп үтеп булмый. Әлеге дә баягы бичара авыл халкына, татар кебек «чит» милләтләргә бигрәк нык эләкте. Һәм, менә «могҗиза»: Россиянең бөтен узган юлындагы иң күренекле тарихи шәхесне ачыклау өчен Интернет алып барган тавыш бирүләрдә бу дәҗҗал да җиңүче була язып калды. Ил башына, котылгысыз рәвештә, нилектән әледән-әле Явыз Иван, шашкын Петр патша, җәлладлар атаманы Сталиннар килеп торуы да җиңел аңлашыла болай булгач. Эш бу шәхесләрдә түгел, Мәхмүт ага бик хаклы язганча, Россия халкының кемлегендә икән ләбаса. Болар Сталиннарны каберләреннән торгызып тәхеткә кайтарырлар иде. Үзләре булмаса, аларның шәүләрәкләрен дә президент итәрләр.

Мәхмүт Әхмәтҗановның бу китаптагы (ялгышмасам, бу аның уңдүртенче китабы) һәр язмасы диярлек мәгълүмат байлыгы, анализларның тирәнлеге, ясалган нәтиҗәләренең төплелеге, ышанычлы дәлилләре, авторның фикер сөрешендәге рух хөрлеге белән сокландыра. Шундый сыйфатлары өстенә, тәрбия темасына

багышланган мәкаләләренең (алар китапның икенче бүлегенә туплап бирелгән) милләтебез мәнфәгатеннән чыгып язылулары, унай мәгънәдәге «татарлыклары» ачык күренә. Педагог-галим (китапка бик шәп кереш сүз язган Фәнзаман Баттал аны «җаннар академигы дип атый) милли тәрбиянең бүген аерата мөһим булган өлкәләрен әтрафлы өйрәнеп, җыйнак, әмма тыгыз фикерле язмалары аша укучы хөкеменә чыгара. «Аналар һәм балалар», «Газиз әтиләр», «Ихтыяр көче», «Хатын-кыз һәм аракы», «Хисләр һәм инанулар» мәкаләләренең исемнәре үк аларда сүзнең ни хакында баруын сөйләп тора. Әйе, бүгенге язучыга бер гасыр гына элек милләтнең уена да килмәгән четерекле темаларны да (мәсәлән, кыз балаларның, әниләрнең һәм әбиләрнең эчүчелеге) күтәрергә туры килә.

Мәхмүт ага мәкаләсендә японнар тормышыннан бер кызык факт китерелә: 25 мең 500 япон кешесе йөз яшьнең теге ягына чыгып яши икән. Ә бездә хәлләр ничегрәк? Японнар атом һәлакәте дә кичергән бит әле. Озын гомерле булуларының иң төп сәбәбе—алар аек халык. Россиядәге милли «атом» исә милләт чикләрен дә, җенес аермасын да белмичә халыкны кырыпмы-кыра. Безнең гаиләгә, безнең кардәшләр арасына кермәс дип, күпләребез гамьсез йөргәндә хатын-кыз исереклеге, истә-уйда булмаган бозыклыклар белән көннән-көн ешрак очрашабыз. «Еш кына «хәзер мәктәп балалары, хәтта башлангыч сыйныф укучылары эчә» дип чаң кагалар,—дип яза Мәхмүт ага. Әниләре эчкәч, сабыйларга ни кала?» Кызганыч, бу илдә халыкны тоталь исертү—тарихи сәясәт. «Эчми торган» халыкның «милли» Сабан туенда гына да күпме-күпме исерткеч сатылуын берәр кешенең исәпли алганы бар микән? Бер елны Балтач районының һәр авылында бу бәйрәмне аек килеш үткәрмәкче булдылар, Сабан туенда исерткеч саткан яки эчкән кеше каты җәзага тартыла дип, эчке эшләр бүлеге хезмәткәре район газетасында язып чыкты. Ә бәйрәмгә барган халык исерткечнең һәр кибеттә диярлек ап-ачык сатылуын күреп хәйран калды. Сәбәбен соңрак ишеттек: аракы саттырмасагыз, Сабан туе үткәрергә акча бирмибез дип, эшмәкәрләр тавыш кубарганнар икән. Милләттәшләрен бер генә бәйрәмдә булса да «яшел елан»нан чактырмый калсалар, күпме табыш югалтачакларын, алар белә дә белә инде. Елга бер Сабан туен уздыру өчен карун эшмәкәрләрнең (карун булмаганы бернинди шартсыз да булышыр) өчәр мең сум акчасына калган хакимиятләрне әйтер идем...

Китапның өченче—соңгы бүлеге—«Әдәбият безгә юл яра» дип исемләнгән, анда Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт, Михаил Львов, Әбрар Кәримуллин кебек, инде мәрхүм булган олпат затларыбызның, шулай ук Марат Әмирханов, Равил Фәйзуллин, Газинур Морат, Солтан Шәмси кебек замандаш талант ияләренең иҗатына бәяләмәләр тупланган. Сүз уңаеннан, Мәхмүт Әхмәтҗановның менә инде берничә дистә еллар буена бу жанрда иң актив язучы булуын, каләмдәшләре иҗатына искиткеч ихтирам белән каравын, һәркайсының диярлек иҗатыннан игътибарга, хуплауга лаек әсәрләр күреп алуын һәм шул хакта укучыларга кинәнеп сөйләүдән үзенә яшәү яме, яшәү мәгънәсе табуын әйтү урынлыдыр. Биредә тагын шунысы мөһим: язмаларында халкыбыз башына төшкән нинди генә бәлаләр, авыр-авыр фаҗигаләр турында сүз алып барса да, һәрвакыт оптимист Мәхмүт Әхмәтҗанов бер очракта да, кайберәүләр кебек, «татар кавеме, аның теле, әдәбияты бетүгә бара» дип язмый, милләткә яман юл юрамый, ясин укымый—ә аны афәттән сакларга теләп кисәтә генә. Юккамыни, китапның иң ахырга куелган язмасы да (ул Әбрар Кәримуллинга багышланган) «Киләчәгебез бар!»—дип атала. Менә язманың соңгы җөмләсе: «халкыбызны юк итү өчен нинди генә гамәлләр кылынмады, әмма без яшәвебезне дәвам итәбез һәм итәчәкбез, иншаллаһ!»

Безгә галим-язучының хак сүзләрен кабатларга гына кала.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

*Шәрәф Мөдәррис (1919—1963)—әдәбиятка сугыш алды елларында килгән шагыйрь. Фронтларда—кыю сугышчы, татарча газеталарда—сәләтле хәрби корреспондент була; «Тупчы Ваһап» кебек поэмасы һәм патриотик рухтагы шигырьләре белән танылa. Сугыштан соң да ул актив иҗат итә, шигырь-поэмалар, сатирик повесть-хикәяләр, очерклар бастырып чыгара. Кыскасы, дөньядан иртә китүенә карамастан, әдәбиятта, язучылар мохитендә шактый үзенчәлекле эз калдыра Шәрәф Мөдәррис.*

*Аның иҗатындагы тагын бер игътибарга лаек өлкә—тәрҗемә эше. Сугыш чорында ук немецча өйрәнеп, Гейненың «Германия» поэмасыннан зур бүлекләр, һәм башка шагыйрьләрнең шигырьләрен тәрҗемә итеп бастыра. Ә инде илленче елларда үзлегеннән инглиз телен өйрәнеп, Байрон, Бёрнс һ. б. шагыйрьләрнең шигырьләрен татарчага тәрҗемә итә. Әмма аның тәрҗемә өлкәсендә чын каһарманнарча зур эше—В. Шекспирның «Сонетлар»ын тәрҗемәләп, китап итеп дөньяга чыгару булды (1961 ел). Дөнья әдәбиятының чын җәүһәрләреннән саналган бу сонетлар (барлыгы 154 шигырь!) татарча да гаҗәп камил, шигъри һәм көнчыгыш шигърияте кебек үк табигый калыплы, хәтта ки үзебезчә милли яңгырый. Димәк, Шәрәф Мөдәррис үзенең эшен чын осталарча башкарган.*

*Бу санда без әлеге китаптан берничә тәрҗемә сонет тәкъдим итәбез.*

Вильям
Шекспир

# СОНЕТЛАР

***

**Син—үзең җыр, үзең көйдән моңланасың?**
**Ямь белән ямь, тәм белән тәм дошман түгел!**
**Ник бәхеттән, җаның бизеп, сызланасың,**
**Ник хәсрәтне гел хуш күрә синең күңел?**

**Әгәр ул көй,—бергә туган, чыңлап торган**
**Моң-аһәңнәр ашый икән колак итең,—**
**Димәк, алар тирги сине, күр, дип, бер җан**
**Музыкада таба алмый үзенең ишен!**

**Тыңла менә: бер калын кыл нечкә кылда**
**Таба лаек яңгырашын, эчке моңын;**
**Гүя бер ир, хатын, бала уртак чыңда**
**Сыздыралар бәхетле бер яшәү җырын.**

**Бер аваздан әйтә кыллар:—Сиңа бу, бел!**
**Ялгыз башың—дөньяда син кеше түгел!**

***

Вакыт белеп, сәгать чыңын саныйм икән,
Күрәм икән көннең төнгә дунгән чагын;
Сулып барган миләүшәгә карыйм икән,
Күрәм икән бөдрә чәчтә еллар чалын,—

Багам икән җәен куак чатыр сузып,
Көзен аннан җиргә яфрак коелганын;
Билен буган чал сакаллы көлтә булып,
Яшел язның кышкы гүргә җыенганын,—

Шул чагында уйлыйм синең гүзәл сының,
Ул да шулай вакыт җиткәч корыр, шиңәр.
Өр-яңа бер нәфис чәчәк үсмәс борын
Синең шушы чибәрлекне үлем җиңәр.

Вакыт—чалгы, барсын кыра берәм-берәм,
Нәсел калдыр, тарткалашып үлем белән!

***

Йолдызнамә миңа таныш. Тик мин ялан
Укып йөрмим язмыш сүзен, йолдыз санап.
Әйтә алмыйм, кайчан булыр яхшы-яман,
Кайчан килер үләт, ачлык, кайгы-газап.

Белә алмыйм табигатьнең әйтер сүзен:
Кайчан давыл, кайчан яңгыр яхут яшен.
Әйтә алмыйм, төнге күккә төбәп күзем,
Падишаһның, шаһзадәнең яшәр яшен...

Синең күзгә карап ләкин яхшы беләм,
Алар—йолдыз, алар миңа сөйли ачык:
Токымыңда саф гүзәллек гөлең белән
Тугрылыгың үрелеп үсәр, чәчәк атып.

Ялгыз калсак, алдан әйтәм, ниләр көтәр:
Гүзәллегең, тугрылыгың бергә бетәр.

***

Мәдхияләр җырлый алмыйм күпләр кебек,
Илһамланып, гүзәллектән һушым җуеп;
Чагыштыру эзләмим мин күккә менеп,
Күп язылган нәрсәләрне тиңдәш куеп.

Күпләр тиңли җырда гүзәл нәрсәләргә:
Ай, кояш һәм йолдызларга, ялкыннарга;
Апрельдәге тәүге назлы чәчкәләргә,
Җир-су биргән энҗе-мәрҗән, алтыннарга.

Ах, юк инде... Сөюем—тугры, җырым—гадел,
Ышансыннар, дусны күрәм мондый хәлдә:
Күктә янган сихри нурлы йолдыз түгел,
Җирдә туган гап-гади бер тыйнак бәндә!

Мактасыннар, үзем ләкин җөрьәт итмим,
Мәхәббәтем сатам диеп йөрмим ич мин.

***

Зур сәхнәдә куркуыннан ролен бозган,
Җитлекмәгән актер ничек үзен тотса,—
Яхут, дулап, усаллыктан ярсып кызган
Тинтәк кеше чыгырыннан ничек чыкса—

Мин дә шулай: сүз әйтергә куркып йөрим,
Мәхәббәтнең йоласыннан өркеп качам.
Яхут кинәт ашкын җанга давыл телим,
Гыйшык йөгем артык зур шул—ярсыйм-шашам.

Ах, бу хисне әйтсен иде сиңа җырым,
Йөрәгемнән булсын иде телсез илче!
Җавап сорар, мин ни дисәм, сөйләр чынын,
Телдән өстен, сүздән көчле—аның ирке.

Күрә бел син мәхәббәтнең шыпырт сүзен,
Тыңлый алсын гыйшык җырын сизгер күзең.

***

Юк, тыныч бул! Үлем мине мәхбүс итсә,
Мәңге бикле, мәңге ябык зинданында,—
Синең белән калыр өчен һаман истә,
Шушы җырда терелермен мин тагын да!

Укып баксаң бу җырны син, уйлан туктап:
Ни яхшым бар—багышладым барсын сиңа.
Үзем—туфрак, алыр шуңар кара туфрак,
Иң шәп нәрсәм—җаным гына калсын сиңа.

Тән нәрсә ул? Куркак сукбай кадап китсә,
Суалчанга табыш була, гүргә кереп.
Югалтырсың тәнем генә соңгы чиктә,
Хәтерләрлек берни югын үзең белеп.

Тәндә түгел, җанда минем бөтен җылым,
Ул—син һаман истә тотар йөрәк җырым.

***

Телсез музам тыйнак минем, тыңлап тора
Тәгъбирчеләр сиңа мәдех түккән чакта.
Кәгазь битен алтын каләм тырнап тора,
Матур сүзләр чигә алар синең хакта.

Кайберәүләр бик шәп яза, ярый! Ә мин
Ишеткәндә төче телле шома юллар,
Надан калган диндар төсле әйтәм: «Амин!»
Язмый гына уйлап торам матур уйлар.

Әйтәм шунда: «Шулай, шулай! Дөрес, бу хак!»
Сине мактап, күп хис өстим шушы җайда.
Өстим, ләкин эчтән генә. Сүзләр бу чак
Уйларымнан артта тора, әллә кайда...

Берәүләрне хупла шигъри тавыш өчен,
Мине үз күр яшьрен янган сагыш өчен.

***

Кем мактана нәсле-заты, хәле белән,
Кем—гайрәте, кем—киеме-ашы белән;
Кем—янчыгы, йорты-җире, малы белән,
Кем—лачыны, кем—эте һәм аты белән.

Төрлесендә мактанырлык төрле як шул,
Тик ул нәрсә аңа зур дан, аңа—бәхет.
Ләкин миңа болар бар да, бар да ят шул,
Миндә иң зур, иң бөек бер яңа бәхет!

Синең гыйшык кадерлерәк алтыннардан,
Кодрәтлерәк зур исемнән, таҗ-тәхеттән;
Сөйкемлерәк эттән, аттан, лачыннардан,
Горурланам: бәхетем зур бар бәхеттән!

Тик бу бәхет синең кулда, шунда—бәлам:
Тартып алсаң, барысыннан мәхрүм калам.

***

Борын заман язмаларын карыйм ачып,
Укыйм гүзәл кешеләрнең йөрәк гамен;
Рыцарьларны, туташларны җырда язып,
Мактаганнар мәхәббәтнең ямен-тәмен.

Макталганда кул-аяклар, ирен-күзләр,
Җырланганда алар барсы күккә чөеп,—
Уйлыйм шунда: сиңа карый бу шәп сүзләр,
Борынгылар сының әйбәт ачкан, диеп.

Пәйгамбәрлек итеп алар, алдан күреп,
Синең сынны сурәтләргә уйлаганнар.
Тик безнең чор чибәрлеген, күп көч түгеп,
Тонык кына төсмерләүдән узмаганнар.

Бу заманның бәндәләре—гаҗиз без дә:
Күз күргәнне тел әйтерлек көч юк бер дә.

*Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәләре*

# ТӨРКИ СҮЗ СӘНГАТЕНЕҢ ТАҖЫ

Борынгы һәм Урта гасыр төрки дөньясында классик ядкарьләр күп. Әмма алар арасында төрки халыкларның уртак мирасы булган «Котадгу белек» китабына тиңләшерлек язма истәлекләр күзгә ташланмый. Бу әсәр үз чорында да, аннан соң да төркиләрнең шаһ китабы, бөек ядкаре исәпләнә. Аны Йосыф Баласагунлы иҗат иткән. Ул якынча 1019 елда Чуй үзәнендәге Баласагун /Күз орду/ каласында дөньяга килә. (Тиздән бу бөек затның тууына 1000 ел тулачак!). Аның асыл Ватаны—Шәркый Төркестан. Биредә 840-1212 елларда Караханыйлар дәүләте яши. Бу кодрәтле мәмләкәт составына хәзерге Кытайның төньяк-көнбатышы (ягъни «Уйгырстан»), Кыргызстан, Казакъстанның зур өлеше һәм Урта Азиядәге кайбер башка төбәкләр керә.


ATATÜRK KÜLTÜR, DİL VE TARİH YÜKSEK KURUMU
TÜRK TARİH KURUMU YAYINLARI

YUSUF HAS HÂCİB

KUTADGU BİLİG

II

ÇEVİRİ

TÜRK TARİH KURUMU BASIMEVİ – ANKARA
1994

Караханыйлар дәүләтендә төркиләрнең төрле кавемнәре яши. Әмма төп халкын уйгыр-карлуклар тәшкил итә. X гасыр урталарында рәсми рәвештә ислам диненә күчкән бу мәмләкәт тиз арада мөселман дөньясының мөһим бер дәүләтенә әверелә, анда икътисад, фән, мәдәният зур үсеш ала. Кашгар, Баласагун кебек мәркәзи калаларда туып үскән Мәхмүд Кашгарый, Йосыф Баласагунлы эшчәнлекләре үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

«Котадгу белек» авторы шагыйрь генә түгел, күренекле дәүләт эшлеклесе дә. Ул Караханыйлар мәмләкәтенең мәшһүр хөкемдары Богра хан (1058—1103 елларда идарә итә) сараенда хасс-хаҗиб (хәзерге премьер-министр вазифасына якын) булып та эшли. Шуңа мөнәсәбәттә аны еш кына Йосыф Хас-Хаҗиб дип тә йөртәләр. Шагыйрьнең үлгән елы билгеле түгел.

«Котадгу белек» әсәре һиҗри белән 462 елда Кашгарда төгәлләнә. Милади белән ул 1069-70 елларга туры килә. Автор бу китабын «18 ай» эчендә (ягъни ел ярым) язуын искәртә.

«Котадгу белек»—зур күләмле шигъри әсәр. (Дөрес, аның кереш өлешендә берике битлек чәчмә юллар бар. Әмма алар да күчерүче яисә башка берәү тарафыннан язылган булса кирәк). Китап һәр юлы үзара рифмалашучы ике юллык строфалар (бәетләр) белән язылган. Аларның саны 6722 гә житә (ягъни 13444 шигырь юлы, дөресрәге—мисраг). Әсәр шигырь системасының гаруз төре (мөтәкадис) белән иҗат ителгән, һәр юлда иҗекләр саны, нигездә,—11—11. Әсәрнең автор кулы белән язылган нөсхәсе сакланмаган. Аның хәзергә мәгълүм иң борынгы күчермәләре («Каһирә», «Вена—Һерат», «Наманган-Фирганә» һ.б.), нигездә, XV йөзләргә карый. Алар гарәп һәм уйгыр язуында. В. Радлов фикеренчә, Йосыф Баласагунлы үз әсәрен әүвәл гарәп, аннан уйгыр графикасында яза.

«Котадгу белек» традицион төстәге кереш белән башланып китә: Аллага, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның сәхабәләренә (Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали), Богра ханга мактау-мәдехләр бирелә, китапның язылу сәбәбе һәм исеме аңлатыла. Керештә

шулай ук автор, белем һәм акыл, телнен өстенлеге һәм файдасы, игелек... турында бүлекчәләр бар. Алга таба китапнын төп өлеше башлана. Шунысын да искәртик: элеккеге әсәрләрнен күпчелегеннән аермалы буларак, «Котадгу белек»нен кереше (мөкаддимәсе), төп өлеше һәм бетеме (хатимәсе) шартлы рәвештә генә бер-берсеннән аерыла. Чынлыкта исә алар һәм төзелеш-композиция, һәм идея-эчтәлек ягыннан үзара табигый рәвештә керешеп китәләр. «Котадгу белек» 100гә якын бүлекчәгә аерылган. Аларнын исемнәре әсәрнен төзелешен, эчтәлеген шактый күзалларга ярдәм итә.

Гадәттә зур күләмле әсәрләр вакыйга-хәлләргә бай була. «Котадгу белек»тә исә фикри як, уй-кичерешләр өстенлек итә. Анын сюжеты чагыштырмача гомуми, схематик, шартлы төстә Көнтугды исемле хан (әлиг—илик үзенә хезмәткә Айтулды исемле кешене чакыра. Бу зат вәзирлек («хажиблык») вазифасын намус белән башкара. Ул үлгәч, анын эшен улы Үгделмеш дәвам иттерә, ханга тугрылык, бөтен күнеле белән хезмәт итә. Үгделмешнен Узгырмыш исемле туганнан туганы була. Бу кеше күп вакытын гыйбадәттә уздыра, изгелеге, акыллылыгы белән таныла. Көнтугды аны да үз сараена хезмәткә алырга тели. Әмма Узгырмыш мондый вазифадан баш тарта. Хан кат-кат чакыргач кына Узгырмыш сарайга килә дә, хөкемдарга кинәштәләкләрен белдереп, торган жиренә кабат кайта һәм бераздан вафат та була. Персонажлар арасында төп урынны хөкемдар һәм Үгделмеш алып тора. Автор бу дүрт затка символик мәгънә дә бирә. Анын карашынча, Көнтугды гаделлек, тугрылык, Айтулды бәхет-сәгадәт, Үгделмеш гакыл, Узгырмыш канәгатьлелек символы. Болар—тереклекнен төп, нигез принциплары. Бу затларнын төрле темалар турында әнгәмә-диалоглары әсәрнен төп төзелешен һәм юнәлешен билгели. Хан күпчелек сөйләшүләрнен үзәгендә. Әнгәмә-бәхәсләрнен бер өлеше Үгделмеш һәм Узгырмыш арасында. Вәзир улы хатлар аркылы да, үзенен сәфәрләре белән дә хөкемдар һәм Узгырмыш арасындагы сөхбәт-диалогларны тәэмин итә. Элекке дәвернен бу төр аерым ядкарьләрендә, мәсәлән, «Кәлилә вә Димнә» жыентыгында, хөкемдар, нигездә, сорау бирүче буларак кына катнаша. Башкалар ана жавап бирә. «Котадгу белек»тә хан сорау биреп кенә калмый, үзе дә аерым мәсьәләләрнен аслын актырта, аларга шәхси мөнәсәбәт-бәясен белдерә. Китап тукымасында авторнын һәм геройларнын лирик чигенешләре, фәлсәфи уйланулары, васыять хатлары да зур урынны алып тора. Әсәрнен «Яшьлекне сагыну һәм картлык турындагы» бүлекчәсе, мәсәлән,—лириканын гажәеп күркәм бер үрнәге. «Котадгу белек»тә табигать күренешләре, кагыйдә буларак, вакыт агышын, хәрәкәтне белдерүгә, вакыйга-хәлләргә фон, жирлек тудыруга хезмәт итәләр.

Йосыф Баласагунлы әсәренен атамасы китапнын мәгънәсе, идея йөкләмәсе белән тыгыз бәйләнешле. Безнен татар фәненә ул бераз гына үзгәртелеп кереп киткән. Чынлыкта әсәрнен исеме——«Кутадгу билиг». Андагы беренче сүз кот, бәхәт-сәгадәт мәгънәләрен белдерә. (Ә инде «адгу» компонентын әдгү—изге—игелекле дип карау мөмкинчелеге дә бар). «Билиг» (билик) белем, китап, ан төшенчәләрен бирә. Шуна мөнәсәбәттә Йосыф Баласагунлы әсәрен «Бәхет китабы», «Бәхеткә китерүче гыйлем», «Бәхетле булу белеме» һәм башка исемнәр белән дә атыйлар. Кайбер галимнәр (С. Малов, А. Вәлитова...) «билиг» сүзенен «идарә» төшенчәсе белән дә бәйләнешен искәртәләр һәм әсәрнен исемен «Осчастливливающее управление», «Наука об управлении» рәвешендә тәржемә итәләр. Бу төр атама да «Котадгу белек»нен рухына, идея эчтәлегенә туры килә. Чөнки ул—төрле гуманитар гыйлемнәрне туплаган мөһим синкретик ядкарь дә.

Йосыф Баласагунлы китабында тормыш-тереклекнен гажәеп күп төрле мәсьәләләре гәүдәләнеш тапкан. Авторны барыннан да элек инсаннын асылы, яшәү мәгънәсе, жәмгыятьтә үз-үзен тотышы кебек мәсьәләләр кызыксындыра. Анын уенча, адәм баласы белемле, һөнәрле, әхлаклы, акыллы, ярдәмчел, сабыр, шәфкатьле, ихлас, намуслы, гадел... булырга тиеш. Автор бу төр сыйфатларнын асылын, яшәештәге әһәмиятен үтемле итеп ачтырта. Ул еш кына капма-каршы кую-антитеза алымына мөрәжәгать итә. Йосыф Баласагунлы раславынча, Алланы хөрмәт итү, иман-ышаныч—камил инсан булунын зарури таләбе.

«Котадгу белек»тә, кеше белән тыгыз бәйләнештә, ижтимагый, социаль, сәяси мәсьәләләргә дә зур урын бирелә. Автор жәмгыятьтәге, идарәчелектәге төп вазифаларга, һөнәр-профессияләргә туктала. Ул игенче, һөнәрче, сәүдәгәр, галим, укытучы, илче, вәзир, шагыйрь, табиб, гаскәри, казначы, пешекче һәм башка бик күп шөгыль-вазифаларнын төп асылын гәүдәләндерә. Шагыйрь сурәтләвеннән шул анлашыла: жәмгыять, мәмләкәт жанлы бер организм кебек; һәр кеше, һәр шөгыль иясе үзенен бурычларын белергә, аларны жиренә житкереп башкарырга тиеш. Шул вакытта гына тормыш организмы көйле

яши, хәятта гаделлек, бәхетле-имин тереклек урнаша. Авторның аеруча хөкемдарларга таләбе зур: алар камиллекнен, иң беренче чиратта гаделлекнен өлгесе булырга тиеш. Китапта гаилә кору, бала тәрбияләү хакында да гыйбрәтле юллар бар. Шагыйрь фикеренчә, гаиләсез, баласыз кешенең буыны киселә, исеме онытыла.

«Котадгу белек»,—гомумән, дөньяви әсәр. Анда тулы канлы тормышка өстенлек бирелә. Әмма мондый яшәеш кайвакыт гомернең чикләнгәнлеге, үлемнең котылгысызлыгы, байлык-хакимиятнең инсанны бозуы кебек суфыйчыл мотивлар белән тәнкыйтькә дә алына. Дәрвишлек, аскетизм-зөһедлек аеруча Узгырмыш образында идеаллаштырыла.

Йосыф Баласагунлы китабы—жанр табигате белән синкретик рухлы фәлсәфи-дидактик әсәр. Анда тормыш тәҗрибәсе, инсан хакында уй-фикерләр тупланган. Авторның төп максаты—укучыны яшәргә өйрәтү, ана күпгасырлык рухи тереклек тәҗрибәсен җиткерү. Нәкъ менә шуна күрә дә ул үзенең күңел байлыгын еш кына үгет-нәсыйхәт, теләк, киңәш бирү рәвешендә бәян итә. Әсәрдә мәкаль-әйтемнәрнең, канатлы сүзләрнең күпләп кулланылуы, гыйбрәтле сөземтәләр китерелүе дә аның дидактик табигате белән аңлатыла.

«Котадгу белек»—афористик фикерләүнең, тыгыз сурәтлелекнең, аз сүз белән тирән, хикмәтле сүз әйтүнең гүзәл бер үрнәге. Анда зиһенгә алырлык, тормышның төрле вәзгыятьләренә туры килерлек, мисал, эпиграф итеп кулланырлык юллар гаять күп. Бу китап—акыл-хикмәтнең тулы сандыгы, төкәнмәс бер чыганагы. Анда бүгенге көнгә авазлаш яклар да бихисап.

Йосыф Баласагунлы әсәре үзеннән соңгы төрки сүз сәнгате үсешендә мөһим роль уйнады. Аны без татар әдәбияты һәм фольклоры мисалында да ачык күрәбез. Кол Галидән алып хәзергәчә яшәгән татар әдипләре иҗатында «Котадгу белек» белән бәйләнешләр, охшашлыклар күзгә еш ташлана. Белем-мәгърифәтне, матур әхлакый сыйфатларны зурлау, кешенең үз гамәле өчен үзенең җаваплылыгы («Ни чәчсәң—шуны урырсың»), иманлылык, «игү ат» калдыру, хикмәтле сүз әйтү, төш күрү һәм Йосыф Баласагунлы белән бәйләнешле башка мотивлар безнең күп гасырлык әдәбиятка гомумән хас. «Котадгу белек»тә гадел патша көтүче, явыз хөкемдар бүре, гавам куй белән, дөнья бизәнгән яшь килен белән чагыштырыла, гыйлемнең бетмәс-төкәнмәс, бернинди карак та урлый алмас байлык булуы искәртелә. Бу төр сурәтләрне Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Утыз Имәни кебек шагыйрьләр дә яратып куллана. Йосыф Баласагунлының аерым юллары фольклорлашып та киткән.

«Котадгу белек» инде күп еллар буе дөнья фәнни һәм мәдәни җәмәгатьчелегенең игътибарын үзенә җәлеп итеп килә. Ул Г. Вамбери, В. Радлов, С. Малов һәм башкалар тарафыннан нәшер ителгән. Бу китап Кытайда да дөнья күргән. С. Иванов аны «Благодатное знание» исеме астында 1983 елда русчага тәрҗемә итеп Мәскәүдә бастырды. 1971 елда әсәрнең Г. Кәримов тарафыннан әзерләнгән Ташкент басмасы дөнья күрде. Анда текст оригиналда һәм хәзерге үзбәк теленә тәрҗемәдә бирелгән.

Йосыф Баласагунлы әсәре татар дөньясында элек-электән билгеле. Аның XV гасырга мөнәсәбәтле Каһирә нөсхәсе Идел буенда күчерелгән. «Котадгу белек»нең Наманган кульязмасы 1913 елда Зәки Вәлиди тарафыннан табылып, гыйльми әйләнешкә кертелә. Бу әсәрнең узган гасыр урталарында дөнья күргән Төркия басмалары биредә яшәүче татар галиме Рәшит Рәхмәти Арат тарафыннан башкарыла. Милләттәшләребез А. Вәлитова, Ш. Абилов та бу мәшһүр ядкярне өйрәнүгә үзләреннән сизелерлек өлеш керттеләр.

«Котадгу белек»нең аерым үрнәкләре бездә Х. Госман, Х. Миннегулов, Ә. Синугыл *(Казан утлары 2001—№6 180—183б)*, Л. Шагыйрьҗан *(Мәдәни җомга. 25.08.1995)* һәм башкалар тарафыннан бастырылган, тәрҗемә ителгән. Әмма аның тулы басмасын татар укучыларына җиткерү мөһим бурычларның берсе булып тора. Мәгълүм ки, профессор Рифкать Әхмәтьянов Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрен хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп бастырган иде. Аның бу хезмәте һәм укучылар, һәм галимнәр тарафыннан унай бәяләнде. Ишетүемчә, Р. Әхмәтьянов хәзер «Котадгу белек»не тәрҗемә итү белән мәшгуль. Аны бастыру хәстәрен күрергә иде.

Йосыф Баласагунлы үз хезмәтенең бөеклеген үзе дә яхшы аңлый. Китапның керешендә ул башка төр бүләкләрнең вакытлы булуын, «Котадгу белек» нең мәңге яшәячәген искәртә. Инде менә мең елга якын гомер узган, Йосыф Баласагунлының бөек әсәре исә һаман да яши, һаман да «тормыш дәреслеге» булуын дәвам итә.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Салман авылы

Кама аръягында Әлки, Чистай, Спас һ.б. районнар җире борынгы тарихи һәйкәлләргә бай булуы белән аерылып тора. Авылларда өлкән буын вәкилләре белән сөйләшсәң, авыллары оешу, тирә-як турында легенда-риваятьләр, борынгы бабаларыбыз тормышына мөнәсәбәтле әллә никадәр тарихи вакыйгалар ишетәсең. Бу җәһәттән караганда, Иске Салман авылы берсеннән дә калышмый шикелле.

Актай елгасына сул яктан килеп кушылган Салман суы буендагы Иске Салман авылы Әлки районы җирләрендә, район үзәге Әлки авылыннан 17 чакрымда, тимер юл станциясеннән—80, пристаньнән 62 чакрым ераклыкта урнашкан.

Салман суы үзенә атаманы авыл исеменнән алган.

Салман һәм Иске Салман авыллары янында археологлар борынгы һәм соңгы болгар чорларына нисбәтле авыл хәрабәсе, зират һәм табылдык әйберләр билгеләгәннәр. Д. А. Корсаков белешмәсе мәгълүматларына караганда, Иске Салманда 151 йомышлы татар, Яңа Салманда 193 йомышлы татар һәм 12 керәшен, Салман авылында 185 алпавыт крестьяны, Түбән Салманда 59 йомышлы татар гомер кичергән. Авыллар Салман суы ярына утырганнар.

Иске Салман авылы оешуы турында түбәндәге легенда-риваять бар. Мөхәммәт пәйгамбәр исән чагында Мәккә шәһәреннән бер зур галим кеше Идел буена дин өйрәтергә җибәрелгән. Бу кеше Сөләйман атлы булып, галим булганга күрә, аны Сөләйман Хуҗа дип йөрткәннәр. Сөләйман Хуҗа Мәккә шәһәреннән, күп газаплар кичеп, Шәһри Болгарга килгән. Шәһри Болгарда хан Хуҗаны үзенең сараенда тотып, соңыннан илне агартыр өчен безнең якка җибәргән. Сөләйман Хуҗа илгә чыгып, зур мәдрәсә ачып, бик зур муллалар чыгарган. Алар, авылларга таралып, илне агартканнар. Сөләйман Хуҗа бик күп телләр белгән. Болгар илен бик яраткан, шуның өчен кире Мәккәгә кайтып китмәгән. Ул безнең бу як халкын яратып сөйли икән. Сөләйман Хуҗа әйтә торган булган: «Шәһри Болгар җире бик бәрәкәтле җир, ул җиргә ислам кылыч көче белән таралмаган. Болгар илендәге халык ислам динен үзе теләп кабул иткән, шуның өчен җомга намазында хотбәләр агач таяк тотып кына укыла»,—дип. Менә шушы Сөләйман Хуҗа Иске Салман авылының беренче карты вә изге бабасы имеш. Ул Салман авылын нигезләүче бабай булган.

Шул рәвешле Салман бабай исеме белән су Салман суы дип, ә авыл Салман дип исем алган. Бу авыл янында башка Салманнар да барлыкка килгәч, монысы Иске Салман дип йөртелә башлаган. Халык сөйләвенә караганда, Сөләйман Хуҗа зираты Иске Салман белән Морза Салманы арасына урнашкан. Салман атамасы тарихи чыганакларда, фольклор әсәрләрендә һ.б. еш кулланыла.

Иске Салман авылы янында археологлар Болгар—Алтын Урда чорларына мөнәсәбәтле каберлек һәм авыл хәрабәләре, Салман авылы янында борынгы болгар заманнарына караган табылдык әйберләр билгеләгәннәр. Хәзерге көндә дә Иске Салман белән Абдул Салманы арасында, су буендагы матур бер урынны «Йортлар өсте», «Салман хуҗа кабере», «Кичү» дип йөртәләр. Халык Салман бабайны онытмый: кабернең өсте койма белән

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

тотып алынган, ул әледән-әле яңартылып тора. Борынгы гореф-гадәт, йола-кануннарны күз карасы кебек сакларга тырышкан олы буын, җәйнең матур көннәрендә сарыклар чалып «Изгеләр өсте», «Салман хуҗа кабере»нә, «Кичү»гә килә.

Революциягә кадәр Иске Салман авылында 450гә якын хуҗалык булган. Шуларның 110лабы ярлы, 290 тирәсе урта хәлле, 50 тирәсе хуҗалык шактый бай исәпләнгән. Авылда 5 җил тегермәне, ике ярма яргыч, 6 кибет эшләгән. 2 мәчет гөрләп торган. Бер мәчетнең мулласы Сибгатулла исемле булган, икенчесе—Әхмәтша мулла булып, нигәдер аны терелдәй күмеп үтергәннәр. Авылда өченче мәчет салырга җыенганнар, ләкин революция чыгу моңа комачаулаган.

Авылда ике мәдрәсә эшләгән. Гайнулла Айтутанов дигән кеше рус-татар мәктәбе ачарга да тырышып йөргән. 1912 елда бина булмауга карамастан, бу мәктәп ачыла һәм сабакларны төрле кешеләрнең өйләрендә укыталар.

1921 елда зур ачлык була, авылда 400 кеше ачтан үлә. Күп кеше ачлыктан котылу өчен читкә китә. Мәктәп бинасында ятим балалар өчен приют ачалар.

1927 елда авылда уку өе һәм клуб ачыла. Уку өендә авыл яшьләре пьесалар, концертлар куя башлый. Шушы елда ук комсомол оешмасы төзелә, клубта стена газетасы чыгарыла. 1929 елда авылда беренче радиоалгыч сөйли башлый. Халык радиога ышанмый, аңа «сихер» дип карый. Шуннан соң, авыл алдынгыларының берсе, Гатауллин Кадыйр Казанга килеп радио аша авылдашларына мөрәҗәгать итә.

Ватан сугышы елларында авылдан 184 кеше фронтка алына, 98 кеше сугышта башларын сала. Бу елларда колхоз бик нык какшый. 1944 елда авылда колхоз икегә бүленә: «Кызыл Байрак» һәм «Ворошилов» исемендәге колхозлар.

1965 елның декабрендә Иске Салман, Иске Тахтала, Яңа Тахтала, Яңа Баллыкүл һәм Иске Нохрат авыллары берләшеп, «Спутник» совхозы оештырыла. Бу совхозның үзәге Иске Салманда урнаштырыла.

Бүгенге көндә авылның табигате, елга-күлләре кеше ярдәменә мохтаҗ. Чыгыш күле көннән-көн пычрана, суы кими бара, ә аның янындагы Алма бакчасында көтү йөри. Язын һәм көзен авыл урамнары бик пычрак.

Иске Салманнан 3 чакрым ераклыкта Яңа Салман авылы урнашкан. Исеменнән үк күренеп торганча, Яңа Салман авылы соңрак төзелгән.

Яңа Салманнан 1-2 чакрым ераклыкта Рус Салманы башлана. Түбән Салман исә түбәнлек җиргә утырган.

Авыллар янындагы географик берәмлекләр бу авылларның борынгылыгына ишарә ясый. Кол атавы дигән топонимны аксакаллар болай аңлата. Борынгы заманнарда бу атауга Тау ягы төбәгеннән Колмөхәммәт исемле бабай килеп урнашкан. Шуңа авылның ул очы Кол атавы дип йөртелә башлаган. Бу бабай югарыда сүз алып барылган Сөләйман Хуҗа нәселеннән булган, имеш.

Иске Салман авылындагы Иске зират дип атала торган каберлектә 3 таш булган. Аның икесен 1974 елгы эпитафик һәм археологик экспедиция вакытында Г. Ибраһимов исемендәге институтның баш гыйльми хезмәткәре Марсель Әхмәтҗанов күргән. Берсенең язмаларын укыган да. Бу ташта ул 1317 ел датасын күрә. Икенчесенең өске өлеше генә җирдән күренеп торган, язулары сакланмаган. Өченче таш инде бөтенләй юкка чыккан. Шушы авылда яши торган Зариф бабай сөйләвенә караганда, мондый ташлар бу зиратта 7—8 булган әле. Ләкин вакытлар үтү белән алар югалганнар.

Аксакаллар Салман бабайның балалары Морзалар авылына чыгып утырганнар дип сөйлиләр. Андагы иске зиратлар аларныкы икән. Абдул Салманы (Морза Салманы) янында Салман суы Морзалар буе яисә Су буе дип йөртелә. Халык сөйләвенә караганда, Су буе кешене тота икән. Кешене тотмасын өчен, аның янында үрдәк чалалар, ягъни суга корбан бирү гадәте сакланган. Урыслар да, чуашлар да бу йоланы үтиләр икән.

Бу авылда да Иске зират бар икән. Элек анда бик күп борынгы кабер ташлары булган. Ләкин аларны, халык сөйләве буенча, трактор белән ваттырганнар. Авылдагы тагын бер борынгы каберлек Кызыл бура дип атала. Имеш, бу урында Болгардан Бүләргә укырга барганда өч кызның берсе үлеп калган, аны күмгән җиргә шундый исем биргәннәр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Илдар Зариповка 70 яшь

Булачак рәссам 1939 елны Казанда туа. Ягодный бистәсе–ташпулат йортлар янәшәсендә авылча йортлар рәте дә тезелеп киткән. Менә шундагы йортларның берсендә, ишле гаиләдә хыялый малай яши. Кулына карандаш ала да рәсемнәр ясау белән мавыга...



Еллар үтә. Казан сәнгать училищесында укыганнан соң ул, мәртәбәле конкурс аша узып, В. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать институты ишекләрен ачып керә.

Бүгенге көндә Илдар Зарипов иҗаты белән дан-дәрәҗә, абруй казанган күренекле рәссамнарның берсе. Аның мактаулы исемнәрен санап чыгу өчен генә дә байтак урын кирәк. Ул–Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1976), РСФСРның атказанган рәссамы (1983), Россия Федерациясенен халык рәссамы (2002). 1994 елда аңа Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Төп әсәрләреннән кайберләрен генә санап китик: «Туган авылымда» (1982), «Кырлай моңнары» (1986–88), «Казан чибәре Зөлфия» (1984), «Сөембикә–улы белән» (1990) һәм башкалар. Рәссамның картиналары Мәскәүнең Третьяков галереясында, Санкт-Петербургның Рус музеенда, Татарстан һәм Россиянең башка зур музейларында саклана. Аның иҗат үрнәкләрен Германия, Англия, Франция, Америка кебек илләрдә дә очратырга мөмкин.

Илдар Зарипов иҗатының төп үзенчәлекләре, үзенә тарту көче нәрсәдә соң? Рәсем сәнгатен сөючеләрне аның төс-бизәкле полотнолары кай ягы белән җәлеп итә, күңелләрендә ничек итеп моң чишмәсе уята?

Бу очракта моң сүзе юкка гына телгә алынмады. Рәссам татар рухын, татар моңын, татар хәятындагы милли колоритны, татар халкына гына хас үзенчәлекләрне җете-саф төсләр гаммасы һәм конкрет сурәтләр аша тасвирлап, җанландырып бирү осталыгына ия. МОҢ аның иҗатында сәнгати образ дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә һәм якты гүзәллеге белән әсир итә, истә кала.

Авыл моржасыннан күтәрелгән төтен баганасы, коймак исе, яшел чирәм өстендәге сөт чүлмәге һәм арыш ипие, ут булып янып торган кызыл миләшләр дисеңме–туган ягың, туган авылың яраткан, ләкин зур шәһәрләргә китеп шәһәрләшкән кешеләр өчен сагынычлы хатирәләр бу... Ә инде үткәннәрне белеп бетермәгән яшь буын өчен–әкияти өр-яңа дөнья, үткәннәргә сәяхәт.

Техника белән тапталып, авылда чирәмлекләр юкка чыга бара. Ипи хәзер мичтә түгел, заводларда һәм кибет киштәләрендә «пешә»... Менә шушы фонда, заманалар бик нык үзгәрә барганда Илдар Зариповның тормышчан, саф-самими, моң һәм тылсым өретелгән картиналары күңелгә аеруча якын. Алар тормышны, табигатьне яратырга, әхлакка өйрәтә. Заманыбызның асфальтка, неон утларга, полиэтилен шешәләргә, арматура-бетонлы төзелешләргә батып барган бер чагында үткәннәргә борылып карарга, югала барган хисләрне уятырга чакыра.

# «ТАТАР СӘНГАТЕ КҮГЕНДӘ АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗ»*

Милләтебезнең җыр сәнгатенә гаҗәеп матур өлеш керткән талантлы композитор Фәтхерахман Әхмәдиев 1929 елның 16 ноябрендә Татарстанның элекке Кызыл Йолдыз (хәзерге Балык Бистәсе) районы Тәберде Чаллысы авылында тимерче гаиләсендә өченче малай булып дөньяга килә. Әтисе Габдрахман авылның оста гармунчысы була, ләкин улына биш яшь тулганда дөнья куя. Фәтхерахман әтисеннән калган иске яшел тальян гармунында уйнарга өйрәнә. Әнисе Фәхрелбәнат тормышның бөтен авырлыгын сыкранмый күтәрә, шуна күрә гаилә яши. Оста тегүче иде Фәхрелбәнат апа.



*Вил Шәрәфетдинов рәсеме*

Сугыш елларында Фәтхерахман Әхмәдиев гармун уйнап, җырлап, солдат хатыннарына кайгы-хәсрәтләрен азга гына булса да оныттырырга булыша. Авылдашлары аны бик яраталар. Ул тырыш, унган бала булып үсә.

Булачак композиторның тормыш юлы җинел түгел иде. Ул, гаиләне туендыру өчен, җиденче классны тәмамламыйча, МТСка эшкә урнаша, чөнки анда эшләгән кешегә 400 грамм ипи бирәләр иде. 1951 елның көзендә Казанга килә һәм музыка училищесына ирекле тынлаучы булып урнаша. Ә икенче елда музыка училищесына укырга керә, һәм шул ук вакытта кичке мәктәпкә дә йөри. Шул елларда ул Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин, Ифрат Хисамов, Арслан Батыршин, Ләбиб Айтугановлар белән таныша. Училищеда укыганда Фәтхерахман «Кызыл Йолдыз районы җыры»н яза. Аннан соң башка көйләр дә иҗат ителә. Шагыйрь Мөхәммәт Садри аны Салих Сәйдәшев белән таныштыра. Сәйдәш егетнең көйләренә унай бәя бирә:

—Синең үз почеркың бар, җуйма. Баянны да әйбәт аңлыйсың, ташлама син аны. Тик шулай да сиңа композиция бүлегенә күчәргә кирәк, мин училище директоры белән сөйләшермен,—ди.

Шулай итеп, Фәтхерахман композиция буенча Юрий Виноградов дәресләрен тынлый башлый. Ләкин озакламый аны армиягә алалар. Ул Казан гарнизонында хезмәт итә. 1956 елда Әхмәдиев Роберт Әхмәтҗановның «Кама буе—туган як» дигән шигыренә җыр яза һәм октябрь азакларында Казан дәүләт университетының «Яшь талантлар» кичәсендә аны үзе уйнап, үзе җырлап күрсәтә.

Хәрби хезмәттән соң Ф. Әхмәдиев музыка училищесын тәмамлый һәм, авыру сәбәпле, туган якларына кайтып китә. «Берсут» ял йортында фотограф булып, аннары пароходта баянчы булып эшли. 1956-64 елларда ул Котлы Бөкәш урта мәктәбендә җыр укыта, мәктәпнең баянчылар ансамблен җитәкли, клубта музыка түгәрәгенә җитәкчелек итә.

1962 елда Татарстан китап нәшрияты аның «Җилләр, җилләр» исемле беренче җыр җыентыгын бастырып чыгара. 1964 елда Ф. Әхмәдиев Казан җитен комбинатында татар хоры түгәрәгенең җитәкчесе һәм баянчы булып эшли. Аннары Горький клубындагы Сара Садыйкова җитәкләгән хорда аккомпаниатор була. Шул елларда

* Ф. Әхмәдиев турында Равил Фәйзуллин әйткән сүз.

ул Зиннур Гыйбадуллин, Әнвәр Шәрәфиев, Мәсгут Имашев, Әхмәт Хәйретдинов белән таныша, аралаша.

Балык Бистәсендә һәм бу районның Котлы Бөкәш мәктәбендә Ф. Әхмәдиевкә багышланган музейлар бар. Кадерле композиторыбызның исләгелән гел күңелләрендә яд итеп торган затлар: хатыны Равия, кызы Ләйсән, оныклары Айдар белән Роза бар. Ләйсән район музеена әтисенең баянын бүләк иткән. Жырчы Гөлзадә Сафиуллина үз студиясендә композиторның 14 жыры кергән аудиокассетасын чыгарган.

«Мәңге яшисе килә» дип жыр язган (сүзләре дә үзенеке) сөекле композиторыбызның гомере кыска булды. 1981 елның 3 сентябрендә, 52се дә тулмаган килеш дөньядан китеп барды ул. Аннан биш жыр жыентыгы калды.

**Әлфия ШАМОВА**

## Ф. ӘХМӘДИЕВ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ:

Ф. Әхмәдиев гажәеп дәрәжәдә образлы ижат итә белүче композиторларның берсе. Ул образларны шулкадәр оста итеп бирә ки, әгәр дә жыр лирик икән, ул инде лирик, шаян булса, чыннан да шаян...

Моннан 40 еллар элек аның «Жилләр, жилләр» дигән жыры халык арасында бик популяр булды. Ул вакытта әле авыл буйлап гармуннарда, баяннарда уйнап-жырлап йөрүләр бар иде. Бу жыр халыкның күңеленә шулкадәр хуш килде ки, һәр кич авылның теге яисә бу урамыннан «Жилләр, жилләр» дип жырлап килеп чыга торганнар иде...

**Мирсәет ЯРУЛЛИН,**
*композитор, Россиянең һәм Татарстанның*
*атказанган сәнгать эшлеклесе.*

Композитор Фәтхерахман Әхмәдиев табигатьнең бер моңлы баласы иде. Үзеннән-үзе агылып торган көйләре жир куеныннан сызылып агып чыккан чишмә кебек саф, ихлас, чын мәгънәсендә табигый иде. Шул табигыйлык аның жырларын халыкчан иткәндер дә инде.

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА,**
*шагыйрә, Г. Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты*

Ф. Әхмәдиев үзенең оригиналь, гажәеп тирән хисле жырлары белән аерым бер урын алып тора. 50-70нче елларда аның жырларын халкыбыз, яше дә, карты да, рәхәтләнеп жырлый иде. «Жилләр, жилләр», «Бер карадым күзләренә», «Жәйнең матур аяз таңнарында», «Жырлыйм әнием турында» кебек жырлары яңгырамаган бер генә концерт, бер генә кичә, бер генә мәжлес булды микән?..

**Рамил КУРАМШИН,**
*баянчы, композитор,*
*Татарстанның халык артисты*

Гомәр Бәширов

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ

Гомерем ахрына якынлашып бара. Һәйбәт кенә китапларым да юк түгел. Мине акылы сай кеше дип тә әйтеп булмас иде. Шулай да мин үземнең бер кимчелегемне гомерем буена җиңә алмадым. Иң якты хыялыма ирешү өчен бөтен көчемне җыеп барлык ихтыяр көчемне туплап тотынмыйм, вакытлы нәрсәләр белән мавыгам да төп максатка ирешү юлыннан читкә тайпылам. Менә хәзер мина өзек-өзек итеп төрле елларда язылган «Гыйбрәт»не бер итеп оештырырга да аны журналда басарлык хәлгә китерергә кирәк. Ә мин, ана ирешүне нигәдер һаман сузам, һаман чигерә барам, башка эшләр белән мавыгып китәм. Я берәр мәкалә язарга, я яна хикәя язарга тотынам. Минем бит хәзер тормышның иң кризиска очраган вакыты: яшем бик күп, 94 тән узып китте. Күзем, бердәнбер сул күзем көннән көн начарлана бара, карчыгым авырый, башка йортка күчтек. Нәрсә көтәм, нигә «Гыйбрәт»не тәмамлап бирмим, ни сәбәпле үземне-үзем җинә алмыйм. Гаҗәп бит! Бу нихәл бу?!

**15 гыйнвар, 1994.**

Кәефем шулкадәр начар, менә, менә елап җибәрермен шикелле. Ләкин алай ук өметне өзәргә минем хакым юк. Мин бит яшем 93кә җитсә дә яза алам әле. Көнгә ярты бит, хәтта берничә юл гына язып калдыра алсам да ул бит яшәү билгесе, алга таба атлыйбыз дигән сүз.

Әйе, күнелне төшерергә ярамый. Югыйсә, мин яза алмый башлаячакмын. Яза алмый башлау исә минем өчен үлем белән берүк дәрәҗәдәге өметсез халәт.

**27 июль, 1994.**

Мина кичә 94 тулды (шулай була инде). Байтак иптәшләр, туганнар туган көнем белән котладылар. Әмма шулар арасында Мәскәүдән тәрҗемәче Залещук һәм аның җәмәгате, шулай ук тәрҗемәче Елена Ивановнаның телефон аша тәбрик итүләре аеруча куандырды. Менә чын мәгънәсендә яхшы күнелле кешеләр һәм чын күңелдән ихтирам итүчеләр нинди була.

Үзем язам, үзем бу минем соңгы язмаларым булыр инде дип чын күнелдән кайгырам. Чөнки сул күзем бик начарланып бара. Әгәр мондый тизлек белән сукырайсам, мин тагын 1-2 айдан ук яза алмый башлаячакмын. Аһ, нинди бәхетсезлек! Минем язасы нәрсәләрем бик күп булырга тиешле иде бит әле.

**8 гыйнвар, 1995.**

Бик авыр хәсрәтле көннәр кичерәбез. 14 июньдә 15нә каршы төндә Мөхәммәтебез элекке әдәби тел белән әйткәндә «дарелфәнидин дарелбакая рихләт әйләде». Соңгы берничә көндә аңына килә алмады. Икенче көнне, ягъни 15нче июньдә аның мәетен

*Ахыры. Башы 11,12 (2008) һәм быелның 1,3,8,9 саннарында.*

үзенең васыяте буенча туган авылы Гөберчәккә анасы күмелгән зиратка илтеп күмделәр. Бездән күмәргә Зөфәр барды. Шулай ук улы Искәндәр, кызы Лилия, оныгы Гәүһәрия, аның ике айлык кызы Зөһрә дә озата бардылар.

Менә Мөхәммәтсез калдык. Кызым тол хатын булып калды, балалары зурлар инде, бик авыр кичерәләр. Хода аларга түземлек бирсен, хәер, һәммәбезгә дә. Кемнәргәдер ияреп барып кабере өстендә дога кылып, аның рухына багышлап кайтасым килә. Мөхәммәтнең авыл укытучысы вакытында, егет чагында безгә килеп керүен хәтерлим әле. Тыйнак кына бер авыл егете иде, күп тә үтмәде, берсе артыннан берсен укып туймаслык һәйбәт әдәби әсәрләр иҗат итә башлады. Һәм тора-бара Мөхәммәт Мәһдиев дигән талантлы әдип пәйда булды. Матур әдәбиятта һәм публицистикада үзенә генә хас әдәби образлар тудырып мәдәни тормышыбызда тирән эз калдырды Мөхәммәтебез. Рухы тыныч булсын. Халык үз улын бик озакка кадәр онытмас.

**30 июнь, 1995. Кич.**

Гаҗәеп бер хәл. Кәримә белән икебез дә 90нан узып киттек. Мин 1901елгы, ул 1902. Безнең тирәдә, белеш танышлар, туганнар арасында да безнең яшькә житкән берәү дә юк. Ходаның рәхмәте, авырмыйбыз да.

Безнең озак яшәвебезнең бер сәбәбе гаиләдәге, балалар, туганнар арасындагы тынычлык, ыгы-зыгы, тавышсыз яшәү булса кирәк. Икенче сәбәп, без хәмер кулланмыйбыз, кунакка соңгы елларда бөтенләй йөрмибез диярлек (чөнки яшьтәшләр һәммәсе дә «китеп» бетте). Улым белән очрашканда эчемлек куллану гадәте шулай ук юк (Мөхәммәт белән азрак шаяргалый идек, юрамалый гына).

**22 август, 1995.**

2 мартта шимбә көн, Г.Ахунов белән Арчадагы дусларыбыз алдынгылар слетына алып киттеләр. Узган еллардагы кебек уңышны бөтен Татарстанда иң күп алучылар булмасалар да безнең якның соры туфрагында шундый уңыш алу бик мактаулы эш инде ул. Гариф та, мин дә сөйләдек. Ләкин мин һәрвакыттагы кебек үз ноткымнан канәгать булмадым. Мин бик начар оратор, бервакытта да фикеремне тыңлаучы игътибарын җәлеп итәрдәй матур итеп әйтеп бирә алмыйм. Ул яктан безнең Гариф якташ бик уңган. Теләсә нинди аудиториядә менә дигән нотык белән чыга ала, аны алкышлар белән озаталар.

Арчага улым Зөфәрләрдән киткән идем, «безгә кайтырсың» диделәр дә аларга кайтып кундым. Анда без кечтеки кызый Камилә белән бик дус. Ул мине һәрвакыт матур киенеп каршы ала, без аның белән ничектер сөйләшергә сүз дә табабыз, аның янында мин үземне берникадәр сабыйлашкан йомшак күңелле, мәрхәмәтле бер бабай итеп, сүзчән итеп тота башлыйм. Сабый баланың беркатлы самимилеге, күрәсең, ничектер миңа да тәэсир итәдер. Кешенең хисләр дөньясы шулкадәр бай, шулкадәр катлаулы һәм төрле, кайчакны үзеңне үзең аңлап бетерә алмыйча аптырашта (монысы бик тупас сүз!) каласың. Менә шул катлаулы дөньяны китабындагы каһарманнарына күчерү шактый ук осталык таләп итә. Ул гынамы әле!..

**6 март, 1996.**

Моңа кадәр мин оптимист идем, менә шушы арада күңел төшенкелегенә бирелә башладым. Моның сәбәпләре дә бар. Аякларымның хәле бетә башлады. Башым да әйләнгәли. Бер күземнең күрмәвенә күптән гадәтләндем инде. Икенчесе дә сукырайса нихәл итәргә? Мин бит ялгыз карт.

Мондый чакта теге карчыкның ходайга ялваруы искә төшә: «Ярабби ходаем! Үзем исән-сау чагымда гына үлеп китсәм ярар иде» дигән ул. Беренче карашка бу көлке сыман. Әмма моның тирән мәгънәсе бар. Авырып кеше кулына калмагаем, кешегә мәшәкать ясамагаем дигән сүз бу. Мин дә шундый теләктә торам... Үземә дә, бүтән берәүгә дә бу хакта үпкәм юк. Миңа бит инде 95 тулды. Кулларым, аякларым нигә бик тиз армасын икән? Алар миңа 95 ел буена хезмәт иттеләр бит инде, начар да хезмәт итмәделәр. Бик рәхмәт аларга.

Шул ук вакытта минем әдәбият өлкәсендә эшләүче галимнәргә үпкәм дә бар.

Нинди үпкә тагын ул дисезме? Менә нинди. Мин татар фольклористикасында шактый эш башкарган кеше. Мәсәлән, мин мәзәкне әкияттән аерым аның үзенә генә хас бер жанр икәнлеген раслаган кеше. Мин мәзәкләргә «җан өрдем». Халыктан җыйган мәзәкләрне тәртипкә салып алардан русча, татарча 5-6 китап бастырдым. Бу игътибарга лаеклы хезмәт түгелмени? Мин бит фән докторы да, хәтта фән кандидаты да түгел. Формаль күзлектән караганда минем хәтта урта белемем дә юк. Шулай да мин үземне кайбер югары белемле бәндәләрдән өстенрәк торучы дип саныйм. Бу минем белемгә омтылып үзлегемнән күп нәрсәләр үзләштерүемнең нәтиҗәсе. Шөкер, гомеремне «трай тибүгә» әрәм итмәдем, бик күп укыдым, күп белергә тырыштым. Нәтиҗәдә кайбер профессорларның хаталарын күрсәтеп «мыекларын кабарттым». Менә шулай эшләр.

**19 май, 1996.**

Без бичара Россиянең колониясе булып яшибез. Россиянең башкаласы Мәскәүдә бөтенләй башка тормыш. Аның кибетләрендә һәммә нәрсә дә—ризыгы булсын, кием-салымы булсын—һәммәсе дә бар. Әле моннан берничә ел элек кенә ак майны, дөгене, чәй-шикәрне, күмәчне, хәтта кайвакыт икмәкне дә Мәскәүдән ташып ашый идек. Шунысы гаҗәп—Татарстан администрациясе мондагы игенчедән игенен, итен, маен актыгына кадәр йолкып ала да Мәскәүнең кап-корсагына озата. Без исә, шуның артыннан ук Мәскәүгә барабыз да шул ук ризыкларны чират торып сатып алабыз. Спекулянтлар исә шул ук ризыкны монда алып кайтып биш-алты мәртәбә кыйммәтрәк саталар иде...

Их,их,их. Әле хәзер дә шулай диярлек. Безнең балаларыбызның ничәнче буыныдыр инде кара икра, кызыл икра, яхшы балык, яхшы колбаса, чын чәй, зәйтүн мае һ.б. кебек ризыкларны ашап карау түгел, нинди икәнлекләрен дә күрмичә үсәләр. Совет хакимияте вакытында да шулай булды. Менә хәзер дә шулай.

Россия халкы 922нче елда Гарәбстан илчесенең сәркатибе Ибн Фазлан килгән вакытта ук эчкече булган, хәзергесен әйткән дә юк. «Известия» газетасының мәгълүматларына караганда Россия халкы бу елларда берүзе бөтен дөнья халкы эчкән аракы кадәр аракы эчә. Безнең халкыбыз, ягъни татарлар, революциягә кадәр бердәнбер эчмәүче—аек халык рәвешендә яши иде. Мона мин үзем җанлы шаһит. Хәзер «өлкән» агабыз безне дә, хәтта хатыннарыбызны да эчәргә өйрәтте. «Агай»ның безгә бөтен «яхшылыгы» шул булды. Ул безне һәлакәт юлына (үз артыннан) сөйрәп алып керде. Бик аяныч безнең хәлебез. Ай-һай...

**12 август, 1996.**

Шулай итеп менә 1997 елга да килеп кердек. Димәк, мина бүген 96 тулган була бит. Йа ходай, кем уйлаган шулкадәр озак яшәрмен дип? Минем анам Минзифа 57дә, атам Бәшир 65 яшендә дөнья куйдылар. Бабам Мостафа да озын гомерле булмаган. Кайвакыт уйга калам: ни сәбәпле мина язмыш шулкадәр озын гомер бирде икән? (Һәм сәламәт акыл дип тә әйтим инде, чөнки зиһенемә үпкәм юк, шөкер).

Шушы яшемдә минем рухи халәтем ничек, нинди дәрәҗәдәрәк? Шөкер, зарланмыйм. Дөрес, ара-тирә кайбер нәрсәләрне оныткалыйм. Ләкин бу яшьтә андый гына зәгыйфьлек гафу ителергә тиеш. 96 ел эчендә ниләр генә кичерелмәгән, бу газиз баштан ниләр генә узмаган! Мин үз гомеремдә аз дигәндә ике мәртәбә үлемнән калдым. Беренчесе, 1920нче елның 9 ноябрендә Юшунь позицияләренә берсе артыннан берсе дүртме, бишме мәртәбә Врангельнең офицер полкына каршы атакага күтәрелгәндә; икенчесе, 1922нче елның җәендә кайтарма тиф (возвратный тиф) белән авырганда мине Кара диңгез буендагы Николаев шәһәреннән кайтарып җибәргәч, Мәскәү поездыннан алып мине Фрунзе исемендәге госпитальгә алып киттеләр. Грузовикның шәрә идәнендә без икәү бара идек. Минем белән янәшә яткан кеше барып җиткәнче җан бирде, мин аңымны җуйганмын. Янадан аңыма килгәндә мин йөз түбән җирдә ятадыр идем. Аңыма килгәндә караңгы иде инде, ә машинага салганда якты иде әле. Димәк, мин җирдә байтак ятканмын. Күземне ачсам кап-караңгы. Башта мин инде җир астында түгелме икән, үлеп мине күммәделәрме икән дип шикләндем. Әмма кулыма чыклы үлән дымы тигәч җир

өстендә булуыма, димәк, исән булуыма ышандым. Менә шуннан бирле тагын берничә мәртәбә бик каты авырсам да һаман да яшим әле, шөкер.

Күнелемдә бер нәрсә оешып килә, менә шуны язып бирмичә һич тә «китеп барырга» ярамый. Иншалла, теләгемә ирешермен.

**7 гыйнвар, 1997.**

Их, их, их! Кайчан безнең татар халкы үзенең зыялыларының кадерен белә башлар икән? Менә бу бөек зат[1] һәм аның кебек тагын Гаяз Исхакыйлар, Җамал Вәлидиләр татар халкына фән, әдәбият дөньясына, гомумән мәгърифәт дөньясына юл ачканнар бит! Моның өчен алар никадәр тырышканнар, күпме көч куйганнар. Нигә һич югында аларның кем булулары белән халыкны таныштырмыйбыз? Нигә Казан урамнарының 98%ның исеме башка халыкның исемен йөртә? Нигә Казанга килеп тә карамаган, Казанга ике тиенлек тә файдасы тимәгән һәртөрле Куйбышевлар, Бауманнар, тагын әллә кемнәр урам исеме йөртә, нигә без үзебезнең мәшһүр кешеләребезнең исемен мәңгеләштерүдән әле һаман да куркабыз? Ниһаять, кешеме, халыкмы без, әллә чүпрәкме? Ни сәбәпле бездә нәни генә булса да милли горурлык юк?! Ничек халыкның исемен пычратудан оялмыйча 1552 елда Иван Грозный безнең бабайларны җинә алмыйча җәфа чиккәч, ана 5 җирдән Казан диварларын шартлатып биргән химик Бутлерның оныгының оныгының исемен зурлап Казан урамнарының берсенә кушабыз? Болай итеп үз халкының дәрәҗәсен төшерүгә, милли хисен мыскыл итәргә башка бер халыкның вөҗданы ирек бирмәс иде. Уф аллаһ. Нигә шулкадәр түбәнгә тәгәрәде безнең халкыбыз?!

**14 гыйнвар, 1997.**

Их без мескеннәр! Тирәнтенрәк уйлап карасаң, без бит, хәзерге татарлар революциягә кадәр яшәгән татарлардан әле хәзер дә әлләни ерак китә алмадык. Без һаман да шул элекке мескен бүрек кигән юаш, кыюсыз татарлар... Мисаллармы? Менә алар.

Чит өлкәләрдән килгән милләттәшләребез үпкәләп кителәр:

—Без Казанны Татарстанның, ягъни татар халкының башкаласы итеп күрергә өметләнеп киләбез. Ләкин кая монда безнең халыкның зур кешеләре, татарның үз тарихы? Юк алар. Казанның иң мәшһүр, иң күз алдындагы мәйданы ниндидер Куйбышев исемен йөртә. Тукайның тууына 110 ел тулу уңае белән мин аңа Габдулла Тукай исемен бирергә тәкъдим керткән идем, аңа һаман колак салмыйлар. Казанның башка иң зур урамнары да Бауман, К.Маркс, Вишневский, Галактионов, Миславский, Островский һ.б. шундый исем йөртә. Ә халыкның иң талантлы шагыйрьләренең берсе булган Хәсән Туфан исемен 7-8 генә йорты булган берьяклы сукыр тыкрыкка бирделәр. Казанда рус исемен 98% урам йөртә.

Татар берсен-берсе ашар диләр. Казанда берәр зур талантлы татар чыга башласа, татарлар аны шунда ук, чирләшкә чебине тазалары чукыган кебек, төрле яктан «чукый» башлыйлар. Ул талант мескен, үз туганнарыннан качып Марига, Уфага барып сыена, аннан доктор булып кайткач кына аңа тешләре үтми. Як-ягыгызга күз салсагыз андый мисалларны күп күрерсез.

Моның иң фаҗигале ягы шунда—бу сәясәтнең кем тырышлыгы белән эшләнүен дә беләләр, шулай да ничә дистә еллар инде дәвам иттерәләр. Уф алла.

**26 гыйнвар, 1997.**

Моннан бер-ике ай элек миңа Союздан чылтыраталар:

—Гомәр абый, Татарстанга килгән Австрия журналисты татарның иң өлкән язучысы белән очрашыр идем, дип үтенә, без аңа Сезне тәкъдим иттек,— диделәр.

—Ярый, килсен,— дидем.

Ул чибәр генә бер туташмы, ханыммы булып чыкты. Үзе русча белми икән, тәрҗемәче бер ханым белән килгән.

[1] Буби Гобәйдулла Габделгаллэм улы(1866-1936), педагог. Көндәлеккә аңа багышланган календарь бите беркетелгән.

—Сезне нәрсә кызыксындыра?—дигән соаль бирдем.

—Гафу итегез. Сез Австрия хакында нәрсә беләсез?—диде.

—Ихтимал, география китабында укыганнан башка әлләни белмимдер,—дидем.—Хәер, мин малай чакта, 1915-1916 елларда булса кирәк, безгә күрше алпавыты Цызгановта эшләүче бер әсир австрияк кергән иде.

—Нинди максат белән?—дип сорады әлеге кунак.

—Алпавыт аларны эшләтә, әмма тамакларын җитәрлек дәрәҗәдә туйдырмый иде. Шунлыктан әсирләр авыл кешеләренә кереп тамакларын туйдыра торганнар иде.

—Минем ватандашларымны кайгыртуыгыз өчен бик рәхмәт сезгә,— диде кунак.

—Минем атам, анама була инде ул рәхмәт... Тагын бер австрияк истә калган, анысы да әсир иде. Зәңгәр шинель, башында бик сәер бүрек. Анысын да әни туйдырып чыгарды. Яһүд язучысы Шолом Алейхем (гарәпчә «әссәләмөгаләйкем» дигән гыйбәрәдән) Австриядә яшәп андагы яһүдиләр тормышыннан «Тевье-молочник» дигән әсәр язган иде. Миңа ул әсәр бик ошаган иде. Юморга бик бай иде ул! (Әгәр ниндидер фактларны, исемнәрне бутаган булсам, гафу итегез).

Китәр алдыннан әлеге ханым миңа үзе төсле аппак битле, кара каешлы җыйнак кына кул сәгате сузды. Көтмәгәндә шундый зур бүләк.

—Бик рәхмәт инде, зур бүләк, кадерләп кенә тотармын... Көтелмәгәндәрәк... дигәндәй.

—Яхшылык беркайчан да онытылмый. Бу барлык халыкларда шулай санала.

Минем алтын сәгатем дә бар. Әмма монысы анардан кадерлерәк.

**31 гыйнвар, 1997.**

Соңгы айларда яшәү рәвешемнән үзем һич тә канәгать түгел, чөнки бер яңа әсәр дә яза алганым юк. Мин үземне алай ук көчсез кешегә санамый идем. Көн саен торып өстәл янына килеп утырам, әмма хыялдан конкрет эшкә күчә алмыйм.

Билгеле, акланырга сәбәпләр дә бар. Берәүнең дә 97 дә роман язганы юк, имеш... Булмаса соң, син яз! Роман ук булмаса, яшьләрнең әдәби телне бозулары хакында мәкалә яз. Аны гына булдыра алыр идең бит!..

**21 апрель, 1997.**

Көндәлек матбугатны күзәтеп барганда һәр көн диярлек мин анда хаталарга очрыйм. Гарәп, фарсы, төрек сүзләрен кулланганда хатаны аеруча күп җибәрәләр. Ә безнең хәзерге әдәби телебездә гарәп, фарсы, төрекчәдән бик күп сүз кергән. Әгәр дә без аларны кулланмаган булсак, әдәби телебез бик ярлы калган булыр иде. Мәсәлән, нәфис, зарури, гаделлек, мөнәсәбәт, дәгъва, хакимият, мәмләкәт, сәрмая һ.б. һәммәсе дә безгә көнчыгыштан кереп үзләшкәннәр. Без аларны чит телдән керүләрен хәтта сизмибез дә. Әгәр гарәп белән фарсыдан кергән сүзләрне ул халыклар бездән кире үзләренә ала торган булсалар, безнең телебез бернигә яраксыз булып ярлыланып калыр иде.

**28 апрель, 1997.**

Газета читенә, ачуланып, шундый сүзләр язып куйганмын: Ильмәт, Ильфар, Рифат, Ильбарис һ.б.

Йа хода! Бу татар дигән халык ни сәбәпле үзенең кадерен белми, нигә балаларын шундый шыксыз, ямьсез исемнәр кушып үзен-үзе кимсетә икән? Борынгы бабаларыбыздан мирас булып калган чын татар яисә башка халыклардан кереп тә үзебезнеке булып әверелгән һәйбәт исемнәр беткәнмени? Киләчәк буын бу тупас хатаны кабатламасын иде. Изге теләктә булыйк.

**16 июль, 1997. Чәршәмбе.**

Күзем торган саен начарлана бара. Мин хәзер О.Бальзакның әлеге мәшһүр әсәренең[2] каһарманы хәлендә. Теләгәнемне үтәү гомеремне кыскарта (күзем авырта торып язып утыру аның күрү куәтен киметә). Язмыйча да түзә алмыйм. Мин бит

[2] Сүз О.Бальзакның «Шагреневая кожа» исемле әсәре турында бара.

7-8 яшемнән башлап язу-сызу эше белән шөгелләнәм. Аз гына мөмкинлек булу белән ничек язмыйча түзмәк кирәк? Аллага тапшырдык.

Хәзер әле «Моннар дәрьясында» дигән язмамны тәмамлап утырам.

Йа ходай, зиһенемне арттыр, күземә куәт бир! Күзем тиз армасын иде.

**19 июль, 1997.**

Ике күзем дә күргән чакта мин бик тә бәхетле кеше булганмын икән, тик мин сәламәтлегемнең кадерен генә белмәгәнмен. Менә хәзер бер генә күзгә калгач, ул чакларны сагынып искә алам.

И адәм балалары! Сәламәтлекнең кадерен белегез! Ул алтын-көмешләрдән, гәүһәр, якутлардан да кыйммәтлерәк тора. Сәламәтлек берни белән дә чагыштырып булмый торган зур бәхет ул, чиксез—чамасыз байлык ул!

**19 июнь, 1998.**

Бу дәфтәр минем бердәнбер сердәшем. Бөтен дөньядан яшергән серемне дә бу дәфтәргә ачыктан ачык сөйләп бирә алам.

Нигә мин бу дәфтәрне байтактан бирле кулыма да алмадым? Чөнки зарланасым килмәгән иде. Шундыйрак мәкаль дә бар бит. «Кеше кайгысы иртә керсә, кич чыга»,— диләр.

Кайгым шул, мин акрын гына, әмма катгый рәвештә сукырая барам. Башта көтмәгәндә, һич тә сиздермичә диярлек, уң күзем сукырайды, аның артыннан менә сул күзем дә бик начар күрә башлады. Дөрес, минем кызым, улым, оныкларым бар, алар миңа ярдәм итәрләр. Ләкин бит, аларның үз мәшәкатьләре дә житәрлек. Шуның өстенә, алар бит минем үз күзләремне кайтара алмыйлар, минем кебек күрә алмыйлар.

Менә шундый эшләр. Иң кулае—бу дөнья белән мәңгегә бәхилләшү. Ләкин кызганыч, анысы адәми затның үз ихтыярында түгел. Югыйсә, миңа бөтенләйгә «китеп барырга» күптән вакыт иде инде.

**Бүген июньнең 23е, 1998ел.**

Мин байтактан бирле яңа квартирда яшим. Үземә аерым бүлмә, миңа беркем дә уңайсызламый, үзем ничек телим, шулай яшим. Бу квартирны хөкүмәт миңа махсус рәвештә атап бирде.

Әмма үземнән үзем һич тә канәгать түгел мин. Чөнки әдәби эш белән шөгелләнүдән берничә ел элек үк туктавыма бик үкенәм. Дөрес, омтылмадым түгел, әдәби әсәр язарга омтылып караган идем. Ләкин инде туксаннан узгач булмый икән дип, бер-ике омтылыштан соң ук туктаган идем. Менә хәзер шуңа үкенәм. Актык көчемне куеп тотынган булсам, бәлки берәр нәрсә килеп чыккан булыр иде әле...

Соңгы атналарда нигәдер мин үлем турында бик еш уйлана башладым. Дөресен әйткәндә, минем күңелем шактый ук төшенке. Кулымнан килгәннең һәммәсен дә эшләдем, инде бу яшькә житкәч әлләни майтарып булмас, хәзер шул кайчан һәм ничек китеп баруыңны гына уйлаштырырга калды... ахрысы. Ә ул хакта уйлау ул күңелне күтәрми.

Тәрәзәм каршында гына бик тә учарлы зур агач үсеп утыра.

*Агач башы тәсбих әйтә*
*Акрын искән җил белән;*
*Кайгырма, дустым, кайгырма,*
*Син генә түгел, ил белән...*

Соңгы көннәрдә күзем бик тизлек белән начарлана башлады. Хәзер бөтенләй сукраю да бик ихтимал инде. Андый шартларда бу дөньядан китеп бару хәерлерәк. Менә кайчан адәми зат үзенә-үзе үлем тели. Моның өчен кешене гаепләү кирәкмидер. Чөнки кеше кулына калып кемгәдер жафа чиктерү мөрәүвәтле эш түгел. Мин хәзер менә шундый хәлдә.

**25 июнь, 1998, пәнжешәмбе.**

Күптән үк уйлап йөргән бер хикәя сюжеты һич тынычлык бирми иде. Ниһаять ул хикәя хәленә килеп житәр ахрысы. Ай-һай, ашыгасың. Башта хикәяңне яз әле! Бу яшьтә ул ансат эш түгел. Сукырая да башладың бит! Аллам сакласын.

Әйе, күземнең күрүе көннән-көн начарлана бара. Мин бит бу күзләремне 7 яшьтән үк рәхимсез рәвештә эшкә җигә башладым. Әти әни кисәтteләр, күзеңне бозасың килмәсә син аны көчләмә, яктыда гына укы диделәр. Мин исә аларны тыңламадым. Хәтеремдә, 1913 елда әти Казанга солы сатарга чыгып китәр алдыннан өйдәгеләргә:

—Әйтегез, Казаннан кайсыгызга нәстә алып кайтыйм?— диде.

Бүтәннәр кайсы яулык, кайсы кәләпүш алуын үтенделәр. Мин исә «Әбугалисина китабын алып кайт» дидем. Ул минем гозеремне үтәгән, китап кибетен эзләп табып миңа «Әбугалисина»ны алып кайткан иде. Печән базарында китап кибете юклыгын да беләидем, димәк ул китап кибетен читтән эзләп тапкан. Ул елны әтинең яше 60тан узган иде инде. Моның өчен мин атама юньләп рәхмәт әйтә белдемме икән, хәтерләмим. Әмма китапны укый башлагач мин аннан аерыла алмадым. Әни «Керосинны юкка әрәм итәсең!» дип утны сүндергәч мин китапны тәрәзәдән төшкән ай яктысында укуны дәвам иттем. Олыларның сүзен тыңламаган өчен менә хәзер җәза күрәм.

**18 апрель, 1999. Якшәмбе.**

Күзем кыенлык белән булса да азрак күрә әле, шөкер. Бөтенләй «сүнмәсен» өчен дару кулланам.

Рухи халәтем нинди? Мин бик зур бер хата эшләвемә үкенеп бетә алмыйм. Яшем 90лардан узганнан соң мин: «Бу яшьтә әдәбият белән шөгелләнеп булмас инде»— дип, әдәби әсәрләр язудан туктау зур хата булган. Миңа хәзер 98 яшь, шулай да башымда хикәя жанры тынычлык бирми. Яза алырмынмы, әллә булмасмы дип икеләнеп утырганчы язасым калган икән, менә хәзер ул тәмамланган булыр иде инде. Хәерле булсын, картлык хатасы инде бу.

**25 апрель, 1999. Якшәмбе.**

Бөек Ватан сугышы беткәнгә инде әллә ничә еллар. Әмма халык теленнән ул һаман да төшми, чөнки совет халкы ул җиңүләр өчен миллионнарны корбан итте.

Мондыйны бигрәк тә сугышта ире яки газиз улы корбан булган бичара тол хатын...

**Май, 1999.**

**(Кулъязма шушы юллар белән өзелә. Әдип Гомәр Бәширов 1999 елның 5 май таңында вафат булды).**

## Татар җанлы Вараксин

Үземнән гармун белән эш барып чыкмады. Малай чакта абыйдан, әтинен бертуган энесеннән калган «Вараксин» гармунын әллә ниләр кыландырып бетердем. Телләренә тамга сугып та, бармакларымны бәйләп тә бактым, өйрәтүчеләр дә ялладым—барып чыкмады, үсмәсә үсми икән инде кычыткан арасында кыяр. Хет «Алмагачлар»ын да тарта алмадым. Колакка аю баскан булып чыкты минем.

Әмма гармунга гашыйк үзем. Өемдә күрегә тартылмаган өр-яңа «сандугачым» бар. Аны Казан остасы Хәйдәр Искәндәрев ясап бирде. Ул гынамы?! Әле мин хәтта Казанның Суконный бистәсендәге «талчук» базарын үз кулында тоткан атаклы гармун барышнигы—Кылый Абдулла белән «бишне» биреп сөйләшкән кеше. Аның өздереп уйнавын, алу-сатуда арадашчы буларак, күрегә чыжлап торган гармуннарны да сайратып, кешеләргә кыйммәт бәядән төрттүен үз күзләрем белән күрдем. Оста гармунчылардан Арча ягы егете Вәгыйз, Дөбъяз тирәсендәге Әсән авылыннан Канәфиләр белән бер табында утырдык, парк-бакчаларны бергә урадык. «Уйнагыз, гармуннар!» бәйгесендә ел саен призлы урыннарны яулаган, инде мәрхүм Канәфинең Татарстан радиосы фондында шактый язмалары саклана, әледән-әле эфирдан яңгыратып торалар. Аларны югалтмаска иде. Аю гәүдәле Вәгыйз дустым гармунны Вараксинның үзеннән ясатып ала иде. Бусы, кем әйтмешли, язмага прелюдия генә...

Сүзем татар халкына җаны-тәне белән көн-төн хезмәт иткән Михаил Вараксин турында. Көн-төн диюем шуна: Михаил Дмитриевич шушы һөнәр белән тамак туйдырды. Карт остага—карчыгы Мария Гавриловна, кияүгә чыкмый сазаган кызлары Маша булышты. Алар Куйбышев (хәзерге Пушкин) урамында, шагыйрь Һ. Такташ йортына каршы якта яшәде. Ни аяныч: шәһәр хакимияте олуг шәхесләр торган шушы ике йортны тарих өчен саклап калмады, теләмәде. Ояты үзләренә булсын!..

Мин Вараксин хакында, анын гармуннары белән дөньяны таң калдырган тиңдәшсез башкаручы Фәйзулла Туишев турында бер әсәремдә шактый күләмле итеп язып та чыккан идем. Өстәп шуны гына әйтә алам: М. Вараксин бик тә татар җанлы инсан иде. Яратты ул безнең халыкны. Аның музыкаль зәвыгын, мәдәниятен үстерүгә көчен кызганмады.

Вараксиннарның гармун ясау эшенә Михаилның әтисе Дмитрий Иванович нигез сала. Ә ул гармун ясау серләренә Вятка (хәзерге Киров) каласында Г. Федосимов дигән берәүнең фабрикасында өйрәнә. Пароходта Чистайга чаклы төшә. Андагы фабрикада беркадәр эшләгәч, Казанга килеп төпләнә. Татар халкынын тальян уйнарга һәвәслеген күреп, милли моңга туры китереп, Дмитрий Иванович үз гармуннарын ясый башлый. «Вараксин» гармуннары остага дан китерә. Ул бу һөнәрен улы Михаилга мирас итеп калдыра.

Без белгән Михаил Вараксин менә шундый кеше иде. Гаҗәеп йомшак күңелле, һәрвакыт ачык йөзле, юмарт зат иде гармун остасы. Юмарт, дим, чөнки ул шулкадәр көч түгеп эшләгән продукциясен авыл агайларына арзан бәядән генә сатып бирә иде. Аның гармун телләрен нечкә җиз чыбыктан чүкеп ясаганын карап торган чакларым булды. Каторга хезмәте, мин синаәйтим. Михаил Дмитриевич гомере буе «Вараксин» гармуннары эшли торган үз фабрикасын булдыру хыялы белән яшәде. Кая инде ул заманда?! Өйдә эшләргә рөхсәт итүләренә дә рәхмәт! ...Юк ул хәзер чынлап торган, тавыш үзгәрткеч биш планкалы «Вараксин» гармуннары. Мин шуларны сагынам!

## Әбугалисина

—Ә сез Әбугалисинаны күреп беләсезме, аның белән кара-каршы торып сөйләшкәнегез булдымы?

Әлбәттә, юк. Сез бит моннан 1000 ел элек дөньяны шаулаткан тыйб фәне галиме Әбү Гали-Синаны күз алдыгызга китердегез. Ә бу безнең заман Әбугалисинасы.

Инсанның фамилиясе Әбүзәров иде. Чын аты онытылган минә. Гел дә Әбугалисина дип йөрткәнгәдер, мөгаен. Икенче бөтендөнья сугышына чаклы ук ул Казан университетында тарих, әдәбият фәннәрен укыткан. Дәрәҗәле белгечләрдән саналган. Сугышта яраланып, контузия алган, бераз гына «түбәсе авышкан». Ә белеме башында калган. Аны шул белдеклелеге өчен һәркем яратты, хөрмәт итте. Әбугалисина дигән гыйльми кушамат тагылды үзенә.

Әбүзәровның сәламәт чагында язган романнары (кайбер әсәрләрен укып белүчеләр бар иде әле) югалган. Инде хәзер язганнарына игътибар итмәделәр. Ул аларны Язучылар берлегендә, редакция, нәшрият бүлмәләрендә калдырып китте. Болары да юкка чыга торды. Сәбәбе нәрсәдә? Кемгә бәйләнергә? Әлбәттә инде, Язучылар берлеге рәисенә. Ул чактагы рәис Ибраһим Гази белән коридорда чәкәшүләрен һич онытасым юк.

—Син тагын килдеңме?!

—Карак сез, минем әсәрләремне урлап бастырасыз.

—Хәзер үк күземнән югал, эзең булмасын.

Кем гаепле? Бер Аллаһы Тәгалә Үзе генә белә. Ярлыкаучы да ул.

Шулай да бар иде бит Әбугалисина-Әбүзәров, заманабыз Хуҗа Насретдине...

## Маэстро

Борын-борыннан татар мәмләкәтен зыялылар тоткан. Татарның үзен дә милләт халимнәре саклаган. Моны узгандагы яшәешебез, тарихыбыз күрсәтеп тора.

Дәүләт һәм милләт чәчәк атсын өчен бүген дә шушы затлар кирәк. Музыкаль сәнгатебезне үстерүгә күп көч куйган, күренекле татар дирижеры Фуат Мансуров турында әйтүем. Даны илләргә таралган шәхес. Дәрәҗәле исемнәрен санап бетерерлек түгел. Ф. Мансуров—Татарстанның һәм Казакъстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе. Шулай ук Россиянең халык артисты, атказанган сәнгать эшлеклесе һәм башкалар.

Маэстро белән, болай концертларына килгәндә, төрле очрашуларда, кул бирешеп, исәнләшеп йөрибез. Ә минә үзем эшли торган «Татарстан» журналының 80 һәм 85 еллык бәйрәмнәрендә тәмам якынайдык үзе белән. Концерт залында узган тантанадан соң «Татарстан» ресторанында оештырылган бәйрәм табынына төштек. Гардеробта чишенәбез. Шул мәлдә, Ф. Мансуров, җиңемнән эләктереп, бер читкә әйдәкләде. Аптырап киттем.

— Карале, дус, гафу ит мине, бер нәрсә сорамакчы идем синнән. Безнең татарда «гарб» сүзе бармы?—ди бу. Филолог диярсең, валлаһи!

Сүзнең яңгырашын абайлап бетермәгәнлектән, икеле-микеле генә җавапладым:

—Юк бугай...

—Ә минә төрекләрдә, казакъларда, үзбәкләрдә бар,—ди маэстро.

—Урысчасын әйтегез,—дим.

—Традиция.

—Соң, шулай диләр аны! Бездә гореф-гадәт дигән бик матур ике сүз белән белдерелә ул традиция дигәннәре.

Көлешә-көлешә «филолог» белән бәйрәм табынына уздык.

Маэстро булып калу гына җитмәгәнме адәм баласына?!

**Госман ГОМӘР**

# К

**КАВАМЕТДИН БОЛГАРИ** (чын исеме Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла Сабави—Наласави) (19 йөзнен 2 нче яртысы, Казан губ., Мамадыш өязе, Байлар Сабасы а.—1833, Каһирә), язучы, дин эшлеклесе. Нократ губ. Малмыж өязе Мәчкәрә а., Бохарада (18 йөз ахыры) мәдрәсәләрендә укый. Кайтып Казан өязе Наласа а. имам-хатиб һәм мөдәррис була. 1826 да Россиядән китә, Төркиядә була, Мисырда яши, Мәккәгә хаж кыла.

Бохарада бергә укыган Г.Курсавиның рационалистик карашлары тарафдары. Татар дин әһелләре Фәтхулла Урави, Фәез Кышкари, Байморат Мәнгериләр б-н ул заманда кискен төс алган дини мәсьәләләр буенча бәхәскә керә, мәс., Урта Иделдә кичке (ястү) намазны уку кирәклеге турында. Кульязма хәлендә сакланган гарәп телендә язылган «Мәгъдәнел—мәкасыйд» («Максатлар чыганагы») исемле фәлсәфи хезмәт, Наласа авылы Фәхретдин Баязит ишан турындагы сатирик шигырьләр (ш.и. Шәмсетдин Кышкари б-н бергә язылганнары) авторы. Р.Фәхретдин К.Б. хезмәтләрен әл—Газали һәм Г.Курсави әсәрләре рәтенә куя.

Әд.: Мәржани Ш. Мөстәфадел—әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Фәхретдин Р. Асар. Оренбург, 1904. 1 җилд., 6 җөзья.

*М.В.Гайнетдинев.*

**КАВИ** Хәмит (1906, Казан губ., Чабаксар өязе, Әлмән а.—15.8.1944), язучы. Көнчыгыш пед. ин-тын тәмамлый (1931). 1926 дан урта мәктәптә биология һәм география фәннәрен укыта. Ил буйлап сәяхәт кыла, күргәннәрен «Кавказ таулары аркылы җәяү» (1930), «Боз дингезенә таба» (1932), «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) исемле китапларында чагылдыра. Бөек Ватан сугышында катнаша. Дружнополь (Украинаның Волынск өлк.) авылы тирәсендә барган сугышларның берсендә һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**КАДЫЙРИ** (Кодирий) Абдулла (10.4.1894, Ташкент—4.10.1938, шунда ук), үзбәк язучысы, журналист. 1912 дә рус—җирле халыклар мәктәбен тәмамлагач, приказчик булып эшли. 1919 дан үзбәк газета һәм ж—ларында әдәби хезмәткәр, корректор булып эшли. 1923-24 тә Журналистика ин-тында укый (Мәскәү). Беренче шигырьләре һәм публицистик мәкаләләре 1913-15 тә «Садои Туркистон» («Төркистан авазы»), «Сәмәрканд» үзбәк газеталары һәм «Айна» («Көзге»), «Муштум» («Йодрык») ж-лларында басыла. Татар периодик матбугаты һәм әдәбияты б-н 1912 дә таныша. Үзбәкнен иске тормышын чагылдырган «Азгынчы» («Жувонбоз», 1915) исемле беренче хикәясен К. татар мәгърифәтчеләренә, аеруча З.Бигиевкә, ияреп яза. «Муштум» ж-лы битләрендә урын алган очерк, хикәя, фельетоннарда Г.Тукай, Ф.Әмирханнар сатирик традицияләре үзен нык сиздерә. «Беркем дә белмәсен» (1921) комедиясе—М.Фәйзинен «Яшьләр алдатмыйлар» пьесасынын өлешчә үзгәртелгән варианты. К.нен төп әсәрләреннән саналган «Үткән көннәр» («Утган кунлар», Ташкент, 1925; татар теленә тәрҗемә 1959) һәм «Михраб чаяны» («Мехробдан чаён», Ташкент, 1929; рус теленә тәрҗемә «Скорпион из алтаря», М., 1964) романнарында Г.Ибраһимовнын романтик прозасы йогынтысы сизелә. «Калфак Мәгсүмнен хатирә дәфтәреннән» («Калвак Махзумнинг хотира дафтаридан») исемле сатирик хикәясе һәм «Үткән көннәр» романыннан өзекләр Казанда 1930 да «Үзбәк антологиясе»ндә З.Бәшири тарафыннан бастырыла. К. үзбәк теленә Г.Тукайнын «Шүрәле» поэмасын тәрҗемә итә. 1936 да К., үзбәк делегациясе әгъзасы буларак, Казанда, Казан арты авылларында була, К.Нәҗми, Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, Х.Туфаннар б-н очраша. Нахакка репрессияләнә; 1956 да аклана.

Әсәр.: Кичик асарлар. Тошкент, 1969.

Әд.: Кошчанов М. Жизнь. Характеры. Мастерство. Таш., 1963; Турдыев Ш. Тукай и узбекская литература // Габдулла Тукай. К., 1979; Алиев А. Абдулла Кодирий. Тошкент, 1967; Кушжонов М. Кодирий—эрксизлик курбони. Тошкент, 1992.

*Р.К.Ганиева.*

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

**КАДЫЙРОВ** Октябрь Халик улы (25.10.1935, Чистай р-ны Дүрт Өйле а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1996). 1958 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1963-70 тә Казан ун-тында; 1970 тән Казан мәдәнният һәм сәнгать ун-тында. Хезмәтләре 19 йөз ахыры—20 йөз башы татар-рус әдәби-сәнгати элемтәләре һәм йогынтыларына; Л.Н.Толстой иҗатының татар әдәбиятында реализм ысулы үсүендә уйнаган ролен билгеләвенә, татар әдәбиятының милли үзенчәлекләре мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Л.Н.Толстой сквозь призму татарской мысли. Наб. Челны, 1995; Л.Н.Толстой в татарских переводах советской эпохи. К., 2005.

**КАЗАКОВ** Борис Васильевич (5.5.1946, Пермь өлк., Лысьва ш.—2.4.2006, Яр Чаллы ш., күмелде Брянск ш.), язучы. Ленинград югары хәрби-диңгез инж. уч-щесын (1966), Лениград ун-тын (1970) тәмамлый. 1963-75 тә СССРның Хәрби-диңгез флотында хезмәт итә. 1976 дан Яр Чаллы шәһәрендә яши. 1976-79 да КамАЗның ДОСААФ к-ты рәисе, 1979-91 дә СССР Автомобиль сәнәгате министрлыгына караган Квалификация үстерү ин-тында укыта, 1991 дән «КамАЗ» акц. җәмгыятьтә. Гражданская оборона буенча фәнни хезмәтләр, уйлап чыгарулар, рационализаторлык тәкъдимнәр авторы. 1996 дан РФ Язучылар берлегенең Яр Чаллы язучылары оешмасы рәисе, 1999 дан РФ Язучылар берлеге идарәсенең сәркәтибе. Беренче «Диңгез хикәяләре» («Морские рассказы») җыентыгы 1967 дә басылып чыга. К.ның жанр һәм язу манерасы төрлелеге б-н үзенчәлекле әсәрләре армия һәм флот, Бөек Ватан сугышында катнашканнарга, интернационалист солдатларга багышланган. Әсәрләренең сюжеты катлаулыгы һәм киеренкелеге б—н аерылып тора. «Ракета күкрәве» («Ракетный гром», М, 1974), «Онытылган герой турында повесть» («Повесть о забытом герое», Минск, 1980), «Чаң нигә чыңнамый» («О чем молчат колокола», М., 1990), «Коммунарлар кыры» («Поле коммунаров», Рига, 1993), «Бу безнең биографиябез» («Это наша с тобой биография», М., 1995), «Орыш-сугышларда» («В боях и сражениях», М., 2000) һ.б. повестьлар авторы. Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗәле «Сугышчан батырлык өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: На пороге XXI века: Российский автобиобиблиогр. ежегодник. М., 1999. Т.2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**КАЗАНЫЙ** Габрашит ибне Гаид (18 йөз), дин эшлеклесе, язучы. Казанның Яңа бистәсендә Алтынчы мәчет каршысында мәдрәсә тота, үзе дин дәресләре бирә. Эпистоляр жанрында язылган «Васятнамә» (1769) авторы. Әсәрдән өзекләр Ш.Мәрҗани тарафыннан «Мөстәфадел—әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (1-2 кит., 1885—1990) хезмәтенә кертелгән.

**КАЛИМУЛЛИН** Илгиз Нурулла улы (20.3.1929, Апас районы Болын-Балыкчы ав. —1.7.1989, Казан), шагыйрь, тәрҗемәче. Рус телендә иҗат итә. Бала чактан ук инвалид. Беренче шигырьләре 1950 еллар башында «Комсомолец Татарии» газетасында, Мәскәүдә чыга торган «Смена», «Юность» журналларында басыла башлый. Шигырьләре һәм поэмалары тупланган «В строю» («Сафта», 1956), «Вместе с вами, друзья» («Дуслар белән бергә», 1959), «Солнце, влейся в песню!» («Кояш, безнең җырга кушыл!», 1966), «На магистрали счастья» («Бәхет магистралендә», 1969), «Священный зов» («Изге чакыру», 1975), «Дорога к людям» («Кешеләргә табан...», М., 1978), «Плывут рассветы сквозь меня...» («Таңнар миннән китә...», 1979), «Верю в день восходящий» («Туачак көнгә ышанам», 1983) исемле җыентыклар авторы. К.ның әсәрләре тормыш турында фәлсәфи уйланулар, югары гражданлык сыйфатлары белән аерылып тора. Шигырьләрендә нык ихтыярлы, батыр ир-егетләргә, бөек төзелешләрдә илһамланып эшләүче яшьләргә дан җырлый, аларның ашкынулы мәхәббәтләрен, хезмәт героикасын романтик күтәренкелек белән гәүдәләндерергә омтыла. 1977 елда К.ның шигырьләре татар теленә тәрҗемә ителеп «Җиргә мәдхия» исеме белән басылып чыга. К. шулай ук Х.Туфан, М.Хөсәен һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә.

Әсәр.:Стихи и поэмы: Избр. К., 1989.

Әд.: Паушкин Г. Сафка кайту // Совет мәктәбе. 1956. №7; Кутуй Р. Перед бедою не поник // Волга. 1968. №9.

**КАЛЬМЕТОВ** Сәет Гани улы (20.4.1918, хәзерге Башкортстан Респ-сы Янаул р-ны Янаул пос.—4.5.1992, Әлмәт шәһ.), драматург. Хезмәт эшчәнлеген рәссам-декоратор (бизәүче) буларак Ташкент (1937-38) һәм Чиләбе (1939-41) татар театрларында башлый, бер үк вакытта Ташкент художество студиясендә дә белем ала. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945-59 елларда башта Ютазы, соңрак Буа колхоз-совхоз театрларында режиссёр булып эшли. «Безнең кияү» дигән беренче пьесасы 1947 елда сәхнәгә куела. Татар академия т-ры тарафыннан сәхнәләштерелгән «Тын алан шаулый» (1951) пьесасы К.ны халыкка танытты. 1955 елдан К. Әлмәттә яшәп иҗат итә һәм

драматургның алдагы иҗат эшчәнлеге Әлмәт татар драма т-ры белән бәйле. Аның сәхнәсендә К.ның «Нуриянең дуслары» (1953 тә сәхнәләштерелә), «Ышанычлы юлдаш» (1957 дә сәхнәләштерелә), «Уйланырсың, кодагый» (1962 дә сәхнәләштерелә) комедияләре, «Соңгы очрашу» (1956 да сәхнәләштерелә), «Зәкия» (1959 да сәхнәләштерелә), «Тайгак тау» (1968 дә сәхнәләштерелә) драмалары зур уңыш белән бара. Пьесаларында замандашларының әхлак, тәрбия мәсьәләләрен күбрәк яктыртырга тырыша. Әсәрләре «Шулай да була» (1972), «Тын алан шаулый» (1978) җыентыкларына тупланган.

Әд.: Ахунов Г. Усал телле драматург // «Казан утлары». 1968. №5.

**КАМАЛ** (Камалетдинов) Әгъзам Камалетдин улы (21.1. 1918, Казан губ. Тәтеш өязе Үтәмеш ав.—16.5.1943), шагыйрь. Казан финанс-икътисад техникумын тәмамлый (1937). 1938-39 елларда «Чаян» журналында һәм «Кызыл Татарстан» газетасында әдәби хезмәткәр. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Җилфердә, байрак!» (1938, Ә.Галиев белән берлектә), «Һәйкәл янында җыр» (1939) шигырь җыентыклары авторы. Сугыш елларында фронт һәм республика вакытлы матбугатында патриотик шигырьләре белән еш чыгыш ясый. Аның әдәби мирасыннан кайбер үрнәкләр «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) күмәк җыентыкларына кертелгән. Сталинград янындагы сугышларда һәлак була.

Әд.: Шакир С. Әгъзам Камал // Совет әдәбияты. 1956. №8; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**КАМАЛ** (Камалетдинов) Әнәс Галиәсгар улы (20.2.1908, Казан—18.3.1978, шунда ук), драматург. Г.Камалның улы. Татар сәнгать техникумын тәмамлый (1931). 1931-35 елларда Минзәлә колхоз-совхоз т-рында директор һәм сәнгать җитәкчесе, 1935-55 тә Татарстан кит. нәшриятында редактор булып эшли. 1921-26 елларда беренче драма әсәрләрен: «Хуҗа Насретдин әфәнде», «Җизнәкәй», «Чегән егете белән качкан мулла кызы Хәмидә» комедияләрен иҗат итә. Уңыш казанган әсәрләреннән «Биш менле Гайнетдин» (1928) комедиясе. Аның «Давыл» (1930), «Ике көч» (1931), «Туй» (1939), «Март бураннары» (1955) пьесалары буенча куелган спектакльләр авыл клублары сәхнәләрендә уңыш белән бара. Әтисе турында истәлек язмалары һәм биографик очерклары тупланган «Халык драматургы Г.Камал» (1950), «Гүзәл тормыш сәхифәләре» (1958) җыентыклары берничә тапкыр басылып чыга. К. Татар дәүләт курчак т-ры өчен Г.Тукайның мәшһүр поэмасына таянып «Кисебаш» (1951) комедиясен дә яза. Ул шулай ук бер пәрдәлек пьесалар, скетчлар, инсценировкалар, интермедияләр авторы; А.Гайдарның «Школа» («Мәктәп», 1956) повестен татар теленә тәрҗемә итүче.

Әсәр.: Комедияләр һәм скетчлар. К., 1966; Беренче тургайлар. К., 1978; Март бураннары. К., 1988.

Әд.: Зәйни Ш. Драматург үткән юл // «Казан утлары». 1968. №3.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Альфред
Халиков

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

**ЗАГОСКИННАР.** XVI йөздән дворяннар. Рәсми шәҗәрәләре нигезендә, Загоскиннар нәселе Алтын Урдада яшәгән Захар Загоскодан башлана (БК II, 243). Загоскиннарның РБСдагы (VII, 152) биографиясендә «Загоскиннар чукынганда Александр Анбулатович исеме алган, 1472 елда Алтын Урдадан Иван IIIкә китүче Шевкан Загордан башлана һәм аңа Пенза губернасындагы Рамзай авылы бирелә», диелгән. С. Веселовский (1969, 40), бернинди дәлил китермәсә дә, әйтелгәннәрне легенда гына дип саный. Чыгышлары төрки-мөселман кушаматлары белән бәйле исем-фамилияләр (Захар—Загор—Загир «җиңүче», Шевкан—Шевкат «көчле»—Гафуров 1987, 146, 209-210) Загоскиннарның төркиләрдән чыкканлыклары турындагы фикерне көчәйтә генә. Соңыннан нәселләреннән чыгучылар арасында галимнәр, язучылар, сәяхәтчеләр мәгълүм.

**ЗЛОБИННАР.** Рәсми шәҗәрәләрендә, Злобиннар Олы Урдадан Бөек кенәз Василий Дмитриевичка күченгән Минчак Касаев (Касаевич) улы Злобадан башлана, диелә (ОГДР V, 33; БК II, № 458). Әгәр бу шулай икән, Злобиннар Давыдовлар, Оринкиннар, Уваровлар (к.) белән тугандаш булып чыгалар. С. Б. Веселовский (1969, 458) үзенең элегрәк язылган бер хезмәтендә Иван Иванович Злобаның инде XV йөзнең икенче яртысында ук гаскәр башы булуын күрсәтеп тә, Злобиннарның төрки-урда чыгышына шик белдерә. Сонрак язылган икенче бер хезмәтендә ул (1974, 123) Злобиннарның төрки исемнәрне (Карандей, Курбат) атап, аларның төрки булуын шик астына куймый. Н. А. Баскаков ( 1979, 96-97) Злобиннарны төркиләрдән чыккан дип исәпләмәсә дә, Злобиннар нәселендәге төрки-гарәп исемнәренең бөтенесенең дә диярлек этимологиясен бирә: Минчак исеменең төркиләрдәге мунчак «кыйммәтле таш, муенса» сүзеннән ясалганлыгын әйтә. Бу исемнең килеп чыгышын икенче төрле дә аңлатырга мөмкин: *минчак*—кыпчак-башкорт берләшмәләренең мин кабиләсе кешесе. Н. А. Баскаков ( 1979, 97) «Касай»ны (Косай) ирләр исеме булып, «коус ай»дан (ягъни «бөгелгән ярымай») ясалуын әйтә. Карандеевлар фамилиясен тикшергәндә дә ул ( 1979, 149, 251) Карандей исеменең төрки-татар *карынды* «зур корсаклы», ә Курбат исеменең төрки-гарәп *карабат* «кыска буйлы» сүзләреннән ясалуын күрсәтә. Злобиннар фамилиясен йөрткән язучылар, галимнәр, тәзүчеләр һ.б. барлыгы билгеле ( РБС VII, 411-417).

*Дәвамы. Башы 5, 6, 8, 9 саннарда.*

**ИЗМАЙЛОВЛАР.** XV-XVI йөзләрдә үк танылган боярлар һәм дворяннар булалар. Бөек кенәз Ольг Игоревич Рязанскийга (ОГДР II, 34) 1427-56 елларда хезмәт иткән кенәз Солохмирның (Солых Әмир) туганы Шайнын (Н. А. Баскаков фикеренчә, шейхнын) оныгы Измаилдан (Исмәгыйльдән). Шабан Исмагил Рязань кенәзләре даирәсендә лачынчылар башлыгы булган *(Зимин 1980, 267).*

«Инка» кушаматлы Иван Иванович Измайлов 1494 елда Рязань кенәзләренен гаскәр башы булып торган. Анын ул вакытта яшәгән туганнарыннан Кудаш, Харамза исемнәре дә телгә алына *(Веселовский 1974, 127).* XVII йөзнен урталарында һәм икенче яртысында Измайловлар (Андрей Петрович, Артемий Васильевич) инде Мәскәү окольничиилары һәм воеводалары буларак искә алыналар. Аларнын Мәскәү янында Измайлове авылы була, соңрак аны патша гаиләсе шәһәр читендә тору өчен сатып ала (РБС VIII, 65-66). Элеккеге Измайловлар белән бәйле Измаил, Солых Әмир, Шабан, Кудаш, Хәрәмзә исемнәре—төрки чыгышлылар *(Баскаков 1979, 93; Гафуров 1987, 87, 153).* Сонрак Измайловлар гаиләсеннән дәүләт эшлеклеләре, галимнәр, язучылар, хәрбиләр чыккан (РБС VIII, 65-68; ЭС 1987, 479).

**КАРАМЗИННАР.** Рәсми шәҗәрәләрендә Кара Морза исемле татар кенәзе белән бәйле булуы әйтелә (ОГДР V, 62; РБС VIII, 500). XVI йөздә анын балалары инде Карамзин фамилиясен йөрткәннәр, мәсәлән, Кострома янында 1534 елда Василий Карпович Карамзиннын, 1600 елда Нижегород өязендә Федор Карамзиннын яшәгәнлеге билгеле *(Веселовский 1974, 134).* 1606 елда биләмәләр бирелгән, ягъни дворянлыкка күчерелгәннәр. *Карамза—Караморза* сүзенен этимологиясе шактый ачык: *Кара* һәм *морза—мирза* «кенәз» *(Баскаков 1979, 178; Гафуров 1987, 166).* Нәселләреннән мәшһүр язучы, шагыйрь һәм тарихчы Карамзин Н. М. чыккан.

**КЕЛДЫШЛАР.** Фамилия Польша һәм Литвадагы поляклашкан һәм руслашкан татарларга хас. Нигезендә төрки *келдыш—килдыш* сүзе ята, ягъни «динсезнен өенә килгән кеше» *(Баскаков 1979, 110—111).* Ләкин XVI йөз уртасында Русь ягына чыгып, йомышлы булып киткән казанлылар арасында Келдышлар булгандыр. Шуларнын берсе 1563 елда Кырымга илче булып киткән һәм 1564 елда Канев районында үтерелгән йомышлы татарлар башлыгы Келдыш Дәүләгаров дигән кеше булган (ПСРЛ 29, 335, 337).

**КОЗЛОВЛАР.** Уллары XVI йөздә Карачура, Шадра, Салтык *(Веселовский 1974, 147)* дигән төрки исемнәр йөрткән Игнатий Григорьевич Козел-Бикләмишевтан. 1573 елдан дворяннар (ОГДР III, 73). Козловлар «козел» дигән саф рус сүзеннән булырга мөмкин, әмма Н. А. Баскаков (1979, 131) төрки-ногай козыли кой «өч яшьлек сарык» ясалу мөмкинлеген дә инкарь итми.

**КОЛОНТАЙ.** 1343 елда Алтын Урдадан рус хезмәтенә күченгән Калантайдан *(Веселовский 1974, 150).*

**КОРСАКОВЛАР.** Нәсел башлары XIV—XV йөзләрдә Урдадан Литвага күченгән Корсактан (В., Д. 1986, 136). XVI йөздә Литванын Мәскәүгә илчеләре Барколат Корсак һәм Семен Ждан улы Корсаков билгеле (ПСРЛ 29, 350). XVII йөздә Литвадан русларга хезмәткә Венцеслав Жегмунтович Корсак та күчә (ОГДР I, 83). Ана патша Федор Алексеевич указы белән 1677 елдан Римский-Корсаков исеме белән йөри башларга кушыла *(Баскаков 1979, 72).* Фамилия төрки корсак «дала аты» сүзеннән *(Баскаков 1979, 73).* Сонрак—танылган композитор, галимнәр, хәрбиләр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*



*Нәшрият йортында (хәзерге «Идел-Пресс») бер очрашу. Сулдан уңга: Р. Зәкиев («Чаян» журналының баш мөхәррире), Ш. Вәлиев («Коммунист Татарстана» журналының баш мөхәррире), Ю. Воронин, А. Бушнев, Г. Карунин, (КПССның өлкә комитеты вәкилләре), Ш. Хамматов («Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире), В. Гаврилов (газета-журналлар нәшрияты директоры), А. Рәхимова (нәшриятның баш бухгалтер урынбасары, хәзер «Казан утлары» журналының баш бухгалтеры), Ю. Щелыванов («Советская Татария» газетасының баш мөхәррире), М. Зәйнетдинов (ул вакытта КПСС өлкә комитеты инструкторы, хәзер «Чаян» журналының баш мөхәррир урынбасары). 1982 ел.*



*Шәриф Камалның 100 еллыгына багышланган тантаналы утырышның президиумыннан бер күренеш. Алгы планда—язучы Гариф Ахунов, трибунада Татарстанның Культура министры—Илтөзәр Алиев. 1984 ел. Казан.*



*Ибраһим Гази «Яшь Ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясендә кунакта. Сулдан уңга— Илгизәр Сәмигуллина, Ренат Харисов, Хәмзә Зарипов, Ибраһим Гази, Саимә Ибраһимова, Тавил Хаҗиәхмәтов, Венера Ихсанова. 1967 ел.*



*Рәссам Эрот Зарипов (1938—2009).*



*Ул елларның яшь язучылары. Сулдан уңга—Мансур Вәлиев, Хәйдәр Гайнетдинов, Рашат Низамиев, Нияз Акмалов. 1978 ел.*

## Рөстәм Галиуллин



Рөстәм Госман улы Галиуллин 1987 елның 26 ноябрендә Арча районы Наласа авылында туган.

2004 елда Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетына укырга керә. Шул елларда «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсе утырышларына йөри башлагач, иҗат дөньясына тартыла.

2005 елдан аның юморескалары, хикәяләре, балалар өчен шаян хикәяләре «Сабантуй» газетасында, «Чаян» журналында, соңрак «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан» журналларында, «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», Мәскәүдә чыга торган «Татар дөньясы» газеталарында басылып килә. Университетта укуы белән бергә ул «Чаян» журналында, «Шәһри Казан» газетасында эшли.

Рөстәм Галиуллин—ТР Министрлар Кабинеты каршындагы мәдәният, спорт һәм Татарстан халыклары телләрен үстерү идарәсе, «Идел яшьләр үзәге» һәм Татарстан Язучылар берлеге оештырган бәйге—«Иделем акчарлагы»нда проза әсәрләре буенча 2006 елда I урынга, 2007 елда Гран-прига лаек булды.

2007 елда әдәбият һәм фән өлкәсендәге уңышлары өчен Арча якташлык җәмгыяте премиясе лауреаты.

2008 елда Татарстан китап нәшриятында беренче китабы—«Гипнозчы малай» дөнья күрә.

2009 ел Рөстәм Галиуллин өчен аеруча уңышлы булды: Татарстан Журналистлар берлегенә әгъза итеп алынды, Журналистлар берлеге белән «Республиканың «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм мәгълүмат чаралары агентлыгы оештырган XII «Бәллүр каләм—2009» («Хрустальное перо—2009») журналистлар бәйгесенең «Ел ачышы» («Дебют») номинациясендә җиңү яулады.

2009 елда публицистика жанрында ирешкән уңышлары өчен Арча район хакимиятенең Гариф Ахунов исемендәге I дәрәҗә әдәбият премиясенә лаек булды.

2009 елда университетны кызыл диплом белән тәмамлады. Хәзерге вакытта «Шәһри Казан» газетасында бүлек мөхәррире булып эшләү белән берләттән, КДУ аспирантурасында укуын дәвам итә.

2009 елның 22 сентябрендә Ркаил Зәйдулла, Госман Садә, Ләбиб Лерон тәкъдимнамәләре нигезендә, Кабул итү комиссиясе һәм Идарә Рөстәм Галиуллинны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алу турында карар чыгарды.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 2010 ЕЛДА ТӘКЪДИМ ИТӘ

## Проза әсәрләре:

**Мәдинә Маликова.** Нурзифа. Роман.
**Рәмзия Габделхакова.** Тау артында кояш бар. Роман.
**Рауль Мирхәйдәров.** Җәяүле татар. Роман.
**Марат Кәбиров.** Бердәнбер һәм кабатланмас. Роман.
**Рашат Низами.** Сәйдәшнең соңгы елы. Кыйсса.

## Шигърият:

**Әхсән Баян, Шәүкәт Галиев, Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Мөхәммәт Мирза, Лена Шагыйрьҗан, Флера Гыйззәтуллина, Салисә Гәрәева, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Луиза Янсуар, Ленар Шәех** һ.б. яна шигырьләре, поэмалары.

## Фән һәм сәнгать:

**Җәүдәт Фәйзи.** Халык җырлары тарихыннан.
**Индус Таһиров.** Татар ничек барлыкка килгән.
**Рөстәм Насыйров.** Урта гасырларда болгар флоты.
**Гамир Гарифуллин.** Нугайлар тарихыннан кайбер сәхифәләр.
**Тәлгать Насыйров.** 30нчы еллардагы татар матбугаты.
**Әхтәм Зарипов.** Татар киносының бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулар.

## Әдәби тәнкыйть

**Адлер Тимергалин.** «Ниһаять, Тукай сүзлеге!»
**Рафаэль Мостафин.** «Хәсән Туфанның яшерен сере».
**Миләүшә Тажетдинова.** «Коръәннең Такташка тәэсире».

## Хәтер:

**Миркасыйм Госманов.** Күренекле шәхесләр турында истәлекләр.
Мирсәй Әмир көндәлекләре.

Киләсе елда шулай ук «Тормыш язган хикәяләр», «Авылларыбыз тарихы», «Татар энциклопедиясе битләреннән» сәхифәләре, әдәбият елъязмасы булган «Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан», «Казан утлары» архивыннан» рубрикалары дәвам итәчәк. «Ак җилкән» сәхифәсендә яшүсмерләрне мажаралы повесть-хикәяләр, шигырьләр, кызыклы язмалар көтә.

Кадерле «Казан утлары»! 5нче санда сиңа кунакка Башкортстанның «Агидел» журналы килгән иде. Шунда бирелгән әсәрләрдән мине аеруча җәлеп иткәне Әмир Әминевның «Танкист» повесты булды. Яшьлектә, 1955-58 елларда, Белорусиядә, Слуцк шәһәрендә өч ел танкист булып хезмәт иттем мин. Т-54 танкы командиры идем. Повестьны мин бер утыруда укып чыктым. Әсәрдә Ватан сугышы кырларында немецларга каршы батырларча көрәшкән һәм карт көннәрендә бомж хәленә төшкән танкист Тимергали тормышындагы авырлыклар, аның якын туганнары белән булган капма-каршылыклар тасвирлана.

Укып чыктым да, озак кына уйланып йөрдем. Тормышыбызда еш очрый торган трагик хәлләрнең берсе повестьта бик нечкәләп, җиренә җиткереп язылган. Повестьның төп герое танкист Тимергалинең уй-кичерешләре, үзенең тормыш плацдармын сакларга тырышуы, көрәше турындагы юллар мине бик нык дулкынландырды. Карт кеше, яшьлегендә нинди генә батырлыклар кылмасын, бүгенге тормышта беркемгә дә кирәкми икән бит. Тимергали бу хәлендә артык кеше, җәмгыятькә дә, якын туганнарына да, хәтта үзе тәрбияләп үстергән кызына да балласт икән. Олы оныгы исә бабасына шундый каты итеп суга ки, бабайның бите манма кан була. Аның акчасын алалар, үзе күтәргән йортны саталар. Бу хәлендә Тимергалигә бомжлар сафында гына урын кала.

Мине әсәрнең соңгы юллары тетрәндерде. Танкист Тимергали танк эчендә, ике кулы белән танк йөртү рычагларын кысып тоткан килеш үлә. Искитәрлек, Ватан сугышында фашистлар белән капма-каршы танк атакаларында булып, исән калган, хөкүмәтебезнең орден, медальләре белән бүләкләнгән яу батыры тимердән ясалган соңгы торагына кереп ятарга, башнясына 555 тамгасы куелган танк эчендә үләргә мәҗбүр була. Хурлык бит бу җәмгыятебез өчен! Әлбәттә, бу алым—язучының үзе сайлап алган әдәби сурәтләү технологиясе. Тимергалинең шундый үлеме безнең хөкүмәт башлыкларына, түрәләргә житди кисәтү ул. Тик аларның кайсысы гына «Танкист» повестын укыр икән?

Бик тә гыйбрәтле бу әсәрне укып чыккач (ике кат укыдым), бер тәкъдим дә туды хөкүмәт башлыкларына. Халыкка социаль ярдәм итү органнары Тимергали хәленә калган сугыш һәм хезмәт ветераннарына (75-80 яшьтән башлап) ярдәмнәрен сыйфат ягыннан үзгәртсеннәр иде. Минемчә, социаль ярдәм органнарындагы хезмәткәрләр ким дигәндә айга бер тапкыр ветераннарның өйләренә барып, аларның ни хәлдә икәнен, нинди ярдәмгә мохтаҗ булуларын конкрет ачыкласыннар иде.

Бу әсәрнең авторы Әмир Әминевка да бер тәкъдимем бар. Повестындагы теманы терелтеп, җанландырып пьеса итеп язсын иде ул. Һәм әсәрне дә, пьесаны да русчага тәрҗемә иттерсен иде. Шул чакта бөтен җәмгыятебез тояр иде кебек бу фаҗигале проблеманы.

**М. ҖӘЛӘЛИЕВ,**
*пенсионер, эшем буенча—*
*нефть чыгару белгече*

*Котлыйбыз!*



**Рәмзия Гайсә кызы Габделхакова** 1959 елдаТатарстанның Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылында дөньяга килә. Шул ук районның Түбән Кәминкә авылында сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, 1975—1979 елларда Казан кооператив техникумында укый. Техник-технолог һөнәре алып, Азнакай районына эшкә билгеләнә.

1980 елда ул гаиләсе белән Лениногорск шәһәренә күчеп килә. Биредә район кулланучылар җәмгыятенең җәмәгать туклану предприятиеләрендә эшли, аннары җирле радиотапшырулар редакциясендә хәбәрче һәм хисапчы вазифаларын башкара. Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген читтән торып тәмамлагач, Лениногорскида чыга торган «Заман сулышы» газетасында эшли башлый.

Әдәби иҗат белән Рәмзия мәктәптә укыган елларыннан ук шөгыльләнә. Аның тәүге шигырьләре балалар матбугатында һәм Чирмешән район газетасында дөнья күрә. Лениногорскида исә ул биредәге иҗат әһелләрен берләштергән «Чишмә» әдәби берләшмәсенә йөреп каләмен чарлый. Аның беренче шигъри җыентыгы—«Кар өстендә миләшләр» дип атала һәм ул 1996 елда дөнья күрә. Әлеге китабы өчен ул төбәктәге Шамил Бикчурин исемендәге әдәби премиягә лаек була. «Көзге яшен» исемле шигырьләр китабы исә «Рухият» нәшриятында 2003 елда басылып чыкты.

Рәмзия Габделхакова проза жанрында да актив һәм уңышлы эшли. Аның шигъри аһәң белән сугарылган заманча хикәя вә бәяннары соңгы елларда татар укучысын үзенә җәлеп итте. 2006 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Көмеш төн» исемле хикәяләр җыентыгын да укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек яратып кабул итте.

Рәмзия Габделхакова—«Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты.

**«Казан утлары» коллективы журналның актив авторын күркәм гомер бәйрәме белән котлый һәм аңа туган халкын сөендерердәй яңадан-яңа әсәрләр иҗат итүен тели.**

## ТАРИХИ ВИЗИТ

14 октябрьдә АКШның Дәүләт секретаре Хиллари Клинтон Казанга килде. Мондый югары дәрәҗәдәге Америка вәкиленең Татарстанга беренче тапкыр килүе. Шуна күрә бу визитны тарихи вакыйга дип санап була. Республикабыз Президенты М. Шәймиев АКШ Дәүләт секретарена Казанга килгән өчен рәхмәт белдерде. «Без моны хөрмәт билгесе буларак кабул итәбез һәм горурланабыз»,—диде.

Беренче очрашу Казан Кремлендә үтте. Хиллари Клинтон үзенең сәяхәтен Кол Шәриф мәчете белән танышудан башлады. АКШ кунагы гыйбадәтханәдә узган никах тантанасының шаһиты да булды. Шәймиев белән Клинтон, яшь парларга чәчәк бүләк итеп, аларны гаилә корулары белән котлады. Благовещенск соборында Хиллари ханым Изге Мәрьям Ана иконасы алдында шәм кабызды.

Кремльдәге сәяхәттән соң, Х. Клинтон Татарстан Президенты М. Шәймиев белән әңгәмә корды. «Казан һәм Татарстанга килүемә бик шатмын»,—дип белдерде Хиллари Клинтон. Аның сүзләренә караганда, республика төрле милләт кешеләре һәм төрле дин тотучыларның киләчәккә бергәләп омтылу үрнәге булып тора. Татарстан Президенты исә төрле кешеләрнең фикерләренә колак сала һәм бу—идарә итүнең иң яхшы алымы.

Дәүләт секретаре Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчете һәм Благовещенск соборының янәшә урнашуын да билгеләп үтте. Бу биредә тарихны хөрмәт итүләрен, шул ук вакытта кешеләрнең карашы киләчәккә төбәлүен күрсәтә. Хиллари Клинтон фикеренчә, бүген ул танышкан «Камминз» двигательләре белән эшләүче «КамАЗ» автомобильләре Россия һәм Америка компанияләренең уңышлы хезмәттәшлек итү үрнәге булып тора. АКШ кунагы Европа һәм ислам дөньясы арасында диалогны җайга салу буенча Татарстан җитәкчелеге тарафыннан алып барылган эшне аерым билгеләп үтте. Республика үз мисалында христиан һәм ислам дөньясының бергә яши алуын күрсәтә. Төрле милләт кешеләре һәм төрле дин тотучылар бергәләп алга хәрәкәт итә ала.

Дәүләт секретаре дөнья буйлап сәфәр кылганда, АКШ Президентының йөкләмәләрен үтәгәндә, шул исәптән Әрмәнстан һәм Төркия арасындагы элемтәләрне җайга салганда Татарстан Президентына киңәш сорап мөрәҗәгать итәчәге хакында белдерде.

Татарстанга сәфәре барышында АКШ дәүләт секретаре Казан дәүләт университетында да булды. Студентлар белән очрашканнан соң, Клинтон уку йортының музеенда оештырылган «түгәрәк өстәл» эшендә катнашты. Чара дини, мәдәни һәм этник күптөрлелек мәсьәләләренә багышланган иде. Хиллари Клинтонга «Электрон хөкүмәт» проекты, «Алгарыш» кадрларны әзерләү һәм янадан әзерләү программасы, православие һәм ислам мәдәниятенең үзара бәйләнешенең уңышлы тәҗрибәсе турында сөйләделәр.

АКШ дәүләт секретаре КДУның Россиядән читтә тә яхшы абруе барлыгы һәм бу уку йортын күрүенә шат булуын әйтте. Хиллари Клинтон сүзләренчә, анарда толерантлык, икътисадый алгарыш һәм Татарстан үсешенең тотрыклылык дәрәҗәсе яхшы тәэсир калдырган. АКШ дәүләт секретаре бу унай тәҗрибәне дөньяның башка илләрендә дә кулланырга мөмкин дип ышана.

Моннан тыш, Хиллари Клинтон Татарстан һәм АКШның инглиз теле укытучылары белән алмашу программасын актив үстерергә тәкъдим итте. Аерым алганда, Татарстанның инглиз теле укытучылары өчен Америкага сәфәр оештыру турында сүз булды. «Барак Обама ислам дөньясына юл ачты, төрле конфессия кешеләренә берберсе белән эшләү мөмкинлеге бирде. Моның белән бәйле рәвештә ислам саммиты үткәрү мөмкинлеген карыйбыз»,—диде ул «түгәрәк өстәл»дә катнашучыларга. АКШ дәүләт секретаре фикеренчә, республикадан өйрәнер әйберләр күп—Татарстан динара мөнәсәбәтләр өлкәсендә үрнәк булып тора. «Без кешеләрне бергә яшәргә өйрәтәчәк программа төзергә телибез»,—диде ул.

Сәясәтчеләр АКШ Дәүләт секретаре Х. Клинтонның кыска вакытлы бу визитын Татарстан тарихында зур әһәмияткә ия дип саныйлар.

## «АЛТЫН МӨНБӘР»НЕҢ ҖЫЕНЫ

30нчы сентябрьдән 4нче октябрьгә кадәр Казанда «Мәдәниятара бәйләнешләргә багланышлар культурасы аша» дигән

девиз астында V «Алтын мөнбәр» Казан халыкара мөселман киносы фестивале узды. Фестиваль Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев һәм РФ Мәдәният министрлыгы химаясендә үткәрелеп килеңә.

Бишенче кинофестивальнең сайлап алу комиссиясен танылган кино сәнгате белгече һәм кинотәнкыйтьче Хане Иохим Шлегель (Германия) җитәкләде.

Быел фестивальнең сайлап алу комиссиясенә 67 илдән 400 фильм (168—нәфис, 138—документаль һәм 94 кыска метражлы фильм) кабул ителде. Гыйрак, Мисыр, Палестина, Согуд Гарәбстаны, Сүрия, Бөекбритания, Канада, АКШ, Франция, Һиндстан, Нидерланд, Россия Федерациясе, БДО илләре кебек фестивальдә даими катнашучы кинематографлар белән берлектә, Польша, Чехия, Чили, Конго, Судан кинематографлары да тәүге тапкыр үз эшләрен тәкъдим итте.

Конкурс программасына 36 кинофильм кертелде: 13 тулы метражлы, 14 документаль, 9 кыска метражлы картина. Конкурстан тыш программага кертелгән фильмнар «Татарстан киносы көне», «Кавказ киносы көне», «Төркия киносы көне» һәм «Халыкара панорама» кебек махсус кинопрограммалар кысасында күрсәтелде.

Татарстан киносы көнендә 10 кинокартина тәкъдим ителде: тулы метражлы «Бөркетләр» (режиссер-куючысы Рамил Төхфәтуллин) һәм кыска метражлы «Тукай» (режиссеры Марат Ганиев) фильмнары. Конкурстан тыш программада 7 фильм күрсәтелде: Салават Юзеевның «Возрождая звук» документаль, кыска метражлы «Фәридә» фильмнары, Рифат Йосыповның «Жизнь с верой» документаль фильмы, Сергей Цихановичның «Без татарча сөйләшәбез», Ринат Юзаевның «Османие. На пути к вере», Әнвәр Габдрахмановның «Фәнис Яруллин очышлары», Борис Максимовның «Мәмәширдән бер гаилә» документаль фильмнары. Татарстан киносы көне кысаларында режиссер Юрий Феттигның «Бибинур» тулы метражлы нәфис фильмын тәкъдим итү булды.

Фестивальне Россия мөфтиләр советы рәисе, мөфти шәех Равил Гайнетдин ачып җибәрде, сәлам сүзләреннән соң үзенә зур җаваплылык алып фестивальне үткәрергә шартлар тудырган Татарстан Президенты М. Шәймиевкә ихлас рәхмәтләрен җиткерде. ТР Премьер-министры, фестивальнең оештыру комитеты Зилә Вәлиева да аны: «Казанны һәрвакыт төньяк Мәккә дип йөртәләр иде. Инде менә Минтимер Шәрипович Шәймиевнең фатихасы белән бүген аны Көнчыгыш Канны дип тә атыйлар»,—диде.

Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин сүз алып, «Фестиваль киноларын гаилә, балалар белән бергәләп карарга оят түгел. Анда бозыклык юк. Фестивальнең киләчәге бар, дип уйлыйм»,—диде.

Фестивальнең ачылу һәм ябылу церемонияләре «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә узды.

Фестиваль нәтиҗәләре мондый: фестивальнең төп бүләгенә «Одна война» фильмы (режиссер В. Глаголева, Россия) лаек булды. Төрле номинацияләр буенча Иран, Согуд Гарәбстаны, Польша, Босния-Герцеговина, Венгрия, илләреннән килгән кинематографлар җиңү яулады. Татарстан вәкилләре дә бу фестивальдә җиңүчеләр рәтендә булды. «Иң яхшы ир-ат роле» дип режиссер Рамил Төхфәтуллинның «Бөркетләр» фильмында күрсәтелгән ахирәт дуслар—Камал театры артистлары Әзһәр Шакиров, Ринат Тажетдинов һәм Равил Шәрәфиев танылды.

### ТАРИХНЫ БЕЛЕРГӘ КИРӘК

Республикада ТАССР төзелүгә 90 ел тулуны бәйрәм итәргә әзерләнәләр.

Күптән түгел Дәүләт Советында юбилей чаралары планы турында фикер алыштылар. Бу уңайдан махсус оештыру комитеты булдырылды, җитәкчесе итеп парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин билгеләнде.

Бәйрәм чаралары киләсе елның маенда узачак. Бәйрәм уңаеннан 2010 елның 27 маенда Дәүләт Советының тантаналы утырышы үткәреләчәк. Тантаналы җыелышны нәкъ менә шул көнне уздыруның сәбәбе гади: ТАССР төзелү турындагы декретка 27 майда кул куелган. Юбилей уңаеннан фәнни-гамәли конференция үткәрү дә күздә тотыла. Бәйрәм тантанасына чит илләрдән дә кунаклар чакырачаклар. Болардан тыш, «ТАССР оешуга 90 ел» дип аталучы истәлек билгесе барлыкка киләчәк. Музей һәм китапханәләрдә тематик күргәзмәләр эшләячәк.

### ДИН ЭШЕНӘ ГЫЙЛЕМ БЕЛӘН КЕР

28-29 сентябрьдә Казанда «Россиядә һәм чит илләрдә мөселман мәгарифе» дигән халыкара гыйльми-гамәли конференция булып узды. Аны Ислам конференциясе оешмасы (ИКО) каршындагы Мәгариф, фән һәм мәдәният эшләре буенча ислам оешмасы (МФМЭИО), Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм Россия Ислам университеты оештырды.

Аның ачылышында ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Җыен алдыннан спикер Ислам конференциясе оешмасы карамагындагы Мәгариф, фән һәм мәдәният эшләре буенча ислам оешмасы генераль директоры Абделгазиз Осман әл-Твәйҗри белән очрашып сөйләште. Очрашу барышында ул әлеге конференциянең Казанда узуы Татарстан өчен генә түгел, бөтен Россия күләмендәге зур вакыйга булып тора, дип билгеләп үтте.

Конференциянең төп максаты: заманча әзерлекле дин белгечләре әзерләү. Бу халыкара форумда Мисыр, Согуд Гарәбстаны, Сүрия, Йәмән; Европа илләреннән—Бөекбритания, Голландия, Албания, Босния... җәмгысы 22 дәүләттән килгән галимнәр, дин, дәүләт эшлеклеләре килгән иде. Җыенда, шулай ук Россия Федерациясенең НКО каршындагы даими вәкиле Камил Исхаков, Россия Ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ӨЧЕН АЧЫК

Мәскәүдә «Россия һәм ислам дөньясы: тотрыклылык өчен хезмәттәшлек итү» халыкара конференциясе узды. Анда ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева да чыгыш ясады. Ул Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең форум кунакларын һәм катнашучыларын сәламләгән хатын укыды. «Россия өммәте үзен ислам дөньясының бер өлеше итеп тоя, ул төрле дин вәкилләре белән әңгәмә алып бару һәм хезмәттәшлек итү өчен ачык»,—диелә хатта.

## КАЗАНДА—ВГИК ФИЛИАЛЫ

Казанда Сергей Герасимов исемендәге Бөтенроссия кинематография университетының беренче филиалы ачылачак. Бу хактагы килешүгә «Алтын мөнбәр» мөселман киносы халыкара фестивале үткән көннәрдә кул куелды. ВГИК ректоры Владимир Малышев сүзләренә караганда, филиалны ачу идеясен Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев тәкъдим иткән. Монда Идел буе һәм илнең башка төбәкләре өчен актер, режиссер, оператор һәм башка кино белгечләре әзерләнәчәк. «Кабул итү тәртипләре Мәскәүдәге кебек катгый булачак,—дип ассызыклады профессор Малышев.—Актерлык факультетына, мәсәлән, 15 урынга 300 абитуриент дәгъва кыла».

Аннан тыш республикада яңа киностудия төзү дә планлаштырыла.

## АРХИВЧЫЛАР КИҢӘШТЕ

«Казан» милли мәдәният үзәгендә Идел буе федераль округындагы архив оешмаларының фәнни-методик советы утырышы булып үтте. Анда Федераль архив агентлыгы һәм «Электрон архив» корпорациясе вәкилләре, Башкортстан, Мари Иле, Мордовия, Удмуртия, Чуашстан, Пермь крае, Киров, Түбән Новгород, Оренбур, Пенза, Самара, Сарытау һәм Ульян өлкәләре архивчылары килгән иде. Фәнни-методик совет утырышы эшендә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

Утырышта архив эшчәнлегенең төрле мәсьәләләре тикшерелде. Архивчыларны заманча автоматлаштырылган мәгълүмати-эзләү системаларын барлыкка китерү, электрон документларның сакланышы мәсьәләләре борчый. Утырышта шулай ук документлардан файдалану өлкәсендә архив оешмаларының дини оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе турында да бәян ителде.

## ФИЛАРМОНИЯ ИҖАТ СЕЗОНЫН АЧТЫ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе үзенең чираттагы 73нче иҗат сезонын ачты.

Киләсе елда мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакировка 75 яшь тула. Шуңа күрә филармония җитәкчелеге бу иҗат елын Илһам Шакировка багышларга ният кылган. Димәк, ел буена И. Шакиров катнашында чаралар күп булачак. Ә 2, 3 октябрьдә филармониянең концерт залында ул Әлфия Афзалова белән бергәләп чыгыш ясады. Концертта җыр-моң шигъри сүз белән бергә үрелеп барды. Шагыйрьләр Гәрәй Рәхим, Разил Вәлиев, Лена Шагыйрьҗан, Мөхәммәт Мирза, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон татар җырына һәм аны саклаган, үстергән, бөтен дөньяга танытkан бу ике шәхескә—И. Шакиров һәм Ә. Афзаловага багышланган шигырьләрен укыдылар. Концертны язучы Рабит Батулла үзенең улы Бәйбулат белән бергәләп алып барды.

## «ИЛҺАМЛЫ КАЛӘМ» КОНКУРСЫ

2008 елның 25 декабрендә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты тарафыннан, Татарстан Республикасының Язучылар берлеге белән берлектә, «Илһамлы каләм» әдәби әсәрләр конкурсы игълан ителгән иде.

Конкурс ике турда—2008 елның 25 декабреннән 2009 елның 15 февраленә кадәр һәм 2009 елның 15 февраленнән 1 апреленә кадәр узды.

Быел «Илһамлы каләм» тагын да киңрәк мәйданга чыкты. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты белән берлектә, конкурска Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең милли-мәдәни автономияләре, якын һәм ерак чит илләрдәге татар милли-мәдәни үзәкләре һәм иҗтимагый оешмаларының барлык гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларының иҗат җимешләрен кабул итә.

Конкурс быел да ике турда уза. I тур—2009 елның 10 октябреннән 2010 елның 15 февраленә кадәр, II тур—2010 елның 15 февраленнән 1 апреленә кадәр үтә. Нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү—2010 елның 24 апрелендә була.

Конкурста катнашырга теләгән укучылар җюри хөкеменә ирекле темага иҗат ителгән ике әсәр җибәрә. Әсәрләрне элек-

трон почтага (Iiyconcurs@yandex.rn) юлларга, хат белән җибәрергә, яки университетка китерергә мөмкин. Безнең адрес: 420021, Казан шәһәре, Татарстан урамы, 2нче йорт, 212нче бүлмә.

Россия Федерациясенең милли-мәдәни автономияләре, якын һәм ерак чит илләрдәге татар милли-мәдәни үзәкләре һәм иҗтимагый оешмаларның гомуми белем бирү мәктәбе укучылары бәйгедә читтән торып та катнаша ала.

### БЕЛОРУССИЯДӘ ОЧРАШУЛАР

Беларусь Республикасының Сморгонь шәһәрендә «Халыкларның аралашу чарасы буларак нәфис әдәбият» дигән III халыкара форум үткәрелде. Анда Беларусь, Казакъстан, Литва, Польша, Россия, Сербия, Таҗикстан, Черногориядән язучылар һәм әдәбият галимнәре, шулай ук «Наш современник» (Мәскәү), «Иностранная литература» (Мәскәү), «Простор» (Алматы), «Люблин» (Польша), «Литературная газета» (Мәскәү) басмалары хезмәткәрләре, Союз дәүләте даими комиссиясенең җаваплы хезмәткәрләре катнашты. Җыенда Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис белән Роберт Миннуллин да катнашты.

Форумда хәзерге заман дөнья әдәбиятенең көнүзәк проблемалары: XXI гасыр әдәбиятының дөнья мәдәниятендәге урыны; Беларусь һәм Россиянең заманча әдәбиятендә рухи эзләнүләрнең уртаклыгы; әдәбиятнең чит ил укучысына юлы; замана герое һәм яшь буынның рухи-әхлакый ориентирларын эзләү; көндәлек әдәби матбугат һ.б. тикшерелде. Ренат Харис «Глобальләшү чорында милли әдәбиятлар» дигән темага чыгыш ясады. Ул шулай ук Минскидагы каләмдәшләренә үзенең «Көмеш нур» («Сярэбраны прамень») китабын белорусча нәшер итүләре өчен рәхмәтен ирештерде.

Халыкара форумда катнашучылар Белорусь язуы көннәре кысаларында милли әдәбияткә нигез салучыларның берсе Францишек Богушевичка Сморгонь шәһәрендә һәйкәл ачу тантанасында катнаштылар.

### ШИГЫРЬ ФЕСТИВАЛЕ

Дөньяның борынгы шәһәрләреннән берсе булган төрек Тарсусында шигырь фестивале уздырылды. Ул һәр елның көзендә бөтен төркиләр арасында танылган халык шагыйре Каражауглан истәлегенә багышлап оештырыла. Быелгы бәйрәмдә төрки дәүләтләрдән килгән шагыйрьләр белән берлектә, Алмания, Болгария, Бельгия, Македония, Румыния, Косово, һәм Гыйракта яшәп, төрек телендә иҗат итүче каләм ияләре дә катнашты. Төркиянең төрле өлкәләреннән генә дә 70ләп шагыйрь һәм ашуг тамашачыларны үз иҗатлары белән таныштырды.

Бәйрәмдә татар шигырьләре дә яңгырады. Казан кунаклары Әнәс Исхаков һәм Фирдүс Фәтхелисламов анда яна әсәрләрен укыдылар.

### ЙӨЗ ЕЛ БУЕ ИСЕБЕЗДӘ

Г. Тукайның әдәби музеенда һәртөрле кичәләр даими үткәрелеп тора. Күптән түгел бередә «Исемдә калганнар» дип аталган әдәби-музыкаль кичә узды. Ул Тукайның шул исемдәге повесте иҗат ителүенең 100 еллыгына туры китерелгән иде. «Исемдә калганнар» әсәре китап булып 1909 елда башкалабызның «Үрнәк» типографиясендә нәшер ителә. Бәяннең ахырында «дәвамы бар» дип язылган була. Тукай бу әсәрен ике өлештән торыр дип фаразлаган һәм икенче кисәктә Казандагы һәм Җаектагы тормышын бәян итәргә уйлаган. Тик әсәрнең икенче өлеше язылмыйча кала... Кичәгә килүчеләр Тинчурин театры актерлары әзерләгән «Сөй гомерне» дип аталган спектаклен карады. Тамаша «Исемдә калганнар» әсәренә нигезләнгән иде. Кичәдә галимнәр Нурмөхәммәт Хисамов, Зөфәр Рәмиев һәм башка каләм әһелләре катнашты.

### ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

23 сентябрьдә Татарстан Милли музеенда шагыйрь Газинур Моратның 50 яшьлек юбилее уңаеннан «Хаталанам—димәк, дөрес яшим» дигән кичә булып узды. Ин элек юбилярны музейның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова тәбрикләде. Дәүләт Советы депутаты, шагыйрь Разил Вәлиев аның хакында: «Чын шагыйрь ул узган, бүгенге һәм киләчәк заманнарны үзенә берләштерә алган шагыйрь»,—диде. Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов билдерүенчә, Газинур Моратның иҗат кичәләре әле башланып кына килә. Юбилейның төп кичәсе «Казан» милли мәдәният үзәгендә үтәчәк. Галимнәр Хатыйп Миңнегулов, Нурмөхәммәт Хисамов һ. б. каләм ияләре Г. Морат иҗаты турында үз фикерләре белән уртаклашты.

13 октябрьдә шагыйрьнең иҗат бәйрәме аның туган төбәге—Кукмара районында да булып узды. Газинурның якташлары белән очрашуга Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, язучылар Марсель Галиев, Фоат Галимуллин, Ләбиб Лерон, Шаһинур Мостафин, Рифә Рахман кайткан иде. Башта алар Кукмараның 2 нче урта мәктәбендә укучылар, татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашты, район үзәк китапханәсендә булып, аларның эше белән танышты. Ә кичен шагыйрьнең туган авылы—Зур Сәрдек мәдәният йортында язучылар һәм район үзешчәннәре катнашында зур әдәби-музыкаль кичә булды. Очрашулар һәркайда шыгрым тулы залларда үтте.

Язучылар Кукмара муниципаль районы башлыгы Рауил Рәхмәтуллин белән очрашты, район, республика икътисады һәм әдәбият-сәнгать хәлләре турында дустанә әңгәмә булды. Гомумән, шагыйрьнең туган ягында очрашулар чын әдәбият бәйрәме булып узды.

### КҮРГӘЗМӘЛӘР

9 октябрьдә «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә Татарстанның һәм Россиянең халык рәссамы, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай бүләге иясе Искәндәр Рәфыйковның күргәзмәсе ачылды. Ул остаңың 80 яшьлек юбилеена тәгаенләп оештырылган иде. Экспозициядә авторның төрле музейларда сакланучы эшләре, күренекле шәхесләрнең портретлары, «Сөембикә», «Болгар ханбикәсе» кебек тарихи әсәрләре һ. б. эшләре белән танышып була. Рәссамның 100гә якын әсәре галереянең 2 залын биләп тора.

Тагын бер яна күргәзмә Горькийның әдәби-мемориаль музеенда ачылды. «Три девицы под окном» дип аталган күргәзмәдә өч рәссам кыз—Лада Аюдаг (Казан), Наталья Сюзева (Пенза), Наталья Шепелова (Самара) иҗат эшләре урын алган. Рәссамнар январь аенда Алабугада үткән халыкара арт-проектта очрашып танышкан һәм бер-берләренең иҗатында уртак чаткылар табып, бергәләшеп күргәзмә оештыру фикеренә килгән булганнар.

### ТИБЕТ МОНАХЛАРЫ КАЗАНДА

Казанда Халыкара дуслык йортында IV Халыкара «Россия-Һиндстан-Тибет» фестивале булды. Бу чараның оештыручысы һәм генераль спонсоры—Казанда ачылган «Наран» Тибет медицинасы клиникасы. Казан фестиваленә Дрепунг Гоман университетыннан (Һиндстан) лама Отог Ринпоче җитәкчелегендә Тибет монахлары делегациясе дә килде. Алар Изге Ком мандалы төзү ритуалын башкардылар. Ком мандалы—егерме төстәге вакланган мәрмәрдән ясалган нәфис рәсем. Ламалар аны ясау өчен Тибеттан 16 кг ком алып килгәннәр. Халыкара дуслык йортында 4 кв. м. зурлыктагы үзенә күрә бер сәнгать әсәре туды. Мандал торгызу—ритуалның беренче өлеше генә. Икенчесе—аны җимерү. Бу ритуалның мәгънәсе шунда—бар нәрсә дә үзгәрүчән, бер нәрсә дә мәңгелек түгел, бар нәрсә дә вакытлыча гына...

Һинд мәдәниятен биюләрдән башка күз алдына да китерү кыен. Һинд биюләрен яратучыларга Санкт-Петербургның «Апсара» һинд классик бию мәктәп-студиясе үз осталыгын күрсәтте. Фестиваль эстафетасын Санкт-Петербург дәвам итә. Бәйрәм Мәскәүдә төгәлләнәчәк. Фестиваль үткәргәннән кергән керемнәрнең бер өлеше Россиянең һәм Һиндстанның балалар йортларына күчереләчәк.

### ЯНА ДИРЕКТОР

Казан музыка училищесы директоры Резеда Газиз кызы Сабитовскаяның эшеннән үз теләге белән китүе сәбәпле, аның урынына яңа директор билгеләнде. Ул—элек ТРның мәдәният министры урынбасары булып эшләгән Айрат Әгъзам улы Җаббаров.

### ЮГАЛТУЛАР

2009 елның 22 сентябрендә әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, СССР Язучылар берлеге әгъзасы **Мусин Флүн Мөслах улы** вафат булды.

***

2009 елның 30 сентябрендә Чиләбе өлкәсенең Снежинск шәһәрендә 77 яшендә шагыйрь, СССР Язучылар берлеге әгъзасы **Мостафин Камил Әхмәди улы** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә: "Исле гөл".* **Илдар Зарипов** *эше.*

*Дүртенче биттә: шагыйрә* **Наилә Ахунова**.

# Яңа китаплар




**Бикә Рәхимова.** Бакый сагыш: публицистик мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр. 2009.—255 б. Тиражы—2000 данә.

Китапка шагыйрәнең публицистик мәкаләләре, эссе-уйланулары, юлъязмалары, язучылар һәм сәнгать әһелләре (Б. Урманче, Г. Афзал, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Т. Әйди, З. Мансуров һ. б.) турында фикер-бәяләмәләре, рецензияләре тупланган. Татар халкының тарихи, милли, дини, икътисади, сәяси һәм мәгариф мәсьәләләрен күтәреп чыккан бу язмалар укытучыларга, студентларга, зыялы укучыларга файдалы булачак.




**Зөлфәт Хәйруллин.** Дусларым, дус-ишләрем. Шаржлар.—Казан. 2009.—124 б. Тиражы—1000 данә.

Зөлфәт Хәйруллин күпкырлы сәләткә ия, ул—журналист, оста баянчы, менә дигән рәссам да. Аның татар дөньясында танылган шәхесләргә ясаган шаржлары күпләргә яхшы таныш. Алар ул үзе эшләгән «Ватаным Татарстан» газетасында һәм башка басмаларда еш күренә. Бу китапка рәссамның ике йөздән артык рәсеме кергән, һәр портрет-шаржга аңлатма рәвештә эпиграммалар бирелгән. Альбом-китапка кереш сүзне Фәнзаман Баттал язган.



Наилә Ахунова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)